ISSN 0206—418

# КАЗАН УТЛАРЫ

2.1990



## ЖУРНАЛ АЛДЫРУЧЫЛАР ИГЪТИБАРЫНА!

Журналның брак саны килгән очракта аны газета-журналлар нәшриятының техник контроль бүлегенә җибәрүегезне үтенәбез. Адресы: 420066, Казань, Декабристов, 2, Типография ГЖИ, ОТК.

Редакция журнал җибәрү белән шөгыльләнми.

Әгәр журналның теге яки бу саны килми калса, «Союзпечать»нең җирле бүлекләренә мөрәҗәгать итәргә кирәк. Бу мәсьәлә редакция вәкаләтенә керми.

Кульъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ЖУРНАЛЫ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

1990

2

(808)

КПССның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНЫҢ ГАЗЕТА ҺӘМ ЖУРНАЛЛАР НӘШРИЯТЫ

КАЗАН

## *Бу санда*

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Г. АФЗАЛ. Ике шагыйрь. *Шигырьләр* . . . 3
М. ӘГЪЛӘМОВ. Ничәнче кат. *Шигырьләр* . . 8
А. РАСИХ. Ишан оныгы. *Роман-истәлек* . . . 15
А. ХӘЛИМ. Яңа шигырьләр . . . . . . . 84
С. МУЛЛАГАЛИЕВ. Зурлыктамыни авырлык. *Шигырьләр* . . . . . . . . . . . 88

ХИКӘЯЛӘР ЯРЫШЫ

Ш. ХӨСӘЕНОВ. Мәхәббәт һәм нәфрәт. *Хикәя* . 90
С. САБИРОВ. Яшен суккан иман. *Хикәя* . . . 98

ӘДӘБИ МИРАС

Г. ИСХАКЫЙ. Ике йөз елдан соң инкыйраз . . 109

ПУБЛИЦИСТИКА

Ф. БАҺАВЕТДИНОВ. Кәрим Тинчуринның соңгы көннәре . . . . . . . . . . . 149

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

М. МӘҺДИЕВ. Европа — безнең хакта . . . . 152
Л. ҖАМАЛЕТДИНОВ. Венгр галиме татарлар арасында . . . . . . . . . . . . 156
Л. ИХСАНОВА. Чишмә җыры. *Бер хатирә* . . 161
М. ВИЛДАНОВА-ХӘКИМОВА. Шагыйрь хатыны булу авырмы? . . . . . . . . . 164

ЯҢА ӘСӘР УКЫГАЧ

Кенәри — читлек кошы. *Хатлардан өзекләр* . 170

МӘДӘНИЯТЕБЕЗ ТАРИХЫНА

Н. ГӘРӘЕВА. Кем ул Морад Рәмзи? . . . . 171

ТАТАР ТЕЛЕ ДӘРЕСЛӘРЕ

Алтынчы дәрес . . . . . . . . . . . 176

Гарәп әлифбасы нигезендә татарча уку күнекмәләре . . . . . . . . . . . . 179

КОТЛЫЙБЫЗ

Х. Хәйригә 80 яшь . . . . . . . . . . . . 160

ЮМОР ҺӘМ САТИРА

К. МОСТАФИН. Хат башы — яз каршы. *Хикәя* . . . . . . . . . . . . 187
Мәдәният тормышы көндәлеге . . . . . . . 189
Тышлыктагы сурәтләр . . . . . . . . . 192

*Баш редактор*
РАВИЛ ФӘЙЗУЛЛИН

*Редколлегия*
ГАРИФ АХУНОВ
МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ
МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ
АЯЗ ГЫЙЛӘЖЕВ
МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ
ФЛҮС ЛАТЫЙФОВ
*(җаваплы секретарь)*
МӘДИНӘ МАЛИКОВА
САЛИХ МАННАПОВ
ФӘРВАЗ МИҢНУЛЛИН
ФЛҮН МУСИН
МАРАТ МӨЛЕКОВ
РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ
РАШАТ НИЗАМИЕВ
*(баш редактор урынбасары)*
ГӘРӘЙ РӘХИМ
КОЯШ ТИМБИКОВА
*(бүлек редакторы)*
МӘХМҮТ ХӘСӘНОВ
МӨДӘРРИС ӘГЪЛӘМОВ
ТӘҮФИКЪ ӘЙДИ
*(бүлек редакторы)*
АЗАТ ӘХМӘДУЛЛИН

Безнең адрес: 420066,
Казань, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар:
баш редактор — 53-07-60.
баш редактор урынбасары — 53-07-09.
җаваплы секретарь — 53-07-09.

*бүлекләр:*

чәчмә әсәрләр, шигърият,
очерк — 53-07-61.
тәнкыйть, фән, сәнгать,
хатлар — 53-07-63.
корректорлар — 53-07-65.

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

«Проза и поэзия»: окончание романа А. РАСИХА «Внук ишана». Стихи Г. АФЗАЛА, М. АГЛЯМОВА, А. ХАЛИМА, С. МУЛЛАГАЛИЕВА.
«На конкурс»: рассказы Ш. ХУСАИНОВА «Любовь и ненависть», С. САБИРОВА «Дуб пораженный громом».
В рубрике «Литературное наследие» опубликовано окончание повести классика татарской литературы Г. ИСХАКИ.
«Публицистика». Статья Ф. БАГАУТДИНОВА «Последние дни К. Тинчурина».
«Литературная критика». Статьи М. МАГДЕЕВА «Ученые Европы о нас...», Л. ЗАМАЛЕТДИНОВА «Венгерский ученый среди татар», Л. ИХСАНОВОЙ о творчестве М. РАФИКОВА, воспоминание М. ВИЛЬДАНОВОЙ-ХАКИМОВОЙ «Трудно ли быть женой поэта?»
Отрывки из писем читателей о новом романе Р. Мухамадиева «Львы и канарейки».
«К истории культуры»: статья Н. ГАРАЕВОЙ «Кто он Мурад Рамзи?»
Юмор и сатира: юмореска К. МУСТАФИНА.
Уроки татарского языка.
Навыки чтения на основе арабской графики.
Дневник культурной жизни.
На наших обложках — булгарский историко-архитектурный памятник «Чертово городище» близ Елабуги; портрет известного татарского писателя, лауреата премий им. Г. Тукая А. Расиха.

*Бүлек редакторлары* Мансур Вәлиев, Рәдиф Гатауллин.
*Редакторлар* Нияз Акмалов, Шамил Маннапов, Җәүдәт Миңнуллин, Рәшит Әхмәтҗанов.
*Техредакция:* Р. Вафина, Г. Моратова, Ф. Сабирова, Т. Сибгатуллина, Р. Сөләйманова.

Производствога бирелде 04.12.1989 ел. Басарга кул куелды 29.01.1990 ел. ПФ 05079. Офсет ысулы белән басыла.
Кәгазь форматы $70 \times 108\ ^{1}/_{16}$. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8).
Тираж 81349. Заказ Б-531. Бәясе 90 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.
© «Казан утлары», 1990 ел.

# ШИГЪРИЯТ

## Гамил Афзал

### Ике шагыйрь

Үткән чорлар моңын тыңлаганда
Төрле фикер туа төрлечә...
Ике шагыйрь торган бер заманда
Берсен-берсе якын күрмичә.

Беренчесе шома шымчы булган,
Сайрап кына тапкан ил малын,
Авызыннан энҗе-мәрҗән койган
Түрәләрен мактап дөньяның.

Җәлладларга, син арслан, дигән,
Син баһадир, дигән, бу эштә.
Хәтфә келәмнәргә басып йөргән,
Күңел төбәп алтын-көмешкә.

Кала буйлап дөмбер дөмбердәтеп,
Имам белән шәех сайларга,
Чапан чабуларын җилфердәтеп,
Мәҗлесләргә йөргән байларга.

Фәкыйрь, дигән, илен ташлап китә,
Бәхет, мөлкәт таба ят җирдә,
Ходай кушып, язмыш язган икән,
Буйсынырга кирәк тәкъдиргә.

Законнарны мактап җырга салган,
Жандармга барган киңәшкә,
Хөрмәт күргән, дан-дәрәҗә алган,
Онытканнар үзен үлгәч тә...

Икенчесе җырдан камчы үргән,
Явызлыкны ярган фаш итеп.
Акыл азатлыгын алга сөргән,
Ил намусын куйган баш итеп.

Иркәләгән ятим-фәкыйрьләрне,
Халык моңын-зарын җырлаган,
Ил өстендә торган хакимнәрне
Көтүчедән өстен куймаган.

---

Гамил АФЗАЛ *(1921) — шагыйрь, татар, рус, башкорт телләрендә дөнья күргән күп санлы лирика, юмор-сатира һәм проза китаплары авторы. Татарстан АССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Әлмәттә яши.*

Шаян жырга күз яшьләре кушкан,
Алга тарткан заман агышын.
Кадер-хөрмәт күргән ярлы дустан,
Байрак итеп йөрткән намусын.

Хөкемдарлар ләгънәт укып, аны
Зинданнарга ябып куйганнар,
Үлсен диеп, сүнсен диеп даны,
Мәсхәрәләп илдән куганнар...

Сары комнар күмеп искеләрне,
Истеләр дә җилләр, истеләр.
Кыяфәтен ак мәрмәрдән коеп,
Сагына аны гади кешеләр.

## Яңа хәбәрләр

Газетлар карап кич-иртән,
Бер яхшы яңалык көтәм.
Һуш китәрдәй хәбәрләр юк.
Кунак килгән, кунак киткән
Китсен әйдә, килсен әйдә
Зур кешеләр ашка-чәйгә,
Елмаеп сөйләшсеннәр,
Чәй эчеп киңәшсеннәр...

Газетлар карап кич-иртән,
Бер кызык яңалык көтәм.
Шаккатардай хәбәрләр юк,
Галәмгә ракета киткән.

Китсен әйдә, йөрсен әйдә;
Бер китәләр, бер төшәләр,
Менә хәзер ракетада
Космонавтлар чәй эчәләр...

Яңа хәбәр: ил иңләгән,
Бу дөньяда күпне күргән
«Идегәй» чыккан төрмәдән,
«Идегәй» кайткан сөргеннән!
Әйдә түрдән, әйдә түрдән!
Халык эзләр, халык табар;
Без дастансыз милләт идек,
Тарих та бар, дастан да бар,
Алмаз кашлы йөзек кидек!

Ул заман да, бу заман,
Җир белән күк арасы.
Күзләрем күрми, балам,
Кайсы юлдан барасы?

Ул еллар да, бу еллар,
Тал-тирәктә былбыллар,
Әйтеп бирче, оланым,
Кая бара бу юллар?

Ул чорлар да, бу чорлар,
Каеннар да, чыршылар,
Бары да матур кебек тә,
Күңел тулы борчулар...

## Дөреслек

«Ай-һай гына» дигән тиреслектә
«Алла бирде» дигән хиреслек.
Алан-йолан карап, дәшми торды,
Аска карап торды Дөреслек.

Алдаламый торган аяз таңда
Яңача уйларга керештек:
Акыл да бар, намус та бар җанда,
Иман булып инде Дөреслек!

# Тубылгытау

Тубылгытау буе яшел чирәм,
Бөдрәләнеп үскән тубылгы.
Борынгы зар тулы якын-тирән,
Борынгы моң тулы, борынгы.

Тубылгытау буе яшел тирәк,
Бу — каберләр иле, кадерсез.
Ничек итеп сүз сөйләмәк кирәк,
Җыр җырламак кирәк әрнүсез...

Түрәләрдән курку,
судтан курку
Ана сөте белән сеңгән кебек.
Адәм балалары бу дөньяга
Куркып йөрер өчен килгән кебек.

Әллә кайда,
әллә кемнәр
Безнең юашлыктан көлгән кебек.
Сикереп аккан сулар комга сеңгән,
Таулар иңгән кебек...

Яшел язын күрдем,
сары көзен,
Уйчан-уйчан аккан суларны.
Ак ефәккә төреп, күңел күзем
Саклап тора икән шуларны.

Һәр яхшылык,
һәр матурлык истә,
Һәр яфрагы истә урманның.
Шуңа микән җәйге зәңгәр кичтә
Кәккүк кебек моңлы булганмын.

Һәр кешенең күңеле тугыз катлы,
Туксан тугыз төрле эше бар.
Минем күңел аяз көндәй якты,
Һәр көнендә шигырь төше бар.

Тау артына китеп кояш батты,
Хәерле кич, дигән кеше бар.

Мескен булып тору бетте,
Менә ипи, әнә кояш!
Туры сөйләр вакыт җитте,
Безнең тормыш, безнең влач!
Халык кыюланып китте —
Югарыдан рөхсәт булгач...

Безнең көнелләрдә моңнар
тартылган кыллар кебек,
Бер чыңламаса, бер чыңлар,
өздереп чыңлар кебек,
Гасырлар тыңлар кебек...

Атабыз Адәм уйланып утыра:
«Ай, авыр бу ил аталарына.
Киләсе буыннар үзләре кайгыртсын,
Майт якаларына!
Демократия кирәк икән
Удмуртына, татарына...»

Күзәтүчән философлар белә:
Ялганга тончыгып илләр үлә.
Дәүләт үсә бара урдән-ургә,
Алдашмаса бер дә.

Сатирага иркен мәйдан сора,
Сатира — ул көләч, шаян кыз.
Тар күңелле түрә уйлап тора:
«Бездән көлә бугай бу дуңгыз...»

Җитәкчеләр килә, китә,
без калабыз әле.
Җәһәннәмнәр сүнә — бетә,
без янабыз әле.
Аждаһаның күзенә карап,
елмаябыз әле.
Без барабыз әле...

*

Туфан язды яшел кара белән,
Яшел яфрак төсен яраткандыр,
Яшьлек бөркеп торган яшел үлән
Кайгы-хәсрәтләрне тараткандыр.
Өмет өзмәгәнгә бирәм, дигән,
Сагындырып кына таң аткандыр...

## Тимер һәм шагыйрь

Тутанхамон фиргавеннең бармагында тимер йөзек,
Тимер дә кадерле булып шул заманнан килде йөзеп.

Тимер-томыр кыйммәтмени, диеп сорарсыз хәзер сез,
Шагыйрьләр дә шулай, дустым, күбәйгән саен кадерсез.

*

Ярлы кеше яманыр да юаныр, ди,
Яңадан да шәп булды дип уйланыр, ди,
Кесәләрдә алтын-көмеш булмаса да,
Эшем бара, кайгы юк, дип куаныр, ди.

Мин дә шулай, ятсам да бер, торсам да бер
Өстәлемдә бер бит кәгазь, каләм әзер,
Көн буена газапланып бер сүз язам,
Менә, димен, шөкер әле, алга барам...

*

Сталин сурәтен күтәреп йөрдек,
Ура кычкырдык, барабан кактык,
Эч тулы иде шатлык.

Сталин эшендә гаеп күрдек,
Аның сурәтләрен ертып аттык,
Тагын эч тулы шатлык...

*

Сау бул инде, егерменче гасыр!
Якты идеаллар, караңгы төрмәләр
Еракларга карап көрсенәләр.

Сау бул инде, егерменче гасыр,
Бик күп даһиларны күмгән заман,
Гади кеше айга менгән заман!

# Мөдәррис Әгъләмов

## Ничәнче кат

*1989, июнь.*

Ике арада калдым мин,
Ике арада калдым.
Юк, бу чакыру авазы
Түгел иде ятларның.

Бу башка бер аваз иде,
Ятларны беләм яттан...
Бу аваз килде мәңгегә
Чакыра торган яктан.

Мин киттем.
Киттем. Син калдың.
Син — горур! Рәхмәт сиңа!
Кием дә авыр, кергәндә
Шигърият бакчасына.

## Рәхмәт, җәй

*1989, июнь.*

Ни өчен әле, ни өчен
Нәкъ шушы җәйдә булды —
Сафлыкның үзе булып, әй,
Хыялым пәйда булды.

Кичке тын эссе бүлмәдә
Ачылды нәни йөрәк,
Үземме, улмы — әллә соң
Хыялмы кадерлерәк?..

Куркытмам микән, тотам дип
Учыма кунган кошны —
Куркытмам микән тирәдә
Кайнаган чолганышны?

---

Мөдәррис ӘГЪЛӘМОВ *(1946) — шагыйрь, «Учак урыннары», «Исәнме, йөрәк», «Киләчәккә кайту» һ. б. шигырь китаплары авторы. Казанда яши.*

Хыялым пәйда булды, әй.
Рәхмәт, җәй, түзим, ярар!
Аксын ул,
Аксын хисләрем —
Аккан су юлын табар.

## Икенче көн...

*1989. июнь.*

Икенче көн бер урын буш
Булмадәме, күңелдәме? —
Чын идеме бәхетләрнең
Кичә күзгә күренгәне...

Коелдымы ромашканың
Таҗындагы чуклар кебек,
Әллә инде үләннәргә
Таңда төшкән чыклар кебек...
...Коелдымы?

Икенче көн бер урын буш
Булмадәме, күңелдәме? —
Күңел тулы,
Күз яшедәй
Тәгәрәде түгелгәне...

Чайпалды да түгелде, әй,
Йөрәк килә сулык-сулык,—
Салкын чишмә суы кебек
Калсам иде чиста булып,
Калсам иде...

Икенче көн бер урын буш
Булмадәме, күңелдәме? —
Күренде бит гүзәллекнең
Яшьлек булып төренгәне.
Әй-йә хода, аңламыйча
Тораташтай басып торыш —
Булмадәме, күңелдәме
Икенче көн бер урын буш.
Икенче көн...

## Ник әйтмәдең, каен

*1968—1970.*

Ни гомерләр талпынсаң да, каен,
Син китмисең туган җиреңнән.
Туфрак булыр өчен алкаларың,
Яфракларың җиргә сибелгән.

Һәркемнең дә, каен, шаулар җире,
Яфрак кояр җире бер генә.
— Бәхет өчен адәм баласына
Җитми, диеп, туган җир генә,—
Ник әйтмәдең, каен, кисәтмәдең?
Күпме йөрдек синең тирәдә.

Куеныңа көзләр кергән сыман,
Шул вакытлар уйга килә дә,
Актарыла хәтер... яфраклар күк,
Истәлекләр булып саргая.
Син шунда ук, каен, ә мин менә
Җанга урын тапмыйм кайда да.

Ник әйтмәдең, каен, кисәтмәдең?
Синең дә бит булган яшьлегең.
— Ә вәгъдәләр кая?
Вәгъдәләр? — дип,
Бер генә сүз шунда дәш идең.

Ышанычлар изге булгангадыр,
Уйлаганбыз: «Вәгъдә кирәкме?»
Вәгъдәләр дә биреп, бозган булсак,
Телгәләмәс иде йөрәкне —
Авыр булмас иде бу хәтле.

Иңебездән еллар узып бара,
Каралабыз инде, дускаем...
Син яфраклар, ә мин дәфтәремә
Истәлекләр коям көз саен.

1980.

Уйлар бүген илаһидан
Чынбарлыкка чыкты,
Кинәт җил бәрелде бугай,
Керфекләрем чыклы.

Оялдым үземнән үзем,
Әйтә килдем: — Гүзәл,
Йөрәк бит ул түзәр өчен
Яратылган, түзәр!

Нигә әле кинәт кенә
Төкәнде бу түзем?
Юк, юк, гүзәл,
Синнән түгел,
Бу мин үзем,
Үзем.

...Дөнья шундый иркен иде,
Якты иде күкләр...
Берәү генә иде, кызый,
Анда синең күкләр.

Менә син бар, иреннәрең
Синең балдан татлы.
Дөнья шул ук,
Дөнья иркен,
Күк тә шулай якты.

Әйе, син бар. Ә чынлыкта
Бу бит сөйләү генә...
Син дә ике түгел, беләм,
Ә ул берәү генә иде,
Һаман берәү генә.

## Онытылган ярам

*1987, август.*

Бервакытны юлым сихри
Авыл аша узды...
Очраттым мин чибәрләрдән
Чибәррәк кызны.
Мин эндәштем: — Минем белән
Барасыңмы?
— Барам!
— Юлым ерак! Армассыңмы?
— Арсам нәрсә?! Калам!
Йөрәгемне тыңладым да
Сулап куйдым авыр...
Ачык тәрәзәләр белән
Карап калды авыл.
Йолдызларга кулым суздым:
— Күрәсеңме?
— Күрәм!
Без ант иттек мәхәббәттә
Шул йолдызлар белән.
Күз күрмәгән якка киттек,
Ярып бардык кылган;
Без барырга теләмәдек
Такыр гына юлдан.
Елмаеп төш күрә-күрә
Кочагымда кунды;
Берничә көн көлде, көлде,
Ә аннары... тынды.
Ә беркөнне әйтте арып:
— Җитәр инде, калам!
...Нигә сөйлим?! Бу бит — минем
Онытылган ярам.

# ЭКСПРОМТЛАР

## Х. Сарьян агай белән сөйләшү

*1974. Саба. Алан авылы.*

Дөрес, агай, акчасыз да булмый,
Кырып булмый акча белән дә...
Рәхәт, дисең, әнә ак сарутка,

Рәхәт, дисең, әнә үләнгә.
...Көзе житсә
Саклап булмый аны
Акчасыз да, акча белән дә.

## Худсоветта

*1983. Горький урамы, 15.*

«Жырның жыртыгы юк», диләр,
Юк та жырның ертыгы —
Күпме күрдек шул ертыктан
Төшеп калган жырчыны.

## Исем биргәннән соң...

*1986, июнь. С. Х.гә*

Сиңа пәйгамбәрлек бирелде, дип,
Тоз сибик дисәләр ярасына —
Ул ярасын алып киткән иде
Инде пәйгамбәрләр арасына.

## Кул нык чакта...

*1989, март.*

Гомер — касә... Көннәр тама
Тамчы-тамчы...
Күп тама шул, бер үз тамчың
Табылганчы;
Гомер — касә... Өлгерәсе иде эшләп,
Соңгы тапкыр
Үлем-язмыш кагылганчы.

## «Таш калада таш кыйбат»

*...агай сүзләре. 1988, сентябрь.*

Таш калада, агай, кыйбат агач,
Син белмисең бары, кагылмагач —
Ташны күтәрергә куллар кирәк,
Агач үстерергә еллар кирәк.

## Атлар

*1972. Болгар.*

Анда учак,
Монда учак...
Без көтүдә — ат көтүе...
Мөмкинмени яктылыкның
Учак сүнгәч бетүе...

## Ничә яфрак

*1989. «Туган як» җәмгыяте.*

Мин туганмын,
миннән беркем сорамаган.
Мин китәрмен,
беркем миннән сорамас та...
Ә бит кызык:
ничә яфрак чыгар икән
минем шигырем саклап калган
бер агачтан?

## Киткәндә

*1983, октябрь. Татар зираты.*

Зират тулы — үлән.
Ә бит кайтасы бар әле
Шушы үлән белән.

## Яфраклар коела

*1964. Әнкәм каберендә.*

Яфраклар коела, яфраклар...
Нәкъ шулай ел саен бу нәрсә...
Күбәләк шикелле талпынып
Очалар, аз гына җил бәрсә.

Торсыннар агачлар. Ялангач.
Көзге җил, син гафу үтенмә,—
Һәр елда
Көз саен
Бу шулай,
Гаепле түгел ич беркем дә.

## Остаханәдә

*1988. Фәһимдә.*

Аллалары бәндә кебек,—
Бәндәләре алла кебек —
Юк та кебек,
Бар да кебек.
...Һәммәсе дә алда кебек.

## Шундый чорда ничек туган ул?

*1986. Кырлай.*

— Нәрсә сорап торасың син монда —
Тукай туган халык хыялында.
Ә хыялның башы — без барлык,
Бар нәрсәдә яши чынбарлык.

## Торбалар астында кара күл

*1986. Кушлавыч.*

«Җон агызып йөрим»,— дигән Тукай.
Тарихына кермим, агар җон —
Янам, янам, халык өчен янам,
Ник сөреме куе каралҗым?

## Истәлек яз, диләр

*1986, октябрь. Осташ.*

Ә ул кирәк иде. Җитте Вакыт,
Китеп барды без барасы җиргә...
Меңнәр әзер әнә күңелләрен
Аның исеме белән җилгәрергә.

## Нинди көн бу?

*1989, июль. Фәиз З. ки.*

Яшәүме бу?
Әллә үлемме бу?
Янулардан калган көнемме бу?
Нинди көн бу — әллә сыердагы
Савылмыйча калган җиленме бу?

...Әллә ялган дөнья,
Әллә чын бу?
Әллә төн бу шунда,
Әллә көн бу —
Әйталәрдер әле синең хакта:
«Әллә кем бу!»

## Кулын кысар идең

*1974. Бабич.*

Яшь бер адәм шигъри сүзләр белән
Хакыйкатьне ярып әйтеп сала.
Без дә белә идек, әйтмәдек, дип,
Гадәтиләр гаҗәпләнеп кала.

...Кулын кысар идек, вакыт үткән.
Үз заманы борып алып киткән,
Гыйбрәт булсын диеп, безгә таба.

## Тиеш

*1982, июнь.*

Остазың акыл сатканны
Тыңлап торган сәгатьтә
Авыр була, гадәттә.

Остазың белгәнен яттан
Сөйләп торган минутта
Булмый юләр булып та,
Һәм акыллы булып та.

Инде остазың иң соңгы
Юлга киткән чагында
Син торырга тиеш икән
Аның соңгы сагында!

## Атилла Расих

# ИШАН ОНЫГЫ

РОМАН-ИСТӘЛЕК

Мәктәптән куылдым. Әти муллалыгын ташлау турында бик нык уйлана башлады. Хәтеремдә, ул хәзер үзенең таныш-дус укытучылары белән сәгатьләр буе киңәш-табыш корып утыра иде. Кала якның иң күренекле урынына безнең шәһәрдә хокуктан мәхрүм ителгән кешеләрнең исемлеген элеп куйдылар. Мин аны Кала якка чыгып укып кайттым. Димәк, безгә барлык юллар ябылды. Ул гына да түгел, безнең мәктәп каршына ук сыйнфый дошманнарның карикатураларын ясап элделәр.

Әти, муллалыгын ташлап, үзенең ни өчен шундый борылыш ясавын шәһәр газетасына язып чыкты. Тик моннан аңа да, безгә дә әллә ни файда килмәде. Маңгайдагы мөһерләр шул килеш калды, бу хәлне бүренең сарык тиресенә төренүе дип кенә кабул иттеләр.

Әти Троицкида эшкә урнаша алмады. Ул, байтак бусагаларны таптаганнан соң, укытучы иптәшләренең киңәше буенча, Урта Азия якларына китеп барды. Дәү әнине хәзер Күлле Кимедән Арчага күчкән Габдрахман абыйларга илтеп куйдылар. Мин исә Амурдагы рус мәктәбенең дүртенче классына кердем. Минем ишеләргә беренче баскыч белеме алырга рөхсәт бар иде әле.

Ә әтидән, байтактан бирле инде, бернинди дә хәбәр юк. Нишли ул? Үзенә берәр эш таба алганмы? Ниһаять, әтидән «Укытучы булып урнаштым», дигән телеграмма килде. Бу инде — безнең өчен чиксез куанычлы хәбәр. Әни бөтен дус-иш, туган-тумачага безнең шатлыкны хәбәр итте. Хәлбуки, алай итмәсә яхшырак та булыр иде. Хәер, монысы турында соңрак.

Әти, эшкә урнашса да, әле аңардан нинди дә булса ярдәм юк. Көтмибез дә. Әмма безгә яшәргә кирәк. Булган акчалар барысы да бер-бер артлы налогларга китеп бара. Безгә хәзер әйбер сатып кына көн күрергә калды. Менә шундый шартларда безнең гаиләдә Суфия апа беренче кеше булып әверелде. Ул базар хәлләрен бик тиз арада үзләштерде. Әни биреп җибәргән кием-салымны шактый уңышлы сатып, табышның соңгы тиенenә кадәр кайтарып тапшыра торган булды.

Шулай яшибез. Тормыш бал-майлык булмаса да, ипи-бәрәңгегә

---

Ахыры. Башы 1 санда.

аптырамыйбыз. Ат-арба күптән сатылды инде, күлмәк-күнчәкнең дә күбесен Суфия апа базарда «дулатты». Тормыш, ярыйсы дигәндә дә, авыр. Базарда азык-төлек бәяләре көннән-көн артып тора. Он мәсьәләсе дә авырлашты. Ләкин без яшибез. Тормыш бара, тәртелеп тормый. Мин элеккечә үк дус малайларым белән уйныйм, тимераякта шуам, пьесалар язам, түбәдән сикерәм. Атымны сагынам. Ул яшәгән абзарга кергәлим, ләкин анда тынлык...

Менә җәй айлары килеп җитте. Мине, этеп-төртеп булса кирәк, бишенче класска күчерделәр. Ләкин бишенче класс дип әйтүе генә ансат. Әгәр чыгышымны яшермәсәм, тагын шул ук тибәрелү кабатланачак бит. Без җәйне өйдә генә уздырдык. Хәзер инде безгә казахка чыгып, ак тирмәләрдә кымыз эчеп ял итү мөмкинлекләре бетте.

Көзен әни мине Казанга алып китте. Казанда озак тоткарланмадык, Арчага, Габдрахман абыйларга юл тоттык. Әни миңа бу кышны Арчада торырга, Габдрахман абыйларда яшәп укырга кирәклеген аңлатты.

Менә мин Арчада, бер катлы авыл өендә, Габдрахман абыйларның ишле гаиләсендә яшим. Һәр көнне иртән, Арчаның урам балчыгын изә-изә, үр өстендәге мәктәпкә китәм. Миңа бик авыр, ямансу, тик шулай да түзәм, түзәм...

## 16

Бүген Агриппина Евграфовнаның куанычы йөзенә чыккан иде:

— Боз кузгалды, иптәш Рәсүлев!— диде ул.— Бүген көндезге икедә сез комиссия белән очрашырга тиеш. Аларның сезне күрәселәре килә.

Аннан ул, гадәтенчә, туп-туры карап елмайды:

— Мин әйткәннәрне исегездән чыгармагыз, иптәш Рәсүлев, үзегезне тыныч тотыгыз, сорауларга бик уйлап җавап кайтарыгыз.

Вакытны ничек уздырырга белмичә, чат баганаларындагы сәгатьләргә карангалап, ут йотып урамда йөрим. Хәтта ашауны да оныттым. Комиссия алдына кереп басу бөтен язмышымны хәл итәчәк бер нәрсә булып тоела.

Якындагы бакчага — икенче яшәү урыныма әйләнгән скверга кереп, андагы эскәмиягә утырам. Юк, тыныч кына утыра алмыйм. Авыр миңа. Вакытны белергә дип тагын бакчадан чыгып китәм. Ниндидер төер тамак төбен өзлексез кытыклап тора. Соңга калуым бар. Әгәр соңга калсам: «Ә-ә, бу егетнең укырга теләге дә шул кадәр генә икән, мондый кешегә институтта урын юк»,— диярләр кебек.

Яңгыр сибәли башлады. Мин Җир эшләре комиссариатының вестибюленә кереп ышыкланам. Андагы стена сәгатенә карыйм, җанымтәнемне дәһшәт уты көйдереп ала: сәгать икене сугып егерме минутны күрсәтә. Һай, хараплар булдым бит, соңга калганмын! Шунда, ничектер, күзем сул як стенадагы сәгатькә төшә. Анысы уникене сугып утыз биш минут кына әле, ди. Тукталып калам. Кайсысы дөрес бу сәгатьләрнең? Мин сул яктагы сәгатьне күзәтәм. Әһә, моның минут угы алга сикерде. Инде уң якка ашыгам, күзләремне текәп, тынымны кыскан хәлдә, сәгатьнең укларына карап торам. Бернинди хәрәкәт юк. Күңелем тынычланып кала. Үзалдыма елмаеп, пыяла ишек аша урам күзәтәм. Яңгыр туктаган, асфальт тротуарларны чылаткан да, Мәскәүнең башка төбәгенә киткән.

Ике туларга унбиш минут калганда мин Агриппина Евграфовна каршында идем инде. Ул язу машинасында тек-тек эшләп утыра. Менә ул башын миңа таба бора. Аның җитди кыяфәте күңелгә борчу сала.

— Бераз сабыр итәргә туры килер, иптәш Рәсүлев. Әле генә Александр Александровичны Коллегия утырышына чакырдылар.

Шуңа күрә бүген комиссия утырышы булмый.

Бөтенләй тетрәнеп: «Ничек инде алай? Мин...—» дип әйткәнемне тоймый да калдым.

— Йә, нишлим соң инде, кадерлем?— диде секретарь, гафу үтенгәндәй.— Миңа үзе кичә әйткән иде, чакыртыгыз, дигән иде бит.

Тәмам күңелсезләнеп, ишеккә таба атладым. Арттан Агриппина Евграфовнаның: «Күңелегезне төшермәгез»,—дигән сүзләре колакка чалынып калды.

Мин тагын шау-шулы Мәскәү урамында. Тәндә эчпошыргыч хәлсезлек тоям. Ах, иртәдән бирле авызга валчык хәтле дә ризык капмаган икәнмен бит. Улының шулай ач йөргәнен белсә, әни нишләр иде, мескенкәем.

Әни... Мин тагын аның турында уйланам.

Әнием, тормышның авыр сынауларын кичеп тә, үзенең гүзәл горурлыгын, кешелеклеген югалтмаган бер хатын. Аның кече абыйсы Габдрахманның, уночечне елны Петропавелдан кайтып, әниләрне Чистайдан Шакир абый янына, Троицкига алып китүе турында әйттем кебек инде. Әни үзенең истәлегендә: «Шулай итеп, без Габдрахман абый белән Троицкига, Шакир абый янына күчеп киттек».— дип яза. Троицк вокзалында Шакир абый аларны үзе каршы ала. Атлар яллап, вокзалдан шактый еракта, тау астында урнашкан шәһәргә юнәләләр алар. Әни болай яза: «Вокзал — тау башында, тау астында шәһәрнең «Мәгьмүрия» дигән кыйсме башлана. Аннан соң — кечкенә генә елга, шуңа бик зур күпер салынган. Шуларны үтеп, асыл шәһәргә килеп кердек. Абый шул Кала якта кечкенә бер бүлмәдә тора иде. Белмим, абый бүлмәсендә ничә көн яшәгәнбездер, бераздан аерым фатир алып, шунда күчтек. Шул өйдә әйберләребезне урнаштырып көн күрә башладык.

Буби мәктәбе ябылу сәбәпле, андагы мулла абыстай үзенең кызлары белән Троицкига күчеп, Җәмгыятел хәйрия тарафыннан ачылган Габдрахман Әхмәревләр карамагындагы кызлар мәктәбе «Сөембикә»дә укыта иде. Мин дә, Троицкига килеп төшү белән, шунда укыта башладым. Ул мәктәп алты класслы. Миңа бишенче һәм алтынчы классларда коръән, әхлак, география дәресләрен тапшырдылар».

Кызлар мәктәбендә укыту белән бергә, әнием ул вакыт Троицкида яшәгән Гыйбад Алпаровтан үзе дә дәресләр ала.

Габдрахман абый, Троицкида бераз кунак булганнан соң, үзенең Петропавелына кайтып китә. Шакир абый исә, Яушевләрдә приказчик булып эшләү өстенә, һәвәскәрләр труппасында да катнаша. Спектакльләрдән керем күбрәк булсын өчен, кайвакыт һәвәскәр артистлар бу эшкә шәһәрнең алдынгы карашлы кызларын да тарта торган булалар. Алар антракт вакытларында халык арасында чәчәк сатып йөриләр. Мондый вакытларда әнием дә аларга булыша, чәчәк сатыша. Истәлегендә ул, Троицк байлары бер чәчәкне бишәр кат сатып алалар иде, дип яза. Ягъни, чәчәк сатып алалар да, аны әниемнең күкрәгенә кадап китәләр.

Шундый кичәләрнең берсендә, әнием янына танышларыннан берәү килеп: «Зәйтүнә, синең белән Зәйнулла хәзрәтнең уртанчы улы танышырга тели»,— ди. Әниемә, заманасының алдынгы кешесе буларак, яшьләр белән танышу гади, гадәти бер нәрсә булып тоела. Әнием үзенә мөрәҗәгать иткән хатын-кызга, аны-моны уйламастан: «Таныштырыгыз соң»,— ди. Алар шул ук көнне тәнәфес вакытында очрашып танышалар. Минем булачак әтием, әле күптән түгел Истанбулда укып кайткан кеше, әниемә Истанбул, Төркия турында сөйли. Әнием исә, әлбәттә, моның белән кызыксына. Буби мәктәбендә алынган төркичелек тәрбиясе аңарда, күптән инде, Истанбулда укысаң иде, дигән яшерен өмет кузгаткан була.

Әнием сораша, кызыксына, ә этием исә, әниемнең истәлекләренә караганда, моны үзенә игътибар дип кабул итә. Озак та узмый, этием аңа кияүгә чыгарга тәкъдим ясый. Бу әнием өчен көтелмәгән бер нәрсә була. Ул шунда ук бу тәкъдимнән баш тарта. Минем әле укыйсым бар, кияүгә чыгуны башыма да китергәнем юк, дигән рәвештә җавап бирә. Юк-юк, ишан малаена кияүгә чыгачакмы соң ул?! Дини фанатикларга, ишан, мөритләргә каршы дошманлык тәрбиясен алмадымыни ул Тукайлар, Әмирханнар мәктәбендә. Шулай! Әни бу турыда артык баш ватуны кирәк тә санамый.

Иллә мәгәр, әни оныткан булса да, эти үз исәбен бер генә минутка да онытып тормый. Ул тавык Вәли һәм аның хатыны Маһибәдәр аша тагын бер тапкыр тәкъдим ясый. Үзенең әнием белән очрашып сөйләшергә теләвен белдерә. Әни, аңардан бөтенләйгә котылу һәм тәкъдимен ныклап кире кагу өчен, очрашырга ризалык бирә. Әниемә тәмам гашыйк булган эти, укырсың, мин сине үз акчама Истанбулга җибәреп укытырмын, тик вәгъдә генә бир, дип бара. Аллам сакласын, ди әни. Бу эшнең гомердә булмаячагын аңлатырга тырыша. Зинһарлап, этинең башка борчып йөрмәвен үтенә.

Шулай көннәр уза. Әнием кызлар мәктәбендә укытуын һәм башта — Гыйбад Алпаровтан, соңыннан Хәлим Искәндәревтән укуын дәвам иттерә. Ул үз истәлегендә: «Бер көнне укытучымнан кайтсам, өйдә Гали абзый утыра»,— дип яза. Монда сүз алда исеме телгә алынган, Кизил шәһәренең бае, дәү әнинең ерак туганы Гали Дербишев турында бара. Ул Зәйнулла ишанның мөрите икән, ел саен Троицкига ишаннан сабак яңарту өчен килә.

Бераз читкә китеп булса да, шуны әйтим: Миңа да Гали абзыйны исән чагында күрергә туры килде. Бу утыз тугызынчы ел урталарында булды. Элекке бай бөлгән, картайган иде инде. Таудай олы гәүдәле, чандыр, озын муенлы, кабак башлы бер кеше. Борыны зур, карчыга борын. Шул борын өстендә күзләрен кимендә ике тапкыр зурайтып күрсәтә торган тимер кысалы күзлек.

Мин аның гамьсезлегенә һәм оптимистлыгына шаккаттым. Аның мактанып сөйләнүе хәтердә калган: «Һәй,— ди Гали абзый, көлемсерәп,— мин бер урам әйләнсәм, бер чалбарлык акча эшлим, минем тормыш рәхәт хәзер»,— ди. Ул пыяла куючы хәзер.

Әнә шул Гали абзыйга ишан хәзрәт үзенең улы Габделкадыйрның гашыйк булганлыгын әйткән. Бар, дигән карт эти (мин аны шулай атый идем), шул кызны, аллага тапшырып, минем уртанчы улыма сора. Әлбәттә, ул Гали абзыйның да, дәү әнинең дә Чистай кешесе икәнлеген белгәнгә күрә шулай әйткән булырга тиеш. Гали абзый исә, бу йомышны үтәүне үзе өчен зур мәртәбә санап, әниләрне эзләп киткән.

Гали абзыйның бу алдым-бирдем вакыйгасына ничек катнашуын язар алдыннан, мин этием белән карт эти арасындагы сөйләшүгә тукталырга тиеш. Этиемне күптән өйләндерергә йөриләр икән инде. Аны, һичшиксез, бай яки зур мулла кызына, иске тәрбия алган кызга өйләндерү шарт итеп куелган. Хәзер инде эш кыз сайлауга гына тукталып калган. Тагын шунысы бар: Троицк ахуны Рахманкулов белән Зәйнулла ишан арасында яшерен дошманлык яшәп килгән. Улын өйләндереп, минем бабай бу хәтәр хәлне җиңеләйтергә теләгән. Шуңа күрә ул этигә ахун кызын алып бирүне кирәк дип тапкан. Һәм менә шундый бер вакытта аның улы әниемне театрда күреп акылын җуя, бер күрүдә гашыйк була. Алай гына да түгел, «Менә шул кызны алып бирсәгез — өйләнәм, юкса беркемне дә алмыйм, башымны алам да өйдән чыгып китәм»,— ди. Әлбәттә, шул кадәр каты куелган сүздән соң ата-ана уйга кала. Аерата карт әни (мин аны да шулай атый идем) бик каты рәнҗи. Ул марҗаң белән мин ничек кеше күзенә күреним, ди, күз яшьләрен түгә.

Үзара бәхәс-тартыш ике ай буена дәвам итә. Ниһаять, этиемнең

сынмаслыгына тәмам ышангач, картлар тыналар. Карт эти, әйдә инде алайса, сөю-мәхәббәт пәйгамбәрләрдән калган эш, дип, ризалык бирә.

Гали Дербишев әниләр торган квартираны эзләп тапканда өйдә дәү әни үзе генә була. Ерак туганын, якташ абзасын дәү әни бик шатланып каршы ала. Аның һәрбер сүзен саф алтын бәясенә кабул итеп утыра. Ә тегесе исә, әниемнең исталегендәгечә әйтсәк, дәү әнине бик нык агулый. Ишан хәзрәт бөтен Рәсәйдә беренче кеше, улы да тәүфыйклы, укыган. Ул егеткә кем генә кызын шатланып бирмәс икән. Ул синең Зәйтүнәңне сорый, инде син бу эшкә каршы килсәң, сине җир йотар, ди. Дәү әни бу сүзләргә тәмам мөкиббән китә, кызын ишан улына бирергә вәгъдә кыла.

«Көннәрдән бер көнне,— дип яза әнием,— дәрестән кайтып керсәм, бездә Гали абзый утыра. Ул, мине күрү белән, нишләп син егет өенә барып йөрисең әле, анда икәү генә утырырга яратасызмыни, монда килеп укытсын, дип, хезмәтчеләрен куркытырга өйрәнгән кыяфәт белән миңа кычкыра башлады».

Башта әнием бу кыланышка аптырап кала, аннан көлә башлый. Мин сабак укыйм бит, Гали абзый, ди, егет эзләп бармыйм анда, ди. Гали абзый һаман үз туксанын кабатлап, әллә нинди шикле сүзләр сөйли башлагач, аны үртәп, монда әни бар бит, безнең, чыннан да, икәү генә утырасыбыз килә, дип көлә. Җитди сүзнең шундый юнәлеш алуын, кызның әз генә дә сүзгә колак салмавын аңлагач, бай тавышын үзгәртә, әниемне үгетли башлый. Әни исә, баштагы фикереннән һич тайчынмыйча, аңа каршы килә, мин аңа күптән җавап бирдем бит инде дип, үзе укыта торган мәктәбенә китеп бара.

Белмим, шул килүендәме, әллә икенчесендәме, Гали абзый дәү әнинең вәгъдәсен рәсми рәвештә, шаһитлар алдында булса кирәк, алып китә. Икенче көнне иртүк, мәхәллә мулласын китереп, вәгъдә бүләге биреп, никах та укыта. Әни, ни әйтсәң дә дини тәрбия алган кеше, бу хәлдән соң, харап булдым, беттем, дип аяктан егыла. Тирә-юньдәгеләр аны юаталар, юк бетмәдең, икенче тормышка гына күчтең, борчылма, диләр. Җитмәсә, дәү әни аны, абыең әйтте, мин биргән кешегә чыкмаса, мин аны асрап тота алмыйм, дип әйтте дип куркыта. Әнием, бу өйдән китүдән битәр, анасының һәм абыйсының бәддогасыннан курка, якыннарым белән дошманлашканчы, аларның корбаны булып үлүем артыграк, диган фикергә килә. Бары тик, биргән акчаларын тотмагыз, бүләк күлмәклекләрен тектермәгез, ишан малаен күреп әйтәсе сүзләрем бар, шартларыма күнмәсә, барын да кире кайтарып бирербез, дип әйтергә генә батырчылык итә.

Минем булачак әтием белән әнием әлеге беренче ячы — тавык Вәлиләрдә очрашалар. Әнием әтигә, язу аша гына, түбәндәге шартларны белдерә: мин синең анаңа — ул уйлаган килен, сиңа — син өметләнгән хатын булмам, ни телим икән, шуны эшләрмен. Сезнең өйгә төшү белән, укырга керешермен, дип яза. Әти барысына да риза, тик әнием анык гына булсын.

Шундый тетрәндергеч көрәш һәм кичерешләрдән соң, әни бик ябыга, кибә. Бу бөтенләй бетерешмәсен тагы дип, якыннары туйны ашыктыра башлыйлар.

Никах мәҗлесен, туйны ишанга бик бирелгән Шакир абыйның хуҗасы Муллагали Яушев өендә уздыралар. Кияүне, ягъни минем булачак әтиемне, әниләр торган өйнең күршесендәге мехчы Һилаловлар өенә ябалар. Туй мәҗлесләре бик тантаналы уза. Ул ундүртенче елның җиденче февралендә була, уночённче февральдә әни кияү йортына күчеп китә.

Әнием үзенең истәлегендә Зәйнулла бабам белән беренче күрешүен түбәндәгечә яза: «Кич булды, әтки ястүдән кайтты, инде аңа күренәсе генә калды. Залга чәй әзерләнде. Әтки белән күрешкәч, мин, килен хезмәтен күрсәтү йөзеннән, чәй ясап эчертәчәкмен.

Этки мәчеттән кайтып чишенгәч, үз залыннан соң өч бүлмә аша үтеп, безнең янга килеп керә. Кайда, кайда сез, балалар, ди. Бөкре генә бер карт. Әнки кебек ачулы йөзле түгел, миңа бик сынап карый, әмма йөзе мөлаем. Без, Кадыйрның сеңелесе Гайшә белән, бирәдәге кагыйдә буенча, аның кулын үбеп күрештек. Ул бик озын итеп дога кылды. Аннан соң, залга кереп чәйгә утырдык».

Бераздан, яңа тормышка иялəшә төшкәч, әнием Зәйнулла бабайдан, Гайшә апа белән берлектә, гарәбияттән дәрес ала башлый. Шунда карт әти, бу киленнең йорт тотуга барыбер дәрте юк, әйдә үз эшен эшләсен, дип, әнине үз иркенә куя. «Бу килен, улымнан бигрәк, кызым өчен яхшы булды, кызым белән бигрәк дус»,— дип сөйли башлый. Кыскасы, әнием яңа шартларга әкренләп күнегергә мәҗбүр була.

Менә яз да килеп җитә. Май аенда әнием, әтием, Гайшә апа һәм әтинең ундүрт яшьлек энесе Сабур карт әтиләренең Уй елгасы буендагы дачаларына күчеп китәләр. Бу дачадан башланган хәл — әти-әниемнең тормышында иң авыр, иң бәхетсез һәм шул ук вакытта бик гыйбрәтле дәвер капкасы.

## 17

Әниемнең кул зурлыгындагы кызгылт-көрән истәлек дәфтәре миңа кечкенә чактан ук таныш. Әнием буш вакытларында, җае чыкканда, без балаларга яки туган-тумачага аның аерым урыннарын ачып укый иде. Ул дәфтәр хәзер минем эш кәгазьләрем арасында саклана. Анда әле генә искә алынган, дачага күченүдән соң булган вакыйгалар тасвирлана. Хатирә дәфтәре 1914 елның 9 июлендә башланган, 1918 елны тәгалләнгән.

Әле мин шул язмаларның сәхифәләрен актарам...

«1914 сәнә, июнь башлары, минем никахыма да 4 ай була инде. Без җәйнең озын, матур көннәрен саф һавалы, акар сулы дачабызда рәхәт кенә үткәрәбез. Мин дә яңа тормышка өйрәнә башлаган идем. Менә бер көнне бездә ирләр мәҗлесе булды. Ул көнне Гайшә белән мин, Калага ахун кодаларга ашка чакырулы сәбәпле, үзебездәге мәҗлесне калдырып, шунда киткән идем. Без аннан икенде алдыннан гына кайттык. Кунаклар таралган иде инде. Без дачага кереп аттан төшүгә, каршыбызга Сабур йөгереп килде. «Хаҗга барабыз, хаҗга!»— дип сөрән салды ул. Бу нинди гаҗәп сүз тагы диюебезгә каршы, ул әткинең кунаклар алдында: «Җәмәгатемне һәм яшьләрнең һәммәсен бу ел хаҗга җибәрәм»,— дип игълан иткәнлеген әйтте. Без Сабурның бу сүзләренә ышанмадык, дача өе белән янәшә торган казах тирмәсендә үз эшләре белән шөгыльләнүче әнки янына кереп, бу сүзнең дөреслеген сорадык. Әйе, ул да әле генә шундый хәбәр ишеткән икән. Шулай сөйлиләр шул, диде».

Хаҗга кемнәр барырга тиешлелеге турында башта шактый күп сүз, хәтта бәхәсләр дә булгалый. Ахырда, анда бары тик яшьләр генә барырга тиеш булып кала. Ягъни әти, әни, Гайшә апа, Сабур абый. Чит ил паспортын юнәтү өчен Оренбург мулласына хат языла. Юл чыгарга бик нык әзерлек башлана. Ниһаять, унберенче июльдә Оренбургтан «Паспортлар җибәрдем», дигән телеграмма да килеп төшә.

Ләкин нәкъ шул көннәрдә Беренче Бөтендөнья сугышы башланып китә. Төрле куркыныч хәбәрләр йөри. Газеталар, Төркия бугазны япкан, Истанбулга кереп булмый, дип яза. Имеш-мимешләр, куе томандай, бөтен нәрсәне каплый. Имеш, солдат ташу аркасында, Чиләбедән ары беркем дә китә алмый. Менә шундый бер болганчык хәл туа. Әмма яшьләр, бер карар кылгач, ни булса шул дип, барыбер сәфәр чыгарга җыеналар. Әгәр Одессадан пароходлар йөрмәсә, һич югында, шуннан кире әйләнеп кайтырбыз, кечкенә булса да бер сәяхәт булыр, диләр.

Менә алар, ниһаять, вокзалда. Догалар укылып, күз яшьләре житәрлек коелганнан соң, алар вагон купесында Чиләбегә юл тоталар. Аларны якындагы станциягә кадәр әтинең абыйсы, жиңгәсе, әнисе, Шакир абый, дәү әни һәм дәү әниләргә Урсайдан килеп яши башлаган Һажәр апа озата баралар. Юлчылар егерме бишенче июльдә — Уфада, егерме алтысында — Самарада, егерме жидесендә — Сызраньда, аннан Пензада... Вокзалларда мәхшәр, тимер юл станцияләре офицерлар, солдатлар белән тулган. Яңгыравык биек вокзаллар эчендә патриотик нотыклар сөйләнә. Кояз дамалар флот, армия файдасына акча жыеп йөриләр. Поездлар станциядә бик озак тукталып тора. Хатыннар, балалар ирләрен, этиләрен ут эченә озаталар. Елаш, сыкташ. Менә әниләр егерме сигезенче июльдә — Харьковта. Анда алар шәһәр карарга чыгалар, атлы трамвайларда шәһәр гизәләр, гүзәл биналарны, сквер, паркларны күреп сокланалар. Аннан — тагын юл, вагоннар кузгалганда буферлар чыңлавы; тагын — ирләрен, егетләрен, улларын сугышка озатучыларның үксеп елавы, хәлсез хатыннарның һуштан язып егылуы...

Утыз беренче июль кичендә поезд Одессага якынлаша. Жимеш бакчалары белән өртелгән гүзәл шәһәргә житәргә инде күп калмый. Ниһаять, менә ул, Кара диңгез ярындагы, ил чигендәге кала.

Анда безнең мосафирлар бер касыйм татарының «Большая московская» дип аталган кунакханәсенә төшәләр. Номерга кереп урнашкач, кинога барып кайталар, истәлек өчен фото алдыралар. Икенче августта, диңгез тотса-нитсә дип, чемоданнарына бик күп лимон, жиләк-жимеш тутырып, пароходка төшәләр. Әмма хәстәрен алданрак күрергә кирәк булган икән. Чөнки билет өченче класска гына калган. Әйдә, була бирсен! Монысы гына безнең дәртле яшьләрнең күңелен төшерми.

Каюталарда ятаклар ике катлы. Менә берзаман безнең чистапакь юлчыларыбыз янына чапанлы, чалмалы, өсләреннән әчкелтем-төчкелтем тир исләре бөркелеп торган бохаралы үзбәкләр керә башлый. Каюталар шулар белән шыгырым тула. Тынчу, тын алырлык түгел. Әниләр түзмиләр, өске палубага менеп, саф һавалы урынга урнашмакчы булалар. Ләкин анда менәргә матрослар рөхсәт итми, чөнки өченче класс билеты белән анда менәргә ярамый.

Шулай итеп, безнең яшьләр сәяхәтнең беренче адымнарыннан ук күңелсез күренешләргә очрый башлый. Тик яшьлек дәрте һәм алдагы романтик билгесезлек аларга түзәргә ярдәм итә. Әниләр өченче класс балконында барырга риза булалар.

Кемнәр генә очрамый аларга бу пароходта! Сугыш, кырмыска оясын туздыргандай, бөтен илнең астын өскә китерә. Чит ил кешеләре үз өйләренә кайтып калырга ашыга. Гарәпләр, хәбәшләр, әниләрнең котларын алган күгелжем-кара йөзле негрлар очрый.

Менә, пароход кузгалып, Кара диңгез аша байтак юл алгач, караңгы да төшә башлый. Инде палубада артык торырлык түгел: салкын, жиләс. Безнең мосафирлар каютага төшәргә мәжбүр. Ә анда хажилар тәмәке тарта, бил тиңентен чишенеп, шапылдата-шапылдата, бер-берсенең аркасын сылый. Яшьләр, мондагы сасыга чыдый алмыйча, мендәр, одеалларын алып, тагы палубага чыгалар. Төнлә Гайшә апаны диңгез тота. Ул, нишләргә белмичә, икенче класс палубасына менеп утыра.

Диңгез сәяхәтенең икенче көнендә, ягъни өченче августта, кичке бишләрдә, пароход Болгар шәһәре Варнага барып туктый. Юл ни өчендер бүленә, пароход туп-туры Истанбулга чыкмый. Пароход Одессадан киткәндә дә яр буендагы руслар һәм французлар, митинг уздырып, рус гаскәрләренә уңышлар теләп, кайнар нотыклар сөйләп калалар. Биредә дә, пароход туктау белән, шул ук хәл кабатлана. Руслар, болгарлар, очынып-очынып, гаскәрләргә сугышта мәдәт, көч теләп нотыклар сөйлиләр.

Дүртенче августта көндез сәгать унда пароход бугаз эченә керә

Моннан Истанбулга ерак калмый инде. Бугаз ярлары үзенең матурлыгы белән безнең юлчыларны тәмам әсир итә. Бугаз үзе бормалы елга кебек. Пароход, ярга төртелә инде дип уйлаганда борыла да, тагын шундый ук иркен су юлына кереп китә. Ә ике ярда да — биек-биек таулар тезмәсе. Алар ямь-яшел агачлар белән әртелгән, шул таулар түбәсендә зиннәтле дача биналары күренеп китә.

Пароход бугаз эченнән бер сәгать чамасы бара. Ниһаять, ул Истанбул ярына килеп туктый. Мосафирлар бу ят, сәер шәһәргә төшәләр. Багажга тентү ясала, паспортларны теркиләр. Шуннан, сәфәрнең рәсми ягы башкарылгач, каекка утырып, Истанбулдагы Серкаҗи пристанена китәләр. Анда җиткәч, Бабгали урамындагы «Мисрат» кунакханәсенә юнәләләр. Бу йорт Истанбулның иң яхшы кунак йортларыннан санала икән. Шуннан ике бүлмә алып урнашалар.

Әтием, кибетләргә барып, чәйнек, азык-төлек кебек әйберләр алып керә. Истанбулда йөзем өлгергән чак, үзе бик арзан. Безнең халык өчен бу тансык җимешне әтием кочак тутырып алып кайта.

Чәйдән соң яшьләр шәһәр карарга чыгып китәләр. Кая гына карама — урамнар халык белән шыгрым тулы. Һәр кибет, һәр кунакханә алдында эскәмияләр тезелеп тора; халык, дөресрәге ирләр, шул эскәмиядә утыра. Безнең юлчылар янәшәдән узганда алар шым булып калалар, европача киенгән, йөзләрен япмаган әнием белән Гайшә апаны күргәч, күзләрен тозландырып, аларга текәләләр. Төрек хатыннары гадәттә, йөзләрен яшереп, «чаршаф» дип аталган кием кияләр икән.

Әнием, Истанбулга килеп төшү көнен хәтерләп, болай яза:

«Кич Шаһзадә башындагы милләт театрына киттек. Анда хатыннарны кертәләр микән, дип, куркып кына бардык. Керү мөмкин икән. Билетлар алып, ложага урнаштык. Ул көнне «Гыйлемдар паша» исемле тарихи пьеса уйналды. Боларның театрындагы тәртип тә безгә ят тоела. Әүвәл, пәрдә ачылу белән, Истанбул шәһәренең байларыннан берсе (һәм иң һимматлесе диделәр) нотык сөйләде. Сугыш хакында барды сүз. Ул вакыт төрекләр сугыша башламаган иде әле. Ул кеше яхшы гына сүзләр әйткән кебек булды. Без начар аңлыйбыз. Кадыйр тәрҗемә итеп утыра.

Пәрдә төшкән араларда, стаканнар чыкылдатып, малайлар су, печенье, шоколад кебек нәрсәләр сатып йөриләр. Гомумән, төрекнең ире, хатыны булсын, йөрү дигән нәрсә белән артык дус түгел, ялкаулыклары шуннан билгеле, һаман утыруны гына карыйлар. Без исә, куркышып кына булса да, чыгып йөрдек. Театрда бер дә ислам хатыннары юк. Гомумән, анда ирләр белән хатыннар бер вакытта йөрми икән. Әүвәл хатыннар театр, синема кебек урыннарга бөтенләй йөрмәгәннәр. Хәзер, йөрсәләр дә, хатыннар — көндез, ирләр кич йөриләр. Рамазанда тамаша бер көнне ирләр өчен куела, икенче көнне хатыннар өчен икән».

Бишенче август көнен кунаклар ял итеп уздыралар. Алтысында көндез диңгезнең икенче ягына — шәһәрнең «Бәк углы» дип аталган, европалылар яши торган якка чыгалар. Истанбулның ул ягы бөтенләй башка, халкы да бүтән. Анда — Европа рухы.

Шунда бераз тамаша кылып йөргәннән соң, номерга кайтып, ахшам алдыннан әтинең Гали бәк исемле иске танышларына кунак төшәләр. Әнием түбәндәгечә искә ала: «Без Гайшә белән башка бүлмәдә калдык. Көн ифрат эссе. Ерактан җәяүләп килеп тәмам эсселәнгәнбез. Тирләребезне сөртә-сөртә, бер-беребезгә карашып утырабыз. Мин, эчемнән генә, хуҗалар белән ни турыда сөйләшергә икән, дип уйлыйм. Сүз табылыр иде дә, сөйләшә белмибез. Телләре һич китаптагы кебек түгел. Артык кызу сөйләшәләр.

Бераздан, яныбызга европача киенгән бер ханым кереп, безнең белән күреште. Гали бәкнең кызлары бар, дигән иде Кадыйр. Сез кызы буласызмы, дип сорадым. «Хәер».— диде. Юк дигән сүз. Янә берничә сөаль бирдем. «Хәер»дән башка җавап ала алмадым. Бу ханым Гали

бәк энесенең рәфикасе икән. Бераздан таза бәдәнле, яшь, бик матур ханым кереп күреште. Анысы үзе сүз башлады. Без әйткәнне яхшы аңлый, үзе дә шактый аңлатып сөйли. Бу ханым Зәкия атлы икән, татар кызы, Гали бәкнең хатыны.

Менә бер заман ифтар* өчен туп ата башладылар. Безне өстәл янына чакырдылар. Без кайдан башларга белмичә торабыз. Чөнки табында бик күп савытларга өләшенгән вареньедән, балдан һәм күмәчтән башка бер ни юк. Безнең тик торганны күргәч, ханым тиз генә вареньене күмәчкә манып ашый башлады. Аннан су эчтек. Бераздан аш килде.

Мунча якканнар икән. Гайшә белән мунчага кердек. Мунчалары һич безнекенә охшамый. Кечкенә генә бер бүлмә. Шуның бер җирендә таш казан, шунда ике кран, аларда — җылы һәм салкын су. Мунчаның бер почмагында тимер мич, анысы мунчаны җылыту өчен.

Мунча кереп чыккач, чәй эчтек. Бик арылган иде, яту белән йокыга кителгән.

Икенче көнне музейханәгә бардык. Андагы экспонатларны карыйкарый арып беттек. Музейга кергәч тә — тарихи шәхесләрнең табутлары. Искәндәр Кәбирнең табуты һәм башкалар. Солтан Хәмитнең егерме биш еллык юбилеен котлап җибәргән кыйммәтле нәрсәләр. Алтын, җәүһәр, якут, алмаз, зөбәрҗәт. Кыскасы, андагы әйберләрне язып та, карап та бетерерлек түгел. Хәмитнең өстәл-урындыклары алтын-көмештән ясалган. Өстәл аяклары урынына хәнҗәр, револьвер куелган.

Без музейга иртәнге унберДә киткән идек, бары кичке биштә генә кунакханәгә кайтып егылдык. Бераз ял иткәч, ашап, синемага бардык. Сигезенче августны шәһәрдә йөреп үткәрдек. Тугызында Истанбул бугазының Мәрмәрә диңгезенә чыга торган тарафындагы Хәйдәр паша пристанена киттек. Ул якта Кадыйрның электә бергә укыган иптәше Галимҗан Фәйрушин тора. Шуның квартирына барып, пилмән пешереп ашадык. Көнне шунда уздырып, кичен генә кайттык. Пароходтан төшкәч, байтак араны җәяү уздык. Тауга мендек. Алдыбызда ифрат гүзәл манзара ачылды. Бер тарафта Кара диңгез, икенче якта ямь-яшел болын һәм урман. Иртәгесен гает көне иде. Без бәйрәмне бугаз эчендә уздырдык. Бугаз буендагы урамга чыксак, һәммә халык түшләренә аййолдыз формасындагы чәчәкләр кадаган. Төрек ханымнары флот файдасына чәчәк сатып йөриләр.

Сәгать унберДә, гает котлап, Гали бәкләргә бардык. Уникесендә һава бераз бозыла төште. Яңгыр булырдай сыман. Шулай да без Мәрмәрәдән Бөек атага барырга булдык. Галимҗан һәм без, бишәүләп, пароходка утырдык. Бугазда байтак баргач, Мәрмәрәгә килеп чыктык. Менә без Бөек атада. Пароходтан төшүгә, коеп яңгыр ява башлады. Без тиз генә пристаньдәге ресторанга кереп аш ашадык. Бераз яңгыр да вагайды, кояш та күк йөзен яктыртты. Без, ат яллап, атауны әйләнә киттек.

Юл нәкъ диңгез кырыеннан үтә. Ифрат матур манзара. Юлыбызда ишәккә йә качырга атланган балалар очрый. Бер ягыбызда диңгез, икенчесендә яшеллеккә күмелгән үрләр. Күңелле. Без, ниһаять, бөек таш тавына барып җиттек. Аттан төшеп, тауга менәбез. Аннан төшкәч, парк сыман урынның павильонына кереп, каһвә, минераль су эчтек. Чыгып даган атындык.

Унөчен без җыену белән уздырдык. Ундүртендә, пәнҗешәмбе көнне өйләдән соң, сәгать өчтә, калачак әйберләрне Гали бәкләргә илтеп, хаҗ сәфәренә дип пароходка төштек».

Әниемнең Истанбул турындагы беренче тойгылары бу...

Һич уйламастан килеп чыкты бу хәл. Мин, гадәттәгечә, иртәнге якта ук Наркоматка барган идем. Мине күрү белән, Агриппина Евграфовна иркен сулап җибәрде:

*Ифтар — дини уразада авыз ачу.

— Шулай вакытлы килүегез ничек әйбәт булды!
Мин аңламыйчарак калдым.
— Хәзер үк монда кирәгез. Комиссия членнарының сезне күрәсе килә.
Югалып калдым. Чөнки әле бу минутта ук мондый очрашуга әзер түгел идем.
Агриппина Евграфовна, өстәл артыннан чыгып, беләгемнән тотты:
— Керегез,— диде, ишеккә кадәр озатып, ишекне ачып, мине алга этте. Тез буыннарымның калтыравын тойдым. Тамак төбенә ниндидер төер тыгылды. Бераздан башыма кайнар кан йөгергәнен сиздем. Ләкин керми булмый, минем башка чарам юк. Язмышым хәл кылыначак җиргә керү өчен, беткән баш бетсә бетсен, дигән мәгълүм кагыйдә буенча алга атладым. Башта күзгә ул-бу ачык кына чалынмады. Аннан ишек каршындагы өстәл артында утырган тузган чәчле бер ирне күреп алдым. Стена буендагы кәнәфиләрдә утырган кешеләр дә күзгә чалынды. Тузган чәчле кеше олырак яшьтә, калын мыеклы, таушала төшкән пинҗәктән. Сул як стена буендагы кәнәфидә утырганы яшь, чибәр һәм бик фырт киенгән. Уң як стена буендагысы исә кысасыз күзлекле, тупас йөзле, чал чәчен кистергән зәңгәр күлмәкле бер хатын.
Кыюсыз гына алга атладым. Бүлмә уртасында тукталып, үземә дә ят тоелган карлыккан бер тавыш белән әйттем:
— Мин килдем,— дидем.
Өстәл артында утырган мыеклы агайның йөзеннән аптырауга охшаш бер чалым үтте.
— Сез кем соң?— диде ул.
— Мин — Рәсүлев.
Апа телгә килде:
— Бу бит теге Казаннан килгән егет. Минем якташ.— Ул миңа карап куйды.— Шулаймы?
— Шулай. Мин Казаннан, — дидем.
— Фамилиягезне кабат әйтегез, — диде мыеклы. Мин җавап кайтардым.
— Исемегез.
— Атилла.
Комиссия членнары, барысы да бердән күтәрелеп, миңа карап алдылар.
— О, әйтерең бармы! Алдыбызда Шекспир Отеллосы басып тора!
— Отелло түгел, Атилла минем исемем.
Бүлмәдәгеләрнең яшьрәге сүзгә кушылды:
— Бу Отелло түгел, бу һуннарның рәхимсез императоры Атилла, — дип аңлатты.
Чыннан да, безнең якта сирәк очрый торган, үз гомеремдә миңа байтак уңайсызлыклар китергән исемем бу юлы да игътибар үзәгендә калды.
Мыеклы абзый, бәхеткә каршы, минем исемем белән артык булашмады, документларымны актарырга кереште.
Сул як кәнәфидә утыручы яшь, чибәр абый әйтте:
— Мин кичә аның документлары белән таныштым, — диде. — Минем фикерем әзер.
— Соңыннан, соңыннан, — диде мыеклы, ишарә бармагын гына селкеп. Ул, тәгаен, комиссиянең рәисе иде, чөнки апа да, абый да аның алдында үзләрен кечелекле бер кыяфәттә тоталар.
— Йә, эш нидә соң? — диде мыеклы, бераз казынганнан соң. — Ни өчен сине институттан кудылар?
Мин үтенечемдә бу сорауга җавапны бик ачык һәм тулы итеп язган идем, агайның моны белмәгәндәй кылануы миңа сәер тоелды.
— Чыгардылар инде, — дип мыгырдандым, — чыгышыңны яшергәнсең, диләр.

Апа кырку гына сорап куйды:

— Ярыймыни инде шулай чыгышны яшерергә, якташ? Синең этиең кем, кулак идеме? Илдә сыйнфый көрәшнең кызган чагы. Алар безнең җитәкчеләргә аталар. Ә син...

Минем күкрәк авызына ниндидер салкын, чирканчык нәрсә йөгергәндәй булды, тыным кысылды. «Болай булгач, беттем, беттем», — дип уйладым. Эш мондый юнәлеш алса, хәерле фал түгел бу.

— Әти мулла иде. Әгәр яшермәсәм, мине институтка алмаслар иде, — дидем мин, чарасызлыктан кыюлана төшеп. Бу инде, саламга тотынып, батып үлүдән котылырга теләү кебегрәк килеп чыкты.

Мыеклы агай сораулы карашын комиссия әгъзалары аша уздырды да, тегеләр берни әйтмәгәч, кинәт миңа:

— Сезгә китәргә мөмкин, — диде. — Сезне күрдек, комиссия карарын көтегез.

Бу очрашуның шулай тиз бетүен, комиссия әгъзаларының миңа ничектер ышанычсыз каравын, кырыс сөйләшүләрен үземчә бик начарга юрадым. Күңелемне тирәнгә кереп энәдәй авырттырган, җанымны ашаган, инде институт миңа насыйп түгел икән, дигән шик бу очрашудан соң ныгыды гына, әлеге энә тагы да эчкәрәк керде.

Урамга атылып чыктым. Үземне ничек тә булса тынычландырырга тырышам. Әйе, нигә әле миңа да гади бер эшче, гади бер токарь булып эшләмәскә!? Мин ул һөнәрне беләм, минем разряд алтынчы. Йөз меңнәр шулай яши ич. Минем кай җирем аларныкыннан артык?!

Мине уйларым тагын ерак-еракларга, балачак хатирәләренә алып китә.

...Менә мин Арчада. Һәркөн иртә белән, балчык изеп, Арчаның көнчыгышындагы Габдрахман абыйлар квартирыннан көнбатыштагы үргә урнашкан мәктәпкә менәм. Яңа танышлар, яңа белешләр, ләкин Троицкидагы кебек монда җан дуслар юк минем. Өйдә без бик ишле. Габдрахман абый, Сәүдә апа, аларның ике улы, Шәүкәт белән Рафаэль, дәү әни, өй хезмәтчесе Гаҗби апа, мин һәм Лалә апа. Лалә апа Габдрахман абый канаты астына миннән соң килеп сыенды. Аны да Каргалыда мәктәбеннән сөргән булганнар.

Әйе, без бик ишле. Тормыш артык матавык. Җитмәсә, көндезләрен генә түгел, төннәрен дә тынычлык юк. Габдрахман абый, Сәүдә апа, Рафаэль түр як бүлмәнең идәнендә йоклыйлар. Шәүкәт белән дәү әни эчке ян бүлмәдә, калганнарыбыз алгы бүлмәнең идәнендә тезелешеп ятабыз.

Идәндә йоклау рәхәт, мин моны бик күптән беләм, Троицкида да тәгәрәп идәндә йоклый идем. Ләкин монда бөтенләй башкача шул. Кандала үзәккә үтә. Алар мәрхәмәтсез канэчкечләр: инде изрәп йокыга киттем дигәндә генә сине таларга керешәләр, ирексездән уянып, шуларга каршы чын мәгънәсендә канлы сугыш башлыйсың. Инде яңадан ятып йокыга китим дисәң, түр яктан бала елаган тавыш ишетелә. Бу Рафаэль шулай елый. Күрәсең, кандала талавы аны шулай елатып уята. Ул бөтен көченә үкерә. Рафаэль елый башласа, аны тиз генә юату мөмкин эш түгел. Өй эчендә барлык җан иясе уяна. Габдрахман абый, Сәүдә апа, чиратлашып, башта иркәләп, соңыннан инде, тәкатьсез калып, каты ачуланып аны юатырга тырышалар. Ахырда, баланың артык үксерлек хәле калмагач, ул әкрен генә тына, алҗып йокыга тала, өй эчен рәхәт бер тынлык баса.

Бу хәл һәр көнне шулай кабатлана. Без, йокыларыбыз туймаган килеш, иртә белән ашык-пошык чәй эчәбез дә мәктәпкә йөгерәбез.

Ашау-эчү яклары такы-токы. Габдрахман абый — район мәгариф бүлегендә инспектор. Сәүдә апа мәктәптә математика фәнен укыта. Күрәсең, эш хакы да җитәрлек түгел. Бәлки, элекке вакытлар булса, ул җитәр дә иде. Әмма хәзер заманалар үзгәргән, азык-төлек бәяләре әллә ничә тапкыр арткан гына түгел, ашау әйберсе хәзер зур авырлык белән

табыла. Иртәнге чәйдә икмәккә май ягып ашыйбыз. Майны базар көннәрендә Сәүдә апа алып кайта. Ул бик кыйммәт, аның кыйммәтләнүен үзара сөйләшкән хуҗалар безгә дә эледән-әле бик үтемле рәвештә аңлаталар. Майны икмәккә якканда бәрәкәтләрәк булсын өчен нишләргә кирәклеген Габдрахман абый, мөмкин булган барлык чаралардан файдаланып, безгә дә күрсәтергә тырыша. Ул, әлбәттә, бер сүз дә әйтми, ләкин барыбыз да күрерлек итеп, икмәк телемен гадәттәгедән өскәрәк күтәреп, майны икмәк телеменә үтәли күренмәле элпә калынлыгында гына итеп яга.

Мин өйне, әниләрне сагынам, монда мин артык сынык, ләкин шулай да канәгать, чөнки мин укыйм, белем алам.

Тик бу бердәнбер юанычым биредә дә озакка бармады. Көннәрдән бер көнне мине, мәктәпнең канцеляриясенә чакырдылар да, чыгышымны яшергән өчен мәктәптән сөрделәр. Ә мин өйгә кайтканда өйдә дәү әнием янында Лалә апа да елап утыра иде. Аны да ул укыган татар мәктәбеннән куып чыгарганнар. Дәү әнинең, ачынып, безнең башларыбыздан сыйпый-сыйпый сыкранып, бу сабыйларның ни гаебе бар инде, дип рәнҗегәне әле дә минем колак төбемдә яңгырап тора. Дәү әниемнең күзләре бик начар күрә иде инде. Ул кармаланып кына йөри. Бездән битәр үзе кызганыч.

Көфер сүз булмасын, бу уй минем башыма бик күп еллар узганнан соң гына килде. Тәгаен безне фаш итүче Сәүдә апа үзе булгандыр. Мин аның хәлен дә аңлыйм. Ишле гаиләне авыр, кытлык заманда карау, тәрбияләү коточкыч бер нәрсә бит. Һәм Сәүдә апа, болай да Габдрахман абыйга карата артык көчле мәхәббәт тойгылары кичермичә генә яшәгән хатын, иренең килмешәк туганнарыннан шулай закон юлы белән котылырга булгандыр. Мин Сәүдә апаны да гаепләмим...

Габдрахман абый, өйгә озатыр алдыннан, миңа бик матур итек тектереп бирде. Аның куныч очларында шнурлары да бар. Нинди мөнәсәбәт белән Габдрахман абый миңа итек тектергәндер, белмим. Юкса, алай ташып торган акчалары да юк иң. Әйе, белер хәл юк, ихтимал Габдрахман абый үзенең бу бүләге белән күңелен тынычландырырга теләгәндер.

Шулай итеп, мин көннәрдән бер көнне вагонның өске киштәсендә туган шәһәремә китеп бардым. Мин утырган вагонда безнең якка кайтучы бер татар агъзые бар иде. Габдрахман абый мине шуңа тапшырды.

Мин шулай өйгә кайтам. Анда ниләр көтәдер, анысын белмим, тик мин барыбер шат, чөнки өйгә, әнием янына, дусларым янына кайтам.

Мин Троицкига ком бураннары дулаган, әле кар төшмәгән, ләкин инде шактый суыткан бер вакытта кайтып төштем. Өйдә әнием белән Суфия апа гына яши иде. Иптәш булыр, бераз килере дә булыр дип, аскы катның яртысына һәм өстәге ян як бүлмәгә әни квартирантлар керткән. Аскы катның икенче яртысында хәзер яһүдләр колбаса ясыйлар. Мин белгән муллык, көр күңеллелек юк хәзер безнең өйдә. Суфия апа иртә таңнан базарга әйбер сатарга чыгып китә. Кайчагында кибетләрдә ситсы-фәлән бирсәләр, ул төнге өчтән чиратка чыгып баса. Әни исә, берсе өстенә икенчесе төшеп торган налогларны киметеп булмасмы дип, учреждениеләр бусагасын таптап йөри. Өске кат бүлмәдә Нәфисә апа белән аның улы, минем дус Рәфкать яши. Мин күбрәк Рәфкать белән булам. Эш юк. Көндезләрен Рәфкать укуда. Мин ишегалдында үзем генә йөрим. Сарайга керәм, анда бик күп китаплар өеме. Аларның байтагы Шакир абыйдан калган китаплар. Ниндие генә юк аның! Пушкин да, Шекспир да бар, барысы да русча. Мин эш юктан шуларны актарам. Кайчак кызыксынып укып та китәм. Хәзер инде бераз русча сукалыйм. Инде укып арысам, түбәгә менеп китәм. Безнең өйнең коймалары кирпеч, өсте калайлы. Капкадан ат абзарына кадәр койма буйлап узам, аннан кире кайтам. Ләкин шулай да миңа күңелсез. Бөтен дуслар укуда, мин генә, кем әйтмешли, б... тибеп, көн уздырам.

Күрәсең, хәлемне аңлап, әнинең дә йөрәге әрнегән булса кирәк. Ул, тормыш никадәр авыр булса да, соңгы мөмкинлекләрен сыгып дигәндәй, мине хосусый укытучыга йөртә башлады. Бу Касаткин фамилияле рус укытучысы Кала якта яши. Аның юан, ләкин әрсез, эшчән һәм чибәр генә хатыны, битен бетчә баскан, буйга җиткән балдызы бар. Аларның өенә барып керү белән борынга сарымсак, суган исе килеп бәрелә. Петр Григорьевичның соры күзләре һәрвакыт елмаеп тора. Үзе ул буйчан, тыныч һәм ягымлы, утыз-утыз биш яшьләрендә. Мин аларга барып керү белән, ул мине әчке бүлмәгә уздыра һәм эшләгән дәресләремне карый башлый, шуннан соң гына яңа темага керешә.

Ул әйбәт укытучы иде, ләкин еш кына үзенең нindидер бетмәс-төкәнмәс хуҗалык эшләре белән мәшгуль. Шуңа күрә күпвакыт минем белән утыра алмый, мин еш кына, аларга бару белән, кире әйләнеп кайтам. Шулай да укыйм, шулай да тик ятмыйм.

Мин артык уйчан, хәтта хыялый булып киттем. Күңелемнән ниндидер героик вакыйгалар уйлап чыгарам, күңелдән гаҗәеп әсәрләр язам, хәтта шулар белән җенләнеп, керәсе капкаларымны узып китәм. Үзем уйлап чыгарган вакыйгалар чылбырын минем хәзер кәгазьгә күчерәсем килә. Әйе, минем язучы буласым килә. Бу омтылыш бөтен барлыгымны били, миңа башка берни дә кирәкми. Менә шул көннәрдә мин үземнең киләчәк тормышымны бизәячәк, авыр көннәремне җиңеләйтәчәк, үземә юаныч биреп торачак, рәхәтле һәм михнәтле язучылык чире белән авырый башладым.

Көннәрдән бер көнне роман язарга тотындым. Аның исеме — «Таулар итәгендә», ул ифрат кызыклы, партизаннар турында булачак иде. Әмма, әсәр башланып кына калды...

Яз айлары якынлашып килгәндә безнең башка тагын бер тукмак килеп төште. Мәскәүдә татар телендә чыга торган «Фән һәм дин» журналында әтием турында, кичә мулла булып мөнбәрдән вәгазь сөйләгән кеше, бүген совет укытучысы исемен пычратып, сарык тиресе ябынган бүредәй, Урта Азиянең Сорхандәрья өлкәсендә эшләп ята, дип язылган мәкалә басылып чыкты. Мәкаләнең авторы нәмәгълүм иде. Ләкин аның вакытында безнең белән аралашып, еш кына бездә кунак булган бер укытучы икәнлеген әни тиз чамалады. Әлбәттә, мондый сыйнфый сизгерлек күрсәткән мәкаләнең нәтиҗәсез калуы мөмкин түгел иде ул заманда. Һәм, чыннан да, март азакларында укытучылыктан сөрелгән әти, сары төстәге зур фанер чемоданын өстерәп, яңадан өйгә кайтып керде.

Безнең котылгысыз хәл авыр фаҗига төсен ала башлады. Һәм, бик ихтимал, әгәр әниемнең батыр һәм оптимистик табигате безгә рух бирмәсә, кем белә, безнең тормыш тагын да авыраячак иде.

Яшәгән өебезнең конфискацияләнәчәге ачык күренә иде инде. Бу хәл чынбарлыкка әверелгәнче, без хәерхаһ кешеләр киңәше буенча, бабайның бу мирасын сатып, үзебезнең ата-баба, туган-тумача, яшәгән Татарстаныбызга китәргә булдык.

Өйне бер казах баена бик арзан гына бәягә саттылар. Өй акчасының бер өлешен бай үзенең җәйләвендә безне кымыз, ит-май белән тәэмин итеп түләргә булды, икенче өлешен исә акчалата бирде.

Авыр идеме миңа? Әлбәттә, туган шәһәремнән, дусларымнан, мохитемнең бер кисәге булган, кирпеч коймалы, асты таш, өсте агач яшел түбәле өйдә, без спектакльләр куйган ике катлы биек сарайдан аерылу авыр иде. Ләкин киләчәккә булган өмет дигән нәрсә дә бар бит әле дөньяда! Әйдә, Казанга икән — Казанга!

Менә безнең гаилә Казанда. Без, вакытлыча, яшәр урын табылганчы, әтиемнең бертуган энесе Сабур абыйларга урнаштык. Ул инде күптән Казанда яши, хосусый адвокатлар курсын тәмамлаган кеше. Аларның квартиры Тукай белән Татарстан урамнары чатындагы китек почмаклы яшел йортта. Сабур абыйның хатыны Зәйнәп апа — Казан

кызы, ул күптән түгел генә медицина институтын тәмамлап чыккан. Зәйнәп апа Сабур абыйның өченче хатыны инде. Беренчесе — ап-ак йөзле, юанрак булса да бик чибәр, нindider Ташкент баеның кызы иде. Мин ул Фатыйма апаны хәтерлим. Аның белән Сабур абый аерылышкан. Икенчесен Сабур абый Казанга килгәч алган. Анысы белән дә бергә озак яши алмаганнар. Хәзер исә ул, әле күптән түгел генә, өченче хатынга өйләнгән.

Әти белән әни иртәдән кичкә кадәр фатир, эш эзләп йөгерәләр. Мин күпвакыт өйдә ялгызым гына утырам. Еш кына Сабур абый белән Зәйнәп апа да ни өчендер өйдә булалар. Аларның миндә эшләре юк. Диванга менеп кунаклыйлар да, өзлексез чапыр-чопыр үбешәләр. Миңа уңайсыз. Мин өй хезмәтчесе — марҗа кызы янына, алгы бүлмәгә чыгып китәм.

Без Сабур абыйларда озак яшәмәдек. Эзли торгач, әниләр Яңа бистә белән Иске бистә арасындагы кыска бер тыкрыктан бүлмә таптылар. Тыкрык рәсми рәвештә Яшьләр урамы дип атала, халык аны «Әтәмбит урамы» дип йөртә. Безнең фатир ике катлы, картлыктан чалшайган агач өйнең өске катында. Безнең бүлмә белән янәшәдә генә хуҗабикә үзе ике баласы белән яши. Әти дә, әни дә үзләренең төп һөнәрләре — укытучылык буенча эш тапмадылар. Табу гына түгел, табылмаячагына бик тиз ышандылар. Мәсьәлә, якын дус-иш, туган-тумача киңәше буенча, болай хәл ителде: әти белән әни тиз арада загска барып аерылышу кәгазе алырга тиешләр. Бу әнигә эшкә урнашу мөмкинлеге тудырачак. Ә әти исә укытучылык турында хыяллана да алмый, аңа бердәнбер юл — сәясәткә катышы булмаган нинди дә булса белгечлек буенча китү.

Озак та үтмәде, әни Казаннан кырык чакрымнар чамасы арадагы Шәле исемле авылның башлангыч мәктәбенә укытучы итеп билгеләнде, ә әти хисапчылар курсына кереп укый башлады.

Менә без хәзер Казан кешеләре. Без әтием белән икәү калҗайган иҙәнле, шыксыз бер бүлмәдә яшибез. Мин Пләтән урамындагы рус мәктәбенең бишенче классында укыйм. Әлегә ул-бу юк, мәктәпкә шома гына уздым.

Әкренләп мин тирә-юнемдәге кешеләр белән танышам. Такта белән генә аерылган кечкенә бүлмәдә, әйткәнемчә, хуҗабикә Мәгъфируз апа яши. Тәбәнәк буйлы, кәкре аяклы, озынча йөзле, моңлы зур күзле олы яшьтәге хатын. Ул ифрат та сөйләшергә ярата. Кайчагында, без әти белән үзара һич аңа катнашы булмаган сүз алып барганда да, ул шул стена аша безнең сүзгә катнашып безне аптырашта калдыра. Ул бик сәер сүзләр әйтеп куя. Мин аны усаллыкта гаепләмәс идем. Аның салынкы аскы иренле, озын борынлы йөзендә, кыек сызылган кашлы моңсу күзләрендә һәрвакыт тормышыннан ризасызлык, рәнҗү билгеләре чагыла. Ире аның күптән үлгән булса кирәк. Олы улын асрамага якын туганнарына биргән, ә калган ике баласы үз янында. Балаларның олысы Әминә исемле кыз, минем яшьләрдә булыр, миннән кайтыш кече улы Әдһәм исемле. Башта мин шулар белән таныштым, ләкин ни өчендер без үз булып китә алмадык. Күрәсең, бер-беребезгә артык ят булып тоелганбыздыр. Аларның «җе»ләштереп сөйләшүләре дә, һәр җөмләгә мин аңламый торган ниндидер сүзләр кыстырып җибәрүләре дә миңа бик сәер һәм ят тоела. Мәсәлән, Әдһәм миңа «малай» дип дәшә. Малай дип безнең якта бары ялчыга гына әйтәләр иде. Ә биредә улга да малай диләр, хәтта кыз кешегә дә кайчак малай дип дәшәләр. Гаҗәп икән бу Казан теле, бөтенләй татарча түгел. Болар бездәге бакайны да кузна дип кенә атыйлар... Кыскасы, миңа Казан татарларының теле мин белгән татарның әдәби, хәтта көнкүреш теленнән шактый ерак, сәер бер тел булып тоелды.

Без биредәге күршеләр белән Троцкидагы кебек якыная алмадык. Ничектер Казан татары, гомумән, кешене туганнарча эчкерсез якын итә белми торган, һәркемгә шикләнеп караучан кеше булып тоелды миңа. Мондагы кешеләр, үзләренә файдасы тиярдәй булса гына, кешегә ярдәм кулы сузалардыр дигән фикер туа иде миндә.

Мәктәптәге сабакташлар да мин юраганча булып чыкмады. Минем әле эшче балалары арасында булганым юк иде. Безнең мәктәптә исә күпчелеге шундыйлар укый. Рус малайлары, рус кызлары. Татар берән-сәрән генә. Арада бер класста инде икенче, хәтта өченче елын утыручылар да бар. Ул малайлар аерата азгын. Башларындагы елтыр козыреклы капитанкаларын алар кайчак дәрестә дә салмыйча утыралар. Класс тынып укытучыны тыңлаганда, кыргый тавышлар чыгарып, дәресне бүлдерәләр. Ә инде андый мөмкинлек булмаса, үзләре бик игътибар белән дәрес тыңлаган булып, парта астына кадап куйган пәкеләрен дырылдатып утыралар.

Андый ата хулиганнар класста икәү иде. Берсе Веселов, икенчесе Абрамов. Веселовы бервакыт яшь кенә укытучыны, класска килеп керүгә, өстенә бүрек ыргытып елатты. Кыскасы, минем өчен артык сәер иде мондагы хәлләр.

Минем тагын менә нәрсәгә исем китте. Мондагы руслар татарга карата аерата үчлекле. Минем туган шәһәремдә руслардан биредәге кадәр хурлау, мыскыллау сүзләре ишеткәнем булмады. Казанга килгәч, беренче тапкыр үземнең «гололобый», «чаплашка» икәнлегемне белдем. Соңыннан аңладым, бу минем халкымның сыйфаты, имеш: ул такыр башлы, түбәтәй киеп йөри, янәсе...

Әмма, бәхеткә каршы, класста Веселов, Абрамов кебек хулиганнар гына укымый иде. Анда Миша Алатский, Вова Киселев, Митя Сальяшинов кебекләр дә, татар баласы Равил Гыйлаҗетдиневләр дә бар иде. Без шушы биш малай бергәрәк була башладык. Мин Миша Алатский белән аерата якынайдым. Ул җыйнак кына гәүдәле, матур зур зәңгәр күзле, көр тенор тавышлы, җырга һәвәс егет. Вова Киселев исә киресенчә озын буйлы, зур башлы, үзе бик аз көлсә дә, юморга бай һәм кешегә яхшылык эшли белә торган үсмер.

Митя Сальяшинов турында мин вакыты җиткәч тулырак тукталырмын әле. Чөнки ул минем тормышымда үзенең изгелеге белән истә калды.

Равил зур башлы, базык гәүдәле, ялтыр битле, калынрак иренле, шулай ук дуслыкның кадерен белә торган малай. Әтисе аның Бондюг эшчесе, алай гына да түгел, Бондюгта гражданнар сугышы чорында кызыл партизан булып йөргән кеше. Хәзер исә Казан клиникаларының директоры. Ләкин Равил әтисе белән әз генә дә горурланмый, киресенчә, аңардан еш кына зарлана. Чөнки әтисе исереп дулый башласа, боларны наган чыгарып куркыта икән.

Алатскийның әтисе вак сәүдәгәр булган, ахры; Мишаның сөйләвенә караганда, алар элек Кокушкинода яшәгәннәр. Хәтеремдә, Мишага әтисе үзенең Ленин белән бергә уйнап йөргән чакларын сөйләгән. Миша Алатский җырчы булырга хыялланды. Ләкин нидер җитмәде минем ул дуска, җырчы була алмады. Инженер булып, каядыр Ленинград тирәсендә сугыштан соң юкка чыкты.

Вова Киселевның язмышы фаҗига белән тәмамланды. Ул үсеп, тәмам җитлеккән егет булгач, Казан елгасында нindидер бер биеклектән суга сикергәндә, абайламыйча, очы суга күмелгән субай өстенә аркасы белән килеп төшкән. Умыртка сөяге урталай сынып, ике көн буена коточкыч газаплар кичергәч вафат була Вова.

Безнең язмышлар төрле булды. Ләкин безнең хәзергә киләчәк турында гамь чиккәнебез юк; без, биш дус, булдыра алганча тырышып укыйбыз. Мин әти белән «Әтәмбит» тыкрыгында торам. Әти аш-су әзерли, хисапчы булырга укый, мин дә укыйм, скрипкада

уйныйм, мандолина чиртәм, рәсем ясыйм. Әйе, бервакыт мин рәсем ясауга аерата нык күңел бирә башладым. Янәсе, «Чаян» журналында басылмасмы рәсемнәрем. Акварель белән ясыйм, шигырьләр иҗат итәм, ул да түгел хикәя, очерк язарга керешәм. Хәзер инде миңа Троицкидагы кебек урамда шайтан чабарга туры килми. Шулай да минем таныш-белешләр, дус-ишләр даирәсе киңәя бара. Мин инде хәзер, мәктәп коридорларыннан һәм үзебезнең тар тыкрыктан чыгып, Әҗем мәчете бизәгән Сабынчы урамына да җиттем. Анда да дуслар таптым. Аларның берсе Наил исемле, безнең мәктәптә укый. Мин аның белән, укудан кайтышлый, бик очраклы рәвештә таныштым. Наил аша Зиннәт, Гомәр, Фәтхерахман исемле малайлар белән дуслаштым. Хәзер инде мин буш вакытларда Наилләргә дә кергәлим. Аның әнисе Яңа бистә мәктәбендә укытучы, әтиләре үзләрен моннан берничә ел элек ташлап киткән. Наилнең чибәр генә Зәкия атлы сеңлесе дә бар. Минем яңа дусларның, Наилдән башкалары, уночение мәктәптә укыйлар. Ул — Иске бистә белән Яңа бистә арасындагы татар мәктәбе, ул көннәрдә шактый атаклылардан саналган үрнәк уку йорты. Безнең төп уен хәзер футбол тибү, инде ул булмаса, капка төбендә юкны-барны сөйләшеп гәп сату.

Наилнең кечкенәдән йөрәге авырта. Күрәсең, шуңа күрәдер, ул үзе турында күбрәк кайгыртырга мәҗбүр, әйтергә кирәк, анда иркәлек тә, үзсүзлелек тә юк түгел. Фәтхерахман аның турында: «Ул бик тиз чирли», — ди. Чирли дигән сүз, аныңча, тиз кылтая, үпкәләүчән дигән мәгънәне аңлата. Мин боларны аның ятимлегеннәндер дип уйлыйм. Язмышына карата булган үпкә аның табигатенә күчкән, ахры. Тик минем өчен ул — якын, дус. Ул миңа үзенең кызыксынучанлыгы, техника белән җенләнүе аркасында ошый. Ул — фотограф та, радио сөюче дә. Аның детекторлы радиоалгычы бар. Үзе җыйган. Ул төрле хикмәтле уенчыклар да ясый. Мин тиз арада аның бу һәвәскәрлеге белән кызыксынып киттем. Үзем дә фотоаппарат ясарга керештем.

Бездән якында гына Вахитов заводының клубы бар. Ул да хәзер минем тормышымны бизәүче бер нәрсә булып китте. Агачтан салынган, шыксыз зур клуб бинасында бик әйбәт уку залы бар. Анда нинди генә газета-журналлар юк! Мин бик еш шунда булам. Татар вакытлы матбугатын әнәсеннән җебенә кадәр калдырмый укып барам. Рус журналлары белән дә кызыксынам. Минем өчен «Крокодил», «Огонек» журналлары аерата кызык тоела.

Кеше өчен татлы мәшгулияттән дә яхшырак дәва бар микән? Минем тормыш шактый авыр, миндә — аз канлылык. Еш кына баш әйләнә, тыным кысыла, әмма болар барысы да төрле мавыгулар аркасында онытыла.

Аз канлылык дигәннән, бераздан минем борын бик еш каный башлады. Мин еш кына ләгән өстенә иелеп, сәгатьләр буе дигәндәй, борын канавы беткәнен көтәм. Борынга мамык тыгу файдасыз, кан авызга тула. Ниһаять, бөтенләй хәлсезләнеп, үземнең агач кушеткама авам. Әти кулларымны өскә күтәреп ятарга куша. Шулай күп азапланганнан соң, кан ойый булса кирәк мин алҗып йокыга талам.

Аптырагач, әти мине бер көнне «Чаткы» кинотеатры каршындагы поликлиникага алып барды. Рәхмәт төшсен докторга. Аның озын бер тимерчыбыкны минем борын тишегенә кертеп чыгаруы булды, шуның белән төзәлдем, борыннан башка кан акмас булды.

## 18

Яз азакларында әтием, хосусый хисапчылар курсын тәмамлап, Казанда урнашу мөмкинлеге булмагач, Урта Азиягә, бу юлы Кыргыз-

стан якларына китеп барды. Хәтерем ялгышмаса, без әнием белән ул җәйне Арчада, Габдрахман абыйларда уздырдык. Укулар башланыр алдыннан, әни бик озак эзләгәннән соң, миңа Казанда бер торыр урын да табылды. Аның шартлары: ятак белән генә тәэмин итү түгел, ашату, кирләремне юу, кыскасы, мине карап, тәрбияләп тору.

Хуҗабикәм — Гафифә апа. Төп Казан кешесе. Ул карчыгка борынлы, килешле генә йөзле, иллеләр тирәсендәге бер хатын. Әгәр аның күз кабаклары һәрвакыт кызарып тормаса, аны чибәр дип әйтергә дә булыр иде. Гафифә апаның ире — хуҗабикәдәй зифа түгел, киресенчә, йомры гәүдәле, кыска гына калдырып алдырган сакал-мыеклы, күбрәк утырып торырга яратучан, бөтенләй сөйләшми торган диярлек авыру карт. Бу абзыйның башы өзлексез кычыта булса кирәк, чөнки ул һәрвакыт, кеше-кара күрмәгәндә, түбәтәен салып, тәмләп-тәмләп, теш суыра-суыра, кетер-кетер башын кашырга тотына.

Гафифә апаның ике кызы бар. Әмма төп гаиләдә кечесе — Нәҗия атлысы гына яши; олысы, чалыш авызлысы, якын туганнарында тора булса кирәк. Яшьләребез бер чама булса да, Нәҗия минем белән бөтенләй сөйләшми, әллә артык оялчан, әллә шундый тәкәббер. Хәер, үзем дә аның алдында бик ачылырга теләмим. Гомумән, мин хәзер ни өчендер кызлардан читләшәм, алардан качам. Бу — минем егет була башлавым билгеседер инде.

Әнием мине Гафифә апаларда ялгызымны калдырды да, беренче сентябрьгә кадәр үк Шәлегә китеп барды. Моңарчы, әтием янымда, иптәшләрем капка төбендә генә булганда, минем күңел тыныч, артык рәнҗеме иде. Әле чит кешеләр арасында ялгызым гына калгач, миңа түзалмаслык ямансу булып китте. Җитмәсә, беренче көннәрдән үк мин бу өйдә ашау-эчүнең такы-токы булуын, әтиемнең тәмле итеп, сарык итен бик вак турап пешергән өреле ашларыннан мәхрүм икәнлегемне тойдым. Икмәкне, шикәр комын карточка белән алам, үзем тотам, башка продуктны Гафифә апа ала. Шулай сөйләшенгән. Икмәге дә көненә дүрт йөз грамм гына бит әле аның, ә мин инде хәзер ай үсәсен көн үсәм.

Минем ятак зал якта, ширма белән бүленгән урында, алгы бүлмәдә хуҗалар йоклый. Көннәрдән бер көнне иртән торып ширманы ачсам, егылып китә яздым, ни күрим, идән уртасында мәет ята. Шушы көннәрдә генә больницага озатылган хуҗа бабай үлеп киткән икән. Гафифә апалар мәетне иртән үк алып кайтып идәнгә сузып салганнар да, үзләре ишекне бикләп чыгып киткәннәр. Мин тизрәк үземнең караватыма түнәм. Ярый, бәхеткә каршы, хуҗалар озак йөрмәде, бер ярты сәгатьтән соң шаулашып кайтып керделәр.

Мин мәктәптән кайтканда хуҗа бабайны алып киткәннәр иде инде. Истә, өйдә бернинди елау-сыктау булмады, бабайны искә алып бер кәлимә сүз әйтүче дә юк иде. Әйтерсең лә гаиләдә бернинди дә үзгәреш булмаган.

Насыйри урамында яшәгән чорымны мин үземнең иң күңелсез көннәрем итеп күз алдыма китерәм. Гафифә апа ялкау бер мещанка булып төсмерләнә. Ул минем турыда, әле канат ярмаган үсмер бала турында кайгыртуны бөтенләй уйламый да иде булса кирәк. Бары аңа гына файда булсын!

Ашаганым — күп вакыт әчи башлаган бәрәңге. Ашау хәлләреннән дә начаррагы — өс-башым. Гафифә апа кирләремне кайнатып юмый, ничек эләкте шулай чылата да киптерә. Тиз арада мине бет басты. Мин кандаланың нәрсә икәнлеген Арчада яшәгәндә белгән идем инде, хәзер миңа бет кебек хәшәрәт белән дә якыннан танышырга туры килде. Минем мәшгулият бирәдә тагын да артты.

Тормышым шулайрак бара. Тик күңел төшерүдә мәгънә юк. Бердәнбер котылу юлы — уку. Бу — минем тормышка карашым, иманым, табигатем.

Әнием, һәрбер мөмкинлектән файдаланып, үзенең Шәлесеннән минем янга кайтып килә. Ләкин аның эшләре авылда да муеннан. Авылда кумәкләшү чоры кызган чак. Әниемне, укытудан тыш, бик күп җәмәгать эшләренә җиккәннәр. Ул — агитатор да, хатын-кызларны оештыручы да, драмтүгәрәк җитәкчесе дә. Әнием юк вакытын бар итеп кайта; әлбәттә, Казанда күп булса бер кич, йә ике кич була. Миңа акча калдыра, авыл күчтәнәчләре белән сыйлый, кием ертыкларын ямый, булдыра алган бөтен ярдәмне күрсәтә. Аның үзенең дә кәефләре шаптан түгел, ул бөтенләй ябыгып беткән. Күренеп тора, аны ниндидер эчке ялкын, дәрт кенә канатландыра, армый-талмый эшләргә мәҗбүр итә.

Әниемнең күчтәнәчләреннән дә бигрәк, минем өчен аның үзен күрү куанычлырак. Мин андый минутларда үземнең кем өчендер бик кадерле, кем тарафыннандыр сөелә торган бер кеше икәнлегемне тоеп калам. Күңелемдә кешелек горурлыгы уяна. Дөрес, әнием киткәч кинәт ниндидер бер авыр бушлык тоям, миңа бик-бик ямансу була, хәтта кайчакта өйалдындагы бәдрәфкә бикләнеп балавыз да сыккалыйм. Ләкин нишләмәк кирәк. Бу ямансулык белән көрәштә минем хәзер сыналган ысулларым бар бит. Укудан буш калган вакытымны әле бу, әле теге эш белән тутырам, шулай онытылам, күңел җәрәхәтләре шулай төзәлә башлый.

Мин әтием белән Яшьләр урамында торганда, әйткәнемчә, музыка белән дә, рәсем белән дә, әдәбият белән дә аз мавыкмадым. Хәтта көйләр дә чыгарып маташтым. Үземчә, алар ярыйсы гына кебек иде. Инде сурәт ясауга килгәндә, «Чаян» журналы өчен карикатуралар ясауны юлга салып җибәрдем. Тик алар басылмады гына.

Мондый бер вакыйга исемдә калган. Үземчә бик уңышлы чыккан берничә рәсемне, болар мотлакан журнал битләрендә басылырга тиеш дип, редакциягә киттем. «Чаян» идарәсе ул вакыт хәзерге Ленин урамындагы Пассаж янындагы йортта иде. Икенче катка менеп, идарәне эзләп таптым. Ишектән кергәч, нәкъ каршы өстәл янында утыручы шагыйрь Һади Такташны күреп, бермәл каушап калдым. Мин аны күрү белән таныдым. Чөнки, еректан гына булса да, аны берничә тапкыр күрү бәхетенә ирешкән кеше идем инде. Ике якка ишелеп төшкән саргылт чәч, бик батырып карый торган зәңгәр күзләр, килешле аксыл йөз.

Ишек янында ук утыручы сакаллы, шешемсерәгәнрәк йөзле абзый, ни өчен керүемне сорашкач, «Әнә», — дип, Такташка төртеп күрсәтте. Мин түрдә торган өстәлгә таба атладым. Шулчак күңелемдәге бик күп кичерешләр арасында оегымның үкчәсе ертык икәнлеге дә искә төшеп куйды. Ул, җитмәсә, минем туфлидән ыржаеп чыгып тора икән бит. Такташ мине күзәтә. Куркуымны җиңәргә тырышып, үзем өчен алла булып тоелган шөһрәтле шагыйрьгә таба атлыйм.

— «Чаянга» материал китердегезме? — диде ул, сүз башлап. Күрәсең, минем каушаудан өнсез калуымны сизенгәндер. Ул ифрат җитди иде. Мин аның зәңгәр күзләрендә әз генә дә мыскыл йә көлү күрмәдем.

— Материал түгел, — дидем мин. — Рәсемнәр китергән идем.

Бу юлы әлеге үтәли карауч зәңгәр күзләрдә мин ниндидер көлемсерәү чаткылары күрдем. Ашыгып, аның алдына рәсемнәр салынган конвертны ташладым.

Такташ конвертны ашыкмыйча гына ачты, миңа тагын бер тапкыр сәер генә итеп күз ташлады. Аннан бик җитди кыяфәттә минем карикатураларыма текәлде. Зур игътибар белән аларның барысын да карап чыккач:

— Мин хәзер сезгә берни дә әйтә алмыйм, — диде. — Рәсемнәрегезне художникка күрсәтермен. Ул аны бәяләр, штрихлары ничек икәнлеген әйтер.

Шуның белән безнең сүз бетте. Хәзер миңа, борылып, атаклы шагыйрьгә тишек оек үкчәсен күрсәтеп, чыгып китәргә туры киләчәк. «Хушыгыз», — дип мыгырдандым да, тирә-юнемә карамастан, башта артым белән чигенеп, аннан борылып, ишеккә таба ашыктым.

Мин ясаган сурәтләр артык шәп булмагандыр, дип уйлыйм; чөнки, бик өметләнеп көтсәм дә, алар журналда басылмады. Бу хәл исә рәсем белән мавыгуыма билгеле бер йогынты ясамый калмагандыр. Хәер, мин рәсем белән бик озак мавыктым, әмма карикатура мине артык кызыксындырмый иде.

Инде музыка өлкәсендәге омтылышларым да озакламый җимерелде. Безнең мәктәпкә композитор Солтан Габәши килде. Аның максаты музыка мәктәбенә сәләтле балалар җыю икән. Теләк белдергән барлык укучыны залга чакырып, Габәши үзе сынау уздыра башлады. Теләүчеләр арасында, әлбәттә, мин дә бар. Рояль янында утыручы композитор янына чыгарга берзаман миңа да чират җитте. Менә мин Солтан абый янында. Габәши тәбәнәгрәк буйлы, соргылт, төксе йөзле кеше. Мин аны шундук таныдым. Без бит әнием белән кайчандыр Казанга килгәндә җырчы Әлмөхәммәдев һәм Габәши белән бер очрашкан идек. Әйе, мин Солтан абыйны таныдым, ләкин ул мине таныймы соң? Юк-юк, танымады. Таныган кеше үз янына килеп баскан балага шундый гамьсез, хәтта, әйтер идем, илтифатсыз караш ташлыймыни? Ә мин дулкынланам. Минем колакка берни дә ишетелми.

— Йә, кабатла әле шуны, — ди Габәши. Бармагы белән рояль тактасына суккалый. Мин, нишләргә икәнен дә аңламыйча, аңа текәләм.

— Йә-йә, — ди композитор. Ниһаять, миңа нәрсәдер барып җитә, мин аны кабатларга тырышам. Тик аныңча барып чыкмый. Әйе, Габәши үзе дә әйтә: «Бармый», — ди. Һәм шуның белән минем музыка мәктәбендә уку турында хыялларым гөрселдәп җимерелә.

Әйдә, шулай булсын соң! Аңа карап мин скрипкамны ташламыйм! Әйе, музыка мәктәбенә үтмәсәм дә, барыбер скрипкамны буш вакытларда чалам. Уйнап арысам, шигырьләр, хикәяләр язам. Бер хикәямнең Мәскәүдә чыга торган балалар журналы «Октябрь баласы»нда басылу вакыйгасын һич онытасым юк. Аңарчы да газета-журналларга хикәя, очерклар җибәреп караганым бар иде. Мәсәлән, узган җәйне — ягъни егерме тугызынчы елны — Германия яшьләренең фашистларга каршы көрәшен тасвирлаган очерк җибәрдем. Әйе-әйе, Германия яшьләре турында очерк яздым. Үзем уйлап чыгарып яздым. Ләкин аның турында хәтта «басмыйбыз» дигән хат та килмәде. Зуррак масштабтагы әсәрем барып чыкмагач, үзем яхшы белгән темага, мәктәп балаларының тимер-томыр җыюына багышланган хикәя яздым. Аны югарыда әйтелгән Мәскәү журналына җибәрдем. Билгеле бу хикәям басылыр дип, аңа нинди дер якты өметләр баглап яшәмәдем. Гадәттәгечә, басылмас та, җавап та килмәс дип йөрдем. Шундый фикер белән килештем. Һәм ул хикәя турында артык уйламадым да.

Ә бер көнне журналның яңа санын алып карасам, ни күрим, анда минем хикәям басылган. Мин хәйраннар калдым. Юк, алай гына түгел, утырган урынымнан кузгала алмас булып, тетрәнеп, зиһенемне җуя яздым.

Бу минем өчен чиксез зур шатлык иде. Мондый шатлык кичерү өчен Гафифә апаның әчегән бәрәңгесен ашап торырга да риза. Ур-ра! Мин яшим!

Хикәя журналның урта бер җиренә басылган. Җитмәсә, рәссам аны шактый килештереп, рәсемнәр белән бизәгән. Башына «Борылышта» дип сырлап язып куйганнар. Авторы «А. Рәсүлев» диелгән. Йә хода! Мондый да бәхетле минутлар кичерер көнем булыр икән!

Шулай итеп, хәзер минем барыр юлым билгеләнде. Мин — язучы. Ә нигә шулай булмасын!? Әнә бит, Мәскәүдә чыга торган журналда басканнар минем хикәямне!

Байтак еллар узгач кына, без Ватан сугышларыннан әйләнеп кайткач кына, минем хикәя басылганда ул журналның редакторы булып Муса Җәлил эшләгәнлеген белдем.

Тик шулай да «Октябрь баласы» белән элемтәм ныгып китмәде минем. Чөнки хикәям басылып чыккач күп тә үтмәде, редакциядән хат алдым. Хат белән бергә анкета кәгазе дә җибәргәннәр. Редакция шул анкетаны тутырырга кушкан. Анда социаль чыгыш турында да сорау бар, фәләненче елдан фәләненче елга кадәр этиең кем булган, дип сораганнар. Бетте баш, әгәр дөресен язсам, мине әдәбиятка якын да җибәрмәячәкләр. Ә алдап язасым килми, чөнки әдәбият дөньясы минем өчен артык изге нәрсә.

Анкетаны тутырмадым. Шуның белән минем язучылык эшем бетте. Хәер, бетте микән соң ул? Бер йоккач, синнән китә торган чир микән соң ул иҗат дигән нәрсә? Әйе, монысын киләчәк күрсәтер. Ә хәзергә миңа укырга кирәк...

Укуда ярыйсы гына алдырам. Байтак фәннәрдән мин хәзер алдынгы укучы. Бары химия белән генә дуслык чамалы: ул миңа авыр бирелә. Ә физика һәм математикадан мәсьәләләрне чишүдә мин — класста беренче. Мин хәзер укытучылар алдында абруйлы. Рус теле укытучысы Зоя Дмитриевна мине аеруча ярата. Үзем дә аңа гашыйк. Ап-ак нәфис йөзле, акыллы карый торган зур коңгырт-кара күзле, сузылып киткән каләм кашлы, зифа буйлы бу яшь укытучы белән без һәрвакыт күз карашларыбыз аша бер беребезгә хәер-хаһ булып яшибез.

Укулар бригада ысулы белән бара. Дальтон план* класс бригадаларга бүленгән. Һәр бригада, бергәрәк утырып, укытучы биргән эшне башкара. Укыйбыз, исәплибез. Укытучының сорауларына җавапны бригададан бары бер кеше генә бирә. Шуның җавабына карап, укытучы барлык бригада әгъзаларына билге куя.

Ә бу ысул бездә җәмгыять дәресләрендә кулланыла. Җәмгыять дигәннән, бу фәнне безгә Рувим Абрамович Левин укыта. Без бу яһүдне «Зубрим Абрамович» дип йөртәбез. Күп еллардан соң мин аның Казандагы рус газетасында эшләвен, республика күләмендә танылган фельетончы булуын күрәчәкмен.

Укулар башланып бераз вакыт үткәч, безнең мәктәптә удар класслар оештырылды. Удар класс ике еллык программаны бер елда үтәргә тиеш. Димәк, бер кышта алтынчы һәм җиденче класс программалары узылачак. Безне, биш дусны да, шул класска күчерделәр. Ә теге тәртип бозучы Веселовлар, Абрамовлар гади класста калдылар.

Вакыйгаларның дәвамын язуга керешкәнче, мин әнием укыткан Шәле авылы турындагы хатирәләремне яңартмакчы булам. Әйткәнемчә, әнием һәр мөмкинлектән файдаланып, минем яныма кайтып китә. Бер генә көнгә, берничә сәгатькә генә булса да. Инде бер дә кайтып китү мөмкин булмаса, әнием миңа хат яза, почта аша акча җибәрә.

Ул авыл Казаннан кырык чакырымда гына торса да, мондый амәнәтләр миңа тиз генә килеп җитми. Ә инде кулга хат кергән көн минем өчен бәйрәм була. Әниемнең хатын кабат-кабат укыйм. Акча килсә, янәшәдәге Печән базарына йөгерәм. Әле ул чорда анда тротуар буйлап лареклар тезелгән иде, вак сәүдәгәрләр, бик зурдан кубып булмаса да, сату итkәлиләр. Миңа кирәге — тәм-том. Анда язын-

* Утызынчы елларда мәктәпләргә кертелгән укыту алымы.

көзен черегән дулә саталар, инде ул булмаганда кәләвә, кипкән өрек алырга була.

Әниемнең Казанга кайтуы, һич югында хатлары, әйткәнемчә, минем өчен бер бәйрәм. Әмма бәйрәмнең тагын да кәттәрәге — әнием янына Шәлегә барып кунак булу. Гадәттә, мондый хәл кышкы һәм язгы каникул көннәрендә. Ә җәен әни үзе Казанга кайта. Без аның белән йә Арчада (баштарак шулай булды), яки Габдрахман абыйның Идел буендагы «дача»сында. Шул «дача»да булу безнең өчен ял гына түгел, ә бәлки чын мәгънәсендә куанычлы көннәр. Әнием канаты астында миңа җан өрелә, мин рухи яктан үсәм. Җитмәсә, биредә Идел елгасы ага. Ә аның уртасыннан, һәр минут саен диярлек, күңелләргә татлы да, сәер дә тойгылар салып, күңелләрне хушландырып, ак пароходлар уза, сузан саллар ага. Баржалар сөйрәгән гайрәтле буксирлар, озак-озак вакытлар күздән югалмыйча, су агымнарын җиңәргә тырышалар. Биек яр башыннан әнием белән Идел өстенә карап утырулары үзе бер ләззәт.

«Кызыл байрак»тан ерак түгел, үзенең бакчалары белән дан казанган рус авылы Шеланга урнашкан. Без, шунда барып, кура җиләге сатып алып кайтабыз. Барасың, хуҗаның бакчасына керәсең, күпме кирәк — шулкадәр кура җиләге җыясың, капкадан чыкканда хуҗадан тырысыңны үлчәтәсең, акчасын түлисең. Ә җиләк бик арзан. Без кура җиләге ашап кинәнәбез.

Әмма, әйткәнемчә, мин кышкы һәм язгы каникулларда — Шәледә, әнием янында. Әти белән бергә Казанда яшәгәндә дә шулай иде. Мин үзем генә әнием янына китә идем. Чөнки әтигә анда барырга ярамый, ул әнинең рәсми ире түгел, алар аерылышканнар...

Хәтерем ялгышмаса, Шәледә мин дүрт тапкыр булдым. Ул ифрат караңгы бер авыл иде. Күпер, ә күпер янында — келәт кебек кенә бәләкәй кибет, шуның яныннан өскә, үргә күтәрелеп, урам буйлап китәсең. Тирә-юньдә — салам түбәле, сукыр тәрәзәле өйләр. Әни Сәйфулла исемле абзыйларның чагыштырмача зур һәм иркен түр бүлмәсендә Настя исемле керәшен кызы — рус теле укытучысы белән бергә яши.

Беренче тапкыр мине Шәлегә Сәйфулла абзый кара-туры атында үзе алып кайтты. Башка вакытларда мин Московский урамындагы «Крәстиян йорты»ннан юлаучы таба идем.

Юл, ни әйтсәң дә, газаплы: кышкы суыкта юка киемнәрдән бик тиз туңдыра, үрәчәле чанада бераз барасың да, төшеп, ат артыннан йөгерәсең. Монда инде сине кашовка чаналарда юрганнарга төреп алып баручы юк. Ләкин шулай да Шәлегә барулары миңа бик күңелле. Каникулымны әнием белән уздырачакмын. Ул, үз авызыннан өзеп булса да, тәмле-томлысын минем өчен күптән әзерли башлаган. Скрипка минем үзем белән, Шәледә аның кирәге чыгачак.

Мин беләм, без — иртүк юлга чыккан кешеләр — караңгы төшкәч кенә авылга барып керәчәкбез. Бу вакыт утлар алынган булачак, авыл этләре безне һау-һаулап каршы алыр. Анысы да үзенә күрә күңелле. Мин таныш өй яныннан узганда, ат туктаганчы ук чанадан сикереп төшеп, әнием янына йөгерәчәкмен. Әни һәм Настя апа мине шатланып каршы алачаклар. Әнием туңып кызарган кулларымны ышкып җылытырга тырышачак; мин исә, никадәр рәхәт булмасын, Настяападан уңайсызланып тартыначакмын. Яшь ябык организм, суыктан җылы өйгә кергәч, тәмам туарыла, мәмрәя, әмма мин бик шат, елмаерга тырышам, әниемнең табынга куйган тәмле әйберләреннән авыз итәм, тик үтереп йокы килә башлый. Әни моны ачык күрә, ул колә, үзе мине кызгана да. Ул тиз генә йомшак итеп урын җәя. Мин беләм, ул әле бик озак дәфтәрләр карап утырачак, аннан минем керләремне уачак. Иртән, мин уянганда, өй шактый суык булганын да беләм. Сәйфулла абзыйның олыгайган, бик аз сүзле җәмә-

гате түр якка кочак тутырып салам алып керәчәк. Өй эченә әчкелтем төтен исе җәелер. Мич авызыннан йөзгә рәхәт җылылык бәрелер. Саламның чытырдап, гөрләп янганы ишетелер.

Шәле халкы, Казаннан ерак яшәмәсә дә, ифрат кара. Хәтта мәктәп директоры Кәрим абзый да гади крәстияннән аергысыз: башында — кырпусыз ситсы тышлы бүрек, өстендә биле бөрелгән бишмәт, аякларында күп вакыт чабата.

Хатын-кыз Шәледә артык чуар киенә. Мине сәерсендергәне тагын шул булды: олы-олы апалар сүз арасында оятсыз гыйбарәләр кыстыруны бер дә гаепкә санамыйлар. Шәле кешесе, аптыраса, «Чө» дип куя. Мин ул сүзне аңламыйм, «Китче»нең кыскартылып әйтелүедер дип уйлыйм.

Сәйфулла абзыйның ике кызы бар, алар мине утырмаларга, аулак өйләргә алып баралар. Мин скрипка чалам, кызлар җыйнаулашып җырлыйлар. Озакламый биюләр дә башланып китә. Бала итәкле, күз явын алырлык чуар күлмәк кигән, ак алъяпкычлы матур авыл кызларының җыйнак чабаталы җитез аякларын тыпырдатып бөтерчектәй җиңел биюләрен беренче тапкыр шунда күрдем. Бу инде лаптыр-лыптыр идән тактасын шакылдату түгел иде, бу — халык сәнгате, карлыгачтай очу иде.

Ә авылда колхозлашу чоры кызган чак. Каникул, ял дип тормыйлар, әниләрне шул эшкә бик нык җигәләр, әнием һәм Настя апа иртән чыгып китәләр, районнан килгән кешеләр белән авылларда җыелышлар уздырып йөргәннән соң, арып-талып кайтып керәләр. Кичләрен һәр көн диярлек Сәйфулла абзый өенә авыл агайлары җыела. Алар стена буена идәнгә чүнкәяләр, инде нишләргә дип баш ваталар, кемнәрдер тараткан коткы һәм уйдырмаларны чәйниләр. Әнидән, Настя ападан чынбарлыкны белеп кайтырга тырышалар. Барысының да телендә «Нишләргә?» дигән сорау. Алар ашыкмыйча гына сүз алып баралар. Ниһаять, мине тәмам йокы баса, мин тәмәке исенә тынчыган алгы яктан әниләр бүлмәсенә чыгам. Агайлар да бераздан өйләренә таралыша.

Бу урында тагын бер вакыйгага тукталасым килә. Мин Гафифә апаларда яшәгәндә хуҗабикәнең Мөхәммәт исемле туган тиешлесе Казанга килеп грузчик булып эшли башлады. Ул төптән юан, иркен күңелле, бик көчле егет. Без аның белән бик тиз дуслаштык. Күрәсең, ул скрипка уйнавымны бик яраткан булса кирәк, мин ясаган сурәтләр дә аны сокландыра иде. Ул миннән биш-алты яшькә олы булса да, мине тиң күреп, барлык серләрен, кичерешләрен миңа сөйли. Үзенең вокзалда күргәннәрен сөйләве хәтердә. Кулакларны, эшелоннарга төяп, Себер якларына озаталар икән.

— Әле бүген алма кебек чибәр кызлар,— дип сөйли Мөхәммәт,— мине күреп, татар икәнлегемне белгәч, килеп муеныма асылындылар. Берсе: «Абый җаным, башкайларыбызны вәйран итәләр бит! Алып кал үзеңә хатынлыкка, мәңге үзеңә тугры булыр идем, чәчем белән идәнеңне себереп яшәр идем!» — дип җылый.

Егетнең күңеле нечкәргән, миңа шуларны ачынып хәбәр итә.

Шәледә дә кулакларны бетерү башланган иде инде. Ләкин миңа бу эшкә бәйләнешле истә калырлык нәрсәләр күрергә туры килмәде.

Әниемнең Шәледә яшәве, хезмәте турында бу вакыйгаларга илле ел вакыт узганнан соң да аны мактап искә алучыларның булганлыгына мин шаһит. Ул хәтта Шәле авылына багышланган китапта да җылы итеп искә алына.

Менә ул китап минем кулымда. «Шәле таңнары» дип атала. Аның кырыгынчы битендә түбәндәге юллар язылган: «Күмәк хуҗалык төзүдә хатын-кызлар аеруча зур роль уйнады. Партячейка алар арасында эш алып баруга зур игътибар бирде. Ул 1930 елда Шәледә барлыкка килгән делегаткалар пункты аркылы тормышка ашырыл-

ды. Укытучы Зәйтүнә Мәүлетова житәкчелегендә делегаткалар пункты башта 16 кешедән оештырылган иде. Менә алар — Шәле авылында беренче хатын-кыз делегаткалары...»

Шуннан соң китапта делегаткалар исемлеге китерелә. Исемлектә беренче — әнием.

Шәле укытучылары арасында Кәлим Исламов атлы егет хәтердә нык саклана. Ул озын, зифа буйлы, куе, дулкынланып торган чәчле, озын муенлы, какча йөзле кеше. Йөз чалымнары да дөрес, килешле. Әгәр аның сул күзе чагыр булмаса, ул бөтенләй матур булыр иде. Хәер, болай да күңелгә ятышлы кеше ул. Бераз ирониялерәк булса да, кыюлыгы, ачыклыгы белән кешене тиз арада үзенә тарта. Мандолинада ярыйсы гына уйный, матур җырлый һәм миңа барыннан да битәр ошаган ягы шул — шигырьләр яза.

Ул Казанда педагогия техникумында укыган, Кәлим Аспиран кушаматы куеп, шигырьләр язган. Ләкин көннәрдән бер көнне республика газеталарының берсендә «Әдәбиятта кара таплар» исемле мәкалә басылып чыга, анда Кәлимнең дә исеме телгә алына, аның чыгышын яшергән кулак малае икәнлеге әйтелә. Менә шуннан соң инде ул, ата-анасыннан ваз кичеп булса кирәк, Шәлегә килеп урнаша.

Без аның белән сәгатьләр буе әдәбият турында гәпләшәбез. Ул язучылар даирәсен яхшы белә. Ул миңа шул турыда сөйли, аннан үзенең шигырьләрен укып күрсәтә. Сүз дә юк, минемчә, Кәлим талантлы. Мин әле ул кеше белән тагын бер тапкыр, инде бөтенләй башка җирдә очрашачакмын, анысы турында да язылыр. Шуңа күрә, сүзне кыскартып, тагын үземнең Казан хәлләремә кайтыйм.

Шулай итеп, Казанның Короленко исемендәге сигезенче мәктәбенең удар группасында укыйм. Минем тормыш шартларымның начарлыгын иптәшләрем яхшы белә. Ләкин нишләсеннәр алар мине кайгыртып? Нинди ярдәм күрсәтә алсыннар? Гафифә апа бетләреннән котылу өчен, мин инде бер тапкыр, мәктәптән китеп, тулай торагы булган печатниклар ФЗӨсенә керергә булдым. Аларның тулай торакларына бардым. Ләкин бу да миңа рәтле тормыш вәгъдә итми иде. Зур шәрә бүлмәдә егермеләп үсмер бала. Тәрәзәләреннән җил өреп тора, юка матраслы шыгырдавык караватлар, таушалып-сидрәп беткән одеяллар. Юк-юк, монда катып, туңып яшәгәнче, бетләп бетсәм дә, хәзергә түзәргә тиеш мин...

Менә шундый аптыраган көннәремнең берсендә безнең мәктәпкә Вахитов исемендәге сабын кайнату заводыннан эшчеләр килде. Алар безнең класска да керделәр. Заводта экспериментал өйрәнчеклек мәктәбе ачыла икән. Ул урта белем бирәчәк, шуңа күрә ул ФЗӨгә җидееллык белеме булган кешеләр генә алыначак. Нинди һөнәрләргә өйрәтәчәк ул мәктәп? Малайларга (теләсәләр, кызларга да) — металл эшкәртү һөнәрләре; ә кызларга (теләсәләр, малайларга да) сабын кайнату, шәм кою һөнәрләре биреләчәк. Кайсыгыз мәктәпне тәмамлау белән безгә килергә уйлый? Кул күтәрегез!

Без инде хәзер удар группаның җиденче класс программасын үтә башладык. Димәк, язга безнең кулда, җиде классны тәмамлап чыкты, дигән таныклык булачак. Завод кешесе үз сүзен әйткәч, без — дус-ишләр — бер-беребезгә караштык. Нишлибез? Миша да, Вова да, Равил дә артык кымшанмыйлар. Митя белән без икәү бердән кул күтәрдек.

## 19

Бүген дә Агриппина Евграфовна янына кердем. Мин аның «Юк, булмады, сезгә отказ»,— дигән сүзләрен ишетергә әзер идем, әмма бу юлы да бернинди җавап ала алмадым. Шулай да аның сүзләре ми-

нем күңелемдә өмет чаткысы кабызды. Чөнки комиссиянең рәисе минем кәгазьләрем белән ныклап танышкан, алар арасындагы «Чаян» журналына игътибар иткән. Янәсе, нигә кирәк булган бу журналны монда кыстыру, анда бит Рәсүлевкә бәйләнешле берни дә юк.

— Ничек юк?! — дидем мин.— Анда да бит минем бер хикәям бар.

Апа бик аптырады:

— Нинди хикәя?

— Анда «А. Расих» имзасы белән басылган хикәя бар. Ул минеке.

— Расих? Ул сезнең псевдонимыгызмы?

— Ул минем әдәби псевдоним.

— Ә сез аны исбат итә аласызмы соң?

— Юк. Ләкин, миңа ышанмасагыз, редакция белән бәйләнешкә кереп белешмә сорый аласыз.

— Яхшы. Мин боларны Антон Ивановичка әйтермен.

Урамга чыктым. Ике-өч минутлык сөйләшү — ә мин эт урнына ардым. Эх, хәзер өйгә кайтып, караватта берәр кызык китап укып, ял итеп ятасы иде! Хәдичә апа хәзер кухняда инде, кызлары кайтуга көндезге аш пешерә. Әйе, рәхәтләнеп, аякларны сузып, караватта ял итәсе иде... Тик ярамый, яхшы түгел. Хуҗалар бит минем шулай иртә китеп, кичен кайтып керүемә күнектеләр. Нигә аларның күңеленә вәсвәсә салырга?

Мин тагын таныш урам буйлап атлыйм. Гадәттәгечә, Мәскәү урамнарында халык кайный. Кая агыла бу халык, кая ашыга шулай? Аякларым мине бакча эчендәге фонтан янына алып киләләр. Мин аның мәрмәр читкормасына утырам, ял итәм. Ә күңелем тагын Казанга китә... Күз алдыма «Чаян» журналында берничә тапкыр «А. Расих» имзасы белән басылган хикәямне китерәм. Аны Мирсәй Әмир бастырды. Ул чакта Мирсәй абый «Чаян»ның җаваплы секретаре иде. Хәтердә, ул минем кулъязманы укыгач:

— Карале, син үзең яздыңмы моны,— дип сорады,— берәрсеннән чәлдермәдеңме?

Бу сорау мине рәнҗетмәде, киресенчә, мактау сүзе булып тоелды.

Мин шул минутларны хәтерлим дә көлемсерим. Ул да булмый, әниемнең истәлек дәфтәрендә язылганнар турында уйлыйм.

Әнием үзенең истәлегендә хаҗ кылырга чыгып китүләрен яза. Алар Истанбулдан Италия пароходына утырып сәфәр кылалар. Мәрмәр диңгезе искиткеч гүзәл. Безнең хаҗилар бу гүзәл диңгезгә сокланып туя алмыйлар. Уналтысында пароход — Измирдә. Икенче көнне инде ул Сакыз атасында, унсигезендә — данлыклы Сиам атасында, көндез — Рәдүстә, ә унтугызында Мекридә булалар. Әни бу шәһәрләрнең ифрат матурлыгын, гаҗәеп тау итәгенә утырганлыгын яза. Диңгездә озак бару юлчыларны шактый ялыктыра. Шулай да тирә-яктагы өзлексез алмашынып торган искиткеч гүзәл манзара аларга ял бирә, күңелләрен хушландыра.

«Егерме икенче августта иртән сәгать сигездә Искәндәрунда булдык — дип яза әнием.— Монда килгәч, ничә көннән бирле ялкауланып беткән күңелне күтәрер өчен шәһәргә чыгып йөрергә булдык. Менә бер каекчы килә. Ифрат дәрәҗәдә киң озын чалбар кигән, фәс өстеннән яулык бәйләгән. Шул каекчы белән сатулашып, ниһаять, ун грушка килештек тә, Кадыйр безне берәм-берәм каекка алып төште. Каек кузгалды. Илаһи диңгез өстенең матурлыгын күрсәң! Тып-тын. Әйтерсең, без күл өстеннән барабыз. Җитмәсә, тирә-якта биек таулар утыра, алар өстендә болытлар. Алар карачкыл-яшел урманнарга тиеп шуышалар».

Әниләр каектан төшкәч, извозчикка утырып, шәһәр гизәргә китә-

ләр. Юлда искиткеч йортлар очрый. Бу кем йорты, дип сораугa, җавап шул: француз мәктәпләре. Төрек мәктәпләре бармы соң, дип сорауга, бары «Ла» дигән җавап кына алалар. Димәк, юк.

Алар, шәһәрне үтеп, болынлыкка чыгалар, шунда табигать кочагында хозурланалар, берәр сәгать йөргәннән соң, яңадан пароходка кайталар. Көндезге аш вакытында салонда җәнҗал куба. Аерым өстәлдә утыручы бер христиан төрекләрне сүгә башлый. Икенче өстәлдәге төрек, моны ишетеп, тегеңә шешә җибәрә. Куба шау-шу, салондагы халык аякка баса. Баксаң-күрсәң, бу җәнҗалның сәбәбе дә әлләни түгел, имеш. Төрекләрне сүгүче итальян, бер французның Бәйрутка баруын ишеткәч, салган баштан, нигә төрек шәһәренә барасың, алар бит вәхши, дип кычкыра икән.

Егерме дүртендә әниләр Бәйрут шәһәренә якынлашалар. Бәйрутта алар Касрелҗәбир кунакханәсенә төшәләр. Урамнарыннан үткәндә хәерче күплегенә хәйран калалар. Әнием истәлегендә: «Бу шәһәрне хәерчеләр шәһәре дип уйларсың»,— дип яза. Истанбулдан өйрәнеп килгәнчә, әниләр «Майсухан» дип, кайнар су сорыйлар, чәй эчәләр. Аннан шәһәр карарга һәм, өйдә чакта ук кушылган китапларны сатып алу өчен, китап кибетенә китәләр. Ләкин бу чит шәһәрдә ниндидер берәр урынны эзләп табу бик авыр. Мондагы гарәпләр төрекчә белмиләр. Истанбул акчасы биредә башка бәядә йөри. Хәтта сәгать тә вакытны башкача күрсәтә.

Иртәгесен алар ул заманда татар интеллигенциясе арасында даны таралган Бәйрут көллиясенә китәләр. Төрекчә көллия дип колледж, югары уку йорты атала. Көллиягә трамвайга утырып баралар. Трамвай бу уку йортының капка төбенә үк килеп туктый икән. Безнең сәяхәтчеләр башта көллиянең музеенда булалар, мумияләргә шаккаталар. Аннан гыйбадәтханәгә керәләр. Зур зал, бихисап күп утыргыч, һәр урындыкта бер инҗил, һәр укучы, нинди генә диндә булмасын, шушы христиан гыйбадәтханәсенә кереп дин сабагын тыңларга тиеш икән. Чиркәүдән битәр, бу урын театрга охшый, дип яза әнием.

Бәйрут көллиясендә әниләр Троицк кешесе Бакиров Закирны очраталар. Аның белән күрешеп туган ил яңалыкларын сөйләшкәннән соң, уку йортының ятакханәсендә һәм гимнастика залында булалар.

Әнием Бәйрутка килгәч үзләре теләгән аш таба алмый интегүләре турында яза. Ашханәдән нинди генә аш алмасыннар, берсе дә без теләгәнчә түгел, тәмсез, хәтта рәхәтләнеп ашарлык күмәч тә юк, ди. Икмәкләре кабартма сыман, үзе тозсыз. Бөтен ризык татлы, төче. Истанбулда, ичмасам, ашханәләрдә безнеңчә пешерелә торган ашлар була, биредә исә андый урын бөтенләй юк, дип яза.

Егерме алтынчы августта безнең хаҗилар, Шамга китү өчен, станциягә төшеп вагонга урнашалар. Поезд кузгала.

Әниләр, Шам юлының гаҗәп матур манзарасына сокланып, тәрәзәләрдән карап баралар. Поезд әледән-әле куыш юлларга — туннельләргә кереп китә. Биек тау һәм кыя төпләрендә тезелешеп утырган зифа агачлар, агачлар янында ук чылтырап аккан саф сулы чишмәләр. Алар яныннан узганда тынчу вагон эче сафланып китә, тын алулары иркен, салкынча һава тәрәзәләрдән кереп, вагон эченә тула. Ә тау астындагы агачлар барысы да җимеш агачлары: әфлисун, лимон, алма, шәфталу һәм тагы безнең юлчылар белмәгән бик күп төрле җимешләр белән тулы. Алар авырлыктан аска салынып төшкән, суга тияр-тимәс, мине ал да мине ал дигәндәй, кешене кызыктырып калалар.

Егерме алтынчы августта поезд Шам-шәрифкә (Димәшкъ) килеп туктый. Поезд туктау белән, әниләр утырган вагон тәрәзәсе янына бер кеше йөгереп килә:

— Әфәнделәр, сез казанлылар түгелме? — ди ул.

Бу кеше әтиләрнең килүе турында Бәйруттан телеграмма алган җирле татар Талип әфәнде булып чыга. Ул үзе, гадәттә, юлчыларны «Котдүс» кунакханәсенә урнаштырып йөри икән. Ләкин якташларының затлы кешеләр икәнлеген күргәч, әйбәтрәк урын табарга була. Әнием үзенең истәлегендә Шам шәһәренең дә агачлыкка күмелеп утырганлыгын яза. Һәр ишегалдында — җимеш бакчасы, татлы җимешләр, ди.

Безнең юлчылар, күп кунакханәләрдә булып та урын тапмагач, ниһаять, «Дарелсрур» атлы кунакханәгә урнашалар. Бу гаҗәеп бинаның иркен холларында агачлар үсеп утыра, фонтаннар су сиптерә. Әниләр өске каттагы бер бүлмәне ошатып, шунда урнашалар.

Иртәгесен сәяхәтчеләрне Талип әфәнде үзләренә алып китә. Аларның торган җире шәһәр читендәрәк урдә, Салихия дип аталган урында икән. Татар мөһаҗирләре яши торган җир. Алар кайчандыр бәхет эзләп шунда килеп урнашканнар. Өйләр, каралты-кура, җимеш бакчалары торгызганнар. Талип әфәнденең исә ишегалдында өч өе бар икән. Әнисе күңелле генә татар карчыгы, дип яза әнием. Байтак кына вакыт сөйләшеп чәй эчәләр. Ирләр бер бүлмәдә, хатыннар икенче бүлмәдә. Өйләре таш, җыйнак, түрдә диван кебек нәрсә бар. Ташка утырмас өчен идәндә көрпә, мендәр кебек нәрсәләр.

Безнең мосафирлар Талип агайның өен күреп, җәмәгате белән танышып, чәй эчеп сыйлангач, яңадан номерга кайтып китәләр. Юлда трамвайга утыргач, олы яшьтәге җирле бер хатын әнием белән Гайшә апага бәйләнә башлый: янәсе, сезгә болай йөзләрегезне ачып йөрү гаеп түгелме, моның өчен хода үзегезне җәзалар.

Шамда әниләр байтак җирдә булалар. Яхъя пәйгамбәр каберен, Хөзер мәкамен, Мөхәммәт пәйгамбәрнең сакал шәрифен карыйлар. Шул мәчетнең Гайсә пәйгамбәр иңәчәк манарасына менәләр. Манарадан төшкәч, Сәлахетдин Әюби каберенә юл тоталар. Борынгы китаплар сакланган Миллик әл-таһра китапханәсендә булалар. Аннан пәйгамбәр хатыннары һәм кызлары каберләрен зиярәт итәләр. Кыскасы, бик күп җирләрдә булалар.

Әни үзенең истәлегендә: «Бу шәһәрнең дә төп кәсебе хәерчелек, ахры,— дип яза.— Мәчет, зиярәт тирәләрен әйтерлек тә түгел, саилче тулган. Эчкә үтәргә бөтенләй мөмкинлек юк. «Хаҗи сабилла»,— дип, арттан калмый ияреп йөриләр, үзләреннән орышып та котылып булмый».

Егерме тугызында, Талип әфәнде кунакханәгә килгәч, тагын урамнар гизү башлана. Бу юлы Кадәм шәрифкә барырга булалар. Трамвай көткәндә һиляле әхмәргә* акча җыеп йөрүче малайлар очрый. Әни белән Гайшә шуларга акча биреп чәчәк кадата гына башлаганнар икән, урамдагы ирләр, ябырылып, әниләр ягына ташланалар. Боларны камап алып, зонтлары астына иелеп-иелеп, йөзләрен күрергә тырышалар. Әниләр көчкә качып котылалар. Тегеләр арттан иярә, күзләрен тозландырып, хатын-кыз йөзен күреп хозурланырга ашыга. Ниһаять, ат кузгала, бары шуның аркасында гына әзәрлекләүчеләрдән котылалар.

Ул көнне гарәпләрнең нindidер бәйрәмнәре була. Урамнар халык белән тулган. Узарлык та түгел. Думбралар кагып, лю-лю кычкырып йөри кешеләр. Халык дәрьясын кичеп чыга алмыйча, кире номерга кайтырга мәҗбүр булалар. Иртәгесен дә бәйрәм дәвам итә. Патшалары Мөхәммәт Рашат туган көн, имеш. Гарәпләр ул көнне тантаналы рәвештә музыкалар уйнатып, кулларына кылычлар тотып: «Дин Мөхәммәт, дин сәеф»,— дип кычкырып йөриләр. Әледәнәле туп аткан авазлар ишетелә.

* Һиляле әхмәр — Кызыл ай җәмгыяте.

Бик озак урамнар гизгәннән соң, ниһаять, бер тыныч тыкрыкка килеп чыгалар. Монда халык юк. Бары ишәк өстенә кәрзиннәр салып, йөзем, кузы чикләвеге сатучылар гына күренә. Шәһәрдән чыгып, бер таш коймa янына тукталалар. Биредә авыл башлана. Шунда, аттан төшеп, җәяү китәләр. Кадәм шәриф дигәннәре кечкенә генә бер мәчет икән. Шул ук авылда. Мәчет түрендә тәрәзә, аның төбендә бер ак ташка ниндидер эзләр уелган. Пәйгамбәребезнең һәм аның дөясенең аяк эзләре бу, дип аңлата шундагы шәех. Шуны карагач, сәдака биреп мәчеттән чыгалар. Ә капка төбендә — хәерче балалар төркеме. Бу бер өер балага тагын сәдака өләшергә туры килә.

Иртәгесен хаҗилар Мөхетдин Гарәбинең каберенә китәләр. Ул зур гына мәчет эчендә икән. Анда да хәерче тулган. Аннан чыгып, юлчылар тар урамнарны үтә, биек тау янында туктала. Тау өстендә ике катлы өй. Аның тирәсендә коймa. Тауга мендәләр. Мәчет эчендә боларны бер шәех каршы ала. Эчәргә су бирә. Бу тауны җирле халык Кырыклы тавы дип исемләгән. Аның мәгарәсенә, имеш, кырык иранлы кереп юкка чыккан. Мәгарә исә мәчет эченә тоташа.

Безнең хаҗилар мәчет бинасының бер бүлмәсенә керәләр. Аның түбәсендә эчкә баткан урыннар бар. Боларны Гали, Госман, Әбүбәкернең таҗ урыннары диләр. Тагын бер бүлмәгә үтәләр. Андагы кара ташта биш бармак эзе кебек уенты күзгә ташлана. Бусы — Һабил Кабилгә таш атмакчы булган, Җәбраил аттырмый тотып калган да, бу шуның эзе, имеш. Шул ук бүлмәнең түрендә кечерәк кенә өч тишек күренә. Теге юкка чыккан иранлылар шунда кереп гаип булганнар, имеш.

Түшәмдә тагын күзгә охшаган зур бер тишек бар, аннан тозлы су тамып тора. Кабил Һабилне үтергәч, бу тау алладан Һабил өчен кыяматкәчә елап торырга рөхсәт сораган. Уң якта авызга охшаш бер тишек күренә. Аның эчендә тел-тешләрне хәтерләткән ташлар ята, бугаз кебек нәрсә дә күренә. Бу тау авызы, имеш. Хәзрәте Һабилне эзләп йөргәндә, тау телгә килеп, аны Кабил үтерде дә күтәреп алып китте, дигән, имеш...

Мәчеттән чыккач, безнең сәяхәтчеләр тагын тау башына югарырак менәләр. Анда Һабил «канын» карыйлар. Ул, агып, ике сажин җирне буяган. Бу «кан», әниемнең әйтүенчә, кызыл төстәге зур бер таш икән.

Шәех шул ташның бер вак кисәген безнең сәяхәтчеләргә дә бүләк итә. Әлбәттә, сәдака хакына...

Өченче сентябрьдә этиләр, Талип әфәнделәргә артык йөкләрен калдыралар да, Котдүскә (Иерусалим) бару өчен поездга утыралар. Поезд Шамнан кичке җидедә кузгала. Күп тә үтми, бер станциядә, бу вагон гел хатыннар өчен генә дип, эти белән Сабурны башка вагонга сөрәләр. Бераздан әниләр янына гарәп хатыннары кереп тула.

Мең бәла белән иртәнге дүрттә Хифага җитәлә. Анда номерга урнашкач, әни белән Гайшә апага тагын көне буе бүлмәдән чыкмыйча номер сакларга туры килә. Чөнки хатын-кызга урамда ачык килеп йөрергә ярамый.

Кичен шулай да кино карарга баралар. Италия картинасын карыйлар.

Җиденче сентябрьдә алар Котдүс пароходында. Анда да ирләр белән хатын-кызны бергә утыртмыйлар. Тыгыз, эссе. Ул арада кайбер пассажирларны диңгез тота башлый. Ыңгырашып, косып, укшып әзаплана кешеләр. Каютада түзә алмаслык бер хәл туа. Әни белән Гайшә апа, салонга кереп, утыргычларда йокларга мәҗбүр булалар.

Сигезенче сентябрьдә пароход — Яфәдә. Анда безнең мосафирлар, сәфәрне поездга утырып дәвам иттерү өчен, вокзалга төшәләр.

Котдүскә китәсе поезд сәгать уникедә генә килеп җитә. Әнием үзенең истәлегендә: «Поездан безнең якташ марҗа түтәйләр төш-

те.— дип яза.— Аларның Котдүстән хаҗ кылып кайтулары икән. Алар белән тәмләп кенә сөйләшеп тордык. Юкса гел гарәп тә, гел төрек, алардан туеп беткән. Рус түтәйләрен очраткач, якын кешеләрне күргәндәй рәхәт булып китте».

Сәгать икедә безнең хаҗилар вагонга кереп утыралар. Юлда боларга ниндидер шикле кешеләр бәйләнә башлый. Ләкин алдан ук: «Хаҗиларны талап кәсеп итүче симсарлар* бик күп, сак булыгыз»,— дип кисәтелгәнгә күрә, болар Котдүстә шәп кунакханә вәгъдә итеп бәйләнүчеләр ярдәменнән баш тарталар.

«Тугызынчы сентябрьдә кичен поезд Котдүс шәрифкә килеп туктады»,— дип яза әнием. Шундук: «Без — дәлил»,— дип, аларны чалмалы хәерчеләр чолгап алалар. Бу чебендәй ябышып яткан «дәлил»ләрдән көчкә котылып, әниләр бер европа кунакханәсенә урнашалар.

Әни үзенең истәлегендә, Котдүснең тыш тарафын яһүдләр әйләндереп алган, дип яза. Алар бу шәһәрне үз кулларына төшерергә тырышалар икән, ди.

Әниләр, Котдүскә килеп төшү белән, кеше башына тәүлегенә дүртәр сум акча түләп, һәрберсендә ике карават куелган ике бүлмәле номерга урнашалар. Тыныч кына, ял итеп төн уздыралар. Иртәгесен торып чәй эчкәч тә, дәлилгә ияреп, битәл-мөкатдәскә, мәсҗет Иксага китәләр. Ифрат зур икән ул түбәсез мәчет, дип яза әнием. Анда Бабҗәннәт дигән ишектән керелә. Ишек янында бер карт утыра иде, дип яза ул. Без дә шуның янына барып утырдык. Бабай идәнгә җәелгән паласны җыерды да шуның астындагы яшел мәрмәрне күрсәтте. «Моның астында хәзрәте Сөләйманның кабере бар, кыямәт булгач, шунда бу таш түбән иңәчәк, дип, сөйли халык, әмма бу дөрес түгел, ялган»,— ди. Әни үзенең язмасында, биредәге шәехләр сүзне кешесенә карап кына сөйлиләр икән, дигән нәтиҗә ясап куя.

Мәчет эче ифрат иркен. Уртасында зур бер таш ята. Аның әйләнә-тирәсенә тәбәнәк кенә койма корганнар. Теге таш «җиргә дә, күккә дә тими» торган таш икән. Ташта Мөхәммәт пәйгамбәрнең чалма эзе төшеп калган. Ташның уртасында бер тишек бар. Пәйгамбәр шуннан күккә ашкан, имеш.

Бер кырыйдарак — Даут пәйгамбәрнең михрабы. Анда без хәзрәте Госман заманыннан калган каләм шәрифне күрдек, дип яза әни. Ул ифрат зур, язулары ачык, кәгазе калын. Хаҗилар, бу мәчеттән чыгып, Сөләйман галәйһи әссәлам каберенә баралар. Аның кабере өч урында дип уйланыла икән, ләкин мәетнең кайсы кабердә ятуы мәгълүм түгел. Бу мәчеттән чыгып, икенчесенә китәләр. Анда хәзрәте Гомәр, тауга менгән дә, «Аллаһы әкбәр» дип кычкырган. Шулвакыт тау тетри башлаган. «Бу мәчет элек чиркәү булган, шундагы кяферләр бу дәһшәттән куркып һәммәсе дә чыгып качканнар»,— дип яза әнием.

Безнең мосафирлар Котдүснең тышкы ягына да чыгалар. Сөләйман Фарси һәм Гыйльми хәзрәтләренең каберлегән зиярәт итәләр. Кайтышлый хәзрәте Мәрьямнең каберенә сугылалар. Ул бер чиркәүдә икән. Капка төбендә сакчысы да бар. Ишекне ачу белән, аска таба баскыч күренә. Шунда төшәләр. Караңгы, бары вак шәмнәр генә җемелди. Бераз баргач, уң яктарак — хәзрәте Мәрьям кабере. Безнең мосафирлар кулларына шәмнәр тотып йөриләр. Кабер урнашкан бүлмә бик матур, зиннәтле, түшәмдә кандилләр, стеналарда бик күп сурәтләр. Биредәге хадимнәр барысы да нәкъ марҗача киенгән. Үзләре гарәп. Юлда этиләр фәластин җәмгыятенә керәләр. Рус хаҗилары барысы да шунда төшә икән.

Иртәгесен безнең юлчылар Хәлилрахманга баралар, юлда бай-

* Симсар — арадашлык итүче комиссионер.

так каберләр зиярәт итәләр. Йосыф пәйгамбәрнең анасы Рәхиләнең каберен күрәләр. Юлда гүзәл бакчалар күреп хозурланалар. Әнием, Котдүс тирәсендә гел зәйтүн белән йөзем агачы гына утыртылган, дип яза. Ниһаять, алар Хәлилрахманга барып җитәләр. Австриялеләр салдырган бер кунакханәгә тукталып ял иткәч, зиярәткә юнәләләр. Тар урамнар аша байтак җир узгач, бер мәчет күренә. Ул ифрат зур. Ишектән кергәч тә Ибраһим пәйгамбәр белән аның хатыны Сараның кабере, аннан ары киткәч — Исхак, Якуб пәйгамбәр хатынннары кабере. Тагы да ары — Йосыф пәйгамбәрнең икенче кабере.

Унынчы сентябрьдә көндезге сәгать бердә, Котдүс шәһәре белән саубуллашып, безнең хаҗилар җигүле атларда Сила станциясенә юнәлә, төрле маҗараларга очрый. Юлларны кемнәрдер җимереп ташлаган. Соңгы вакытта юлбасарларның бу тирәдә азынуы турында сөйлиләр. Күп мәшәкатьләрдән соң, Силага житеп, Җиддәгә китәләр.

Унберендә Шам шәрифкә, Талип әфәнделәргә кайтып төшәләр. Аларда биш-алты көн ял иткәннән соң, унҗидесендә поезд белән Мәдинәгә юл тоталар.

Мәдинәгә барышлый әниләр поездда хаҗга баручы татарлар белән очрашалар, алар белән танышып, юлны бергә дәвам итторәләр. Унтугызынчы сентябрьдә, ниһаять, байтак юл газапларын кичергәннән соң, алар Мәдинә вокзалына килеп җитәләр. Әнием бу турыда үзенең истәлегендә түбәндәгеләрне яза: «Сәгать өчтә поезд Мәдинә вокзалына килеп туктады. Мәдинәнең йортлары — йортка, урамнары урамга һич тә охшамый. Йорт дигәне таш өеме. Аны күккә житкәнче таштан өйгәннәр дә өйгәннәр. Тәрәзә урынына бер тишек, аңа кафәс дип аталган челтәрле такта капланган. Урамнар, бик тар булу сәбәпле, бөтенләй күренми дә, юк хөкемендә. Мәдинә тышында анда-монда сирәк кенә хөрмә бакчалары, яшеллекләр күзгә чалына.

Без алдан ук телеграмм биргән идек. Мәдинәдә яшәүче татар Исмәгыйль әфәнде улы белән станциягә безне каршы алырга төшкән икән. Әйберләрне карарга Исмәгыйль әфәнденең өендә торучы фатирчы Насыйп әфәндене калдырып, без качыр җиккән арбаларда Исмәгыйль әфәнделәргә киттек...

...Исмәгыйль әфәнделәрнең өе өч катлы. Безне иң югары катка алып менделәр. Баскыч башына, каршыбызга, ябык кына, чырайсыз, йөзенә кызыл иннек яккан, тар капот күлмәктән, башына ортү япкан бер хатын килеп чыкты. Кадыйрны күрү белән тиз генә борылып кереп тә китте. Бу — Исмәгыйль әфәнденең хатыны Нәфисә ханым иде. Без аның артыннан зур, чиста, шәрык ысулынча җыештырылган бер залга кереп утырдык. Көн ифрат эссе. Кадыйрлар да бүлмәгә керде. Безне Гайшә белән кечерәк кенә бер бүлмәгә алып керделәр. Анда Насыйбулла әфәнденең җәмәгате Шәмсебәдәр белән күрешеп, әзер табынга чәйгә утырдык.

Бүлмә кечкенә, самавыр гөжләп кайнап утыра, бик сусап кайнар чәй эчү аркасында без тәмам тиргә баттык. Гөнаһ шомлыгына каршы, миңа бик авыр җилпәзә тоттырдылар тагын. Аны күтәрерлек түгел. Җилпи-җилпи тәмам хәлләрем бетте.

Без кабартмалап шулай бик озак чәй эчкәч, Кадыйрлар утырган зур бүлмәгә чыктык. Чәйләр эчелеп бераз хәл алгач, кечкенә генә таш мунчада юынып чыктык. Безгә йоклау өчен тирәсе тотылган өй түбәсен тәкъдим иттеләр. Мәдинәгә килеп керү белән, бигрәк эссе, ничек йокларбыз инде, дип борчылган идек. Кичләрен биредә, кирәсенчә, суык икән. Беренче төндә үк өсләребезгә калын юрган ябынырга мәҗбүр булдык.

Егерменче сентябрьдә дәлил Исмәгыйль әфәнде, Ибраһим, Нәфисә апа белән бергәләп, тәһарәтләр алганнан соң, Хәрәм* шәрифкә

* Хәрәм — Мәккә һәм Мадинә шәһәрендә чикләре билгеләнгән изге урын.

зиярәт кылырга киттек. Хәрәм шәриф ифрат та зур. Биш манаралы. Дүртесе дүрт почмакта, бишенчесе — баш манара — уртада. Ул пәйгамбәребезнең кабере янында. Аны пәйгамбәрдән калган, диләр. Хәрәм шәриф дүрт ишекле. Без аның эченә Бабелислам дип аталганыннан кереп, байтак баргач, пәйгамбәребезнең рәшәткә белән әйләндереп алынган, яшел атласка укалар тоткан, кашагалар эленгән кабере янына җиттек. Коймасы сары җизгә салаватлар язылган. Дәлил кычкырып зиярәт кылды. Аның артыннан без дә әкрен генә зиярәт кылып йөрдек. Әүвәл пәйгамбәребезгә, соңра Әбүбәкер, Гомәр ризалыгына, аннан байтак баргач, хәзрәте Фатыймага зиярәт кылып йөрдек. Тагын Хәрәм шәрифнең башка тарафларында зиярәт кылгач, Бабрәхмән капкасыннан чыгып киттек».

Безнең хаҗилар иртәгесен дә изге саналган байтак урыннарда зиярәт кылып йөриләр.

Кайткач, әниләр үзләренең бередә яшәүче татарларга хатын-кыз мәҗлесенә чакырулы икәнлекләрен беләләр. Әнием белән Гайшә апа шунда китә. Әнием андагы татарлар турында: «Һәммәсе дә калфак кигәннәр, үз гадәтебезне саклап, бер-берсенә ашка-чәйгә йөриләр икән. Гарәп һәм төрекләргә ул кадәр катышмыйлар»,— дип яза.

Егерме өчендә хатын-кыз Хәрәм шәрифкә кандилләр юарга бара.

Әнием: «Без дә бер ләгән янына килеп бераз юган булдык,— дип яза.— Ә җирле хатыннар шул сабынлы суны эчәләр, йөзләренә, күзләренә сөртәләр».

Әниләр тагын сандал иләүгә дә катнашалар. Бусы Мөхәммәт пәйгамбәр кабере өстенә сибелгән исле, сары агач череге. Шуны һәр ел иләп яңарталар икән. Искесен агалар сәдакага өләшәләр. Ага дигәннәре — Хәрәм шәриф хадимнәре. Алар гөнаһсыз кешеләрдән булырга тиеш. Шуңа күрә андыйларны, бала чактан ук печтереп, «гөнаһсызландыралар».

Сандалны кара җарияләр сикерә-сикерә, салават әйтеп, җырлап илиләр. Эш беткәннән соң, сандал иләүчеләрне ашаталар.

Мосафирлар егерме сигезенче сентябрьгә кадәр Мәдинәдә яшиләр. Бередәге рәхәт тормышта тугыз көннең узып киткәнен тоймый да калалар. Егерме сигезендә атлы-дөяле юлчылар кәрваны белән Мәккәгә сәфәр чыгалар.

«...Озатучылар белән саубуллашабыз,— дип яза әни.— Алар җылашалар, безнең йөзләребездән үбәләр. Дөяләрнең муенына баскычлар куйдылар. Әүвәл мин менеп утырдым, аннан — Гайшә. Ниһаять, кафилә* хәрәкәткә килде. Без, бишектәге балалар кебек тирбәлә-тирбәлә, алга киттек. Безнең янда гына йөк төялгән дөядә Насыйбулла әфәнде бара. Зур әрҗәләр дөянең ике ягына асылынган, шуларның уртасында зонт тоткан Насыйбулла әфәнде утыра.

...Насыйбулла әфәнденең: «Мәхдүмнәр, торыгыз, туктыйбыз»,— диюенә уянып киттем. Төн икән, караңгы. Насыйбулла әфәнде безнең янда мәшгал, ягъни факел тотып тора. Без, киенеп, шүрдүфләребездән төштек, ерак китмәгез, бәдәви сугар, дип кисәттеләр. Безне алып баручы бәдәвиләр: «Әрбагъ, әрбагъ»,— дип кычкырышып, дөяләрдән шүрдүфләрне алдылар да, аларны түгәрәкләп тезеп, урын әзерләделәр. Без туктаган урын мәнзил дип атала икән. Әйләнә-тирәдә таулар. Тау төбендә агачлар күренә. Тауда мәгарәләр, шунда бәдәвиләр яши икән.

Урын әзерләнгәч, тиз генә самавыр куеп җибәрдек. Сөтләп чәй эчтек. Гомеремдә шундый тәмле чәй эчкәнем юк иде. Намазларыбызны укып, җирдәге шүрдүфләребез эченә кереп яттык. Дөя өстендә тоташ уналты сәгать килү аркасында бик арылган икән, яткач йоклап та киткәнмен.

---

* Кафилә — кәрван.

Иртәгесен Насыйбулла әфәнде пылау салды, дөяче бәдәвиләргә чәй бирде. Һәркем чәйдән соң җанланып китте. Мәш килеп йөриләр. Ифрат күңелле. Бәдәви малайлары һәм кызлары, сулар китергән булып, әйбер чәлдерергә йөриләр. Кечкенә кызларының өстендә күлмәк юк. Бары гаурәт турысына бездәге кашагага куя торган чәчәк бәйләнгән. Чырадайябык бәдәвиләр: «Хап, хап, хаҗи», кайберсе «Хаҗи хитап», кайсысы «Әмай, май»,— дип кычкырышып йөриләр. Хатыннары озын күлмәк кигән, кара шәл япкан, йөзләрендә күз турысында гына тишекләр калдырылган кара чүпрәк, аның өстендә тәңкә тезелгән. Алар да су сатып йөриләр.

Насыйбулла әфәнде, пылау томалагач, чәй урынын җыеп йөри. Бәдәвиләр артык әрсезләнеп китсә, аларны куа, кайберләренә чәй эчерә. Бераз ятып ял иткәннән соң, торып пылау ашадык, чәй эчеп тәһарәтләр алып, юлга җыена башладык. Шүрдүфләрне дөяләр өстенә куйдылар. Көндезге сәгать бердә кафилә кузгалды. Без тагын бишекләребездә тирбәлә башладык.

Юл матур, урын рәхәт, кояш эссесе беткәч, икенде намазыннан соң, яшьрәк ирләр шүрдүфләреннән төшеп, бәдәвиләр белән йөгерешеп, уйнашып баралар. Ахшамга тәһарәт алырга дип, без дә төшеп, бераз җәяү бардык.

Ирләр ахшам намазын җәмәгать белән укып, без яңадан дөяләргә урнашкач, төнлә фаҗигале бер вакыйга булган, бер карт хаҗи дөясеннән егылып төшеп үлгән.»

Әнием үзенең истәлегендә тагын болай дип яза: «Октябрьнең икесендә, көндез сәгать унбердә, пәнҗешәмбе көн, Мәдинәдән чыкканга унбер көн дигәндә, без Мәккә-и-мөкәррәмәгә якынлаштык. Юлда хәзрәте Мәймүнәнең каберен зиярәт иттек. Шул җиргә җиткәч, каршыга дәлилләр, мөһаҗирләр, хәерче балалар чыкты. Балалар җылапҗылап теләнәләр, хәер эстиләр...

... Озакламый Мәккә-и-мөкәррәмәгә дә җиттек. Икенде вакыты узган иде инде. Шәһәргә кердек. Мөбарәк җиргә кергәндә җәяү барырга теләсәм дә, фатир ерак, дип төшермәделәр. Шәһәргә кергәндә үк безгә бер татар малае очрады. Бездә беркем дә юк,әнием белән апам гына, өебезгә Хәрәм шәриф тә бик якын дигәч, бер русияле Гомәр әфәнде өенә төшәргә булдык.

Менә Мәккә шәһәренең киң урамнары. Урам тулы халык. Кайберсе бәләкәй ишәкләргә атланган.

...Шәһәрнең тар урамнарына кереп киттек. Ниһаять, киңрәгенә килеп чыктык. Дөяләр тукталды. Без дә, уф алла, дип, бер иркен сулу алдык. Чөнки соңга таба безнең урыннар тәмам бозылган, шүрдүфтә утырулары ифрат җайсыз була башлаган иде.

Әлеге кечкенә татар малае Салих атлы икән. Ул безне өйләренә алып китте. Кадыйрлар әйберләрне рәтли калдылар. Тар гына баскычтан югары катка мендек. Зур, чиста гына гарәп өе. Әйберләр белән ул арада Кадыйрлар да кайтып җитте. Аш ашадык, чәй эчтек. Тәһарәтләр алып, Кәгъбәтуллага киттек. Тотынышып, догалар укый-укый, Бабелислам капкасыннан кердек. Кергәч тә дәлил йөзебезне ачтырды. Кәгъбәтулланы күрсәтте. Хәрәм шәриф ифрат зур, әллә ничә мең кешене сыйдырырлык. Алты манарасы, кырык ике ишеге бар. Уртасында ифрат киң мәйдан. Мәйдан уртасында — Кәгъбәтулла. Ул дүрт почмаклы мөрәббәгъ дүрткел шәкелендә «Лә иләһе илләллә, Мөхәммәд рәсүлуллаһ»* дигән кәлимәләр белән тулы, тукылган постау кебек кара материя. Хәрәм шәрифнең һәммә җире кандилләр белән яктыртылган. Кәгъбәтулла янында халык кайнап, тәваф кылып йөри...

...Тәваф кылып бетергәч, ике рәкәгать тәваф намазы кылып, Хәрәм шәрифтән чыгып киттек.

---

* Аллаһтан башка хак-илаһ юк. Мөхәммәд Саллаллаһи галәйһиссәлам аның илчесе.

Кадыйрлар юлда чәч алдырдылар. Без дә өйгә кайткач, чәч очларыбызны кисеп, тарап үрдек. Ихрамда* вакытта чәч тарарга, битне сабынлап юарга, ихрамны йөзгә тидерергә ярамый.

Шулай итеп, ул көнне хаҗыбыз тәмам булды».

## 20

Сөйкемле секретарь апа мине һаман тынычландыра, һаман сабыр итәргә куша, сезнең язмыш хәл кылынып бетмәгән әле, ди. Бу комиссия өчен бер өтек студент язмышын хәл итү шулкадәр авыр эш микәнни, дип аптырыйм.

Мин тагын көнне Мәскәү урамнарында үткәрәм. Хәер, вакыт уздыру өчен хәзер Казан вокзалына да баргалыйм. Бәлки, берәр казанлы танышны очратырмын дип, вокзалның күккә ашкан биек, яңгыравык залларындагы халык ыгы-зыгысын ярып йөрим. Бер тапкыр, йөрер юлымны үзгәртә төшеп, Каланча урамына да чыктым, Садово-Спасскаяда да булдым. Инде хәлдән тайгач, Басманнаядагы кафега кереп, бик аз гына акча тотып, тамак туйдырдым. Юк, ни әйтсәң дә, тамак туйгач, таныш бакчадагы таныш эскәмиягә кайтып ял итүе шәбрәк...

Тик менә хәтер дигәнең алны да, ялны да белми...

Менә без, биш дус, озакламый җиде еллык мәктәпне тәмамлаячакбыз. Минем киләчәгем мәгълүм. Мин Сабынчы урамындагы дусларым юлыннан китәчәкмен. Наил дә, Зиннәт тә, Гомәр дә күздән бирле инде Сталин исемендәге ФЗӨ мәктәбендә укыйлар. Болар — шулай атарга яраса — урам дусларым. Ә тегеләре исә — Миша, Вова, Митя, Равил — мәктәп дусларым. Минем «урам дусларым»ның өчесе дә токарьлеккә өйрәнәләр. Наил нык бәдәнле, интеллигент йөзле, типик татар малае. Аның техника белән кечкенәдән җенләнүен, тумыштан йөрәк чире белән азаплануын мин язган идем инде. Гомәр урта буйлы, кара тутлы, озынча йөзле, шадра, хәйләкәррәк һәм саранрак, артык хуҗалыклы, әмма үзе менә дигән гармунчы. Зиннәт исә барыбыздан да буйлырак, ябык, озын, коңгырт күзле, теләсә нинди авыр эшне дә сөеп, күңелле итеп башкара торган үсмер. Ул ифрат беркатлы, садә, дуска түгел, дошманга да хыянәт итмәс. Мин аның җырчы булуын теләгән идем. Чөнки аның моңлы баритон тавышы шулкадәр көчле, безгә бергәләп «Алмагачлары» көен җырларга туры килгәндә, Зиннәтнең тавышы барыбызныкын да басып китә.

Гафифә апаларга күчкәннән соң, мин ул урам дусларымны сирәгрәк күрәм. Ләкин, һәр мөмкинлектән файдаланып, алар янында булырга тырышам.

Алар белән очрашкан саен, сүз хәзер токарьлек һөнәре турында бара. Тегеләр үзләренең булачак һөнәрләрен мактап бетерә алмыйлар, телләрендә — мастерской, станок, кискеч, американский патрон һәм тагын мин белмәгән, мин ишетмәгән бик күп нәрсәләр. Шул кадәресен дә тоям: алар үзләренең миннән өстенрәк икәнлекләрен аңлатырга тырышалар. Аларга икмәкнең дә күкрәк киереп кисәрлек зур сыныгын бирәләр — беренче категорияле карточка, сигез йөз грамм! Ә мин нәрсә? Бер йолкыш укучы малай. Алар эштән соң кара борын, корымлы маңгай белән кайталар. Алар — ил хуҗасы, эшчеләр сыйныфы! Ә мин кем? Мин — аксөяк, мәми авыз. Юк, мин дә ФЗӨ га керәм, мин дә токарьлеккә өйрәнәм!

Без класстагы биш дус арасыннан Митя Сальяшинов белән икәү генә ФЗӨ га керергә булдык. Бу уртак теләк мине Митя белән тагын да

---

* Ихрам — дини хаҗилар кия торган япма, кием.

якынайта төште. Тәнәфес вакытларында без гел бергә хәзер. Сөйләшенгән сүз — үзебез укырга керәсе өйрәнчекләр мәктәбе турында гына.

Митя миннән тазарак та, калкурак та. Ул киң битле, сыланып торган салам чәчле, җәенке борынлы, борын тирәләрендә сирәк кенә шадрасы да бар. Аның сыек зәңгәр төстәге күзләре, күпвакыт аскы кабаклары күперенке булганга ахры, кысыграк. Шуңа күрә ул еш кына елмайган сыман булып күренә.

Укулар бетеп, таныклык алгач, мин Миша Алатский белән пионер лагерена, Кама буендагы Красный Борга киттем. Без Вахитов заводы клубы каршындагы отряд пионерлары идек. Путевканы шуннан бирделәр.

Лагерьда ял итеп, Камада туйганчы су кереп, лагерьдагы физкультура ярышларында катнашып, вакытның узганын да сизмибез. Мин, лагерьдан кайту белән, Митя янына барачакмын.

Митяның үги әтисе — Михаил Петрович — тупас йөзле, бөтен битен сары сакал-мыек каплаган, «Кызыл шәрык» сыра заводында ломовой; әнисе исә — Мария Павловна — элек-электән без эшкә керәсе заводның шәм цехында эшли. Митяның тагын әле укырга кермәгән җиде яшьлек, Борис исемле тиктормас энесе дә бар. Анысы — үги әтисенең малае.

Мин лагерьдан кайтканда әнием Казанда иде инде. Ул, мин ял иткән арада, миңа яңа торыр урын эзләп йөргән. Әмма, күп эзләнүләренә карамастан, берни дә майтара алмаган. Мин аңа үземнең планнарымны сөйләдем, аны көндергәч, Митяларга киттем.

— Я, ничегрәк, син ФЗӨ турында кире уйламагансыңдыр бит? — дидем мин аңа.— документларыңны илтмәдеңме әле?

Юк, илтмәгән икән. Мине көткән. Хәзер бу эшкә вакыт җиткәнлеген әйтә, соңга калмадык микән әле, дип, күңелгә вәсвәсә сала.

Мин үзем алдан ук аяк киенгән идем инде, хәтта Митяларга барганда үтенечем дә кесәдә иде. Без, эшне озакка сузмас өчен, шундук андый гаризаны Митя исеменнән дә яздык һәм сабын заводының ФЗӨ канцеляриясенә юнәлдек.

Юлда Митя үзенең көтелмәгән бер тәкъдиме белән мине чиктән тыш шатландырды. Мин аны бу дәрәҗәдә үк тирән дуслык хисләрен кичерә белә торган егет дип уйламаган идем.

— Беләсеңме нәрсә, Атилла,— диде ул.— Синең бик тә хөрти квартирада яшәвеңне беләм мин. Мин өйдә әнием белән сөйләштем. Әйдә, безгә күчеп кил. Без синнән квартир өчен бер тиен дә алмабыз. Бергә ашарбыз, тик продукты карточкаларыңны гына әнигә бирергә онытма.

Мин, колакларыма ышанмастан, Митяга текәлдем:

— Син моны чынлап әйтәсеңме, Митя? — дидем.

— Менә тагы! — диде Митя, үпкәли төшеп.— Мондый эш белән шаярып буламыни?!

— Ә әтиең? Михаил Петрович?

Митя кулын гына селтәде:

— Ә ул әни сүзеннән чыкмый.

Әнием, әйтканемчә, җәйге каникулда, хәзер инде Казанга күчеп килгән Габдрахман абыйларда торып тора. Митяның миңа ясаган тәкъдиме үзем өчен генә түгел, аның өчен дә күктән төшкән бер бәхет булачак.

Без Митя белән документларыбызны илтеп тапшыргач, яңа һөнәрләребезне ачыклау өчен тагы килербез, дип, урамга чыктык. Дустымның тәкъдиме турында әйтеп әниемне дә куандыру өчен, трамвайга утырып, Арча кырына таба, Габдрахман абыйлар квартирына киттем.

Шат түгел идеме соң минем хәбәремә әнием!? Ул, барын да

җентекләп сорашканнан соң, үзе дә Митяның әнисе белән таныштырга, аның белән сөйләшергә теләде. Мин аларны озакламый таныштырдым, алар бик тиз уртак тел таптылар. Гомере буена заводта эшләгән намуслы эшче хатын Мария Павловна беренче күрүдә үк кешенең ышанычын казана торган зат иде. Үз гомерендә бик күпләр белән очрашкан, тормышның ачысын-төчесен нык татыган әнием аны шундук үз итте.

Минем токарьлеккә өйрәнү мәсьәләсе дә җайланды. ФЗӨның кыру станогы бирәү генә икән. Шуңа күрә ул бары ике токарь гына әзерли ала. Минем бик токарь буласым килгәнен белгәч, әле яңа гына завуч булып эшли башлаган, теге чакта безнең документларны кабул итеп калган Кузнецов исемле бик тә ягымлы абый ул станокка өйрәнчек итеп мине һәм тагы Цветков фамилияле бер рус малаен билгеләде. Мин, озын-озакка сузмастан, булган әйберләремне Гафифә апалардан алып, Мария Павловналарга илттем. Әнием исә, минем өчен шактый тынычланган хәлдә, үзенең Шәлесенә китеп барды.

Менә мин хәзер Митяларда яшим. Без яңа уку йортында икебез ике группага эләктек. Мин токарьлеккә өйрәнәм. Митя тимерче һөнәре серләрен үзләштерә. Рәхәт. Завод та, мактап тә ерак түгел. Мактап бинасын әле күптән түгел генә салдылар. Ул — заводтан ары Плэтән һәм Тукай урамнары чатында. Биек, ике катлы, таш бина. Классларда өр-яңа өстәлләр, идәннәре сап-сары, әле генә буялган. Котылдым мин Гафифә апаларның шыксыз, ярым караңгы, күгәрек исе килеп торган фатирыннан. Монда без Митя белән «әлиф ятып», саф һавалы иркен бүлмәнең идәнендә йоклыйбыз. Мария Павловна безгә һәр көнне иртән ярмаланып торган кайнар бәрәңге пешерә. Икмәк җитәрлек. Көндезләрен без завод ашханәсендә тукланабыз. Дөрес, анда күбрәк кәбестә ашы, ите дә бармак башы хәтле генә, икенчегә дә күбрәк саго, ясмык, яки арпа ярмасыннан пешерелгән ботка була. Ләкин аның каравы ул бик арзан. Аннан, ни әйтсәң ди, бу сабын заводы бит әле! Сабынны майдан кайнаталар. Пахта мае, җитен мае тулып ята.

Мин укыган класста укучыларның күпчелеге татар. Митялар классында исә күпчелеге руслар. Югыйсә, параллель класс, бер программа белән чиратлашып, бер аудиториядә укыйбыз, бер хезмәт урынында эшләп өйрәнәбез. Безнең бу рәвештә шундый программа белән уку Казанда беренче эксперимент булмады микән әле?

ФЗӨ минем тормышыма яңа бер сулыш өрде. Мондагы мөхит, хезмәт һәм мөнәсәбәтләр — минем өчен яңа. Беренче тапкыр кыру станогы янына килеп баскан мизгелемне мәңге онытасым юк! Металл суыклыгы, кискеч очыннан тимер йомычканың бөтерелеп, җанлы нәрсәдәй өскә күтәрелүе...

Көннәрдән бер көнне безгә эш киемнәре бирделәр. Чем-кара сатин чалбар, шундый ук дүрт кесәле пинҗәк, тупас, ләкин бик нык ботинкалар һәм барыннан да күңеллерәге — көрән төстәге шыгырдап торган, юка, хром җиңсәләр. Барысы да өр-яңа, әзрәк бушрак бушрагын, ләкин аның каравы бу бит — эшче киеме!

Шул спецовканы киеп хозурланганымны хәтерлим. күңелдә әйтеп бетергесез шатлык хисләре. Әйтүе генә ансат! Мин бит хәзер илнең иң кадерле кешесе, хуҗасы!

Әдәбият белән кызыксынуым билгеле бер тәртиптә булмаса да, өзлексез көндәлек әдәбиятны уку һәм мәктәп мине чын мәгънәсендә совет рухында тәрбияләгәннәр иде. Мин хәзер рус әдәбиятын да укыйм. Көндәлек матбугатта мактап телгә алынган бер генә әсәрне дә укымый калмыйм.

Вакытлы матбугат дигәннән, мин үзем аларны яздырып алмасам да, табам. Татар телендә чыккан һәр газетаны, һәр журналны башыннан азагына кадәр укып барам. Вахитов клубының уку залындагы иркен өстәлдә ята алар. Һәр көн диярлек кичкырын шунда кереп уты-

рам да, уку ләззәтенә чумам. Дөресен әйтим, кайчакларда башлаган әсәремне уку залы ябылганчы укып өлгермәү куркынычы да туа. Мондый вакытларда, сиздермичә генә куенга кыстырып, журналны өйгә дә алып кайткалыйм. Юк, мин үземне карак дип исәпләмим, мин бары укый башлаган әсәремне бик-бик яратканмын, шуңа күрә аннан аерылып бер генә төнемне дә уздыра алмыйм. Аны укып чыгу белән, яңадан китапханәгә алып барып, шулай ук кеше сизмәгәндә генә, өстәлгә куям.

Без һөнәр аласы заводның ремонт цехында эшләр болайрак башланды. Беренче көнне мине Сергеев дигән яшь бер эшче станок һәм эш кораллары белән таныштырды. Мин, урам дусларымнан ишетеп, аларның байтагын белә идем инде. Остә калдыру авыр булмады. Сергеев коралның исемен әйтә, мин аны кулга алам да исемен кабатлыйм.

Бу эш тәгәлләнгәч, оста мине станок янына бастырды. Өстә асылынып торган тимер чыбыкны тартты. Кинәт станок патроны, мине сискәндереп, бик кызу әйләнә башлады, сул яктагы сырлы тәгәрмәчләр гөрләп хәрәкәткә килде.

— Яле, бер стружка алдырып кара әле, егет,— диде оста.

Шулай итеп, мин станокта металл кырдыру әлифбасын, заманына күрә фырт киенгән, башына ялтыр козыреклы капитанка элгән Сергеев фамилияле егет кул астында үттем.

Безнең Плэтән чатындагы мәктәбебездә дә укулар бара бит әле. Хәтердә, металл технологиясен безгә Синев дигән бик тәҗрибәле абзый укытты. Ул металл эшкәртүнең бөтен серен белә. Инженермы, техникмы ул Синев? Тышкы кыяфәте, торышы, теле белән ул мастеровой эшчегә тартым. Мәгәр белеме — инженер белеме. Юравымча, ул гади эшчедән күтәрелгән, үзлегеннән укып белем алган кеше иде.

Мин һөнәрне тиз үзләштердем дип уйлыйм. Конуслар кырдыру, андагы исәпләүләрне дә яхшы башкарам. Шулай да, шәп токарьләр кебек тәмле итеп, күңелле итеп, уйнап кына торгандай итеп эшләп булмый. Тәҗрибә җитми. Ай-һай, тәҗрибә генәме икән? Сәләт җитми булса кирәк. Мин ашыгам, кабаланам, игътибарымны бер ноктага туплый алмыйм. Бу инде, күрәсең, сәләт эше. Гомеремдә беренче тапкыр сәләт дигән нәрсәнең хезмәт башкарганда нинди зур роль уйнаганын үз башымнан кичердем мин. Әйе, хәзергә тойдым гына, әле аңламадым. Сәләтнең шәхси бәхет өчен һәм, гомумән, кешелек өчен нинди зур урын тотканын соңыннан, күп еллар узгач кына чын мәгънәсендә аңлаячакмын әле мин.

Берәүләр турында ул эшен яраткан, шуңа күрә уңышка ирешкән, диләр. Сүз дә юк, яраткан. Ләкин кайбер кеше үз хезмәтен башта ярата да, соңыннан ни өчендер өнәми башлый. Минемчә, хезмәтеңне әгәр ул синең күңелеңдә канәгатьләнү тудырса, рәхәтлек бирсә генә яратасың.

Соңыннан, татар әдәбияты мәйданында «үз кеше» булып киткәч, күп кенә язучылар белән якыннан таныштым мин. Аларның бик тәҗрибәле, әмма чамалы сәләткә ия булганнары белән дә очрашырга туры килде. Авыр, авыр иде аларга, иҗат куанычларыннан битәр, алар иҗат газапларын кичереп яшиләр иде.

Әйе, бик-бик дәртләнеп, токарьлек һөнәренә өйрәнә башладым. Ул ифрат мавыктыргыч, кызыклы хезмәт. Ләкин, әлеге дә баягы каударлану гадәтем кайчак мине авыр хәлләргә калдыра. Башкалар сабыр гына эшли алганда, кызып китәм һәм шуның аркасында, еш кына, ясалып яткан детальне бозып куям. Алай да эшлим үзем, сөртенгәләсәм дә, алга барам.

Шулай итеп, мин эшчеләр сыйныфының бер вәкиле булып киттем. Минем дуслар күптән тәмәке тарталар иде инде, цехтагылары да шәп көйрәтәләр. Мин дә тәмәке тарта башларга булдым. Моның эштә

әйбәт кенә сылтавы да бар бит әле: янәсе, тартмасаң, ничек инде эш арасында, станокны туктатып, ял итеп ятарга була? Ләкин бу күз буяу гына иде. Нигезендә аның теге Сабынчы урамындагы дуслардан калышмау теләге ята.

Эшчеләрнең яше-карты, хәтәр сүгенеп, оятсыз сүзләрне бик мул сиптереп сөйләшә. Нигә, мин алардан киммени? Анысын да тиз арада үзләштердем. Завод капкасы янында гына аяксыз татар инвалиды тәмәке сатып утыра. Ул эшкә килүчеләргә, бик шаулап, үзенең тәмәкесен мактый.

— А ну, налетай! Табак саранский, я сам казанский. Налетай, покупай! Один раз курнешь, тридцать три раза п...!

Акча булганда шул зәһәр сасы тәмәкене чалбар кесәсенә бер стакан тутыртып аласың да, көне буе бай сыман кыланып йөрисең. Инде акча яклары такыр чакта, абый синең кесәңә ярты стакан яки чирек стакан гына сала.

Кайчагында цехка ашыгыч заказлар килә. Андый вакытта безнең кебек «фабзайчонок»ларны да, ярдәм итәр өчен, цехтагы станоклар янына бастыралар. Гадәттә, бу инде — икенче сменага калу дигән сүз. Шунда карт эшчеләр белән еш кына гәпләшәбез.

Алар безнең белән күбрәк шаяртып кына сөйләшәләр. Эштән туктап тәмәке тарткан араларда әллә нинди оятсыз табышмаклар белән йөдәтәләр, йә булмаса тузга язмаган нәрсәләр турында сораулар биреп баш катыралар. Мин мондый чакта оялып кызарам, минем өчен бу артык урынсыз нәрсә, үзе оят. Ә теге, шаяртып сүз алып баручы кеше, аптырап калуыбызны безнең аңгыралыктан, тәҗрибәсезлегебездән күреп, рәхәтләнеп көлә, безне «агартырга» теләп, ир белән хатын арасында гына була торган хәлләрнең нечкәлекләрен аңлатырга керешә.

Без әнә шулай һәрьяклап һөнәр һәм тәҗрибә туплыйбыз. Шулай эшчеләр гаиләсендә яшәп, эшчеләр гаиләсендә эшләү мине күп нәрсәгә өйрәтте. Мин бу сыйныфның мал колы булмавын, өзлексез дулап торган тормыш океанында хәвефле бер көймәдә бергә-бергә ишеп баручы кешеләр икәнен аңладым.

Завод мине хезмәт дигән нәрсә белән бүрек салып сөйләшергә өйрәтте. Син зур эшкә тотынасың икән, башта ныклап уйла, егет: ничек итсәң ул сыйфатлы да, рух азыгы да, кешеләргә файдалы да булыр, диде миңа хезмәт.

Әлбәттә, ул чорда, беренче бишьеллык чорында, ашау-эчү һәм кием-салым яклары әйтеп бетергесез хөрти иде. Бөтен нәрсә карточка, йә ордер белән бирелә. Анда да котырмаслык кына. Икмәк — бары тик чи арыш ипие генә, анысы да кибеттә еш кына булмый тора. Ул әләксен өчен, сәгатьләр буе чират торырга, биш дилбегә буе чират үткәрергә туры килә. Кайчагында икмәккә төннән үк чират алып, уч төбенә номер суктырып, кибет ачылганын көтеп зарыгасың.

Безгә шулай да рәхәт. Без идеаллар, зур өметләр белән яшибез. Эш беткәч, Вахитов клубына барабыз. Кино карыйбыз. Еш кына гастрольләр була анда. Хәтердә, беренче тапкыр Спарри дигән гипнозчы үзебезне хәйранга калдырды. Хәтта үземне сәхнәгә чыгарып, әллә ниләр кыландырып бетерде. Безнең клубта тагы шактый мәшһүр шагыйрь Михаил Голодный чыгыш ясады. Һич онытылмый, бу буйчан, көлтә чәчле шагыйрь очына-очына үзенең шигырьләрен сөйләде. Ләкин зал аның шигырьләрен өнәмәде, залда тавыш, үзара сөйләшү, көлешү һич тукталмады. Ахырда горур шагыйрь моңа түзмәде, публиканы мокытлыкта, тәрбиясезлектә гаепләп, сәхнәдән дулап чыгып китте.

Бервакыт безнең клубта Лидия Сәйфуллина да булды. Ул үзе генә түгел иде. Бу атаклы Мәскәү язучысына безнең татар әдипләре дә ияргән иде. Хәтерем ялгышмаса, алар арасында Мирсәй Әмир, Ибра-

һим Гази, Төхфәт Имаметдинев һәм тагын кемнәрдер бар иде. Сәйфуллина үзенең чыгышында Мирсәй Әмирнең «Аяк» дигән хикәясенә «таш атып» узды. Соңыннан чыгыш ясаган Мирсәй Әмир — ул вакытта яшь, чибәр кеше — хәтере калган хәлдә: «Без Лидия апа хәтле үк шәп яза алмыйбыз шул»,— дип куйды.

Ял көннәрендә мин Наилләргә барам. Наил, Зиннәт, Гомәр һәм мин, дүртәүләп, еш кына «Чаткы» кинотеатрына китәбез. Аңа якын ларекта сыра саталар. Акча булса, сырадан авыз итүдән дә баш тартмыйбыз. Аны эчү ул, безнеңчә — егетлек, мөстәкыйльлек билгесе, янәсе.

Бервакыт без Митя белән циркка бик еш йөри башладык. Анда безне җәлеп иткән нәрсә французча көрәш булды. Нинди генә көрәшчеләр исеме безнең авызларда әвәләнмәде ул чак! Бервакыт Казанны аякка бастырган Хаҗи Морат дигән көрәшче килде. Ул чыгыш ясаган көннәрдә татар агай-энесе циркны шыгрым тутыра. Шул гастрольләрдә дип әйтимме, ярышларда диимме, миңа рус баһадиры Иван Поддубныйның да көрәшкәнен күрергә туры килде.

Кышкы айларның берсендә шул ук шәһәр циркында Мюзик-холл гастрольләре башланды. Без Митя белән, арзанлы гына билетлар алып булса да, аның һәр спектакленә йөрдек. Атаклы Нальскийның уенын күрдем мин шунда. Ләкин ул бик сәер булып истә калган. Нальский уен барышында опереттаның сюжетына һич бәйләнеше булмаган, әмма безнең көндәлек тормышка, хәтта политикага кагылышлы репликалар әйтеп җибәрә иде. Бер репликасы әле дә истә. «Нәрсә ул Мюзик-холл?» — дип сорый артист, үзе үк җавап та бирә: «Ул музыка на хо-ло-де!»... Чыннан да, циркта коточкыч суык иде, Нальский шуңа ишарә ясый.

Кайвакытларда без Митя белән өйдә репродуктор янында озаклап концерт тыңлыйбыз. Мин Митяның татар музыкасын яратуына әле дә гаҗәпләнәм, чөнки русларның татар музыкасын шул дәрәҗәдә яратып тыңлаганын элек тә, соңыннан да күргәнем булмады. Митя аерата Сәйдәшев музыкасына гашыйк. Андый тапшыру булса, ул радионы миннән дә битәррәк бирелеп тыңлый.

Берәр ай чамасы без Митя белән ОСОДМИЛ*чы да булып йөрдек. Без хәзер, беләккә кызыл тасма бәйләп, еш кына «Чаткы»да тәртип саклыйбыз; җыйнаулашып, хулиганнарны өркетеп, урамнарда патруль булып йөрибез. Ләкин бу эш мин көткәнчә үк романтик булып чыкмады. Бер вакыйгадан соң, мин уйга калдым һәм бу эштән ваз кичтем.

Шулай көннәрдән бер көнне Митя белән безгә милиция бүлекчәсеннән бер вак каракны милициянең Черек күл артындагы шәһәр идарәсенә илтергә куштылар. Без, әлбәттә, мондый зур ышанычка шатланып, теге каракны — олы яшьтәге татар абзыен — урлаган капчыктагы әйберләре белән озата киттек. Абзый салмак кына атлап бара, өстендә иске брезент яңгырлык, башында колакчыны ертык бүрек, аркасында җиңел генә нәрсә салынган капчык. Тик бу агайның баштагы адымнары гына шундый тыныч, салмак һәм үзе бик күндәм күренгән икән. Аның белән газапны күрәселәребез алда икән әле.

Мин бирелә аның белән нинди газаплар чигүебезне тулы итеп язмыйм. Аның чат саен түктап озаклап ял итүен дә, инде без Кольцога җиткәч, кинәт җиргә ятып: «Каравыл, талыйлар!» — дип халык җыюын да... Без аны шулай да, өстерәп дигәндәй, көч-хәл белән тиешле урынга илтеп тапшырдык. Ләкин безне бу «романтикалы» эштән ваз кичәргә мәҗбүр иткән нәрсә аның чыгымлаулары түгел, ә бәлки аны тиешле урынга тапшырганнан соң булган хәл иде.

Әле дә күз алдымда: иркен бүлмәдә — барьер, барьерның эчке

* ОСОДМИЛ — общество содействия милиции

ягында ике милиционер. Митя бүлекчәдән бирелгән кәгазьләрне шуларның берсенә тапшыра. Каракны барьерның теге ягына кертәләр. Һәм ни эшлиләр? Милиционерлар теге абзыйны кыйнарга керешәләр. Алар — икесе ике якта. Әле берсе суга, әле икенчесе. Карак әле бер милиционерга таба авып китә, әле икенчесенә.

Мин, үз күзләремә ышанмастан, бу тетрәткеч тамашаны күзәтәм. Гуманизм рухында тәрбияләнгән, бездә ору-сугу кебек җәзаларның булуы мөмкин түгел дигән кагыйдәне үзләштергән кешегә бу җитә калды. Мин андый эштә милиция әһелләренә ярдәмче була алмаячагыма шундук ышандым. Без өйгә кайтканда, ничектер, Митя белән бер-беребезгә карарга да уңайсызланып, тавышсыз-тынсыз гына атладык. Шул көннән башлап ОСОДМИЛга йөрмәс булдык.

Мине өйдәге яман хәлләр дә чиркандыра башлаган иде инде. Атнасына бер көн — шимбә көн булса кирәк — Митяның тиктормас энесе Борис җәзаланырга тиешле көн. Бу, гадәттә, өйдәгеләр йокларга яткач була. Митяның үги әтисе, Борьканы табуреткага корсагы белән яткыра да, чалбарын төшереп, малай атна буена ясаган «гөнаһларны» саный һәм һәрбер «гөнаһы» өчен, аларның дәрәҗәсенә карап, каеш белән суктыра. Бу алгы бүлмәдә, ә без залда тын гына ятабыз. Боря җан ачысы белән үкерә, бүтән алай эшләмәм, дип антлар итә. Аның саен Михаил агай: «Менә монысы фәлән, ә менә монысы төгән өчен»,— дип сөйләнә-сөйләнә, улын каешлый.

Минем өчен — гайре табигый хәл, мин аңламый торган гаҗәп нәрсә иде бу! Белүемчә, безнең халыкта баланы шулай җәзалау юк, һәрхәлдә, минем моны күргәнем дә, ишеткәнем дә булмады. Мин моңарчы андый нәрсәне Горький әсәрләреннән генә укып белә идем. Соңыннан, еллар узгач, байтак рус дусларымнан ишетеп, рус халкында, аерата крестьян гаиләләрендә, моның гадәти йола икәнлеген белдем.

Без Митя белән бер-беребезнең сүзеннән чыкмый яшибез. Ә укуга килгәндә, ул да ярыйсы бара. Әйткәнемчә, безнең группада (ул заманда классны «группа» дип атыйлар иде) күпчелеге — татар малайлары, татар кызлары.

Башта малайлар турында. Без җидәү: Мөхәррәмев, Шибаев, Енгалычев, Салихов, Дербишев, Хәйруллин һәм мин. Егетләр арасында минем өчен иң якыны Рәсүлзадә Салихов дисәм, ялгышмамдыр. Бу — төз гәүдәле, киң күкрәкле, калын тавышлы, аз сүзле егет. Мин соңрак аның әтисе Сәмигулла абзыйның заманында бик күренекле җәмәгать эшлеклесе икәнлеген, думаларга сайлануда выборщик булып актив катнашкан, немец телендә нотыклар сөйләп, читтән килгән кунакларны каршылаган, җаваплы һәм сәләтле кеше булганлыгын белдем. Аның берничә абыйсы, бер апасы бар. Энисе, Зөһрә апа, олы яшьтә булуына карамастан, әле дә ифрат нибәр, горур, шулай ук заманында алдынгы хатын-кызлардан булып, җәмәгать эшләренә катнашып йөргән.

Рәсүлзадә бик оста рәсемче иде. Казандагы Гаспринский исемендәге җидееллык мәктәпне тәмамлаган. Ләкин, ниндидер сәбәпләр аркасында, ФЗӨгә килеп эләккән. Үземчә шуны гына юрап әйтә алам: ул елларда аның әтисен совет органнары эзәрлекли башлаган булса кирәк. Чөнки ул, белүемчә, утызынчы елның урталарында кулга алынды. Шуңа күрә, минемчә, аның әнисе, улыбыз эшче сыйныфын калкан итеп мондый хәлләрдән исән-сау котылыр, дип уйлагандыр.

Хәтердә нык сакланган егетләрнең берсе — Мөхәррәмев. Хәтерем ялгышмаса, ул әнисе һәм бер кыз туганы белән генә яши иде. Җәен дә, кышын да сынык козыреклы аксыл-чуар иске кепка киеп йөри. Өстендәге төсе уңып беткән ситсы тышлы бишмәте дә, ямаулы күлмәкләре дә аның бик авыр тормышта яшәве турында сөйлиләр. Безне Рәсүлзадә белән сурәт ясау якынайтса, Мөхәррәмев белән әдәбият

дуслаштырды. Мөхәррәмев шигырьләр яза иде. Ләкин ул моны бик нык яшерә. Ачыктан-ачык әдәбият турында сөйләнүләрем аңа минем белән дуслашуга, минем алда берникадәр ачылуга юл бирде шикелле. Мин, ул килсә, станогымны туктатам, аның тапкыр сүзләрен, хыялланып әкәмәт вакыйгалар сөйләвен, мәгълүм шагыйрьләрнең әсәрләреннән уңышлы, истә калырлык юлларын тыңлыйм. Әгәр эш артык ашыгыч булмаса, без бик озак шулай станок янында юк-барны сөйләшеп юанабыз. Кайчакта, хыялга бирелеп, әллә кемнәр булып кыланабыз. Аннан, тыела алмыйча, көлә башлыйбыз. Мөхәррәмев миңа караганда тапкыррак, аның кыланулары да әсәрлерәк килеп чыга.

Мөхәррәмев татар әдәбиятын гел күзәтеп бара. Ул яңа басылган әсәрләрдән генә түгел, кайбер атаклы язучыларның шәхси тормышыннан да хәбәрдар. Ул миңа татар язучылары турында мин белмәгән әллә нинди яңа мәгълүматлар бирде. Без аның белән утыз өченче елның язында, укулар тәгәлләнгәч аерылыштык. Ул башка цехка күчте булса кирәк. Шуннан соң мин бу романтик, хыялга бай, мәзәкчел, йомшак табигатьле егет белән бер тапкыр да очрашмадым.

Үзем якын күргән өченче егет Шибаев Әнвәр атлы. Ул безнең барыбыздан да матур, барыбыздан да әйбәтрәк киенә. Башында — ул заманның модалы капитанкасы булыр, өстендә — мин моңарчы гомеремдә кияргә хыялланмаган соры каракүл якалы пәлтә. Әнвәрнең йөзе ап-ак, тулы, зәңгәр күзләрендә һәрвакыт наянлык чаткылары көйри, авыз-борын бик тә килешле. Әнвәр гел көр күңелле, һаман шаян сүз, кызык вакыйга булыр аның телендә. Тик аның сөйләвендә гаҗәп бер үзенчәлек бар: ул да булса — һәрбер хикәясе хатын-кыз мәсьәләсе, секс хәлләре белән тәгәлләнә. Сөйләп бетерүгә үк ул, кулларын чәбәкләп: «Эх, мәлтәтәй»,— дип куя, үзе сөйләгәннәрдән үзе кәефләнеп, кулларын уа. Ул безнең белән укучы, үзе кебек тулы, ак йөзле, аксыл чәчле кызга гашыйк. Шуның белән җенләнә, шуның белән булачак татлы минутларны күз алдына китереп дәртләнә.

Күп еллардан соң, сугышлар бетеп, армиядән кайткач, ул Әнвәрнең Казанда яшәвен, шофер булып эшләвен ишетәчәкмен әле мин.

Безнең белән нык кына аралашкан егетләрнең тагын берсе — Сәлим Дербишев. Бу егет исә — кайчандыр әниемне этигә димләүче Гали Дербишев оныгы. Ул бакыр чәчле, җирән, йөзен эре сары сипкел көрпәсе баскан, зур яшькелт-сары күзле, мишәр акценты белән сөйләшә. Ул, күзләрен тасрайтып, үзенең ачы-нечкә тавышы белән һәрвакыт сүзгә тыгыла, үзенең һәр мәсьәләдә белдеклелеген сиздерергә ашыга. Безнең арада ул артык абруй казанмаса да, без аны читкә тибәрмибез. Әллә аның ифрат беркатлы булуы, әллә дуслыкка бер дә хыянәт итмәве аңа карата олының кечегә булган мәрхәмәтлелеге кебек тойгы уята шикелле. Алар Московский урамының вокзалга якын ягында, бер пычрак ишегалдындагы квартирда яшиләр. Сәлим — эти-әнисенең бердән-бер улы. Аның этисе Газиз абзый — бухгалтер, ләкин ул чирле, елына бер-ике тапкыр психбольницада ятып чыга. Әнисе исә — Мөнирә апа — гаилә тәрәге, иртәдән кара кичкә кадәр эштә. Сәлимнәрдә безнең, аулак өй ясап, Зиннәтләр, Наилләр, Гомәрләр белән кәефләнеп — гармуннар уйнап, җырлап утыргалаган да бар. Әйе, безнең арада хәзер инде минем балачак дустым, Троицкидан Казанга укырга килгән Морат Габетдинев тә була.

Сәлим, ФЗӨне тәмамлап, заводта берәр ел чамасы слесарь булып эшләгәннән соң, Казан институтларының берсенә кереп укый башлады. Ләкин аның язмышы артык фаҗигале булып бетте. Инде югары уку йортын тәгәллим дигәндә генә, ул этисе һәм әбисе җәфа чиккән авыруга юлыга. Күрәсең, ул чир аңа нәсел мирасы булып калгандыр. Көннәрдән бер көнне, моңарчы сау-сәламәт күренгән Сәлим этисе больницада чакны, төн уртасында уяна да, тыныч кына

йоклап яткан энисенең корсагын пычак белән ярып җибәрә. Сәлимнәр белән бер үк коридорда яшәүче күршеләр иртәгесен, боларның шул хәтле озак йоклауларына аптырап, милициягә мөрәҗәгать итәләр. Милиционер килгәч, бикне ватып, бүлмәгә керәләр. Керсәләр — Мөнирә апа кан эчендә ята, үлгән; ә Сәлим исә, баштан ук ябынып, үз караватында йоклый.

— Нишләдең син, Сәлим, нишләдең? — дигән сорауга егет бер сүзне генә кабатлый: «Ул бит курчак, мин аның эчендә ниләр бар икән, дип кызыксындым»,— ди.

Сәлим соңыннан психиатрик больницада үлде.

Инде безнең арада, исеме телгә алынган Искәндәр Енгалычев дигән егет тә бар. Ничектер гәүдәсенә тәңгәл күренмәгән кечкенәрәк башлы, кытай кыяфәтле, ябык чырайлы бу егет бик фәкыйрь киенә иде. Аның да өстендә ситсы тышлы иске бишмәт, башында ямьшәеп беткән, сынык козыреклы кепка. Ул һәрвакыт куырылып, бөкрәебрәк, бишмәт чабуларын корсак турысыннан кысып йөри. Без аңардан барыбыз да шүрлибез. Аның бик ачы телле булуы, кешене хурлау, мыскыл итү аның өчен чүпкә дә тормавы безгә ошамый. Аның кечкенә генә коңгырт-кара күзләрендә ачу уты һәрвакыт көйрәп тора. Әйтерсең, аның бар теләге — өнәмәгән кешесенә бер-бер үтергеч сүз угы ату.

Искәндәр безнең барыбызга да бик ямьсез, хурлыклы кушаматлар тагып бетерде. Ләкин ул үзе эштә дә, укуда да алдыра, яшен ташыдай елдам, булдыклы.

Күп еллар күрешми торганнан соң мин аны, көтмәгәндә, Казанда трамвайда барганда бер очратачакмын әле. Аның кыяфәтенә үз-үзен тотышына хәйран калачакмын. Минем алдымда бишмәтенә төренеп бөрешеп торган усал Искәндәр түгел — ә бәлки күкрәген киергән, көләч, хәтта чибәр үк диярлек идем, бер егет басып торачак.

Безнең группада тагын Хәйруллин дигән егет тә бар. Кечкенә генә буйлы, чекри күзле, шактый ачы телле. Ул өйрәнчеклек сабагын башка цехта ала. Шуңа күрәдер, бездән читтәрәк яши.

Мин биредә ФЗӨ буенча иң якын иптәшем Рәсүлзадә Сәлиховның язмышы турында берни дә әйтмәдем. Ул Казанда институт тәмамлады. Сугыш башлангач, аны фронтка озаталар. Рәсүлзадә, әйтүләренә караганда, шунда батырлыклар күрсәтеп, башын сала.

Әйткәнемчә, без бер станокта Цветков белән алмаш-тилмәш эшлибез. Бу егет Митя белән бергә бер группада укый. Ул группада барысы да диярлек руслар.

Рус группасы белән безнең группаны чагыштырырлык та түгел. Андагы укучыларның күбесе фырт киенгән, үзләре матур, ыспай, егетләре дә, кызлары да карап туйгысыз. Аерата андагы кызларның үзләренә һич кулай булмаган һөнәр өйрәнеп азапланулары миңа сәер тоела. Әлбәттә, без ул чакта эшчене һәм завод өйрәнчеген фәкыйрь киемле, артык гади кыяфәтле кеше итеп күрергә өйрәнгәнбез. Ә болар соң? Болар бөтенләй башка кыяфәттәге затлар. Кызлары модалы күлмәкләрдән, матур мех якалы пәлтәләрдән, йөзләреннән нәфислек аңкып тора.

Хәтергә Софа исемле бер туташ сеңеп калган. Ул тулы бәдәнле, сөттәй ак чырайлы, кыйммәтле муенсалар тагып йөри торган бер блондинка. ФЗӨ укучысыннан бигрәк, артисткага охшаган. Аның апак, күперенке гүзәл куллары да чүкеч, игәү тоту өчен түгел, ә рояль телләрендә хәрәкәтләнү өчен, наз өчен яралганнар кебек иде. Җитмәсә, аның алсу симез бармакларында кыйммәтле йөзекләр ялтырый. Йә хода, шул кыз безнең арада, слесарьлыкка өйрәнә! Нинди язмыш аны монда китереп ташлаган, алла белсен!

Йә булмаса атлет кыяфәтле, өстенә күн куртка кигән, үткенгән чалбардан йөрүче Леваны ал. Аның басып торышы ук үзенә

бер төрле. Бер кулы белән бөеренә таянып, бераз янтайган хәлдә, тәмәке төтенен авыз читеннән генә чыгарып, эре генә кыяфәттә сиңа күз ташлар.

Лева — профессор Кушников улы. (Соңыннан миңа, институтта укыганда, шул егетнең әтисен тыңларга туры килде. Профессор Кушников безгә физика һәм метеорология фәннәреннән лекция укыды. Аның лекцияләрен без ярата идек. Сүз дә юк, ул абруйга лаеклы кеше булды. Тик озакламый аны, ишетүебезчә, төрмәгә япканнар. Төрле сүз йөрде: янәсе, элек ак офицер булган икән. Шуннан соң ул Казанга әйләнеп кайтмады булса кирәк).

Мин Митяларда бер елга якын яшәдем. Бу чор минем өчен авыр ялгызлыктан иркенгә, иреккә чыгу чоры булды. Мин, уналты яшьлек үсмер малай булсам да, әле балалыктан һәм балалык үзенчәлекләреннән бөтенләй котылган кеше түгел идем. Без Митя белән, ялт итеп җыештырылган өй эчен астын өскә китереп, кәрәшә дә, котырына да идек. Пычрак аяк белән, абайсызланып, көзгедәй ялтырап торган чиста идәнне дә еш кына пычратабыз. Мәгәр хуҗаларның миңа карата берәр авыр сүз әйткәннәре, караңгы чырай күрсәткәннәре булмады. Алай гына да түгел, гомумән, татар халкына карата әз генә дә кимсетү сүзе ишетмәдем мин ул өйдә! Милли мәсьәләгә килгәндә, Митяның үги әтисе генә бераз ычкынып ала: исереп кайткан чакларында аның бар сүккәне — яһүдләр. Тормышының авырлыгын ул бары шулардан күрә. Михаил Петровичның фикеренчә, яһүдләрдән дә хәйләкәр, рәхимсез һәм тәкәббер халык юк бу дөньяда. Ә татарга килгәндә, ул — ләм-мим. «Што татарин, што русский, одно и то же»,— дип кенә җибәрә.

Мин укуның беренче елын тәмамлагач, Шәледә дүрт кыш эшләгән әнием Казанга кайтты. Яңа бистәдәге татар мәктәбенә эшкә урнашты. Без тагын фатир эзләп көн-төн чаба башладык. Ниһаять, ул табылды. Хәер, аның табылуында Жорка исемле бер егеткә квартир хәсрәтен чишүем сәбәп булды ахры. Бер катлы агач өй. Шунда Жоркалар квартирының алгы ягын такта белән икегә бүлгәннәр дә, тагын бер караңгы бүлмә ясаганнар. Әлбәттә, ул заманында йокы бүлмәсе итеп эшләнгәндер, ә хәзер хуҗалардан арткан. Чөнки Жора үзенең олы апасы Лидия Васильевна белән генә яши.

Кыскасы, без әнием белән шул йокы бүлмәсенә урнаштык. Әйтеп бетергесез шат без. Әнием белән биш елга якын аерым яшәү үзәк бәгырьләремә үтте. Ә хәзер минем көнкүреш шартларым да үзгәрде. Өс-баш бөтен, әнием һәрвакыт киемнәремне тикшереп, ямап тора, ни туры килде шуны киеп чыгарга юл куймый. Вакытында ашыйм, вакытында эчәм. Әнием ризыкны тәмле, ләззәтле итеп пешерә. Мин тазарып, ныгып киттем. Хәтта әнием, син егет кеше инде дип, бер көрән төстәге йон костюм да юнәтте. Бары тик шунысы аяныч: ул костюмны үзем киеп туздыра алмадым. Аны Лидия Васильевнаның бер ерак кардәше, бер исерекбаш урлап китте. Берничә атнадан соң ул тагын килде, һәм нәкъ менә минем костюмны киеп килде. Билгеле, ул аны бераз үзгәрткән, астарын, төймәләрен алыштырган иде. Ә минем башта костюм кайгысы түгел. Семен Смирнов дигән егет белән дуслашып, уйлап табучылык белән шөгыльләнәм. Максатлар зур. Без Семка белән бөтен сабын кайнату производствосын яңа, камил технологиягә күчерергә җыенабыз. Смена беткәч тә, модель ясаучылар мастерскоенда очрашабыз. Анда Семен һәм аның әтисе модельщик булып эшлиләр. Эшләре — бер генә сменалы.

Йомычка исе аңкыган тар остаханәдә, ышкы, пычкы, өтергеләр арасында, завод хәлләрен кайгыртабыз, үзебез өчен искитмәле булып тоелган яңа җайланмалар уйлап чыгарабыз. Мәсәлән, сабын әрҗәләре ясау өчен килгән агачны әрдәнәләргә өю бик авыр эш, кул көче кирәк. Ә без аны механик көчкә күчерәбез. Сабын кайнату цехында бай-

так эш кул көче белән башкарыла. Безнең максат — эшчеләрне бу газаплардан азат итү. Әлбәттә, болар барысы да кәгазьдә генә.

Минем заводта уйлап табучылык эшем, аннан Семен белән, танышуым цехта бер белдерү укудан башланды. Көннәрдән бер көнне цехыбыздагы рәсми кәгазьләр эленгән тактада мөрәҗәгать укыдым. Анда заводның ниндидер ВОИЗ бюросы завод күләмендә конкурс игълан итә диелгән иде. «Кем дә кем сабын штамплау станын кадак ясый торган станокка үзгәртеп кору ысулын таба, сызымнарын фәлән цехтагы кешегә илтеп тапшырсын. Конкурста җиңгән кешегә премия биреләчәк».

Бу белдерүне укып чыккач, Наил белән пилмән автоматлары өстендә баш ваткан көннәрне хәтерләдем, күңелемдә ташый башлаган бер дәрт белән шушы кадак станогына керештем.

Моңа кадәр, заводның әрҗәләр ясау цехында кадак булмау сәбәпле, өзеклек килеп чыкканлыгын әйтteләр. Бу конкурс шуңа күрә игълан  ителгән икән. Мин туалет сабыннары штамплау цехына керәм, станокның сызымнарын ясап алам. Аны ничек үзгәрткәндә, җайлаганда тимер чыбыктан кадак ясап булыр икән, дип баш ватам.

Берничә көннән соң, үземнең сызымнарымны тиешле урынга илтеп, кешесенә тапшырдым. Нинди булыр инде нәтиҗә? Нинди бәя бирерләр минем җайланмага? Дулкынланып, түземсезлек белән конкурс нәтиҗәләрен көтәм.

Менә бер көнне мине заводның конструкторлар бюросына чакырдылар. Минем проект кайбер төзәтмәләр белән кабул ителгән. Төгәл расчетлар ясау өчен миңа бер техникны беркеттеләр.

Алгарак китеп әйтәм, безнең җайланма шулай да гамәлгә ашмады. Без аны үзгәртеп, эшләп бетергәнче, заводка кадак килә башлады. Әмма мине барыбер буш итмәделәр. Мин сиксән сум премия алдым. Ул премия алу турында белешмәдән Мәскәүдә, уку хокукы яулап йөргәндә файдаланачакмын әле мин.

Менә шул кадак станогы белән булган көннәрдә мин Семен Смирнов белән таныштым. Ул да бу конкурста катнашкан икән. Бераздан мәсләктәш кенә түгел, чып-чын дуслар булып киттек. Аның миннән өч яшькә олырак булуы безнең мөнәсәбәтләргә комачауламый иде.

Семен эре сөякле, бик ачык, йомшак табигатьле, кызлар алдында үзенең әйбәт мөгамәләсе, тапкырлыгы белән зур абруй казана торган, зәңгәр күзле, саргылт чәчле егет. Без аның белән бик тиз уртак тел таба алдык. Ул ифрат күндәм. Һавалану дигән нәрсәне бөтенләй белми. Эшче гаиләсеннән чыккан, ата-бабасы да эшче булган Семен Смирновны мин бик күп еллардан соң тагын очратачакмын әле. Ул мине онытмаган, үзе эзләп тапкан. Ул үз гомерен уйлап табучылыкка багышлаган.

Завод өйрәнчеклегендә чакта ук үзен гел сиздереп торган тагын бер сөекле мәшгулиятем, үземнән калмыйча, күп вакытымны алып, миңа гел ияреп йөрде. Бу — әдәбият иде. Безнең заводның күптиражлы газетасы каршында татар әдәбияты түгәрәге оештырылды. Аның җитәкчесе, газета редакторы Хан Җәмил исемле бик гади, соңыннан әдәбият җәмәгатьчелеге тарафыннан ниндидер гөнаһлары аркасында тибәреләчәк бер кеше иде. Аның «Гудок» һәм «Сөрем» исемле сәхнә әсәрләре, хәтерем ялгышмаса, татар академия театрында да куелды. Хан Җәмил оештырган әдәби түгәрәккә мин ашкынып йөри башладым. Без, һәр атнада җыелып, үзебез язган әсәрләрне укып тикшерәбез. Бераздан түгәрәк утырышларында мәгълүм язучылар да күренә башлады. Хәсән Туфанның безнең белән бик озаклап сөйләшеп утырганы хәтердә. Язучылар безнең түгәрәккә төркемнәре белән дә килделәр. Алар клубта чыгыш та ясадылар. Аннан соң аларны ашханәгә алып кереп ашаттылар. Ибраһим Газиның, ашны кабып карагач та, ашаудан баш тартуы хәтердә калган. Әле яңа гына күтәрелеп килгән бу проза

остасы, нигә ашамыйсың, дигәч: «Мин үз-үземә дошман түгел»,— дип бер иптәшенә җавап кайтарганы истә.

Тагын бераздан безнең түгәрәккә Язучылар союзыннан ярдәмгә даими шеф та билгеләделәр. Бу кеше Абдулла Алиш иде. Ул безнең түгәрәккә йөри башлаган чорда мин, зурдан кубып, завод уйлап табучылары турында повесть язарга керештем. Алиш катнашкан утырышларның берсендә бу әсәремнән бер өзек укырга да батырчылык иттем. Хәзер аңлыйм: әлбәттә, ифрат шәфкатьле шефыбыз бу эшне минем дәртемне күтәрү өчен эшләгәндер. Әмма шунысы хак: ул мине үтереп мактады. Мин бу иптәш әсәрен укыганда ук кул чапмакчы идем, тик аны бүлдерәсем килмәде, диде.

Билгеле, гомеремдә беренче тапкыр ишетелгән мактау сүзләреннән соң, минем күңел күкнең җиденче катына очты. Шул утырыштан соң, һәр буш вакытымны повестька багышладым.

Абдулла Алишның кара хәтфәдәй күзләре, тыныч йөз-кыяфәте, икегә ачып таралган чәчләре, икегә аерылыбрак торган матур ияге — барысы бүгенгедәй күз алдымда. Ул урта буйлы, нык бәдәнле, матур, зур башлы кеше иде. Беркайчан да чыгырыннан чыкмас, үзен һәрдаим рухи тигезлектә тотар. Ләкин ул сүлпән кеше түгел, үзенә мөрәҗәгать иткән яшьләрне күзләре белән генә елмаеп тыңлаганнан соң, тулы һәм аңлаешлы итеп җавап кайтарыр. Мин аның күкрәктән чыккан, үзенчәлекле яңгыравык тавышын да ачык хәтерлим.

Абдулла Алишның һәр утырыш саен минем белән озаклап сөйләшүенә шәһәрнең икенче очында яшәвем сәбәп булгандыр. Без, әнием белән Җоркаларда бер елга якын яшәгәннән соң, аерым квартирга күчү бәхетенә ирештек. Ул әллә ни уңайлы түгел иде. Бары тик чарлактагы бер бүлмә генә. Ләкин без монысына да чиксез шат, үзебезне җәннәткә эләккән кешеләрдәй сиздек. Безнең квартир хәзер Арча кырында Чехов урамында.

Ул заманнарда трамвайлар аерата начар йөри иде. Трамвай көтеп интеккән вакытларда без Абдулла абый белән Кольцога таба җәяүләп кенә китәбез. Ашыкмайча гына атлыйбыз, күбрәк әдәбиятка караган мәсьәләләр турында сөйләшәбез. Алишның үзен өстен куеп, остаз сыйфатында мине өйрәтергә керешкәнен хәтерләмим. Ул, гади дусларча, мине үзе белән тиң күреп сөйләшә иде.

Көннәрдән бер көнне Хан Җәмил миңа, синең повестеңны «Кызыл Татарстан» газетасында басарга телиләр, әйдә, тизрәк язып бетер дә, редакциягә илтеп бир, диде. Йә хода! Бар икән минем дә иң якты максатыма ирешер көннәрем!

Повестьның өзеге безнең завод газетасында басылып чыкты инде. Җитмәсә, портретым белән. Мин хәзер татлы хыяллар бакчасында гизәм. Шулай ук республика газетасында минем әсәр басылыр микәнни? Ничек күтәрермен мин шундый зур шатлыкны!

Ул заманда «Станоктан — әдәбиятка!» дигән лозунг гамәлдә иде. Шул чорда безнең завод эшчесе Мөхәммәт Садри әдәбият мәйданына аяк басты. Заводтан әдәбиятка килгән рус язучысы Авдеенконың «Я люблю» дигән повесте һәр почмакта мактала. Мин дә шулар рәтенә басармын кебек. Ә нигә! Минем әсәр дә бит завод тормышыннан, үзем белгән нәрсәләр турында, татар әдәбиятында моңарчы бөтенләй булмаган яңа темага язылган! Бәлки ул да «Я люблю» кебек үк шаулар. Кызык булыр иде, ә!

Әнә шундый беркатлы йөгәнсез хыяллар белән яшим. Мәгәр минем бу ашкынуларым, бәлки бәхеткә каршыдыр, хыял көенчә генә калды.

## 21

Һаман көтәм. Минем мәсьәләне комиссия һаман да суза. Әллә нинди тәшвишле юраулар белән азапланам. Бәлки институтта миңа

тагын берәрсе агу «тамызгандыр?» Бәлки минем хакта Казанга өстәмә сорау җибәргәннәрдер, тикшерергә булганнардыр? Әгәр шулай икән, тәгаен, безнең институт директоры үзен аклау өчен миңа әллә ниткән гөнаһлар тагар. Аннан соң инде бөтен юллар ябылачак. Авырмыни кеше турында уйдырма язып, аны юкка чыгарып ташлау. Мин шундый куркыныч уйлар белән вакыт уздырам.

Бүген Агриппина Евграфовна тагын минем язучылыгым белән кызыксынды. Янәсе, ни өчен шундый сәер псевдоним уйлап чыгардыгыз. Әллә ул да миннән шикләнә инде? Мин, ирексездән, әти-әниләрнең узган юлын, аларның миңа сөйләгәннәрен, бу турыда язган истәлекләрен хәтерлим.

Әйе, алар хаҗ сәфәренә барып «Лаеш шулпасын» аз чөмермәгәннәр. Язмыш аларны, Мәккәдән Мәдинәгә кайтып төшү белән үк, авыр сынаулар алдына куя.

Дөрес, Мәккәдә алар вакытны начар уздырмыйлар, әйтерлек авырлыклар күрмиләр. Максатларына ирешәләр, изге саналган урыннарны тәваф кылалар. Ислам дөньясы өчен бик мәгълүм Гарәфәт тавына менәләр. Андагы күз күреме кадәр җиргә җәелгән, ачык мәйданны тутырган хаҗиларның тәкбир, ләббәйкә әйтеп, алланы зурлауларына катнашалар. Гарәфә көнендә бәдәвиләр солтанының үзенең яраннары һәм сакчылары белән һавага туплардан аттыра-аттыра тау итәгенә килүен тамаша кылалар. Кайтышлый юл буе музыкалар уйнатып, шигырьләр, салаватлар укып, ашыгып атлаган гарәпләрне озаталар. Корбан гаете көнне Мина дип аталган авыл сыман урынга барып, шуннан шайтанга таш атарга ашыгалар. Минадан арырак бер багана төбенә сигезәр таш атып, саваплы булырга телиләр. Биш сарык, өч кәҗә суеп, итен андагы бетмәс-төкәнмәс саилчеләргә, дин әһелләренә өләшәләр.

Кыскасы, барлык ритуаллар үтәлә, хаж кылына. Ул яктан этиләрнең теләк почмаклана. Әмма Россиядән, өйдән соңгы вакытларда хәбәр булмавы бик борчый. Чыннан да, бу ни бу, берниндидә хәбәр юк. Даими рәвештә җибәрелеп торырга тиешле акча да юк. Безнең хаҗилар пошаманга калалар. Ә акча көннән-көн кими. Инде этинең кесә төбе саега. Хаҗ ритуалы тәмамланганда Мәдинәгә кайтып егылырлык кына акча кала.

Мең төрле маҗаралар кичереп, юлдагы баскын бәдәвиләрдән чак котылып, тәмам алҗып, авырып, ниһаять, дөяләрдә Мәдинәгә кайтып егылалар. Алар инде, билгеле, үзләрен хаҗга җылый-җылый озатып калган, йөзенә иннек-кершән яккан сырхау Нәфисә апаларына төшәләр. Егерме җиденче октябрьдә кафилә белән Мәккәдән юлга чыккан кешеләр алтынчы ноябрьдә генә үз өйләренә кайтып төшкәндәй рәхәткә таралар.

Әнием үзенең истәлегендә болай дип яза: «Безнең кулда Истанбулга кайтып җитәрлек акча булмавы аркасында, без Истанбулдагы танышыбыз Гали бәкләрдән тиешле акча килгәнен көтеп, Мәдинәдә ятарга мәҗбүр булдык. Без бер биш көннән дә артык тормабыз, акча килер, китәрбез, дип уйласак та, эш без уйлаганча барып чыкмады. Соңыннан Истанбулга телеграмма суктык. Һаман көтәбез. Байтак көннәр үтте. Мәдинәдә дә тормыш уңайсызлана башлады. Бер тиен акча булмаган хәлдә, ят кешеләр өстендә дүрт кешенең ашап ятуы әйбәтмени? Алар да элек очрашкандагы кебек «Мәхдүм, мәхдүмә»,— дип кадерләп дәшми башладылар. Артык дүрт тамак бит. Әйбер кыйммәт, фәлән-фәсмәтән, дип сөйләнә башладылар. Безгә бигрәк тә кыен иде. Көннәр барысы да бер төсле, ифрат акрын узалар. Һәр көнне иртән сәгать уннарда торабыз. Торгач — икмәк, булмаганда — кичтән калган яшелчә белән чәй эчәбез. Нәфисә апалар без торганчы ук ашап-эчкән булалар. Чәйдән соң без, эшебез булса, эшкә тотынабыз, булмаса, китап укыйбыз.

Кружуа бәйләргә башладык. Сигез аршин бәйләп саттым инде. Ә безнең телеграммага каршы Истанбулдан һаман җавап юк. Эч поша. Тагын бер телеграмма суктык, хат та яздык. Гомеребезнең болай хәятсез-нисез җәһәннәм кебек җирдә үтүенә хафаланабыз. Аз булса да файдадан хали булмас дип, күршедәге Мөхәммәтгыйш дигән, Мәдинәнең беренче карыйларыннан саналган шәехтән Гайшә, Нәфисә апа, мин кыйраәт укый башладык. Ходаем, хәерле гыйлемлекләр бир, амин.

Ястүдән соң карыйга кереп укыйбыз да, чыккач, чәй эчеп, йокларга ятабыз».

Әнием, гамәл кешесе буларак, тик ятмый. Үзе белән Гайшә апаны да иартә. Алар тирә-юньдәге кешеләр белән танышалар, чакырулы һәм чакырусыз мәҗлесләргә йөреп, гарәп тормышы, Мәдинәдәге мөһаҗир татарларның хәл-әхвәле белән танышалар. Ләкин көннәр барыбер күңелсез, мәгънәсез үтә. Истанбулга тагын телеграмма сугалар. Тагын газаплы көтү минутлары, сәгатьләр, көннәр, атналар уза. Ләкин бернинди хәбәр юк.

«Бүген беренче декабрь,— дип яза әнием,— без көннәрне йокы, ашау, вак-төяк китаплар карап, бәгъзән Хәрәм шарифкә барып уздырабыз. Әмма бик эч поша. Кеше өстендә ятулары — әҗәл. Йә ходаем, тизлек белән хәерле юл бирсәң иде, дип аһ орабыз».

Шулай соры, шыксыз, үзәкне өзгеч авыр көннәр үтеп тора. Декабрь ахырларында өй хуҗасы Исмәгыйль һәм дәлил Насыйбулла, бу артык кашыклардан котылыйк, дип булса кирәк, үзләре дә акча эзли башлыйлар, чөнки Истанбулдан «Акча җибәрә алмыйбыз» дигән хәбәр килеп төшә. Эш нидә, ни өчен туган илдән вәгъдә ителгән акча килми? Сугыш, сугыш, сәбәп шунда булырга тиеш.

Ниһаять, өй хуҗалары Мәдинә татарларыннан бурычка акча җыялар. Әтигә сигез йөз сумнан азрак акчаны, мең итеп кайтару шарты белән, рәсми рәвештә тапшыралар.

Менә Яңа ел көннәре дә узып китә. Алай гына да түгел, гыйнвар ае узып бара. Безнең мосафирлар поезд көтәләр. Берсенә утыра алмыйлар, икенчесе шулай ук ниндидер шәехнең мөритләрен төяп китә, урын юк. Ниһаять, өченче февральдә, сишәмбе көн, кичке сәгать ун тулганда әтиләр утырган поезд, Мәдинәдән аерылып, Шамга таба кузгала. Шам шәриф тә боларны артык җылы каршыламый. Чөнки Истанбулга диңгез юлы ябык. Ат юлы исә үтә алмаслык пычрак. Безнең мескен хаҗилар җирләр кипкәнче, берәр айга Шамда тукталып торырга булалар. Алар элекке таныш татар мәхәлләсендә яшәүче дәлил Талип әфәнденең кечкенә өенә фатир керәләр, тормыш кирәк-яракларын, керосин, күмер кебек нәрсәләрне сатып алып, үзләре көн күрә башлыйлар. «Шамда ак май ифрат очсыз,— дип яза әнием,— батманы — алты кадагы — унике груш, ягъни бер сум. Һәммә нәрсә шулай очсыз. Рәхәт кенә торабыз. Кеше өстендә, кеше икмәгенә карап яшәү түгел, үзебезгә бер аерым өй, бер караваты да бар. Без шунда, Сабур — түшәмә өстендә, Гайшә — идәндә, йоклыйбыз. Хаҗдан кайткан кечкенә самавырыбыз бар, балчыктан ясалган бер мангал алдык. Ун көндә бер кер уабыз. Әбиләрнең авылча кара мунчалары бар. Атна саен шуны яктырып юынабыз. Әмма, рәхәт торсак та, минем һич кая барасым килми, чыгасым килми. Күңелем һич күтәрелми. Өйләгә кадәр генә мин аякта, аннан кәефсезләнеп ятам. Ә Шам көннән-көн матурлана, көннән-көн яшеллек, ап-ак чәчәкләр белән каплана.

Көннәрдән бер көнне, арып-талып өйгә кайтып керсәк, Талип әфәнде белән аның энесе Җәмил килеп керделәр. Безгә йөз лира акча килгән икән. Бик озакка сузылган тынлыктан соң ишетелгән шатлыклы аваз булып тоелды бу».

Икенче көнне әтине Әсгать исемле бер шәех чакырта. Бу шәех заманында минем Зәйнулла бабай узган Нәкышбәнди мәктәбеннән чыккан кеше икән. Шуңа күрә әтиләргә аерата хөрмәт күрсәтергә

теләгәндер. Шәех, Италия консулы ярдәмендә, этиләрне Истанбулга җибәрергә булган. Хикмәт шунда, сугыш башлану аркасында Шамдагы Россия консульствосы бетерелгән, арадашлык вазифасын Италия консуллыгы алган.

Тагын көтү газаплары башлана. Ни булып бетәр бу? Россиягә таба юл ачылырмы, юкмы?

Ниһаять, безнең хаҗилар Бәйрутта. Алар инде хәзер, полициядән куркып, бөтенләй урамга чыкмыйча, номерда гына яталар. Хәзер Бәйрут та элекке Бәйрут түгел. Мондагы тынлык урак өстендәге авылны хәтерләтә.

Алты көн яшеренеп ятканнан соң, Италия консулының ярдәме белән, этиләргә Триполитаниягә китәргә мөмкинлек туа.

Менә өченче класста, пароходның алгы ягында, йөк әрҗәләре, тавык кетәклекләре арасында Триполтаниягә дә җитәләр. Аннан ары — Искәндәрун, Италия, Макри.

Унбишенче мартта, якшәмбе көн пароход Макридан Рәдүскә таба алып китә. Диңгез котыра. Пассажирлар, шул җөмләдән әниләр, укшыйлар, косалар, аларны рәхимсез рәвештә «диңгез тота». Пароходта поварлар вино өләшә башлыйлар. Ләкин әнием аны да эчә алмый. Вино, киресенчә, отыры укшыта гына төшә.

Менә, ниһаять, Солоник шәһәре. Унбер көн иң җайсыз шартларда барганнан соң, егерме беренче мартта, шимбә көн әниләр Солоникта коры җиргә чыгалар. Билетлар, документ тикшерүләр...

Солоник — зур, матур грек шәһәре. Безнең юлчылар бу шәһәргә нәкъ бәйрәм каршылау вакытына килеп төшәләр. Егерме икесендә пасха бәйрәме икән. Хаҗилар, өч көн грек җирендә яшәгәннән соң, Болгар җиренә таба юл тоталар. Әни үзенең истәлегендә: «Солониктан Дәдагачка барышлый поездда егерме тугыз туннель кичтек»,— дип яза.

Алар Дәдагачка егерме тугызында барып төшәләр. Бер кич кунгач, чит илгә чыгу өчен тиешле документлар җайлагач, Әдәрнәгә китәләр.

Әдәрнәдә Сабур абыйга Россиягә кайтып киту өчен документ юнәтәләр. Ул Болгария аша туган илгә кайтып китә. Монда бер бик җитди сорау тууы бар. Ни өчен соң этиләр дә шунда ук илгә кайтып китмәгәннәр, инде туган илдән киләсе акчага ышанып, чит-ят җирдә калуның ни дәрәҗәдә хәтәр икәнлеген үз башларыннан кичерделәр бит? Моңа җавап итеп, дүртәүләшеп Россиягә кайтырлык акча булмавын һәм бигрәк тә Бөтендөнья сугышының иң кызган чаклары якынлашуын әйтергә кирәктер. Этинең илгә кайту белән солдатка алыну ихтималы монда иң мөһим сәбәп булмады микән, дип уйлыйм мин. Сугыштан чит илгә китеп котылырга теләүчеләрне алар үз юлларында аз очратмыйлар. Андый кешеләрнең киңәше тиешле тәэсир ясамый калмагандыр. Ә Сабур абый ул әле яшь, аның солдатка каралу вакытлары әле еракта. Өстәп тагын шуны әйтергә кирәк, шул ук сугыш елында Төркиядән Россиягә кайтып киткән этинең абыйсы (ана башка, ата бер) Габдулла Рәсүлев Истанбулдан илгә кайтып төшү белән солдатка алына һәм фронтка китеп юкка чыга.

Сабур абыйдан аерылгач, этиләр инде хәзер өчәү. Әдәрнәдән Истанбулга таба сәфәр чыгалар.

Менә ул Истанбулның Европа өлеше, Америка, Франция, Германия байлары салдырган банклар, бизнес биналары. Менә аның әллә ничә йөз манаралы тарихи мәчетләре. Менә аның гүзәл диңгез култыклары, бугазлары.

Безнең мосафирларга шушы шәһәрдә язмышның сикәлтәләрен үтеп, барлык газапларга түзеп, сугыш беткәнче яшәргә туры киләчәк әле.

Истанбулга килеп төшкәч, кунак өенә урнашу белән, эти беренче чиратта акча мәсьәләсе турында белешергә тиешле кешегә — әлеге Гали бәкләргә барырга ашыга. Аннан өмет өзелмәслек хәбәр алып кайта.

Аның әйтүе буенча, алда искә алынган Габдулла Рәсүлев хәзер Истанбулда икән. Алар шуны эзләргә тотыналар.

Әтиләр аны эзләп табалар. Күңелле очрашу. Балалык чорын, Троицкины искә алулар. Икенче көнне аңа тагын баралар. Ләкин, алдан сүз куешуга карамастан, Габдулла абыйны өйдә очратмыйлар. Баксаң-күрсәң, ул эчкечелеккә сабышкан кеше икән. Атналар буе эчеп йөреп, атасыннан килгән акчаны туздырып гомер сөрә, имеш. Бу кадәресе, әлбәттә, соңыннан гына мәгълүм була.

Истанбулдагы татар студентлары, укучы яшьләр, этиләрнең мондалыгын ишетеп, кунакханәгә килә башлый. Заманында Петербургта укыган Ләбиб һәм Галимҗан атлы врачларны әнием үзенең истәлегендә еш кына искә ала. Ләбиб әфәнде белән алар фатир эзлиләр, эзли торгач, аның яраклысы «Паша бакча» дигән мәхәлләдән табыла. Әтиләр кунакханәдән шунда күчәргә әзерләнә башлыйлар. Кирәкле хуҗалык әйберләре сатып алалар. Ләкин алар көнендә күченә алмыйлар, чөнки әтиләрне бохаралы Гомәр исемле кибетче кунакка чакыра. Ул сәүдәгәрнең хатыны казанлы икән. Әнием үзенең истәлегендә: «Андагы кунак хатыннар белән без шау-гөр килеп, үзебезчә күңелле генә сөйләшеп утыра идек, төрек хатыннары килеп керде һәм һәммәбез дә шым булдык та калдык,— дип яза.— Мондагы татар хатыннары, гәрчә үзләре монда кечкенәдән килеп, шулар арасында үссәләр дә, бәгъзеләре хәтта шушында туса да, һаман төрекләрне чит күрә, үзләренең телен саклап килгәнлеге мине аерата хәйранга калдырды».

Ул көнне этиләрнең яңа квартирга күчә алмау сәбәбе тагын шунда, русияле кешеләр булганга күрә, билгеле рәвештә моны формалаштырмыйча, алар яңа урынга күчә алмыйлар, имеш.

Билгеле мәшәкатьләрдән соң, ниһаять, күченергә мөмкинлек тугандай була. Әмма тагын кунакка дәшү. Исмәгыйль атлы бер хаҗиның этиләр белән танышасы килә икән.

Ирле-хатынлы карт белән карчык һәм аларның Галия атлы кызлары — өчәү генә яшиләр икән алар. Әниләр хуҗалар белән сөйләшкәндә яңа квартирга күчкәч өйдә хезмәтче хатын кирәк булачагын әйтәләр. Болар берәр тырыш, намуслы хатын табарга сүз бирәләр.

Иртәгесен, чыннан да, сүзләрендә торган хаҗи гаиләсе хезмәтче булачак хатынны һәм аның кызын этиләр яшәгән кунакханәгә җибәрә. Бу хатын исә бер казанлы татар хатыны булып, аның ире хәзерге көндә гаскәри хезмәттә икән. Шул апа белән түләү турында ризалашалар. Тегеләр иртәгесен, урын-җирләрен күтәреп, кунакханәгә килергә булалар. Шуннан соң гына яңа квартирга күченү мәшәкатьләре башлана.

Күченәчәк урын — җәйге дача. Анда бару өчен пароходка утырырга кирәк. Иртәнге унбердә юлга чыккан булсалар да, бары кичке дүрттә генә, күп мәшәкатьләр чигеп, дачага җитәләр.

Әнием үзенең истәлегендә болай яза: «...Икенче көнне күмер, су кебек кирәкле нәрсәләр алып, кайсы кибеттә нәрсә сатылганын белеп, яхшы гына яши башладык. Истанбулга караганда монда һава байтак яхшы. Һәр җирдә чәчәкләр ачылган, кошлар сайрый, сулыш алулары җиңел. Әмма иртә-кич бик салкын, ачы җил безгә чыгып йөрергә, рәхәтләнеп яшәргә ирек бирми.

Фатирыбыз югары катта. Дүрт бүлмә. Урта катта өй хуҗалары үзләре тора. Керү юллары аерым. Урта каттан безгә дә бер бүлмә билгеләнде. Анда безнең хезмәтчебез кызы белән урнашты.

Өебезнең бер ягында тар гына урам. Тәрәзәдән башыңны сузып карасаң гына күренә ул, чөнки аны күршенең бакчасындагы төрле хуш исле агачлар каплый. Икенче яктагы тәрәзәдән үз ишегалдыбыз күренә. Ул якта Гайшә бүлмәсе һәм безнең йокы бүлмәбез. Бакча зур, агачлар күп, бакча артында диңгез күренеп тора. Пароходларның килгәне, киткәне — һәммәсе күренә.

Кичләрен бигрәк тә матур. Утлар белән тулган пароходларның шәүләләре суга төшеп бриллиант кебек ялтырый. Ай яктысында гаҗәеп матур. Безнең бакча артында гына Габдрахман пашалар өе. Ул татар гаиләсе. Анда Фәридә ханымнар пианино уйныйлар, скрипка чалалар. Өстәвенә, мондый гүзәллекне мең кабат арттырып, кичтән иртә беләнгә кадәр, безнең боек күңелләрне күтәрү өчен генә дип әйтерлек, сандугачлар сайрый. Без йокы вакытын өч сәгатькә кичектерергә мәҗбүр. Инде житте, ятыйм дисәң, ул арада Кадыйрның: «Зәйтүнә, тыңла әле, тәрәзә янына тизрәк кил, әнә «Тәфтиләү» көен уйныйлар»,— диюенә адәм чыдап ята алмый, тәрәзә төбенә килә һәм скрипкада сузып-сузып, сандугачлар сайравына кушып уйналган татар моңын тыңлый башлый.

Көннәр, һавалар көннән-көн яхшыра бара, җылына. Чәчәкләр, яфраклар көннән-көн күбрәк ачыла. Матурлык һәм тирә-юньдәге гүзәл аһәң үзеңне дә музыка уйнарга кыстый башлый. Электән үк безнең мандолинада уйнарга теләк бар иде. Без Гайшә белән Ләбиб һәм Шәриф әфәнделәр ярдәмендә мандолиналар сатып алдык...

...Истанбулга да баргалыйбыз. Мин күбрәк докторга күренер өчен барам. Хаждан кайтканда мин бөтенләй хәлсез, зәгыйфь идем. Монда урнашкач, саф һавада бераз тынычландым, йөземә төс керде. Һәр көнне һавага чыгып йөрибез. Тирә-юньдәге тау, урманнарны йөреп чыктык инде. Ике ягыбыздагы Бәккүз, Чыбыклы пристаньнарына барып кайттык. Бер көнне төрекләрнең ватан бәйрәме, солтан Рәшатның тәхеткә утырган көне булды. Без Истанбулга шуны карарга киттек. Пароходтан төшүгә Бәк углы ягына чыктык. Һәммә җирне электрик рәсемнәр белән зиннәтләгәннәр. Урамда халыкның исәбе-хисабы юк. Хәрбия нәзарәтендә утлардан ай белән йолдыз бизәкләре ясалган. Халык дәрьясы чиксез, гаскәриләр музыка уйный. Полислар, халыкны икегә аерып, артка чигел, дип кычкырып йөриләр. Шулвакыт капкадан бер автомобиль хәрбия нәзарәтенә кереп китте».

Безнең әсирләр — хәзер инде алар әсир хәлендәге кеше исәпләнәләр — Россияле мөселманнар, җирле татарлар белән аралаша башлыйлар. Ләкин күңелләре һаман китек аларның. Туган илдән хәбәрләр әллә нигә бер килә. Дәү әни ни хәлдә, Шакир абый, Һаҗәр апа исәннәрме? Алар турында кыскача хәбәр дә юк ичмаса. Әнием туган илдән аерылып яшәүне аерата авыр кичерә. Җитмәсә, нәни бәби көтеп яшәү...

Әнием — Истанбулда укуын дәвам иттерү турында Буби мәктәбендә хыялланган кеше. Истанбулга барып төпләнү белән, үзенең күптәнге хыялын тормышка ашырырга омтыла башлый. Истанбулдагы алдынгы мәктәпләр белән таныша, андагы уку программаларын, укыту ысулларын үзе барып өйрәнеп, күреп йөри. Бу эштә аңа ул заманда Истанбулда яшәгән Йосыф Акчура да ярдәм итә. Бу кешене — ярым төрек, ярым татар дип әйтергә була, Истанбулның үз кешесе дип атасаң да була. Ул, мәсәлән, Балкан сугышы чорында төрек армиясендә офицер булып хезмәт итә. Мин моны Фатих Кәриминең «Истанбул мәктүпләре» исемле китабын укып беләчәкмен. Акчурин Истанбулда «Төрек йорты» исемле журнал чыгара.

Әни дарелмөгаллиматка (кызлар өчен югары мәктәп) кереп уку турында хыяллана. Ләкин моңа чама аз.

Һавалар да көзгә таба борыла башлый, йә эссе, йә суытып җибәрә. Сугыш аркасында һәр җирдә кытлык үзен сиздерә. Әни истәлегендә: «Элек Паша бакчасында гаскәр күп булу аркасында икмәк житми иде, икмәк пешереп өлгермиләр иде, ә хәзер гаскәр тупланмаса да, икмәк җитешми»,— дип яза. Он бөтенләй сатуда юк. Он тарттырырга тегермәннәр эшләми икән, чөнки алар өчен ягулык җитешми. Һәр гаиләгә бер дәфтәр биргәннәр, анда ничә җан икәнлеге язылган. Шуның буенча икмәк тараталар һәм дәфтәргә теркәп куялар. Кеше башына ярым ука икмәк. Бу арада шикәр дә юк. Аны да хөкүмәт,

үз кулына алып, кеше башына аз-азлап кына бирәчәк. Чишмәләрдә сулар корый. Әрмәниләрне Истанбулдан һәм бугаздан куалар. Һәр көнне аларны озаталар. Ә көз рәхимсез рәвештә якынлаша. Инде салкыннар башланганчы дөньяга киләсе нәни Россия гражданины турында да кайгырта башларга вакыт.

Әниләр, кышны дачада каршылап булмас, шәһәргә, җылы квартирга күчәргә кирәк, дигән фикергә киләләр.



## 22

Әниемнәр шулай яңа квартирга урнашалар. Әти, полиция идарәсенә барып, яңа адресны теркәтеп кайта. Бәхеткә каршы, Грециядән бик күп он килгән чак була, берничә көн икмәкне хәтта язусыз да бирәләр.

Әни үзе, хәзергә исән-сау чагым дип, Истанбулдагы Фатих базарына төшеп, май, он кебек ашамлыклар алып кайта. Таныш-белешләреннән үзләренә кирәкмәс караватъ, урын-җир кебек әйберләр алып тору турында сөйләшеп куя.

Унбишенче сентябрь көнне әнием үзе яратып сайлаган, булачак кендек әбисе Расиха ханымга барып килә. «Синең вакытың бик җиткән инде»,— ди ул ханым. «Өйгә кайтып, кичен ашап-эчеп яттык,— дип яза әнием.— Һәммәсе йокладылар, минем кәефем китә башлады. Кая гына ятсам да, урын ошамый. Минем кәефсезләнүемне Гөлсем җиңги дә сизде, ул да үз бүлмәсеннән минем янга керде. Байтак торгач, авырый башладыгызмы әллә, дип, ул минем яныма килде. Кендек әбисенә хәбәр итәргә кирәк, дип, Кадыйрны уятты. Расиха ханым килеп җитте. Таң аткач, диде. Мин авырыйм. Авыру киткән арада ашап, эчеп алам. Иртәгесен Расиха ханым мине карады да: «Ахшам»,— диде. Үзе чыгып та китте. Ярый әле озак югалып тормады. Мин бик курыккан идем. Сәгатьләр, минутлар бик акрын үтә. Акрын гына икенде вакыты җитте. Аш булдырдылар. Мин дә ашап алдым. Ахшам вакыты да җитте. Мин инде бала тууыннан өмет өздем. Утлар алынды, һаман юк та юк. Авыру ешрак килмәсме, дип, коньяк та эчерттеләр. Ләкин файдасыз. Йөреп тә карыйм, ятам да. Һаман юк назлы кунак. Ниһаять, бик озак газапланганнан соң, мең тугыз йөз унбишенче сәнә — милади, мең өч йөз утыз өч — һиҗри, уналтынчы сентябрь, егерме зөлкагдә, чәршәмбе көн төнлә сәгать ун ярымда бала дөньяга килде. Җиңги, ир бала дөньяга килде, дип, минем сәламәт котылуымнан өйдәгеләргә хәбәр бирде. Баланы калдырдылар, аны — караватка, мине идәнгә, тыныч йокла инде, дип яткырдылар. Кендек әбисен озатып кайткач, Гайшәләр шатлыктан самавар куеп чәй эчтеләр. Соңыннан Гөлсем җиңги минем янда, башкалар түбәнгә төшеп яттылар. Иртәгесен минем бүлмәмне җыештырып, идәннәрне юып, мине караватка салдылар. Балага мәммә бирергә теләдек, алмый. Мәммә сөт белән тулы, бала алмый. 3-4 көн шулай азапландык, соңыннан егет бераз имә башлады».

Инде бервакыт исем кушу кайгысы да алга килеп баса. Кендек әбисе, егеткә минем исемне кушыгыз. Расих дип атагыз, ди. Әниләр, шаяртып, мин исемсез чакта, мине баштарак Әптерәшит дип йөртәләр. Әти исә көннәрдән бер көнне, аралашып йөрешә торган дус-ишләр белән киңәшкәннән соң, миңа һуннарның Атилла хан исемен табып кайткан. Әнием миңа исем кушуны түбәндәгечә яза: «Җиденче көнне балага исем куштырабыз дип хәзерләнделәр. Кунакларны көндез сәгать икегә дип чакырсак та чакырулы кунак булгач, назландырып, өченче яртыда гына Ләбиб, Гариф, Касыйм, Кави әфәнделәр килде. Алар югары катка менеп утырдылар. Баланы арулап түйдырганнан соң, Кадыйр өскә, кунаклар янына алып менеп китте.

Менгәч тә, син куш та, син куш, дип назланмыйча гына, Русия студенты булган кеше Ләбиб мәхдүм кычкырып азан әйтеп исем куша башлый. Ахры, өйләреннән үк исем кушасын сөйләшеп килгәннәрдер. Безнең кечкенә Әптерәшит тиз арада Атлыхан булып куйды. Кадыйр базардан ак роза чәчәге алып кайткан иде. Үскәч үзенә күрсәтербез дип, ул өстәлгә куелды».

Әлеге роза чәчәге, кипкән, кечерәйгән, хәтта төсен югалткан хәлдә булса да, әле дә миндә, китап битләре арасында саклана.

Әнием шулай әкренләп аякка баса, йөри башлый. Ләкин аның күңеле һаман төшенке. Минем дөньяга килүем болай да авыр тормыш сөргән гаиләнең хәлен тагын да авырайта, әниемә зур мәшәкатьләр өсти.

Мин биредә үзем өчен бик җитди бер мәсьәләгә тукталырга тиешмен. Документларымның барысында да, матбугатта чыккан биографияләремдә дә туган елым уналтынчы, туган шәһәрем Троицк дип язылган. Хәлбуки, күренгәнчә, мин Троицкидан бик еракта туганмын. Ничек инде алай, син, димәк, ялган мәгълүматлар биреп барыбызны да алдагансың, диючеләре бар. Кызганычка каршы, шулай килеп чыкты шул. Мин дөньяга килеп бераз вакыт узгач, минем туу хәбәрем Троицкига җиткерелә. Хат бик озак бара. Зәйнулла бабай мине, күрәсең, хат килгәч тә әле үзенең мәчет кенәгәсенә теркәми торган булса кирәк. Шулай итеп, ул заманда туу турындагы бердәнбер ышанычлы документ саналган мәчет кенәгәсенә мине 1916 нчы елда туган дип терки. Бу минем үземнең туган елымны һәм туган җиремне исбат итә торган бердәнбер документ булып килде.

Кыскасы, мин бер елга соңрак, Троицкида туган кеше булып исәпләнәм. Хәер, әниләрем миңа, син Истанбулда тудың, дип әйтмәсәләр, мин моңа беркайчан да ышанмаган булыр идем. Чөнки күңел күзем ачылганда мин тирә-юнемдә бары Троицк мөхитен генә күрдем. Юкса кайберәүләр үзләренең ике яшьлек вакытларын да хәтерлиләр. Этиләр илгә кайтканда миңа ике яшь ярым булган. Әниләр, Кара диңгез аша чыкканда пароходта ишеккә бармагың кысылды, син бик ачы чырылдап елый башладың, дип сөйләделәр. Һич югында шул бер вакыйга истә калырга тиеш иде кебек. Ләкин анысын да хәтерләмим.

Әниемнең күңел түрендә һаман — уку, белемен арттыру. Ул, әз генә тернәкләнә башлау белән, үзенең тыелгысыз теләген кабатлап, этине дә йөдәтә башлый. Бик аптырагач, эти көннәрдән бер көнне Истанбулда алдынгы саналган бик атаклы кызлар мәктәбенә барып сөйләшә. Аның хуҗасы һәм мөдире Сатигъ бәк этине, мәктәптә мөгаллимәләр сыйныфы бар; теләсә, хатыныгызны шунда кабул итәрбез, дип җибәрә. Әнием өчен бу искиткеч шатлыклы бер хәбәр була.

Әнием инде хәзер шул мәктәптә уку уе белән дәртләнеп, янып яши башлый. Әле ул мәктәпкә барып ныклап белешергә, сөйләшергә җай юк. Сәламәтлек, гаилә, бала. Аннан укыган өчен елына дүрт ярым лира акча түләргә кирәк. Ә андый акчаны арттыру, гаиләдән каерып алу әнинең кулыннан килә торган нәрсә түгел. Әле дә алар Гали бәкләрдән бурычка гына алып яшиләр бит. Эти бер китапханәдә эшләштергәли. Ләкин аның хезмәт хакы, кем әйтмешли, чебен чукындырырлык та түгел. Гайшә апа укый. Әни исә бала яныннан китә алмый.

Әнием үзенең истәлегендә: «Без, акчабыз бетеп, Гали бәкләрдән бурычка акча ала башлагач, хәл кысынкылыкка каласын белеп, хезмәтчебезне дә чыгарырга булдык,— дип яза.— Аның китүенә бар эшнең миңа калып, миңа хезмәт итәргә кирәклегеннән дә курыкмыйм. Бар хафаланып баш ватканым — мәктәпкә керә алмавым. Шул кадәр галим, бөек затның мәктәп капкасы ачык булып торганда, бу манигъларның булуы бары минем бәхетсезлегемнән генә. Йә алла, бу көнгә кадәр мин ничек өмет, хыяллар белән яшәп килдем, ләкин арттан куып барсам да бернигә җитешә алмадым».

Газеталарда, Болгар белән Австрия арасы диңгез юлыннан ачылган, дигән хәбәр басыла. Безнең әсирләр, юл шулай ачылса, бәлки әйберләр арзанаер әле дип өметләнәләр. Чөнки Гали бәкләр, әҗәтне күп бирә алмыйбыз, дип торалар. Әле җитешмәүчелек өстенә тагын менә нинди кайгы килеп баса: көннәрдән бер көнне этине, урамда тотып, гаскәри хезмәткә ала башлыйлар. Имеш, барлык чит ил кешеләрен армиягә алырга дигән фәрман килгән. Бу хәл бөтен гаиләне тетрәтә. Әнием, бала күтәргән килеш, ярдәм эзләп, якташларга йөгерә, абруйлы кешеләрдән ярдәм эсти. Мең бәла белән, консуллык ярдәмендә генә, бу эшнең очына чыгып, этине солдаттан калдыруга ирешәләр. Ләкин алай да вакытлыча гына. Яман кылыч һаман баш өстендә асылынган килеш кала.

Әнием үзенең көндәлегендә бу турыда ачы сүзләр тезгән: «Менә нинди зур кайгы төште башыбызга. Әгәр Кадыйрны Мисырга йә Чынак кальгәгә гаскәр итеп җибәрсәләр, ни хәлләр итәрбез. Кадыйр урамга чыкса, тотып алмадыларммы дип, кайтып кергәнче, йә ул өйдә калып, үзем чыгып китсәм, аны алып китмәделәрме, дип, ут йотып яшим. Каракүл яныннан кайткан вакытларда Атилланы ялгыз калдырырга кызганып, баланы күтәреп чыккан Кадыйрым күренмәсме дип, тирә-юнемә карангалап узам...»

Ятып калганчы атып кал дип, әнием соңгы саламга тотынырга була. Ул кайчандыр үзләрен кунакка чакырган якташ кеше Исмәгыйль хаҗиларга акча сорап бара. Икенче көнне үк шундый йомыш белән Гали бәкләргә бара. Ничек тә этине гаскәри хезмәттән коткарырга кирәк. Аңа, бу эш акча төрткәндә генә мөмкин, диләр. Әйе, коткарырга!

Ләкин эш барып чыкмый. Исмәгыйль хаҗи унбер лира, Гали бәк тә унбер лира гына биреп тора алалар. Ә барлыгы кырык дүрт лира кирәк икән.

Авыр көннәр, кылыч астында көн күрү вакытлары байтак дәвам итә. Күрәсең, ул вакыт Төркиядә чит ил кешеләрен армиягә алу киң таралган булса кирәк. Бу эшкә Греция һәм Австрия протест белдерәләр. Шуннан соң гына бу яман хәлләр туктала.

Әни бу чорда үзенең көндәлек-истәлекләрен элеккечә тулы итеп, тәфсилле рәвештә язып бармаган. Ул үзенчә аерата игътибарга лаек күренгән вакыйгаларны һәм үзенең рухи халәтен генә теркәп бара:

«...Утыз беренче декабрьдә безгә кунаклар килде. Яңа елны каршы алабыз, дип, сәгать уникегә кадәр мандолина уйнап, җырлап, биеп вакыт уздырдык. Унбишенче ел бик авыр булган иде. Ходаем, уналтынчы елны көтелгән шатлыклар белән уздырырга язсын.

Гыйнвар да керде. Көннәр бер-берсенә охшап, әкрен генә үтәләр. Һаман солых көтәбез. Егерме бишенче декабрьдән соң инглизләрне Чынак кальгәдән куып җибәрделәр. Ул көнне төрекләр рухлы гына милли бәйрәм ясаганнар. Без белмичә өйдә калдык.

Декабрь ахырларында Ләбиб, Зиннәт әфәнделәр килде. Бездән кайтышлый Зиннәт әфәндене полиция тоткан. Әҗнәбиләргә төнлә урамда йөрү ясак, имеш. Шулай гомер әкрен генә үтеп тора. Мин дә хәзер ирекле сыйфатында дәрелфөнүнгә атнага дүрт көн лекция тыңларга йөрим.

Яңа елның гыйнвар, февраль айлары матур гына үтте. Февраль бигрәк матур. Чәчәкләр ачыла, агачлар яфрак яра. Нәкъ бездәге май числосы кебек.

Март начаррак узды. Һавалар суык, җилле. Бик ямансу, безнең хәл кыенлаша бара. Әйберләр ифрат кыйммәт. Мартның егерменләрендә Троицкидан Стокһолм аркылы бер хат алып шатландык. Бурычлар күбәйде. Өч-дүрт көн ашсыз үткәргән чаклар бар.

Бүген утыз беренче мартта ханымнар җәмгыятенең инглизләрне шәһәрдән куу мөнәсәбәте белән оештырылган бәйрәмендә булдык. Өйдә ризык юк. Кадыйр аптырап тагын Гали бәкләргә акча сорарга

китте. Аһ, раббем, кайчан котылырбыз бу караңгы өметсез хәяттан?

Бу квартирабыз диңгезгә, диңгез буен кичә торган паром юлына карап тора. Паромнар кичләрен бигрәк моңлы итеп, адәмне уйлата-елата кычкырталар. Иртәгә — беренче апрель. Ул ай ничек үтәр. Истанбулга килеп урнашканга да бер ел булды. Үнөченче елны Чистайда идем, үндүртенче елда — Троицкида, хәзер — Истанбулда. Киләсе елларда кайларда булырга язган?..

...1916 сәнә. Сентябрь. Сәгатьләр, көннәр, һәфтәләр, айлар һич туктамый узып торалар. Җәебез дә узды. Кара йөзле, салкын чырайлы, рәхим-шәфкатьсез кыш килә. Яңгырлар яугалый, иртә-кич салкын.

Августта минем туган көнемне уздырдык. Таныш-белешләр таңга кадәр бездә булдылар. 16 сентябрьдә җомга көн Атилланың да бер яше тулды. Үзе каефсез. Алты теше чыкты инде. Һәммәсен бик авыр чыгарды вә бик ябыкты. Үзебезгә дә төннәрен тыныч йокы юк.

Бүген 17 сентябрь. Хәзер сәгать бер. Мин ялгыз, әллә нигә эчем поша. Греция сугыш башлады. Әйбер бәяләре тагын артты. Август айларында өйдән акча алдык. Бу юлы да Сатигъ бәк мәктәбенә керү насыйп булмады. Хакы безнең өчен бик кыйммәт. Ирекле булып кына уку файдасыз, шәһадәтнамә бирмиләр. Шуңа күрә эшкә кердем. Ходай муаффәкыять бирсен».

Әни үзенең язмаларында нинди эшкә керүен язмый, үзе исән чакта аның турыда сөйләгәннәрен дә хәтерләмим. Минем юравымча, үзе белгән тегү-чигү эшенә кергәндәр ул.

«Бүген 9 зөлхиҗҗә, 24 сентябрь, гарәфә көн. Иртән сәгать биштә йокымнан торганда ук елыйсым килеп, туган илне, әнине, абыйларны уйлап уяндым. Атилла да терелеп җитмәде. Эч тә бик поша, сугыш бетү ихтималы да күренми. Ни теләсәң — шул юк. Әниләрнең хәлен хатларда язмыйлар. Һич белеп булмый. Бик сагындым. Исәпли башласам, үзәкләрем өзелә. Берни дә уйламый Атилла белән генә мәшгуль булсаң, гомер узганын тоймыйсың.

Кадыйр бүген консулга китте. Бу айларда тагын тотып яба башладылар. Быел һавалар бик иртә суытты. Узган ел бу вакыт эссе иде әле. Кыш бик каты булыр, диләр. Ходай ярдәм бирсен.

25 сентябрьдә гает тә узып китте. Төнлә давыл булды. Шуңа күрәме, ил турында уйландыра. Кичә кичен танышлар килде. Һава әйбәт иде. Ай яктысында һавада йөрдек.

3 октябрь, 1916 сәнә. Минем бик эчем поша. Атилланы хуҗа әбигә калдырып, үзем Гадилә ханымнарга киттем. Бу якташ кызның Сатигъ бәк мәктәбенә укырга киткәнен ишетеп, гаять мәгъзул хәлдә, үземнең кара бәхетемә ләгънәтләр укый-укый өйгә кайттым. Без бәйрәмгә кадәр үк Гадилә ханым белән Сатигъ бәк мәктәбенә барып, андагы шартлар белән танышып кайткан идек. Ул Нуретдин әфәндедән — иреннән рөхсәт алган иде. Кичә Гадилә килде. Кичә язылырга барган идем, алып калдылар, еллык егерме ике лира бирдек, ди. Дәресләрнең шәплеген сөйләп, мине ифрат кызыксындырды. Ул шуларны сөйләгәндә мин үземне бөтенләй авыру хәлендә тойдым. Ике елдан бирле аһ-зар итеп тә, шул мәктәпкә керә алмаганга ут йоттым. Кадыйр белән электән үк сөйләшеп куйган вә, үз шартым белән кабул итсә, кермәкче булган идем. Гадилә ханымга, иртәгә мине көт, мәктәпкә бергә барырбыз, дидем.

Кичке ун. Гадиләне илтеп куйдык. Йокларга яттым. Һич кенә дә йокы алмый. Барыргамы, юкмы? Ни булып бетәр? Кадыйр да йокларга ятты. Аның белән дә сөйләшеп карыйм. Ул бару ягын куәтли. Мине дә бәлки кабул итәрләр, ятып калганчы атып кал, дигәннәр бит. Ниһаять, барып карарга булып йокыга талганмын.

Иртән сәгать биштә мине Атилла уятты. Алтыга кадәр аның белән шаярып яттым. Аннан торып эшкә керештем. Йөрәгем урыныннан

чыгып китәрдәй булып тыпырчына. Көндәлә өмет белән өметсезлек көрәшә. Гайшә белән генә чәй эчтек. Кадыйр йоклый иде. Аны уятып, үземнең китүемне, Гайшә белән икесенең дә догада торуларын үтенеп, еларга җитешеп, аллага тапшырып, теләк тели-тели, Гадилә ханымнар өенә юнәлдем.

Дүртенче октябрь көнне иртә белән сәгать тугызда Баязит мәхәлләсендәге Сатигъ бәк мәктәбенең мәһабәт зур капкасыннан, бисмилла әйтеп, Гадилә ханым артыннан барып кердем. Бинага кердек. Бераздан Сатигъ бәк үзе дә безнең янга керде. Аякка басып күрештем. Гозеремне әйттем. Мине, мөгаллимә булганым өчен, үз мәктәбенә имтихансызнисез алды да куйды. Миңа көтелмәгән, булуы мохәйял тоелган бәхет! Инде бу дөньяда булмый дигән нәрсә юк икән. Бары юлыңнан язмый барып, аны таба белергә генә кирәк. Йә алла, бу кадәр дә рәхмәтең киң икән синең. Мин бәндәңне дә җәннәткә керттең бит...

...Егерме тугызынчы ноябрь көнне мине тәнәфес вакытында аска чакырып алдылар. Түбән төшсәм, ни күрим — Кадыйр утыра. Янына баруым булды: «Сөенче»,— ди. Солых булачагын әйтте. Мин дә шашып калдым. Тиз генә Гадилә ханымга хәбәр иттем. Йә алла, рәхмәтең киң, без мохтаҗ бәндәләреңә дә якты көн күрсәтерсең икән».



## 23

Шул кадәр зур өметләр баглап, барлы-юклы акчаларыннан өзеп түли-түли кергән мәктәптә укый башлавына күп тә үтми, әниемнең ул уку йортыннан гайрәте чигә. Баксаң-күрсәң, ул бер дә искитәрлек, европача белем бирә торган мәктәп түгел икән. Әниемнең көндәлеген укуны дәвам иттерик:

«Мәктәпнең ни икәнен эченә кереп укый башлагач белдек. Тышы шундый җәннәт кебек вә мөнтәзар күренгән бер нәрсәнең бераздан күз буяу булганлыгы аңлашылды. Берәр ай үткәч тә мөдирнең кем икәнлеге дә беленде, дәресләр фаниләште. Татбикый дәресләр соңга таба бөтенләй бетте. Без дә монда керүебезгә вә югалган акчабызга үкенә, ачына башладык.

Шулай кыш якынлашты. Вакытлыча бездә торган әби дә китте. Февральдә Кадыйр белән Атилла өйдә утырдылар. Бары пәнҗешәмбе кичләрен генә өйдә тупланып театрлар уйныйбыз, кичәләр ясыйбыз. Шулай тагын бер кыш узды.

Егерменче майда табигатьтән имтихан булачак. Ни өчендер, күрәсең, татар җанлы кешеләр булуыбыз өчендер, сыйныфта беренче укучылардан баруыбызга карамастан, Сатигъ безне имтиханга кертмәскә теләи. Барыбер кердем.

Майның икесендә үк без Истанбулга Чөңгел көенә (Каюм абзыйларга) бер бакчага күчкән идек. Шуннан йөреп, ниһаять, имтиханнарны тәгалләдем.

Көннәрне бугаз эчендә, бик тук яшәмәсәк тә, хозур гына үткәрәбез. Көн дә мосафирлар. Фәйзи бәкләр дә якшәмбе көннәрдә килеп куналар. Имтихан көннәрендә Гадилә ханым унбиш көнләп бездә ятты.

Җәй үтә. Тормышлар тагын авырайды. Июль бетеп, август та керде. Миңа тагын эч пошу, сагыну авыруы килде. Көнен дә, төнен дә елыйсы килә. Бер көн дә биредә яшисем килми. Бәйрутка мөгаллимә итеп алып китәләр икән. Анда китәргә уйладым. Истанбулда мөгаллимә булып урнашырга да теләдем, ләкин күңелем берсенә тартмый. Нишләмәк кирәк? Ниһаять, китү өчен рөхсәт сорарга булдык. Тәмам, тәмам туйдык ачлыктан. Бездәге кечкенә бер тиенлек түгәрәк булка монда уналты груш. Балага ашатырга җүнле бер нәрсә дә юк. Май юк, ит юк. Булса, язу белән генә...

Өйдәгеләр белән сөйләшеп, шулай да китәргә булдык. Рөхсәт

кәгазьләре булдыру өчен Әнвәр пашаның кулы кирәк. Ул читтә. Шуны көтәбез. Ноябрь азакларында гына кайтты ул. Безгә Бәйрутка китәргә рөхсәт бирелде. Шатлык белән көлә-көлә әйләнеп кайтырга язсын. Яңа квартирга күчтек. Инде тиешле документлар көтә-көтә ноябрь да узып китте».

Газеталарда Россиядәге вакыйгалар турында язалар. Анда — инкыйлаб — революция. Ләкин безнең мосафирлар берни дә аңламыйлар. Бер газетада болай язылса, икенчесендә — бөтенләй капма-каршы сүзләр. Җитмәсә, Россиягә бәйләнеше булган һәр гаиләнең үз имеш-мимеше.

Берзаман әсирлектә калган якташларга Россиядә патша төшерелүе турындагы хәбәр килеп җитә. Бәлки сугыш шуны гына көтеп торгандыр? Юк-юк. Беркем дә сугышны туктатырга җыенмый. Газеталар сугыш кырларында һәлак булган кешеләр турында һәр көн язалар. Истанбулдагы һиляле әхмәр шифаханәсенә һәр көн яралы гаскәриләр килеп тора. Ә азык-төлек, кием-салым җитешмәүчәнлек көннән-көн арта. Безнең әсирләр, җыелалар да, туган илдәге хәлләр турында сөйләшәләр. Белсәң иде, ниләр булган икән анда? Әмма Россиядәге революция, андагы эчке агымнар, андагы хәрәкәт, коммунистлар дип аталган кешеләрнең мәсләге, максаты белән тирәнтен берәү дә таныш түгел.

Ә мохтаҗлык, ачлык, фәкыйрьлек көннән- көн муенны ныграк буа. Тизрәк, тизрәк Бәйрутка. Һич югында ачлыктан котылу өчен генә булса да китәргә! Анысы да әле аның тиз генә хәл кылынмый. Рөхсәт кәгазен бирми интектерәләр.

Россиядә коммунистлар властьны үз кулларына алганнар. Хәзер Вакытлы хөкүмәт башында утыручылар сөрелгән. Керенский качып котылган. Ләкин кемнәр кулында соң хәзер дәүләт, кем соң ул коммунистлар? Кайбер имеш-мимешләргә караганда, коммунистлар — эшчеләр, крестьяннар, солдатлар мәнфәгатен күзәтүчеләр, имеш, алар вак милләтләргә дә хокук бирәчәк икән. Йә хода, әгәр бу чыннан да шулай икән, димәк, Россия бөтенләй яңа бер дәвергә аяк басачак!

Ә көннәр үз чиратында аккан судай узып торалар. Нихәтле авыр булмасын, вакыт бер генә секундка да терәлеп тормый. Менә, тагын көз үтеп, кыш ае керә. Ул да уза.

1918 елның дүртенче мартында әти, иртәнге чәен дә эчмичә, әлеге очы-башы күренмәгән рөхсәт кәгазе артыннан йөрү өчен чыгып китә. Гадәттәгечә, өйдәгеләр аны дүрт күз белән көтәләр. Кич була. Берзаман әтинең баскычтан менә башлавы ишетелә. Әни болай яза: «Баскычтан Кадыйр өскә менә башлады. Йөрәкләребез тибүдән тукталды, тын да алмый торабыз. Ә Кадыйрның йөзе шат. Ул:

— Ике юл бердән ачылды. Русиягә пароход бар. Безгә шуңа утырып кайтырга мөмкинлек туды,— диде».

Әлбәттә, мондый чакта әниләрнең кайсы юлны сайлыйсы мәгълүм инде. Шунда ук алар туган илгә, менә шушы Брест солыхы төзелгәннән соң, беренче тапкыр Россиягә карап, Кара диңгез кичүче пароход белән кайтырга булалар.

Карар икеләнмәстән кабул ителә. Шул ук минутта юлга җыену ыгы-зыгысы башлана. Әзерлек төне буена бара. Чөнки пароход Россиягә иртәгә көндезге икедә китәчәк. Әтиләр, ашыгычлык аркасында, байтак танышларына хәбәр дә итә алмыйлар. Шуңа күрә озатучылар арасында танышлардан бары ике генә кеше була. Әнием истәлегендә болай яза: «Пароход Истанбулдан кичке сәгать биш ярымда гына китте. Берәр сәгать баргач, бугаз авызы Сары җирдә тукталып торды. Без чәйдән соң ятып йокладык. Иртән, югарыда кешеләр йөри башлагач, уяндык. Пароход һаман алга бара. Без каютада өчәү: Гайшә, Атилла,

мин. Каюта гаять гүзәл, беренче класс. Кадыйр үзе аерым бер каютада.

Бүген җидесе. Һава матур, рәхәт. Һаман алга барабыз. Руслар безне каршы алу өчен кырык биш мил ара узганнар. Алты сәгатьтән Феодосиядә булырбыз, диләр. Сәламәт кенә барып җитик. Миңа диңгезнең тәэсире аз, Атиллага бөтенләй тәэсир итми. Ул шат, уйный, аны һәркем сөя.

Унсигез март, 1918 сәнә. Сәгать икедә Феодосиягә якынлаштык. Безне музыкалар уйнатып каршы алдылар. Алдагы бөтен мәйдан халык белән тулган».

Брест солыхыннан соң әсирлектән котылып кайткан кешеләрне туган ил шулай тантаналы рәвештә каршы ала. Әни үзенең истәлегендә әчке кичерешләрен язмый. Ләкин дүрт елга якын михнәтле сәяхәттән соң туган ил туфрагына аяк басу аларда гомергә онытылмаслык шатлык тудырганын аңлавы читен түгел.

Ә аннан соң нәрсә? Аннан әтиләр, күп мәшәкатьләр чигеп, поездда Троицкига кайталар. Ләкин мондагы мәшәкатьләр үзеңнең туган өеңдәге мәшәкатьләр генә. Мондый мәшәкатьләргә түзәргә була. Моңа зарлану уңайсыз. Һәм әнием бу турыда зарланып бер сүз дә язмый.

Ниһаять, әниләр утырган тыгыз, тынчу вагон Троицк ташвокзалының пәкъ каршысына килеп туктый, бөтен перрон халык белән тулган. Йә хода, бу кадәр ишле туган-тумача, дус-иш илдә безне көтәдер дип уйладылармы соң бер әниләр!?

Әнием дәү әнине, Шакир абыйны, Һаҗәр апаны берьюлы барысын да кочып ала. Шатлыктан елашу, шатлыктан көлешү, аннан хәл-әхвәл турында бетмәс-төкәнмәс сүз китә.

Әнием белән әтиемнең хаҗ сәяхәте менә шулай тәмамлана.

## 24

— Эшләр ничегрәк тора, Агриппина Евграфовна?— дип курка-курка гына сорау бирәм. Апа, берни дә юк бит әлегә дигәнне аңлатып, күзләрен зур ачкан хәлдә миңа текәлә. Тәгаен ул да минем өчен борчыла. Минем хәсрәтем йөземә үк бәреп чыккан булса кирәк. Ул ихлас күңелдән минем өчен көенә, кашларын җыерып аска карый. Аннан:

— Җитәрлек тинтерәттеләр инде сезне дә, кадерлем,— ди. Ачуланып, председатель ишегенә күз ата. Мин тирән сулыйм да, башны иеп, гадәттәгечә, ишеккә таба юнәләм. Акланырга теләгәндәй, секретарь апа үзенең Антон Ивановичка минем турыда әйтәчәклеген сөйләп кала.

Мин тагын урамда. Башка төрле уйлар килә. Муенса энҗеләредәй таралып, сибелеп яткан хатирәләрне тагын бер җепкә тезә башлыйм.

Нәрсәдә тукталган идем әле? Әйе, без әнием белән Лидия Васильевналарның караңгы булса да тыныч бүлмәләрендә яшибез. Әни, көндәлек аш-су әзерләп, иртүк мәктәбенә китә. Гадәттә, ул караңгы төшкәч кенә кайтып керә. Аның өстендә кыска плюш пәлтә, аягында ботинка. Бу плюш пәлтә кайчандыр яңа, озын, матур иде. Ул искерде, шуннан аны әнием үзе кыскартып «яңартты».

Әнием арый, бик туңа. Мин аны кызганам, ләкин берниндн ярдәм күрсәтә алмыйм. Ярый әле, без Жоралларга күчеп бер-ике ай яшәгәч, Ташкенттан безгә кунакка Шакир абый кайтып төште. Әниемне ул да кызганды булса кирәк, үзенең яшькелт брезент итекләрен аңа калдырды. Әни әнә шул үзенә зуррак булган итекне чолгау өстенә чолгау чорнап киеп йөри башлады. Шулай да итек брезент кына бит. Салкын көннәрдә әнием, өйгә кайту белән, барыбер элеккечә ялангач тәпиләрен җылытып мич янында утыра.

Миңа, ни әйтсәң дә, әнием белән бергә булгач, бик рәхәт. Ашау яклары да яхшырды. Хәзер авызга тәм-том да эләккәли. Дөге дигән нәр-

сәнең кибетләрдә эзе дә юк, ләкин минем әнием тапкыр, көннәрдән бер көнне ул пылауны арпа ярмасыннан пешереп карады. Һәм, әйтергә кирәк, бу тәҗрибә бик тә уңышлы чыкты. Аннан истә калганы тагын шул: ул вакытларда Казанда Торгсин* дип аталган берничә кибет ачылды.

Әнием үзенең алтын йөзеген сатып, шул кибеттән көннәрдән бер көнне өйгә какао һәм тагы нindидер затлы ашамлыклар алып кайтты.

Безнең хуҗалар да бик әйбәт. Без алар белән туганнар кебек тату яшибез. Жорка да әдәпле һәм, әйтер идем, интеллигент җанлы, менә дигән егет. Без аның белән ял көннәрендә өйдә бергә булабыз. Кайчагында безгә Митя керә, чөнки алар да шушы урамда ук торалар, ара ерак түгел. Митя кергәндә без көрәшеп-әүмәкләшеп көч сынашабыз, ә кайчакларда бәхәс куба, барыбыз да бик җитди рәвештә үзебезнең карашларыбызны раслау өчен сүз көрәштерәбез. Хәер, дусларча онытылып, без еш кына романтик темаларга гәпләшә дә беләбез. Көч сынашканда Жоркага каршы торып булмый. Митя белән икебезне берьюлы бөтереп кенә сала.

Һәр көнне кичләрен без Жора белән, чиләкләр сайратып, күрше урамдагы фонтанга су алырга барабыз. Мондый эшләрдә дә ул миннән сәләтлерәк. Су алып кайтканда мин арып калсам, миннән көлә генә.

Жоржикның апасы Лидия Васильевна — буйчан, тулырак гәүдәле, әмма тулылыгы үзенә бик килешле сазаган кыз. Гадәттә, кияүгә чыга алмыйча яки чыгарга теләмичә олыгайган кызлар артык гарьчел, хәтта усал табигатьле булалар, алар күп вакытта кеше белән тынышып яши алмыйлар. Ләкин Лидия Васильевна моның нәкъ киресе. Көләч йөзле, тыныч, ягымлы бер изге җан. Ул астма белән газаплана, әмма үзенең авыруы хакында зарланып, сыкранып кеше күңеленә ник бер тапкыр борчу салсынчы! Аларда бер елга якын яшәсәк тә, безнең арада аз гына да күңелсезлекләр булмады. Хәер, минем әнием дә ачык күңелле, түземле, кеше җаен белә торган акыллы хатын-кыз бит.

Без еш кына, кичке аштан соң җыелышып, әлеге уртак алгы бүлмәдә бер гаиләдәй өстәл артында утырабыз. Чәй эчәбез, беребездә яңа, моңарчы күренмәгән чәй әйберсе пәйда булса, кысташып сыйланабыз. Яки инде болай гына, яңалыклар уртаклашып, гәп сатабыз. Бик күркәм кешеләр безнең хуҗалар.

Әйткәнемчә, Лидия Васильевна астма белән газаплана, бәлки шуңа күрә кияүгә чыгарга базмагандыр. Ләкин ул шулай да шактый озак яшәде. Мин әле ул ягымлы апаны сугыштан соң да очратачакмын. Без әле аның белән туганнарча сөйләшәчәкбез. Жоржикны да күрәчәкмен. Ул, Казан төзелеш институтын тәмамлап, зур абруйлы инженер булачак. Күрәсең, шуңа күрәдер, аны армиядән дә азат иткәннәр. Әмма бу искиткеч егетнең гомере озын булмады, аның йөрәге җитмешенче елларның башында кинәт тибүдән туктады.

Жоржикларда яшәгән вакытларымны иң гүзәл чорларымның берсе дип исәплим. Чөнки иҗат эшенең кешегә никадәр зур шатлыклар бирүен мин беренче тапкыр шул вакытта татыдым. ФЗӨдә укуның икенче елында миңа мәхәббәт дигән тойгының да ләззәтен беренче тапкыр татып карарга туры килде. Мин, үсмерләргә хас булганча онытылып, шашып, үзебезнең класста укучы бер рус кызына гашыйк булдым. Әйе, чын мәгънәсендә гашыйк булдым. Мин гел шуның турында уйланам, мәктәптә аның белән очрашу мине дулкынландыра, хәтта тетрәтә. Мин ул кызга мәхәббәт хатлары язам, әмма аның кулына аларны тапшырырга батырчылыгым җитми. Ул кыз минем татлы кичерешләремне үзенең гадәти игътибарсызлыгы белән рәнҗетеп пыран-заран китерер кебек.

Ул кызның кыяфәт-сыны әле дә минем күз алдымда тора. Киң кал-

*Торгсин — торг с иностранцами.

су маңгайлы, коңгырт күзле, җыйнак, барлык җире килгән гәүдәле. Чая, хәтта бераз хулиганрак иде ул. Аның укуда әз генә дә рәте юк. Бервакыт аны, начар укуы аркасында, мәктәптән куарга булдылар. Бу хәл мине чыгырымнан чыгарды. Минемчә, бу гаделсезлекнең аргы ягы иде. Тәнәфес вакытында, моңарчы һич булмаган кыюлык күрсәтеп, җыелыш оештырдым, ул кызны мәктәптә калдырыгыз дип, класс исеменнән мөдиргә мөрәҗәгать яздырдым. Кызны калдырдылар. Ләкин моңа карап кына ул миңа карашын үзгәртмәде. Мин әллә бар аның өчен, әллә юк дөньяда.

Гаҗәп икән ул беренче мәхәббәт тойгысы! Урамда ул кыз кия торган кызыл берет күрсәм, йөрәгем урыныннан кубып чыгардай булып дулый, күңел түремә татлы дәшһәт ургылып керә.

Кызганычка каршыдырмы, әллә бәхетемә күрәдерме, әйткәнемчә, ул кыз мине бөтенләй өнәмәде, миңа түбәнсетеп карады. Әмма мин һаман аны яраттым. Соңыннан, бик күп еллар узгач, без сугышлардан әйләнеп кайткач, аны олы бер хатын булган хәлендә очратачакмын әле һәм, нәрсәсе өчен соң мин үсмер чакта аны шулкадәр шашынып яраттым, дип аптыраячакмын. Минем каршымда гайбәтчел, дөнья баскан, телендә бары көнкүреш хәлләре генә булган, хатын-кыз нәфисләгенең эзе дә калмаган тупасрак бер хатын басып торачак. Мәңгелек мәхәббәт, диләр. Бармы соң ул?

Мин әдәбият белән Җоркаларда торганда бик нык шөгыльләнә башладым. Уйлап табучылар турында повесть язуымны да, аның Абдулла Алиш тарафыннан макталып каршы алынуын да хәбәр иткән идем. Мәктәпне тәмамлагач, әнием белән яңа квартирга, Арча кырына күчкәч, ниһаять, республика газетасына илтеп тапшырдым мин аны.

Хәзер түземсезлек белән аның «Кызыл Татарстан»да басылып чыгуын көтәм. Ләкин атналар, хәтта айлар да үтә — хәбәр-фәлән юк.

Без хәзер әнием белән Арча кырында яшибез. Әнием якындагы унсигезенче татар мәктәбендә укыта, читтән торып педагогия институтының тел-әдәбият бүлегендә укый. Мин исә Вахитов заводында эшлим.

Әсәремнең язмышы өчен бик борчылам. Ничек инде шулай? Мактап, үзең үк сорап ал да, дәшми-тынмый тик утыр. Бу хәл миңа гайре табигый тоела. Мин газета редакциясенә барырга җөрьәт итәм. Анда миңа повестьның нәшриятка тапшырылуын әйтәләр. Янәсе аның аерым китап булып чыгуы муафыйк. Мин ул чорларда балалар журналында хезмәт иткән Алиш абый янына керәм. Без инде аның белән бик якын мөнәсәбәттә. Аннан сорыйм, миңа эшнең нидән гыйбарәт икәнлеген ачыктан-ачык әйтүен үтенәм. Ул биредә эшли, барысын да беләдер кебек. Ләкин ул белми, үзе дә аптырашта. Алиш абыйның киңәше буенча, Татарстан китап нәшриятында редактор булып хезмәт итүче шагыйрь Нур Баян белән сөйләшеп карарга булам. Нур Баянны күреп тә, укып та беләм. Әле дә аның тышкы кыяфәте күз алдымда тора. Чандыррак, башына кепка, өстенә күн пәлтә кигән, иелебрәк йөри, күзлекле бер кеше. Мин аның шигырьләрен артык өнәмим. Ул Такташка ияреп яза, ләкин Такташ килеп чыкмый...

Көннәрдән бер көнне, батырланып, аның янына кердем. Ул миңа әсәрнең хәзер рецензиядә икәнлеген әйтә. Рецензиядән килсен, аннан хәл итәрбез, ди. Мин тагын көтәм. Хәзер инде рецензия көтәм. Ниһаять, менә ул. Рецензент — Халикъ Садри. Мин аны да беләм ит.

Хәтердә, Казан шәһәре уйлап табучыларының ниндидер бер зур җыелышы булды. Ул вакытны республика уйлап табучылар оешмасының башында Халикъ Садри тора иде. Мин, бу язучының әсәрләрен укыган кеше, ул әлеге җыелышта ясаган докладны аерата игътибар белән тыңладым. Менә нинди икән ул Халикъ Садри! Җәлпәк генә битле, саңак сөякләре күзгә бәрелеп торырлык калку, буйчан,

олы бәдәнле, «Зиятдин балалары»ның авторы. Мин әле бу кешенең, язучылыгыннан тыш, «Спартак» аяк киемнәре фабрикасының директоры икәнлеген дә, заманында Самарада Валериян Куйбышевлар белән бергә эшләгән кеше икәнлеген дә белә идем.

Мин докладчының кыюлыгына сокландым. Русчаны бераз вата ватуын, ләкин бер дә уңайсызланып тормый. Менә ул, сәхнә буенча әрле-бирле йөренгәләп, безгә уйлап табучылар һәм бу эшнең аферистлары турында кызыклы вакыйгалар сөйли. Хәзер инде докладның бөтен эчтәлеген хәтерләмим. Тик ул сөйләгән бер вакыйга әле дә истә.

Берәү килә дә боларга, мин мәңгелек двигатель уйлап чыгардым, ди. Күрсәт, диләр. Теге Халикъ абзыйларны өенә алып китә. Ишекне ачып керсәләр, өстәл өстендә, чыннан да, двигатель сыман бер нәрсәнең маховигы әйләнеп тора. «Менә карагыз,— ди уйлап табучы,— әгәр фәлән сум акча бирсәгез, мин бу машинаның серен ачам». «Бәлки ул әз генә вакыт эшлидер?»— диләр тегеңә. «Ышанмыйсыз икән, әйдәгез өйне бикләп китик»,— ди теге.— Берәр айдан килербез, машина һаман эшләп тора торган булыр». Башлыклар бу тәкъдимне кабул итәләр. Ишекне бик нык бикләп, сургучлап китәләр. Һәм күпмедер вакыттан соң, җыйнаулашып, тагын киләләр. Ишекне ачып эчкә узалар — машина һаман эшләп тора.

Соңыннан гына ялган фаш ителә. Теге аферист машинасын ишеккә тоташтырган икән. Ишек ачканда машина маховигы хәрәкәткә килә һәм инерция буенча бер сәгать чамасы әйләнеп тора.

Ә минем повестька язган рецензиясендә Халикъ Садри, әсәр бик әйбәт, кирәкле темага язылган, ләкин ул озын, аны кырык процентка кыскартырга кирәк, дигән. Мин тагын Нур Баян белән сөйләшәм. «Яз син менә Авдеенко кебек шәп повесть, рәхәтләнеп басарбыз,»— ди шагыйрь.

Хәзер инде әсәрнең басылмаячагын беләм. Ниләр генә уйламый адәм баласы, үзенең юлында яткан киртәгә очраса? Минем дә күңелемдә ул вакыт әйтеп бетергесез юраулар, шикләр бөтерелде. Эш нидә соң? Моңа сәбәп минем фамилиям түгелме? Юкса, килешмәгән җирләрен килештерү өчен, миңа берәр тәҗрибәле редактор беркетмәсләр идемени?

Шулай-шулай, дип уйлыйм мин. Үземчә бик дөрес бер карарга киләм. Әгәр мин әдәбият мәйданына омтылам икән, бу теләккә үз фамилиям белән беркайчан да ирешә алмаячакмын.

Мондый карар, бәлки беркатлылыгым аркасында тугандыр. Ләкин шул көннән соң үземә кушамат-псевдоним эзли башладым.

Әниемнең сөйләгәннәре искә төшә. Кара! Минем кендек әбием Расиха атлы булган бит! Әниемнең сөйләвенчә, ул бервакыт минем күкрәк анам да булып, әнием авыру чакта мине үзенең күкрәк сөте белән тәрбияләгән. Аның да күкрәк баласы булган. Нигә миңа үземне А. Расих дип йөртмәскә? Бернинди Атилла да түгел, Рәсүлев тә түгел, ә А. Расих. О. Генри бар ич, шуның кебегрәк... Минем имзага инде, агайне, ул чак берәү дә, бу сыйнфый дошман нәселеннән, дип бәйләнмәячәк.

ФЗӨне бетергәндә миңа дүртенче разряд бирелде. Мин инде хәзер цехка чыктым. Аерым станок беркеттеләр. Эшләр хәзер көйле генә бара. Мин ударник. Уйлап табу эшен дә Семен белән бергәләп алып барам. Ләкин шулай да хәзер шактый авыр. Станок янында инде көненә дүрт сәгать кенә түгел, ә сигез сәгать буе эшлим. Аерата төнге сменаларда эшләве авырга килә. Трамвайлар йөрмәве аркасында еш кына өйгә җәяүләп кайтам. Аякларның авыраюы, үзалдына гүләп, сыкрап торуы әле дә хәтердә. Әмма яшь организм тиз язылa. Иртәгесен инде син, берни дә булмагандай, үзеңне сау-сәламәт итеп сизәсең.

Мин хәзер элекке дусларым Зиннәтләрдә, Наилләрдә сирәк булам. Хәзер дустым Морат белән күбрәк очрашабыз. Ул, Казанга килеп, медицина институтының рабфагына керде. Кайчандыр юаш, артык сабыр булган Морат хәзер тәмам буйга җитеп, акылга утырып дигәндәй, мөстәкыйльлек сабагын алган бер егет. Ул һәр ялда безгә килә. Һәр кунакка якты чырай күрсәтә белгән әнием безне, булдыра алганча, тәмле ризыклар пешереп сыйлый. Мин Моратка повестемнең өзекләрен укып күрсәтәм.

Әйе, менә шулай тулы канлы бер тормыш белән яшәп ятам. Миңа бары өч нәрсә генә җитми: йөргән кызым юк, әдәбият мәйданына аяк баса алмыйм, укуымны дәвам иттерү мөмкинлеге күренми.

Габдрахман абыйлар бездән ерак тормыйлар. Әнием Сәүдә апаның үзен өнәмәвен, дөресрәге — абыйсы Габдрахманны яратмавын белсә дә, туганлык хакына алар гаиләсенә гел яхшылык итәргә тырыша. Әгәр берәр тәмле нәрсә пешерсә, әнием аларны чакырмый калмый. Сәүдә апа, гадәтенчә, безгә керүдән баш тартса, әни аларга күчтәнәч кертә. Әнием кебек туган җанлы кешеләрне мин бик сирәк очраттым үз гомеремдә.

Ял көннәренең берсендә, Габдрахман абыйларга кереп, аларда моңарчы миңа очрамаган ниндидер бер чибәр кызый күрәм. Ул үзе минем яшьләрдә булыр, тулы, алмадай кызарып торган битле, чем кара күзле, сызылып киткән каләм кашлы. Әйтәсе юк, гүзәлләрнең гүзәле, барлык җире килгән, халык әйтмешли, бер кашык суга салып йотарлык. Мәрзия атлы икән үзе. Сәүдә апа аңа Бәзия дип дәшә.

Гадәттә кызлар белән артык ачылып сөйләшергә яратмасам да, бу кыз белән без ничектер ансат кына танышып киттек. Ул Сәүдә апаның туган тиешлесе икән. Мәрзиянең Бишбалтада ФЗӨ мәктәбендә укыганлыгы да мәгълүм булды.

Сәүдә апа бу очрашуны махсус оештырмады микән, дип тә уйлыйм мин. Ни өчен дигәндә, Сәүдә апа, без сөйләшә башлау белән ниндидер сылтау табып, ишегалдына чыгып китте, өйдә икебезне генә калдырды. Алай гына да түгел, әйләнеп кайткач, безгә бергәләп паркка барып кайтырга киңәш итте.

Без киттек. Көн урталары иде. Паркта әле яңа гына агачлар яфрак ярган чак, халык заты бөтенләй юк диярлек. Ничектер, сөйләшеп йөри торгач, берзаман кыюланып китеп, Мәрзиянең кулыннан тотып алдым, бераздан инде култыкладым да.

Минем әле үз гомеремдә кызлар култыклаганым юк иде. Хәтердә сакланган, Мәрзияне култыклап алуым булды, бөтен җаным-тәнем үзенә бер төрле тетрәнү кичерде, миңа эсселе-суыклы булып китте, мин беразга бөтенләй телдән калдым.

Бәхетсезлеккә каршы, ул да бик аз сүзле кеше иде. Мин болай тавыш-тынсыз баруның начар икәнлеген яхшы аңлыйм, ләкин әйтер сүз таба алмыйм. Башка килми генә бит берәр сүз! Юк, юк. Нишләмәк кирәк?! Без шулай, култыклашкан килеш, авызга су капкандай тын гына парк аллеяларында йөрибез дә йөрибез. Ниһаять, сөйләшер сүзнең йомгак очын таптым булса кирәк. Ул минем нинди эш эшләвем турында сорап куйды. Иркен бер сулыш алып, сүзгә керештем. Һөнәрем турында, станок турында, инструментлар турында сүз китте. Ләкин бу теманың кызым өчен кызык түгеллеген үзем дә тиз абайладым. Уңайсызланып, тагын тукталам. Нәрсә турында гына сөйләргә соң, йә хода!?

Бераздан ниндидер китапта язылган вакыйга турында сөйли башладым. Минем өчен бик кызыклы тоелса да, Мәрзиямнең исни үк башлавы мине тәмам аяктан екты. Мин инде сүз табудан гаҗизмен. Үземнең шаркылдап көләрлек берәр нәрсә сөйли алмавымнан гарьләнәм дә, аптырыйм да. Юкса мин, дус-ишләр арасында җыен юк-барны сөйләп, аларның эчләрен катырып бетерә торган кеше.

Күп еллар узганнан соң гына бер кагыйдәне белдем: андый чакта тузга язмаган нәрсәләр турында гына сөйләшергә кирәк икән. Андый чакны егетне хур иткән нәрсә — тирән мәгънә, акыллы сүз эзләп маташу икән.

Без шулай да, элекке исеме белән әйткәндә, «Казан Швейцариясе»ндә байтак йөрдек. Аны озатып кайткач, аерылышыр алдыннан, без тагын кайчан очрашуыбыз турында вакыт билгеләдек. Ул Сәүдә апаларга китте. Мин исә, ни әйтсәң дә, каһарманлык эшләгән бер батырдай канатланып, өйгә таба юл тоттым.

Ә берәр атнадан соң без бик еш очраша башладык. Гадәттә бу гүзәл минутлар Кольцо бакчасында була. Казанның кыл уртасында, заманында Балык базары булган урында, рәшәткәле түм-түгәрәк сквер. Утырып ял итәргә артлы эскәмияләр дә бар. Трамвайлар, көпчәкләре ышкылудан чыелдашып һәм дугаларыннан очкыннар сиптереп, бакча тирәсендә әйләнсәләр әйләнәләр — әмма бу безгә комачау ясамый. Без Мәрзия белән монда озак утырмыйбыз. Арча кырына паркка menәбез яки Тукай урамындагы «Чаткы» кинотеатрына юнәләбез.

Кичләрен аулакта, берәрсенең капка төбендәге эскәмиядә Мәрзия белән икәүдән-икәү генә янәшә утырган чаклар да еш булгалый. Ул тын гына нидер уйланып утыра, мин дә тын гына, сүзне нидән башларга белми утырам. Үземнең мөнәсәбәтемне бары аның кайнар йомшак кулын кысып кына белдерә алам. Ул миңа озын керфекле күзләрен тутырып кына карап ала. Бу карашта сорау, нидер өмет итү чагылган кебек, моңа җавап итеп мин аның учымдагы кулын тагын да кыса төшәм. Һәм без, тагы авыр сулап, тын гына утырабыз.

Безнең дуслык бер-ике атна дәвам иткәннән соң, өйләнешергә булдык. Нигә өйләнмәскә? Шундый матур кыз, үзе мине ярата ди. Мин бит инде хәзер бала түгел, миңа дүрт айдан унтугыз яшь тула. Тик миңа өйләнгәч, гаилә корып җибәрү өчен бер куыш кирәк. Мәрзиянең ата-анасы юк. Үзе дә бер бәләкәй генә почмакта яши. Ә минем аны өйгә алып кайтырга бер генә мөмкинлегем дә юк.

Без, Мәрзия белән нык кына уйлаштык та, мондый карарга килдек: мин, тотам да, Урта Азиягә китәм. Анда тормыш җиңел, ди, квартир табуы да бик ансат булыр. Кулда — менә дигән һөнәр, анда минем кебек токарьларга зарыгып торалар. Әлбәттә, без Мәрзия белән бергә дә китә алыр идек, тик Мәрзиянең укуы бетмәгән. Ул ике айдан соң гына, укуын тәмамлап, тукучы һөнәре алып чыгачак.

Планыбыз яхшы. Урта Азиядә безнең Шакир абыйлар яши, мин инде башта шуларга барып төшәчәкмен һәм Мәрзия килгәнче барысы да без уйлаганча көйләнәчәк.

Һай, яшь кешенең беркатлы уйлары! Ул чакта миңа сөю-мавыгу дигән нәрсә алдында барысы да, хәтта минем барлыгымны, йөрәгемне биләгән гүзәл әдәбият та, бала чактан ук яшәвемнең иң көчле чыганагы булган уку, белем алу да арткы планга күчтеләр. Мин андый нәрсәләрнең барлыгын оныттым. Бик бөек тоелган ул максатлар бөтенләй кичерәеп калдылар. Гаҗәп икән ул яшьлектәге мавыгулар.

Кыскасы, без Мәрзия белән сүзне шулай беркеттек. Вәгъдә — иман! Әйткән сүз — аткан ук! Егет сүзе бер булыр! Мин эшләгән җиремнән киттем. Әниемә, дөнья күреп кайтасым килә, Шакир абыйларга барып кайтырга уйлыйм, дидем. Юл кирәк-яракларын кечкенә чемоданга тутырдым да, скрипкамны алып, Үзбәкстанга, Термез шәһәренә таба юл тоттым.

## 25

Атна буе юл газаплары кичергәннән соң, тәмам хәлдән таеп, Термез шәһәреннән арырак урнашкан Комкурган совхозына барып җиттем.

Шакир абый шушы совхозның тыштан акшарланган балчык кибетендә сатучы булып хезмәт итә. Тирә-як футбол кырыдай тип-тигез җирдән гыйбарәт. Өйләр барысы балчыктан ясалган, бер катлы, яссы түбәле. Җир кызган табадай, яланаяк басарлык түгел. Юлларга кызгылт-сары тузан түшәлгән. Аңа баскан саен, аяк тубыктан шул көлсыман кайнар нәрсәгә чума, өскә пырхылдап тузан болыты күтәрелә. Миңа бу як җирләренә килеп керү белән күренгән телеграмм баганаларындагы зәңгәр каргалар бик сәер булып тоелган иде. Инде бераздан юлда очраган дөяләр, ишәкләр, аларга атланган чалмалы кешеләр, мәһабәт чинарлар игътибарымны җәлеп итте. Ә менә монда, Комкурганда, мин шуларның нәкъ уртасында. Монда үзбәкләр һәм таҗиклар яши. Барысы диярлек сакаллы, буй-буй төсле, биленә калын пута буылган чапаннардан, төрле төстәге керле чалмалардан.

Шакир абыйларның квартиры кибет белән бер үк түбә астында. Шакир абый мин килеп төшү белән кибетен япты, өйгә кереп, чәй эчәргә утырдык. Мин Казаннан ук телеграмма суккан идем, алар мине тиешле әзерлек белән каршы алганнар. Фатыйма апа тәмле пылау пешергән, чәй янына йөзем, кипкән өрек, кавын эчәгесе, өрек төше, үзбәк наны куелган.

Биредә хикәямне беразга өзеп, Шакир абыйның тормыш хәлләренә тукталырга уйлыйм. Башта әйтелгәнчә, Шакир абый артистлар труппасы белән ачлык елында Троицкидан Урта Азия җирләренә китә. Труппа нинди дер сәбәпләр аркасында таркалгач, иске һөнәре буенча, сәүдә эшенә керә. Дәүләт сәүдәсе оешмаларында эшли башлый. Шул эшендә йөргәндә Сәрвәр апаны очрата һәм алар өйләнешәләр. Бу вакытта Шакир абыйга инде илле яшьләр була.

Сәрвәр апа заманында «йомышлы татар» дип аталган, Азия белән Россиягә арадаш буларак, Россиягә күп хезмәтләр күрсәткән бер гаиләдән. Ул ифрат ябык, зифа буйлы, җитез һәм уенчак, теле үзбәкләшкән нәфис бер хатын иде. Шакир абыйга чыкканчы ул кияүдә булган инде, ләкин аерылган. Әмма ул шулай да кызлар кебек чибәр, елдам, үзбәк биюләрен һәм җырларын профессиональ осталык белән башкара. Мин аның кияүгә чыкмый картайган апасы Мәрьям Якупова турында да әйтергә тиеш. Аның турында әле кичәчәктә Фатих Кәриминең атаклы «Истанбул мәктүпләре»ннән укып күп мәгълүмат алачакмын. Хикмәт шунда: бу врач — Мәрьям апа Якупова — уникенче елгы Балкан сугышы вакытында ирекле булып Төркиягә китә, янә ике татар кызы белән (аларның берсе — алда искә алынган Гөлсем апа) шәфкать туташы буларак, яралы төрек солдатларында медицина ярдәме күрсәтә.

Шакир абый белән Сәрвәр апа бик матур яшәделәр дип исәплим мин. Аларның Фәрит исемле бер уллары да булды. Ләкин ул егетнең язмышы коточкыч ямьсез тәгәлләнде. Хәер, бу турыда соңрак. Хәзергә сүз Сәрвәр апа турында. Кызганычка каршы, уенчак, күбәләктәй җиңел сөякле Сәрвәр апаның гомере озын булмады. Ул утызынчы ел урталарында ук вакытсыз үлеп китте. Шакир абый Фәритне Мәрьям апага уллыкка тапшырырга мәҗбүр булды. Берәр ел тол яшәгәннән соң, ул казанлы Фатыйма апага өйләнде. Фатыйма апа Шакир абый вафат булганчы аның белән яшәячәк.

Ә Шакир абыйның бердәнбер улы Фәрит, әйткәнемчә, тормышын ямьсез тәгәлләде. Ул башлыча, әнисе үлгәннән соң, Сәрвәр апаның олы туганы Мәрьям апада тәрбияләнде. Бу егет күбрәк әнисенә охшаш иде. Шундый ук җиңел сөякле, хискә тиз бирелүчән, искиткеч матур тенор тавышлы җырчы, кешелекле һәм чибәр.

Ул, Ташкентта медицина институтын тәмамлап, балалар врачы булды. Әмма үзенең берсеннән-берсе гүзәл улларын бәхетле итә алмады. Врач булып эшли башлагач та, эчкечелеккә бирелде. Бераздан әле ул бөтенләй тилереп, котырып эчә башлаячак, чын алкоголикка

әйләнәчәк. Һәм шулай яман каты эчкән көннәренең берсендә ул, исерек хәлендә, Мәрьям апаны пычак белән чәнчеп үтерәчәк...
Бу коточкыч фаҗигадән соң Фәрит диваналар шифаханәсендә ятачак, ләкин аннан чыккач та эчкечелеген ташламыйча, ахырда аракыдан агуланып үләчәк.
Ә бит бик-бик гүзәл, ачык, ягымлы кеше иде минем бу туганнан туган энем.
Ә хәзергә мин кипкән, корыган Үзбәкстан җирендә, һәр яңалыкка шаккатып, яңа дөнья белән танышам. Май ае гына әле, ләкин шул кадәр эссе, һич чыдар чама юк. Юкка гына Термезны эсселек котыбы дип атамыйлар шул! Ләкин бер генә минутка да онытылмыйм. Мин бит бирегә бик җитди максатлар белән килгән кеше. Минем эсселектән куркып өйдә ятарга хакым юк. Килгәннең икенче көнендә үк совхоз мастерскоена юнәләм. Ул саманнан салынган зур амбарны хәтерләтә. Анда теләсә кем кереп йөри ала. Рөхсәт. Эчтә ике кыру станогы, бер тишү станогы һәм эшкә яраксыз фрезер станогы. Токарь булып озын борынлы, чандыр бер рус эшли икән. Беренче күрүдән үк мин аның әтрәк-әләм икәнлеген аңладым. Андый бер җирдән икенчесенә очып йөрүче эчкечеләрне Казанда да күргәләгән бар иде.
Хезмәткә урнашу озакка сузылмады. Бер станок күптән буш тора икән. Мастерской мөдире, юан бәдәнле рус кешесе, шул станок янына алып керде дә, инструментлар тәрәзә янындагы верстакта, дип, аягы белән генә төртеп күрсәтте. Нәрсә эшләргә кирәклеген төшендерде һәм китеп тә барды.
Мин эш кораллары белән танышам. Йә ходай! Монда җүнле бер генә дә эш коралы юк бит. Кискечләр үтмәс, сыньк, җитмәсә гади корычтан ясалган, кайракка тидерү белән аксыл йолдыз чәчрәтәләр. Кайда ул минем Казандагы, кадерләп тоткан эш коралларым?! Аларны кайракта үткерли башлагач та кан кебек кып-кызыл очкыннар чәчри иде бит! Ләкин нихәл итәсең. Тимерчелектә (аныс да ташка үлчим) кискечләремне чыныктырып чыктым да, станокны худка җибәрдем. Һай, һай, һай! Станок дип әйтерлеге дә юк ич моның, бу бит ватык арба. Ләкин... мин станокны бераз киртәсенә керерлек бер хәлгә китереп, тарттырасы гайкаларны, тарттырам, шөрепләрне боргалыйм да, тешләремне кысып булса да түзеп, эшкә керешәм.
Шулай итеп, беренче адым ясалды. Мин әлеге озын борынлы әтрәк-әләм белән танышам. Ул гаҗәп кеше икән үзе. Җырчы булырга хыялланган, әмма моңа ирешә алмаган бер бәхетсез җан. Рус операларыннан шундый арияләр җырлап җибәрә — шаклар катарсың! Ул: «Мин беренче солист булырга тиеш идем, минем урыным Мәскәүнең Большоенда иде, тик аяк чалдылар»,— ди.
Беренче көннән үк кызымнан хат көтә башладым. Казанда ук аңа Шакир абыйлар адресын биргән идем бит. Үзем исә алдан ук хатлар сала килдем.
Мин эшлим. Дәртләнеп эшлим. Калып та эшлим, вакыт дигән нәрсә һәм ял белән исәпләшми эшлим. Ул кадәр ватылма, ди теге бәндә, барыбер монда түләү бик түбән, куелганыннан артыгын түләмиләр, ди. Мин аңа ышанмыйм, кара тир түгәм, әмма станок яныннан китмим. Арып-талып өйгә кайтам. Кичләрен бераз ял иткәч, тәрәзәне ачам да скрипка уйныйм. Бөтен Комкурган мине тыңлый сыман.
Бер ял көнне без Шакир абый белән дача поездында Термезга бардык. Анда Шакир абыйның күптәнге дуслары, сәүдә эшендәге якын танышлары бар. Без Фәйзи абыйларда тукталабыз. Фәйзи абый исә сары гына төкле, салынкы борынлы бер кеше. Әмма аның хатыны Сәгадәт апа гүзәлләрнең гүзәле. Була бит шундый кара күзле, төз борынлы, матур авызлы, зифа буйлы, дулкынланып торган чәчле чибәр татар хатыннары. Ул — әнә шуларның беренчесе. Алар белән бер үк ишегалдында тагын Сәгадәт апаның сеңлесе Маһирә апа да

яши. Ул да бик чибәр. Анысының да ире ямьсез бер кеше. Тупас йөзле, пеләш башлы. Истә калганы шул: аларның ишегалдында көне буе патефон уйнаталар. Бу ике баҗа гаиләсендә өч бала ускәнлеге истә калган — бер малай, ике кыз. Кызларның берсе Сәгадәт апаныкы, икенчесе сеңлесенеке.

Байтак еллар узгач, без сугышлардан әйләнеп кайткач, әлеге патефон уйнатучы кызның әнисе Мәһирә апаны мин Казан урамында очратачакмын һәм аның кызы Венера Шәрипованың атаклы татар җырчысы булып киткәнен ишетәчәкмен.

Әлегә мин кечкенә ак балчык өйләр шәһәре, Әфганстан чигендәге болганчык сулы дуамал Амударья буендагы Термез шәһәрендә. Шакир абыйның танышларына Казан хәлләре турында сөйлим. Үземнең Урта Азия якларында эшкә урнашып калырга теләгәнлегемне аңлатам. Ләкин төп максатым — өйләнергә җыенуым турында ләм-мим.

Мондагы якташлар мине аңлыйлар, алар миңа хәер-хаһ. Тик минем, урта белемле бер кеше була торып та, монда килеп станок янына басуыма аптырыйлар. Аларча бу акыллы эш түгел, иң кимендә үз кадереңне үзең белмәү. Бу ялгышны Термезга күчеп тиз арада төзәтергә була. Анда менә дигән эшкә керергә була, диләр.

Мин, чыннан да, уйга калам. Күз алдыма Комкурган совхозы, андагы ялангач, кипкән бушлыклар, мастерскойдагы көйсез станок килеп баса. Сүз иярә сүз чыгып, тагын шундый бер яңалык ишетәм. Биредәге Биһбуди исемендәге җидееллык мәктәпнең директоры Кәлим Исламов дигән бер татар икән. Үзе шагыйрь дә, ди. Тукта, тукта! Бу теге әнием белән бергә Шәле авылында укытучы булып эшләгән Кәлим Исламов түгелме соң?

Озын-озакка сузмыйча, Биһбуди исемендәге мәктәпне эзләп табам, аның завхозы белән очрашам, сорашып ачыклыйм. Әйе, Исламов шул үзе, Кәлим Әспиран! Шәледә минем белән күп тапкыр әдәбият турында гәпләшеп утырган, хикәяләр, шигырьләр язучы, мандолинада шәп уйнаучы, йөзеннән беркайчан да ирония чалымнары китми торган, ләкин рәхимле Кәлим Әспиран. Әле ул үзе өйдә юк икән, Татарстанга хатынын бәби табарга озата киткән. Шушы көннәрдә әйләнеп кайтачак. Ул биредә бик абруйлы кешеләр рәтеннән, зур хөрмәт казанып яши, имеш.

Шундый яңалыклар ишетеп, иртәгесен беренче поездда Шакир абый белән Комкурганга кайтып киттем.

— Йә, ничегрәк уйладың? — дип сорады берничә көннән соң Шакир абый.

— Китәм,— дидем мин.— Термезга барып урнашам, чөнки монда эшнең бер дә рәте юк. Станок начар, җүнле корал юк...

Шакир абый миңа, Фәйзи абыеңа тапшырырсың дип, хат язып тоттырды. Чемоданымны, скрипкамны алдым да, поездга утырып, Термезга киттем.

Икенче көнне үк мине эшкә урнаштырдылар. Мин хәзер — китап магазиннарының район идарәсендә инспектор. Эшем — райондагы китап кибетләренең эшен тикшерү. Эшли торган төп урыным — китап складлы. Монда рәхәт, монда салкынча. Бөтен тирә-ягым китап белән тулган. Аларның күбесе үзбәк телендә булса да, буш вакытны шуларны актарып уздырырга ярый. Урын начар түгел, әмма күңел тынычланмый, чөнки Мәрзиядән берниндиә дә хәбәр юк. Ничәмә хат язып салдым үзенә, бер генә юллык хәбәр килсенче!

Мин эшлим. Китап кибете булган бер кышлакка да барып кайттым. Андагы китап магазинын тикшердем. Минем хәзер үземнең квартирам да бар. Складтан ерак түгел, иркен ишегалдының түрендәге җир идәнле бәләкәй балчык өй.

Иләмсез эсселәр башланды. Төннәрен йоклап булмый. Идәндә

ятам. Йоклар алдыннан урын-җир янына ишегалдындагы коедан чиләк белән салкын су кертеп куям. Шул суда җәймәне чылатам да шәрә килеш шуны ябынып ятам. Җәймә кипкәнче йоклап була. Ул киптеме, әсселеккә чыдар хәл калмый; уянып, яңадан җәймәне чиләккә батырам.

Биредә үземә бик әйбәт бер иптәш таптым. Ул милләте белән дүнгән. Шулкадәр акыллы, ипле, күңелле егет. Үзе татарча менә дигән итеп сөйләшә. Без хәзер буш вакытларда һәр көн очрашабыз. Хәтта бер тапкыр Амударьяга дә бардык. Данлыклы Аму гаҗәп елга икән ул. Аның саргылт, болганчык суы котырынып ага. Суга керсәң, аякта басып торыр хәл юк — егыласың. Ятсаң, агым очыртып алып китә. Шулай да бераз йөздек, комда да берничә минут кызынып яттык. Су буенда чик саклаучы кызылармеецлар ат коендыралар, ә без дүнгән егете белән гәп сатып кояшта кызынабыз. Су аръягында — Әфган җирләре, анда бернинди хәрәкәт һәм кеше заты күренми.

Без кояшта күп булса ун минут ятканбыздыр. Ләкин моның нәтиҗәсе мин көткәнчә булып чыкмады. Шул ук кичне минем аркам сулы куыклар белән капланды. Алар бераздан сытылып, җәрәхәткә әйләнделәр. Арка авыртуына түзәр хәл юк. Ул кояшта тәмам янган. Менә сиңа Аму!

Ә Мәрзиядән һаман хәбәр юк. Берәр фаҗигале хәл була күрмәсен инде. Мин бик борчылам. Мин аны һаман бик әйбәт итеп каршы алырга җыенам. Вакыт-вакыт минем хезмәт хакым да аз тоела башлый. Карасана, чыннан да, эш хакым тормыш корып җибәрү өчен җитәр микән? Мин бит гаилә корасы кеше. Минем бит кирәк-яраклар да аласым, рәтле кием дә җунәтәсем бар. Болай булмый. Өстәмә эш алырга кирәк!

Мондагы кинотеатрның афишаларына игътибар иткән идем инде. Бигрәк хәрти тоелды алар миңа. Мөгаен, аларның художниклары юктыр, дип уйладым мин. Кинога барып, аның мөдире белән сөйләшәм. Кирәксенсәгез, мин сезгә художниклык хезмәтен күрсәтә алам, дим. Әлбәттә, билгеле бер эш хакы бәрабәренә. «Юк шул, кирәксенмибез, безнең бик шәп художнигыбыз бар, ул әле ялда, шушы көннәрдә кайтачак, бу әле мин язган афишалар гына,— ди мөдир.— Нәрсә рәте-җүне юкмы?»

Монысы барып чыкмады. Нишләргә соң? Мәрзиянең килешенә бераз акча туплаганда шәп булыр иде дә... Термезда радиоузел бар икән. Чәйханәләрдә гәпләшеп, чәйләп, пылау ашап утыручыларның репродуктордан үзбәк җырларын тыңлап кәефләнгәннәрен үзем күреп торам. Туктале, булмаса болай итеп карыйм...

Көннәрдән бер көнне мин, көндезге ял вакытыннан файдаланып, скрипкамны култыкка кыстырдым да, радиоузелга киттем. Андагы кеше белән сөйләшәм. Янәсе, мин сезнең тапшыруларны үземнең скрипка уеным белән җанландырып җибәрә алам. Теләсәгез, мин моңа әзер. Билгеле, эш хакы түләнсә.

Кызганычка каршы, аларда мондый эш хакы каралмаган икән. Шулай да узел башлыгы миңа ул көнне микрофон алдында скрипкада уйнап күрсәтергә кушты. Мин, бөтен чәйханәләрдәге мићманнарның игътибарын җәлеп итеп, скрипкада татар көйләре сыздыра башладым. Бу исә соңыннан һич көтелмәгән гаҗәп бер нәтиҗә бирде. Гаҗәплеге шунда — Термезның бик күп татары минем уенны яратып тыңлаган булып чыкты. Мин берзаман татар агайне алдында атаклы скрипач булып киттем, кунакка чакыра башладылар. Ә Термезда татарлар җитәрлек. Хәлле, таза тормышлы, туган якларын сагынып, әмма бу җылы урыннан китәргә батырчылык итмичә яшәүче татарлар алар.

Көннәр бик эссе булу аркасында, гадәттә, учреждениеләр иртәнге якта һәм көн сүрелә башлагач кына эшлиләр. Кыскасы, хезмәт көне

бик соң бетә. Мин хәзер эштән соң, складымнан кайтам да, скрипкамны култык астына кыстырып, көн аралаш диярлек, кунакка ашыгам. Биредәге халык портвейнны суытып эчә. Юка кырлы стаканга кызыл салкын шәрабне салалар, төбеннән генә тотып чөмерәләр. Мин уйныйм, кунакларның күңелен ачам. Миңа да портвейн биргәлиләр.

Кем белә, бәлки минем бу яшьлек җүләрлегем бер кәсепкә әйләнеп үк киткән булыр иде. Әммә Мәрзиядән хатлар килми интектерүе һәм бер олы абзый белән дуслашып китүем мине бу юлдан коткарып калды.

Олы абзый дигәнем — Габдулла атлы бер кеше — мин яшәгән ишегалды каршындагы кибетнең сакчысы иде. Бер тапкыр, урамнан узып барганда, ул үзе мине янына чакырып алды. Сораша башлады. Сүздән сүз китте. Без шулай танышып та алдык. Инде мин кунакка бармаган көннәрдә кичләрен гел аның белән булам.

Бервакыт Кәлим Исламовның Казаннан кайтып төшкәнлеген ишеттерделәр. Билгеле инде, мин шундук аңа йөгердем. Гадәтенчә, Кәлим мине кочаклап каршы алды. Ул мәктәп бинасында ук яши икән. Хәзер ялгызы гына калгач, минем килеп чыгуыма бик шатланганын белдерде, үз квартирында куныл калырга кыстый башлады. Мин квартирыма скрипка алырга киттем, ул сый әзерли калды.

Менә без мәктәп коридоры идәненә җәелгән паласта табын тирәсендә утырабыз. Без өчәү — Кәлим минем янга тагын бер яшь укытучыны чакырган. Аныcы үзбәк егете.

— Безнең мәктәпнең мөгаллимнәреннән,— дип таныштыра мине Кәлим аның белән. Минем гаҗәпсенүемә каршы, Кәлим хәзер шигырьләрен үзбәкчә яза икән. Ул миңа район газетасында басылган соңгы шигырен күрсәтә. Без күрешмәгәнгә артык күп гомер дә узмаган кебек, ә ул инде тәмам үзбәкләшеп беткән. Соңыннан ул мине үзбәкләр арасына бер туйга да алып барды. Анда беренче сүзне, могтәбәр кеше буларак, аңа бирделәр. Ул исә мәҗлесне ачып, саф үзбәк телендә шундый нотык сөйли башлады, шаклар катарсың! И, безнең татарның җайлаша белүе! Ничәмә-ничәмә кешебез безнең руслашып, башкортлашып, үзбәкләшеп, төрекмәнләшеп — тагын аллә кемләшеп, шул халыкларның хәзинәсенә мәдәният энҗеләре өстәми!

Беренче очрашуда без Кәлим һәм үзбәк кунагы белән бик күңелле итеп утырдык. Кәефемне бераз кырган нәрсә бары шул: теге үзбәк укытучы мин скрипкада уйнаган татар көйләрен бер дә яратмады. «Мин татарны алдынгы милләт, көйләре дә әйбәттер, дип уйлаган идем, бернигә дә тормый икән сезнең моң»,— дип мине аптырашка калдырды. Менә сиңа зәвык! Мин тагын аңа, барлык тырышлыгымны җигеп, үзем яраткан иң матур татар көйләрен уйнаган булам.

Кәлим шигырьләрен татарча да язгалый икән. Ул заманда урта Азиядә тау араларында басмачылар бетерелмәгән иде әле. Үзбәк, таҗик авылларында Ибраһим бәк дигән корбашы ерткычлыклар ясый. Кәлим шул турыда язылган поэмасыннан өзекләр укыды.

Ә минем Мәрзиякәйдән һаман хәбәр-хәтер юк. Мин бу турыда теге Габдулла абыйга да серемне чиштем. Ул миңа бик җитди генә карады да:

— Борыны нинди иде кызыйның?— дип сорады.

— Ничек инде,— дидем мин аптырый төшеп.— Борыны борын кебек.

— Юк, борынының очы тумпакмы, очлымы?

— Алай очлы түгел...

— Менә!— дип куйды Габдулла абый бик мәгънәле генә итеп.— Тумпак борынлы кызларны беркайчан да якыныңа җибәрмә. Хатын-кызның холкын борынга карау белән белеп була аның. Әгәр тумпак борынлы икән, аннан хатын түгел, ә дәҗҗал чыга. Әгәр борыны очлы икән, аның холкы-фигыле бик ипле була.

— Беләсеңме нәрсә, энем,— диде ул көннәрдән бер көнне миңа, бик үз итеп.— Син юкка уку йортлары үзәге булган Казанны ташлап, бу кыргый якка килгәнсең. Без инде ярый, үз ихтыярыбыз белән түгел. Бу якларда каңгырып, сөрелеп йөрергә нужа куша безгә. Ә бит әле син өеңә кайтып укырга кирә аласың...

Чыннан да, Габдулла агайның сүзләрендә дөреслек юк түгел иде. Бигрәк тә Мәрзиядән бернинди хәбәр килмәгәч, бигрәк тә миңа «скрипач» булып, түбәнсенеп, мәҗлесләрдә бер стакан портвейн өчен кеше күңелен күреп йөрергә туры килгәч...

Мин утыз дүртенче елның июль урталарында Казаныма кайтып киттем.

## 26

Ул төнне минем күзләремә йокы кермәде. Бу, билгеле, артык арудан, өметнең вакыт узган саен кителә баруыннан, комиссиянең соңгы сүзен көтеп алҗудан иде. Мин артык арысам, аерата зур рухи тетрәнүләр кичерсәм, шулай йокыдан мәхрүм калам. Башыма бәйләнчек бер уй кереп, миемне өзлексез каезлый башлый. Димәк, дип уйладым мин, барлык тырышлыкларым, арыш ипие һәм тозлы кильки ашап унөч көн буена Мәскәү урамнарын таптавым бушка гына китте. Хәзер инде бәлки Наркоматка барып йөрүнең дә хаҗәте калмагандыр. Ахыр чиктә алар үзләренең дәһшәтле карарларын миңа почта аша да җибәрә алалар бит. Анда, ичмаса, күңелсез хәбәрне каршы алу җиңелрәк тә булыр. Шулай дип, юка такталар өстенә иске көрпә түшәлгән шыгырдавык ятакта, изге Хәдичә апаны һәм аның кызларын уятмас өчен, артык кымшанмый гына, караңгы түшәмгә карап уйланып ятам.

Хәзер инде минем уйларым — Казанга кайтып исән-сау эшкә урнашу тирәсендә. Әнием дә, эти дә минем уңышсыз сәфәремә бик кайгырачаклар. Ләкин алар моны эчтән кичерәчәкләр. Әле юаткан да булырлар. Исең китмәсен, улым, үзлегеңнән укырсың, диярләр. Ә мин җиң сызганып эшкә керешермен, станок янына басармын. Нигә, начар эшмени ул? Әнә, Зиннәтләр, Наилләр, Гомәрләр уку турында уйлап та карамыйлар. Дәртләнеп, бирелеп эшлиләр, үзләренең көндәлек хезмәтләреннән ләззәт табалар, алар өчен заводтагы хезмәт — иң татлы җан азыгы. Минем кай җирем аларныкыннан артык? Шулай! Ярар, әйдә, мине институтка кайтармасыннар, ди. Аннан гына дөнья җимереләмени! Ярар, бетте, моннан соң мин үз-үземне таба алмаячакмын...

Әмма шулай да... Дөресен генә әйткәндә, алдыңа бер максат куеп ыргылгач, бу эшнең барып чыкмавы рәнҗетмимени адәм баласын? Аннан бит әле, тирәнтенрәк уйлап карасаң, уку хокукыннан мәхрүм ителерлек гаебем бармыни ил каршында?

Аңлыйм мин политиканың асылын. Ул иң элек чыгышлары белән изелгән сыйныф вәкилләре укысын һәм алар командалык постларын алсын, юкса дошман сыйныф вәкилләре аларны басып китәр, реставрация булыр дип уйлаудан. Тик бу миңа карата дөрес түгел. Икмәктер менә!

Мин үземчә шулай, мәсьәләнең һәр ягын исәпкә алып, төрлечә фәлсәфә корып, бу фәлсәфәмнең әле бу, әле теге ягын тикшереп ятам. Ахыр чиктә минем бу уйлануларым — үземне тынычландыру өчен. Салына башлаган канатларны үз урынына күтәреп кую иде максатым.

Шулай төнне уздыра алмый азапланам. Ниһаять, июль иртәсе килде. Гадәттәгечә ашык-пошык, сабынсыз гына юынып, портфелемне эләктердем дә, өйдән урамга чыгып киттем.

Караңгы коридорда, әле бик иртә булуына карамастан, примуслар чыжлый, безнең Хәдичә апа да үз өстәле янында кайнаша. Мин, аңа күренмәскә тырышып, ишеккә таба ашыгам. Соңгы вакытларда мин аның, әле озак торырсыңмы икән, энем, кайчан исәп-хисапны өзәрбез икән, диюеннән куркам.

Ходайга шөкер, мине шәйләсә дә, Хәдичә апа андый сорау биреп туктатмады. Бары, нишләп шул кадәр иртә тордың, дип кенә калды. Мин бик кыю тавыш белән: «Эш, эш шулай йөгертә»,— дигән булдым.

Наркоматка минем аякларым бөтенләй тартмый иде. Мин анда нинди сүз ишетәчәгемне юрап беләм. Аның зур, пар ат сыярлык ишегеннән кире чыкканда канатларымның тагын да каерыла төшкән буласын сизәм.

Трамвайларга утырып тормадым. Мин инде барасы юлны биш бармагым кебек шәп белә идем. Җәяүләп кенә, анда да әле эленке-салынкы гына атлап барам.

Кабинетка барып керү белән Агриппина Евграфовна мине, яктырып кына түгел, урыныннан ук сикереп торып каршылады. Миңа тискәре җавап булган, шуңа күрә бу сөйкемле апа минем башка төшәчәк чукмарны җиңеләйтү өчен тырыша, дип уйладым. Әмма апа, кулындагы папкадан бер бит кәгазь алды да миңа таба атлады. Аның йөзе шатлык белән тулы, күзләрендә бетмәс-төкәнмәс куаныч нуры чагыла иде. Агриппина Евграфовна каты үкчәле туфлиләре белән түк-түк басып килде дә иңемнән кысып тотты.

— Булды бит, иптәш Рәсүлев! Сезне чын күңелемнән котлыйм, акыллым!

Күкрәктән башыма кадәр ниндидер кайнар нәрсә күтәрелүен тойдым. Ләкин бу дәһшәт кайнарлыгы түгел, шатлык җылысы иде. Мин, тиле кешедәй өнсез килеш, урынымда тик басып торам. Агриппина Евграфовнаның миңа кәгазь тоттырганын да, аның «Комиссиянең карары» дигән сүзләрен дә төштәге кебек кенә кабул иттем.

Мин, һаман елмайган килеш, күзләремне язу юллары буйлап йөртәм. Ләкин ачык кына берни дә күрмим, юллар, хәрефләр бутала.

Ниһаять, якын итеп янып-көеп йөргән секретарь апаның кулын ашыгыч кына кыстым да Мәскәү урамнарына ташландым.

Хәзер Казанга, Казанга кайтырга кирәк миңа! Кайтырга, әти-әниемне, институттагы дусларымны шатландырырга, тизрәк имтиханнарны биреп, курстагы иптәшләремне куып җитәргә!

Наркоматтан чыгу белән, йөгереп Хәдичә апаларга кайттым. Вактөяк әйберләремне портфелемә салдым. Түр якта нидер ямап утырган Хәдичә апа янына уздым:

— Мин сезнең белән саубуллашырга һәм исәп-хисапны өзәргә тиеш,— дидем. Күрәсең, минем йөземдә уйнаган шатлык чалымнарыннан ук Хәдичә апа сизенде булса кирәк. Яктырып:

— Теләкчә булдымы барысы да, энем?— диде.

— Барысы да нәкъ мин теләгәнчә булды, рәхмәт сезгә,— дидем.— Әгәр сез мине өегездә тотмасагыз, берни дә майтара алмаган булыр идем.

Булган акчамны билетка дигәнен генә калдырдым да калганын аңа суздым:

— Гаеп итмәгез инде, Хәдичә апа, башка акчам юк, үземә билетлык кына калдырдым. Әгәр азсынсагыз, Казаннан җибәрермен.

Хәдичә апа акчаны бик игътибар белән санап чыкты да:

— Шул бик җиткән,— диде. Бер сумын кайтарып бирде.— Юлда кирәге чыгар.

Бар бит дөньяда изге кешеләр, дидем мин эчтән генә. Мин биргән акча болай да бик аз бит. Хәдичә апа квартирга башка кеше кертсә, ике тапкыр артык табышлырак булыр иде. Әле шулай да, юлга ипилек акчам юклыгын белгәндәй, кайтарып бирә. Тамак төбен авыр

төер баса башлады, күзләрне яшь элпәсе каплады. Артык җебеп төшмәс өчен, аскы иренемне тешләдем. Аннан, тынычлана төшкәч, тагын рәхмәт әйттем.

Шул ук көнне гомуми вагонда Казанга кайтып киттем. Ул заманда поезд Мәскәү белән Казан арасын тәүлектән артыграк утә иде. Мин иң өске чемоданнар куела торган шүрлектә рәхәтләнеп йоклап кайттым. Эссе, тыгын, тынчу. Әйдә, теләсә ничек булсын, барыбер шушы поездның бөтен составында миннән дә бәхетлерәк кеше юк. Миңа уку хокукы кайтарылды. Инде бу хокуктан мине беркем дә мәхрүм итә алмый. Ур-ра! Яшәсен гаделлек!

Максатыма ирешеп кайтуым әтием белән әниемне дә шатландырачак. Әлбәттә, кайберәүләрнең шатланмавы да ихтимал. Хәер, ансыз — дөнья сансыз. Миңа әле институт директоры ачу итеп бер ел буена стипендия түләмәячәк. Ул әле, Мәскәүдән алып кайткан кәгаземә ышанмыйча, башта миңа килсен, аннан күз күрер, диячәк. Аннан, үзенә дә кәгазь килгәч, беренче курстан укый башларсың, диячәк. Юк инде. Ничек итеп мин сыналган, кадерле иптәшләремнән аерылып калыйм. Мин җәйнең калган өлешен тапшырылмаган имтиханнарга әзерләнеп уздырам. Имтиханнарны биреп, икенче курска күчәм. Икенче курста кафедраларга таблицалар, рәсемнәр ясап акча табам, шулай укыйм. Менә шул!

Моның белән генә сүз бетми икән әле. Хәзер мин әниемнең педагогия институтының кичке бүлегендә укуын әйткән идем. Дөнья гизеп, гомер буе югары мәктәп бетерү турында хыялланган әнием, әллә кайда түгел, шул ук үзебезнең Казаныбызда бу бәхеткә иреште. Мин укырга кергән елны ул да институтта укый башлады. Башта — читтән торып, аннан — кичкедә. Һәм нәкъ мин институттан сөрелгән елны аны да чыгардылар. Мин Мәскәүдән кайтканда ул укудан мәхрүм ителгән иде. Ләкин хәзер курыккан юк. Мин инде хәзер әниемә киңәшче. Без инде бу юлы туп-туры Мария Ильинична Ульянованың үзенә хат язабыз. Эшнең уңай барып чыгачагына беребездә дә шик юк. Шуңа күрә әниемнең иптәшләре һәр көн безгә килә, нинди дәресләр, нинди темалар үтелгәнен әйтеп тора. Алар әниемә лекция-конспектларын укыталар, бергәләп дәрес әзерлиләр. Һәм, чыннан да, озакламый Мәскәүдән «восстановить», дигән язу килә. Әнием татар теле һәм әдәбияты бүлеген язучы Абдулла Әхмәтләр, Шәйхи Маннурлар белән бергә уңышлы тәмамлады.

Инде әтием турында.

Башта ул хисапчы булып эшләде, аннан читтән торып бухгалтерлар курсына керде. Ул арада, элекке укытучыларны яңадан педагогия эшенә тарту өчен махсус курслар ачылгач, башлангыч мәктәп укытучысы булды. Ул гына канәгатьләндермәде аны, француз теле курсларына керде. Аны тәмамлап, Мөслим районында, Симәк дигән авылда француз теле укытты, шул ук вакытта чит телләр институтында читтән торып укырга тотынды. Ихтимал, ул аны тәмамлар да иде, тик сугыш һәм әтиемнең сәламәтлеге начарлану моңа комачау итте.

Гаиләбезнең укуга булган мөнәсәбәтен һәм шул юлдагы кичерешләрен күз алдымнан уздырам да, ирексездән үзебезне кыяларга үрмәләүче альпинистлар белән чагыштырасым килә. Мең төрле газап-җәфалар чигеп булса да, уку, белем алу иң олы максат итеп куелган. Күрәсең, ул кече яшьтән үк канга сеңгәндер.

Әйе, үзем турындагы хикәятне очлыйсым бар бит әле.

Термездән кайтып төшү белән, беренче эш итеп, Мәрзиянең яшәгән квартирасына, Бишбалтага киттем. Тик андагы таныш әби, Мәрзиянең хуҗабикәсе, бу юлы минем белән рәтләп сөйләшмәде. Аның миңа карамыйча гына мыгырдануыннан мин шуны аңладым: Мәрзия хәзер башка фатирга күчкән, әби исә аның кайда икәнлеген белми.

Димәк, ул исән-сау. Ләкин шулай да аның бу хикмәтле эше башка сыймый. Квартир алыштырган да, кая күчәсен дә әйтмәгән. Бу хәл үзе генә дә минем күңелемә авыр таш булып ятты. Бу сүзләрдән ниндидер мәкерле хыянәт, алдау исе аңкыгандай булды. Ләкин мин, күңелем түрендәге өмет чаткысына ышанып, аны эзләвемне туктатмадым. Адреслар өсталенә мөрәҗәгать итеп карадым, тегәл җавап булмады.

Мәрзияне, укырга кергәч, институтта укулар кызган бер чорда, кышкы сессия алдыннан, мунчадан кайтышлый трамвайда очраттым. Башта күзләремә ышанмадым. Ул эчтәрәк, пассажирлар арасында бара иде. Ак-караны абайламастан, юлымда очраган кешеләрне ярсытып, аларны этә-төртә, алга таба атлыйм. Мәрзия исә, әллә мине күреп, әллә төшәр вакыты җиткәнгә, үзе дә пассажирларны эткәләп, алга уза башлады. Менә тукталышка да килеп җиттек. Ул ашыга-ашыга трамвайдан төшә, мин дә трамвайдан сикердем. Мәрзия юл аркылы кызу-кызу тротуарга таба атлый.

Хәтердә, йөгерә-атлый сулышыма буылып, мин аны бер таш капка янында туктаттым. Ул миңа күтәрелеп карамады. Бары тонык тавыш белән: «Мин кияүгә чыктым»,— диде. «Ә вәгъдәң?»— дидем мин тетрәнеп.— Вәгъдәң?» Ул дәшмәде, башын тагын да аскарак иде.

Әйе, барысы да аңлашылды. Авыр иде миңа: ләкин аркамнан бер авыр йөк төшкәндәй, җиңел дә иде. Авыр иде — чөнки алдады мине вәгъдәләшкән кызым; җиңел иде — чөнки вәгъдәсез дустан котылдым. Һәрхәлдә, эш миннән калмады. Мин үзем эшләргә тиеш нәрсәләрнең барысын да егетләрчә башкардым. Намус белән, барлык көчемне куеп. Минем вөҗданым саф.

Мәрзияне күңелемнән тиз арада йолкып ташлый алдым. Ул ясаган яралар артык озак газапламадылар. Мин әле дә, андый вәгъдәсез кеше белән яшәсәм, барыбер бәхетле була алмас идем, дип уйлыйм. Кем белә, ихтимал, безнең арада чын, тирән мәхәббәт булмагандыр да. Бәлки шуңа күрә ул тиз онытылгандыр. Бәлки, бәлки...

Мин Термез шәһәреннән Казанга утыз дүртенче елның июль урталарында кайтып төштем... Тукта, тукта, мин бу сүзләрне әсәрнең башында ук яздым түгелме соң? Шулай, язганмын икән. Бу китап шундый сүзләр белән башланган икән. Димәк, вакыйгалар очланган, хикәят түгәрәкләнгән дигән сүз.

*1983 ел.*

*Беренче китап тәмам.*

## Айдар Хәлим

# ЯҢА ШИГЫРЬЛӘР

❁

*Яңгырады тау вә таш...*

«Кисекбаш» дастаны.

Төн. Кара төн. Качты йокы.
Уйлар агышы...
Колакта һаман яңгырый
Тояк тавышы.

Көндез михнәтле юлларда
Күтәрсә тузан,
Төнен ярсып кешни бүз ат
Сүнгән йолдыздан.

Гомер буе тынгы бирми,
Ээзли, эзәрли.
Әллә үз итеп кызгана,
Әллә каһәрли?

Җайдаклымы бу аргамак,
Йә җайдаксызмы?
Җайдагы булса, башлымы,
Әллә башсызмы?

Кайсы гасыр капкасыннан
Чыккан ул җилеп?
Кайсы гасыр капкасына
Югалыр кереп?

Түгелме ул бер Кисекбаш?
Чикләр үтәлми,
Ничә дәвер иленә кайта,
Кайтып җитәлми?

Әллә йөгәнсез-иярсез,
Төннәрне сөзеп,
Качкан ул кансыз тираннан,
Тышавын өзеп?

Атылган йөрәк мәллә бу,
Сатылган намус?
Үз иясен эзли намус —
Аралар алыс...

Үткәннән сабак ал, кеше,
Сәгатькә кара! —
Төзәт хатаңны, гомерең
Кысыла бара!

Очкыннар чәчри тояктан
Монда, аръякта —
Йөрәктәге яра сыман
Яна байраклар.

...Коела таллардан яфрак —
Күбекле көмеш.
Син төнлә тояк тавышын
Ишетергә тиеш.

---

Айдар ХӘЛИМ *(1942) — Уфада яшәүче татар шагыйре, башкорт һәм рус телләрендә дөнья күргән шигырь һәм публицистика китаплары авторы. Әсәрләре Казанда татар телендә дә еш басыла килде. Бу санда тәкъдим ителә торган шигырьләре — авторның буровойда бораулау ярдәмчесе булып эшләгәндә язылган «Өзеклектә» һ. б. цикллрынннан алынды.*

## Тирәнлек сәгате турында баллада

I

Бер чак шулай без кул сәгатьләрен
Куранттан дөресләп күчердек.
Күчердек тә ике мең метрга
«Тирәнлек сәгате»[1] төшердек.

Таң ата, көн ярмаланып килә...
Йөрәк типми. Тәмам кысылган.
Кара алтын көттем үлем көткән
Әсир сыман — язып һушымнан.

Үлем — яшәү, яшәү — үлем иде;
Туып мәгърифәтле анадан,
Мәгърифәтле катламнарны талап,
Без мәҗүси булдык яңадан.

«Чыксын!..» «Юк, чыкмасын!..»
Җир — дегет-саз.
Үпкәдә — газ... Нәфт[2] беркәнгән
Шакшы суда шашкан соңгы торна
Егылып төште соңгы Коръәнгә.

Шул торнаны эзләп, тирән төшәм.
Әмма һаман җанны турайтып,
«Ул монда!» дип сөрән сала сыман
Җир астыннан сәгать куранты...

II

Һәм, ниһаять — вакыт! Без үткәнне
Бүгенге көн аша фашладык.
Корбан чалган нурлы пәйгамбәрдәй
Мирасны күтәрә башладык.

Пычрак идек, ай-һай, шакшы идек!..
Тау-тау баткак өскә тәгәри.
Күкертле баткакны сукыр шәмдәй
Безләп янган күзләр зәңгәрли...

Миңа кинәт... Чиркәү суы сыман
Кургаш сулар шарлап бөркелде.
Торна түгел — торбадан бәгъзе сак,
Бәгъзе җылы нәфт сикерде!..

Тамак хакы өчен ялчы-батрак —
Мин, «алтын»ны алып учыма,
«Торнам!» — дидем...
Торнам — сорнай икән,
Кан кычкыра иде һушымда...

Ялтырга алданган мәҗүсидәй,
Мин тәмләдем алтын карасын.
Мәгърифәтсез учта дерләп яна
Мәгърифәтле катлам баласы!..

Яшәү — утрак, мәгънәбез — бәдәви,
Ил пычратып, калдык бәетсез.
Син гафу ит, Бөек Җылытучы,
Без бәетсезгә син гаепсез...

III

Күтәрдек пакерны... Текелдәми,
Йөреми тирәнлек сәгате!
Аптырадык... Шулай да мөмкинме?
Күп тә үтми, белдек сәбәбен:

Безгә килгән сәгатьче-инженер
Алексашка исерек уянган.
Кызма баштан тирәнлек сәгатен
Онытkан ул борып куярга...

Кешеләргә әмма бу җир мае
Җибәрсә дә сагыну өлгесен,
Каләм астан язып ук алмагач,
Нәселе аның калган билгесез.

Йөрәгеңдә бәхет басымы нинди?
Ирекләме дәрман, куәтләр?
Җир өстенә ташылган алтыннан
Алтынга бай микән киләтләр?

---

[1] Җир асты катламнарындагы казылма байлыкларның куәтен, басымын һ. б. билгеләп торган җайланма. Пакер дигән күп буынлы торба эченә куела.
[2] Нефть гарәп сүзе «нәфт»тән алынганлыктан, аны үз телебезгә ярашлы рәвештә кулланырга булдым (Автор искәрмәләре).

Кинәт миндә басым күтәрелде.
Беркем борчылмады. Шул көнне
Моңнан яздым. Ник сәгать боручы
Булып тумавыма үкендем.

...Курантларда сәгать төзәткәндә
Курант үзе, ахры, искәрми:
Кул сәгатьләребез эшли дә бит,
Тирәнлек сәгате эшләми...

## Заман башында

*Венерага*

Дөнья тыныч. Туплар атмый. Әмма
Нидер, кемдер шартлый... Беләсең.
Шундый тыныч... Җәлил Әминәсе
Булып күз алдыма киләсең.

Сиңа төртеп күрсәтәләр сыман:
«Халык дошманының хатыны».
Төш кенә бу. Бу — хыялда булган
Кыргый курчак уены, алтыным.

Каурый белән хәят көзгесеннән
Бар тапларны сөртсәм, кыз бала,
Гүзәл Илаһ булып бу көзгедә
Синең генә нурлы йөз кала...

Карашыңның кырыс сөрмәсендә
Кайдан мондый моңсу тирәнлек?
Яшьли сиздем: халык милке икән
Синең түземе, синең зирәклек.

Соңламаска! Кояш күкрәгеннән
Сыдырып бераз сөю сөрмәсен,
Илгә бирик! Кеше сөймичә дә
Яшим, дип, алдана күрмәсен.

Кем өчендер заман ахыры бу,
Безнең өчен — башы заманның.
Заман башы сөюе хакына
Пычак йөзе сыман таландык.

Сак бул, дисең. Әйе, мәкер сансыз.
Тыныч туплар турыдан атмыйлар.
Буровойда җиңел тимер тонна,
Фәрештәләр мине саклыйлар.

Төнгә каршы дошманга гөл бирик.
Ул гөл сөя. Чөнки үлемсез.
Һәм, ут алып, без балконга чыгыйк;
Дусларга ерактан күренсен!

## Хушлашу

*Бергә эшләгән дусларым Владимир Кощеев, Александр Фабрициус, Илдус Низаев, Индус Кәримов, Флүр Хөснияровларга*

Ишек ач та — сер көт. Шулай икән.
Ишек ачтым — кинәт яшәрдем.
Бу дөньядан шашкан күзләремә
Сандугач моңнары чәчрәде.

Колак күрер, күз ишетер булды.
Мондый мәлдә нинди рәнҗүләр?!
Бүре казыган Күзәй урманнарын
Яңгыратып көлдем мин, юләр.

Һәм үземне мәңгегә шат тойдым.
Бөре яшькелтенә буралып,
Баксам — тездән балчык...
Күккә баксам —
Кояш чыккан җирдә торамын.

Буровойның нәзек челтәр сыны
Шәфәкъ канындамы яралган?
Ак каеннар, үрелеп, бу каннарның
Читен генә әле ялаган...

Я, хушыгыз, мазут сөргенендә
Чәчкә аткан умырзаялар!
Шигърияттнең мәңге сөргенлеген
Аңлап үлә алар, заялар.

Я, хушыгыз, зәһәр салкыннарда
Җылы почмак биргән дусларым!
Сарайларга илтер өчен
Сезнең
Йөрәк алтыннарын учладым...

Сандугачлар гүя бәхил бул, дип,
Моңны көрәк белән кориләр.
Саф һаваның зәңгәр сөтен имә
Төндә карыны ачкан бөреләр...

Китәм дәме? Вакытмы? Җиттеме?
Мин дә бәхиллекләр биримме?

Күрә торып, әллә сазлыкларның
Классикасында эримме?

Болдырда ни? Каен суы, ахры.
Чиләгеннән эчәм чәмләнеп.
Юлга чыгам, бурлактай өстерәп
Буровойдан төшкән шәүләне...

*232 буровой. Күзәй авылы яланы.*

●

Адаштым таныш урында, нык аек булсаң кыен;
Упкыннарга алып керде кемнәрдер таккан уем.

Тауга тезләнгән авыллар тауга ни ялваралар?
Кысыр болытлар «Бетмибез!» дип микән кабаралар?

Тирбәлә телдә якты сүз, тик нигә өзеп булмый?
Ник җиргә шатланып баксаң, кайгырмый түзеп булмый?

Сине уйласам, и тормыш, җаным җырлар ыргыта;
Тик халкыма сузган чакта кемнәрдер кулдан тота.

Маңгаемнан нур чәчелә — томанда нурлар фидан;
Намусның тук базарында сатылып бетте иман.

Мин алла белән бәхәстә, аллалар мине сөйми.
Бу хакта пртакул белә, кеше дә шулай сөйли.

Томан сукырайткан кояш, күрми батышка күчә.
Ул да иртән яктырам, дип, кичен упкынга төшә.

# Сафуан Муллагалиев

## Зурлыктамыни авырлык

Бәлки кургашын сеңгәндер
Без күргән авырлыкка? —
Үлчәмәк булам аерып,
Юк, булмый аерып та...

Заман бизмәненә куям,
Ышанмаса да күңел —
Тау-тау алтыннар басалмый,
Әллә ни зур да түгел.

Зурлыктамыни авырлык —
Хакыйкать булуында!..
Мин бер бөртек кызыл чәчәк —
Ык буе болынынан...

## Ирек

...Бәлки тылсым,
Бәлки ут син,—
Иң мөкатдәсе утның:
Бернидән дә курыкмыйсың,
Кодрәтең синең үткен...

Тик курkасың син кешенең
Ирексез калуыннан.
...Ирексезләрнең язмышы
Гомергә канлы булган.

...Сине кеше киләчәге
Кызыктыра бигрәк,—
Син — Галәм күген яктыртыр
Бер кояш кебегрәк...

Тик кояш бата кич булгач,
Син төнлә дә нур чәчеп,
Яктыртасың — рухыбызны
Киләсе көнгә дәшеп...

## Көтәләрдер кебек

Тугры булып туган туфрагына
Имәнкәйләр тауга иңгәннәр...
Канатсыз кош кебек чакларымда
Канатларым булды имәннәр...

Мин рух көче
Алдым имәннәрдән,
Тарихыма салдым күперне —
Имән күпер аша
Иң борынгы бабам
Миңа шигъри тылсым китерде.

Шигъри тылсым...
Шигъри нәкыш уеп,
Бизәдем мин күперләремне...
Оныклар да бүген
Көтәләрдер кебек
Мәңгелек җыр китергәнемне...

---

*Сафуан МУЛЛАГАЛИЕВ (1927) — шагыйрь, «Сәлам бирәм», «Көзге балкыш», «Мәңгелек йөрәк» исемле шигырь китаплары авторы. Казанда яши.*

## Сүндермәгез

«Искелекне» бетерәбез, диеп,
Рухи күперләрне сүттеләр...
Аңыбызны яктырткан кояшка
«Янгын» диеп, сулар сиптеләр,—
Кояш исән, ләкин томан каплый —
Томан аша нурлар үтәме?
Томанлы аң белән томангамы
Хәсрәтемне әйтим, үпкәмне...

Кара томан аша юлларымны —
Киләчәкне күрә аламмы?
Куанырмынмыни —
«Чиксез дөньям бу...»,— дип,
Кәрлә агач үскән аланны...

...Күңелемдә томан таралыр бер,
Зиһенгә нур үтеп, балкыр аң!
Ялган бәхет нигә кирәк мина,
Ялган... нигә безгә, батырлар!

«Янгын» диеп, су сипмәгез безнең
Аңга якты биргән кояшка...
Билен бөгеп кенә тора алмый,
Баш күтәрә хәтта юаш та...
Мәңгелек юл булсын кояшка!

## Эт түгел ул — кеше, югыйсә

Кем икәнен аның белмәсәм дә,
Туры килде бергә эшләргә:
Бер карасаң, яхшы кеше төсле,
Бер карасаң, әзер тешләргә...

Эт икән, дип уйлый күрмәгез сез,
Эт түгел ул — кеше югыйсә...
Ләкин телен эт тә яламыйдыр,
Пычак белән кырып юмыйча...

## Шәриф Хөсәенов

# МӘХӘББӘТ ҺӘМ НӘФРӘТ

хикәя



Бибигайшә кичтән берничә кисәк кер чылатып куйган иде. Сигезенче дистәнең унсигез түгел икәнлеген уйлый-уйлый шуны уып маташканда, күрше кызы Рушания шалтыратты.

— Бибигайшә апа, сөенче! — диде ул, ишекне ачуга.— Сәйфетдин абзыйны газетага басып чыгарганнар!

— Ни өчен? Кайда? — диде Бибигайшә, үзенә сузылган газетага күз салып.— Юк лабаса.

— Син аның рәсемен эзлисең. Рәсемен эзләмә, менә бу җирен укы син аның! — диде Рушания, газетага бармагы белән төртеп күрсәтеп.— Менә шушы бөтенесе Сәйфетдин абзый сөйләгән сүзләр.

— Нәрсә дип сөйләгән ул ахмак? — дип кызыксынды Бибигайшә, кулларын алъяпкыч итәгенә сөртә-сөртә.— Күзлегем янымда түгел. Үзең генә укы булмаса.

Җирле советларга сайлау алды көннәре иде бу. Шул уңай белән Бибигайшәнең карты Сәйфетдин каравыл торган балалар бакчасына бер журналист килеп чыккан да, карт аңа берничә сүз әйткән булган икән. Менә мин, дигән, юньләп укый-яза да белмәгән бер авыл мужигы, егерме бишенче елда Казанга килеп урнаштым, дигән. Биш бала үстердем, дигән. Биш баламның бишесе дә институтларда укып чыгып, зур кеше булдылар. Бер улым Сүрия дигән мәмләкәткә барып биш ел эшләп кайтты, бүгенгесе көндә Мәскәүнең үзендә яшәп ята, менә дигән квартирасы, өр-яңа «Волга» машинасы бар. Калган балаларым да зур кешеләр булдылар. Әле былтыр гына хөкүмәт үземә ике бүлмәле фатир бирде, җитешмәгән җирем юк. Картаеп беткәч тә эшләп йөрүем акча җитмәүдән түгел, аллага шөкер, пенсиям әйбәт. Өйдә утыруны яратмыйм, шуңа эшлим. Совет власте булмаса, каян килер иде шундый бәхетле тормыш минем ишегә? Шулай дип сөйләгән икән журналистка Сәйфетдин карт.

— Укып бетер, укып бетер! — диде Бибигайшә, сабырсызланып.

— Бетердем, Бибигайшә апа.

— Ничек? Соң, минем турыда бер сүз дә әйтмәгәнмени?

— Юк, Бибигайшә апа.

— Пыразит! — диде Бибигайшә, бу сүзнең баштагы иҗегенә ба-

---

*Шәриф ХӨСӘЕНОВ (1929) — язучы, драматург, «Профессор кияве», «Зөбәйдә — адәм баласы», «Әниемнең ак күлмәге» кебек пьесалар, «Мәхәббәт сагышы» исемле повесть һәм башка әсәрләр авторы. Казанда яши.*

сым ясап, Рушания кулындагы газетаны тартып алды да, өй буйлап күзлеген эзләп китте.

— И Бибигайшә апа, кайдан килеп Сәйфетдин абзый паразит булсын ди инде! Пенсия дә ала, шушы яшенә кадәр эшләп тә йөри. Паразит бит ул кеше тапканны гына ашап ятучы була.

— Пыразит ул,— диде Бибигайшә.— Син белмисең. Бу яңа йортта яшәүчеләр белмиләр. Гомер буе минем канымны эчеп яшәде ул кеше. Менә бу чәч юкка гына агармаган.

— Җитмешкә җиткәч чәч агара торгандыр инде ул, Бибигайшә апа, картың паразит булмаса да,— дип үз фикерен дәвам итте Рушания. Аннары, карчыкның агарынып-күгәренеп киткән йөзенә беравык карап торды да, газетасын калдырып чыгып китте.

Аның чыгып китүенә Бибигайшә игътибар итмәде. Күзлеген киеп, йомшак креслога утырды, газетага күз салды. Грамотасы әллә ни булмаса да, газетадагы кып-кыска хәбәрне шактый тиз ерып чыкты. Карчыгы Бибигайшә турында Сәйфетдин карт, чыннан да, бер сүз дә әйтмәгән иде. «Аһ, шадра тәре! Аһ, пыразит! — дип ярсыды Бибигайшә.— Минем балаларым да, минем балаларым, имеш! Хурланып үләрсең бу хурлыкка! Кайдан килеп аның балалары булсын алар? Бибигайшә балалары! Шуңа алар шундый яхшы булып чыктылар да. Аларның Бибигайшә балалары икәнлеген бөтен халык белә. Дөрес, бу яңа йортта бик белеп бетермиләр, әмма элек, үз йортлары белән Пороховойда яшәгәндә, бөтен урам белә иде. Бер генә кеше дә ул балаларны Сәйфетдин балалары дип әйтмәде, Бибигайшә балалары, Бибигайшәнекеләр дип йөртеләр. Башка кешеләрнең балаларын Ибрай балалары, Сабирҗан балалары дип, аталары исеме белән йөртәләр, ә аларның балаларын Бибигайшәнеке диләр. Хәтта урамга чыккан мәчесенә хәтле Бибигайшә мәчесе дип йөртәләр иде. Йортны да хәтта, ялгышып кына да, Сәйфетдин йорты дигән кеше булмады, Бибигайшә йорты, һич югында Бибигайшәләр йорты дип әйтә торганнар иде. Ни өчен шулай ул? Ни өчен кеше йорт-җирне дә, бала-чаганы да Бибигайшәнеке дип әйтә? Чөнки Сәйфетдин — чүпрәк. Чөнки йортны йорт итеп, тормышны тормыш итеп Бибигайшә тота. Бибигайшә булмасамы — Бибигайшә булмаса, башка авачак хәлләрне сөйләп кенә бетерерлек түгел аларны. Ике бүлмәле квартир алдым дигән, аһ, пыразит! Алдык дип тә әйтмәгән бит әле шуны, алдым дигән. Тоттыралар иде сиңа ике бүлмәле фатирны, әгәр Бибигайшә үзе исполкомга барып, Михайлов дигән кешенең якасына ябышмаган булса?»

Бугазына кантар булып тыгылган ачуына буыла-буыла, Бибигайшә керен уарга тотынды. Куллары кер уды, теле Сәйфетдинне сүкте. Кайтсын әле, кайтып күзенә генә күренсен әле, пыразит. Күрмәгәнеңне күрсәтәчәк әле сиңа Бибигайшә моның өчен. Ә соң нигә дип әле шушы гомергә тиклем ул кайтмый? Кайтып керергә курка, имансыз. Бибигайшәнең ачуы басылганны көтә. Юк, басыла гына торган ачу түгел бу! Гәзитләргә басып чыгарып, үзен бөтен халык алдында рисвай иткәнне Бибигайшә болай гына калдырмаячак...

...Бибигайшәнең яшьлеге давыллы елларга туры килде. Ул балалыктан чыгып, талдай зифа буйлы, алмадай алсу йөзле кыз булып өлгереп җиткәндә гражданнар сугышы бара, дөньяларның шактый болганган чагы иде. Аннан ел ябык килде, ачлык башланды. Билгеле инде, андый чакта авыл халкында өйләнү яки кыз бирү кайгысы түгел, тамак кайгысы. Өстәвенә, егет-җиләннең борын астына төк кунып өлгерми, сугышка алалар. Шунлыктан, инде буйга җитеп узып барган сылу һәм чибәр Бибигайшәне сораучылар әллә ни күп булмады. Сабый чакта ук колагын тешләп куйган, Бибигайшәнең үсеп җиткәнен көтеп йөргән Чытыр Гарифулласы дөнья сугышында ук юкка чыкты. Бибигайшәгә гыйшык хатлары җибәреп, бишмәт кеса-

сене исле сабыннар тыккан Хәнәфинең үлем хәбәре килде. Яр буе Шәмсиенең шадра Сәйфетдиненә сорап килгән яучыны, шактый тәкәллефсезлек күрсәтеп, кире борып җибәрделәр. «Бөтен тирә-якта дан тоткан кызымны Шәмсинең шадра малаена биреп торасым юк әле»,— диде Мөхәммәтша абзый яучыга. Бәлкем шул тиклем тупас итмичә, җылырак сүзләр белән дә кире борып җибәрергә мөмкин булгандыр ул яучыны, ләкин дуамаллыгы белән аты чыккан Мөхәммәтша абзыйның икейөзлеләнә торган гадәте юк иде.

Бибигайшә шулай, әле күзгә бик үк ташланмыйча, сизелер-сизелмәс кенә олыгая-картая башлаган көннәрнең берсендә авылга берничә атлы килеп төште. Читтән килгәләп торган мондый кешеләргә авыл халкы инде күнегеп беткән, аларның ни өчен килеп йөрүләрен дә бик яхшы белә иде. Бирергә килмиләр, алырга киләләр. Ат сорыйлар, икмәк сорыйлар, сорап бирмәгәннәрнекен тартып та алып китәләр. Бу юлы да авыл халкын мәчет янындагы мәйданга җыйдылар. Килүчеләрнең берсе нотык сөйләп алды. Җәмәгать, диде, кала халкының икмәге юк, кала халкы — сезнең туганнарыгыз булган эшчеләр сыйныфы — ач утыра, диде. Сез авыл халкы, крәстияннәр, калада яшәгән туганнарыгызга ярдәм итәргә, икмәк бирергә, аларның балаларын ач үлемнән коткарып калырга тиешсез, диде. Бу сезнең мактаулы бурычыгыз, дип тә өстәп куйды. Тик мондый үгет-нәсихәттән авыл халкы күптән гарык иде инде, бераү дә янчыгын чишеп ташларга ашыкмады. Турысын гына әйткәндә, артык икмәге булган кеше авылда юк та иде. Булган кадәресе инде күптән сатылган, моннан алдарак килгән кала кешеләре тарафыннан алып кителгән иде. Печән өсте җитеп килгәндә, инде быелгы уңышның нинди рәк булачагы хакында сүзләр куерганда кемдә инде артык икмәк булсын! Шул, берәр килем-китем, йә булмаса туй-мазар ясарга ниятләп торган кешедә булса гына.

Гражданнар сугышы басылып, тирә-як авылларга дөнья сугышы әсирләре кайткалый башлагач, Гарифулланың әти-әнисенә дә җан керде. Әнә, ләбаса, үгез куагы Җиһаншасының малае алты ел юкка чыгып торганнан соң кайтып төшкән. Әсирлеккә эләгеп, мадьяр дигән халыкта яшәп яткан булган. Гарифулла да исән-саудыр, бәлкем. Бәлкем, ул да шулай кайтып төшәр. Ходай тәгаләнең рәхмәтләре киң булып, таза-сау килеш кайтып килә калса, озакка сузмыйча гына, егетне башлы-күзле итәргә кирәк булыр. Кечкенәдән баглап куйган, үсеп җиткәч тә күңеленә охшаган Бибигайшәсе олыгаеп бара югыйсә. Гарифулланың әнисе күргән төш бу уйларны тагын да куәтләп җибәрде. Имеш, Бибигайшәләр урамыннан алар урамына таба чигешле сөлгеләр белән бизәп җигелгән пар ат чабып килә. Хәбәрсез югалган улын сигез ел буе көтеп зар-интизар булган анага җитә калды. Гарифулла кайта икән, сөлгеләр белән бизәлгән атларның Бибигайшәләр урамыннан чаптырып килүе якын арада булачак туйга киная икән, дип юрадылар бу төшне. Төшнең кич яткач ук түгел, таң алдыннан, йокыдан торыр алдыннан гына күрелгән булуы фараз ителгән эшнең озакка сузылмыйча чынга әйләнергә тиеш икәнлеген аңлата иде.

Әле кайтмаган, исәнлек хәбәре дә булмаган Гарифулланы өйләндерү хакында һәр ике өйдә уйлана башладылар. Дөрес, ике өй арасында барган бу чыш-пышка Бибигайшәнең әллә ни исе китми. Гарифулла кайтса да, кайтмаса да аның өчен барыбер кебегрәк иде.

Туйга һәм туй алдыннан була торган чыгым-китемгә тоту өчен дип саклап торган биш капчык бодае бар иде Мөхәммәтша абзыйның. Ул бодай әледән-әле икмәк таләп итеп килгәләп торучы кешеләрнең күзе төшмәслек җиргә яшереп куелган иде.

Мәчет янындагы җыен беткәч, арбаларына авыл советы рәисен утыртып, каладан килүчеләр авыл урамнары буйлап киттеләр, хәллерәк кешеләрне сайлап, йорттан-йортка кереп йөри башладылар. Бераз-

дан алар Бибигайшәләр капкасы төбенә килеп туктадылар. Атларын капка төбендә калдырып, йортка керделәр, быдыр-быдыр килеп, Мөхәммәтша абзый белән сөйләшә башладылар. Ишегалдындагы ят тавышларны ишетеп, Бибигайшә тәрәзәгә күз салды. Өй алды болдыры янына ук килеп баскан, өстенә күн тужурка, башына картуз кигән бер егетне күреп, эсселе-суыклы булып китте. Кинәттән ярсып тибә башлаган йөрәген ике кулы белән учлап, ни өчен икәнен үзе дә белмәстән, дөресрәге, ул хакта уйлап та тормастан, Бибигайшә болдырга атылып чыкты, тужуркалы егеткә карап тәкатьсез калды. Ул арада егет тә Бибигайшәне күреп алды. Әллә нишләтә, йөрәккә без булып кадала торган карашы белән беркадәр вакыт Бибигайшәгә текәлеп торды да сорап куйды:

— Икмәкне кая яшердегез, туташ?

Була бит ул егетләрнең бер күз ташлау белән кызларны очып китәрлек иттерә торганнары. Бибигайшә өчен тужуркалы егет шундый булып чыкты. Аның елкылдап торган чем кара күзләре, әллә ничек кенә балкып, дөньяларны яктыртып торган нурлы йөзе Бибигайшәне сихерләде дә ташлады. Күзләренә текәлеп карап биргән соравы сорау булып түгел, ниндидер тылсымлы аваз булып, музыка булып яңгырады. Шуңа ул әтисе Мөхәммәтша абзыйның:

— Монда ник чыктың? Нигә дип әле син чит ир-ат алдында тасыраеп торасың? Хәзер үк күземнән юк бул! — дигән боерыгын бөтенләй ишетмәде. Ә егет музыка шикелле яңгыраган тавышы белән янә Бибигайшәгә эндәште:

— Туташ, икмәкне кая яшердегез?

Юк, бу кешенең соравын җавапсыз калдырып та, йә булмаса ялган җавап биреп тә булмый иде. Шуңа Бибигайшә:

— Ат абзары артында. Өстенә чөгендер утырткан! — дип әйтте дә салды.

Дилбегә белән кыйнады кызын Мөхәммәтша абзый, тәнен кара кан сауганчы ярды. Келәткә бикләп куеп, атна буе чыгармады. Аннары, шадра Сәйфетдингә үзе яучы җибәреп, кияүгә бирде. Карышмады түгел, карышып карады Бибигайшә. Тужуркалы егетне күрү белән йөрәгенә капкан утның нәрсә икәнлеген әле аңлап житкермәсә дә, «Шул шадрага биреп, мине бәхетсез итмә, әти бәгырем! Минем кайтасы Гарифуллам бар лабаса! Гарифулла кайткач, аңа ни дип җавап бирерсең?» — дип елады. Ярдәм итмәде.

Гомерендә беренче кат гашыйк булып, күкләргә очып китәрлек хәлгә килгән Бибигайшәнең тормышы шулай башланып китте. Имештер, Сәйфетдин беренче кичтә әйткән, әллә кемгә барырмын дип бик борыныңны күтәргән  идең, барыбер минеке булдың, дигән. Бәлки әйтмәгәндер дә. Ни дисәң дә, Сәйфетдин Бибигайшәне яраткан булган бит, яраткан кешесен беренче кичтә үк рәнҗетергә теле бардымы икән.

Катлаулы еллар иде ул чакта. Авылдан-авылга, өйдән-өйгә берсеннән-берсе шомлырак хәбәрләр йөри. Имештер, бөтен мөэмин-мөселманны чукындырып, урыс итеп бетерәчәкләр. Әллә кайсы авыл мәчетенең манара башындагы аен бәреп төшереп, тәре кадаклап куйганнар, ди. Имеш, озакламый мал-туар да, ир белән хатын да уртак булачак, шуңа риза булмаганнарны Себергә сөрәчәкләр.

Шундый имеш-мимештән, ың-шыңнан, аннан да бигрәк, ничәмә ел гыйшык тотып йөреп алган Бибигайшәнең күңел түренә сукмак сала алмыйча башы каткан Сәйфетдин, көннәрдән бер көнне хатынын ияртеп, тотты да ягага чыгып китте. Бибигайшә карышмады. Бу читкә китүдә ниндидер бер томанлы өмет бар иде аның өчен, күңелнең әллә кайсы җирен кытыклап, әллә нәрсәгә адарындырып торган яктылык бар иде. Белгән юк лабаса әле, бәлкем аның тужуркалы бәхете дә шунда, алар барачак Казанда яшидер.

Казанга килеп бер заводка эшкә урнаштылар алар. Баштарак ту
лай торакта тордылар, бераздан, беренче балалары тугач, баракта
бер бүлмә бирделәр. Күктән аккош тотмасалар да, үзләре бела
бергә яшәгән, бергә эшләгән кешеләрдән ким яшәмәделәр. Баштара
Казанга килеп урнашкан елларда, Бибигайшә урамда янсә трамвайд
барганда күн тужуркалы кешене күрсә, магнит тәэсирено буйсынга
кебек, шул кешегә тартыла, куалап җитеп, йөзенә карый торган иде. У
елларда күн тужурка кию модада булганга, андый кешеләр шактый е
очрый иде Бибигайшәгә. Ләкин ул зарыгып көткән, күзенә пәри булы
күренгән ире кырында ятканда сагышланып хыялланган кеше оч
рамады.

Бер генә тапкыр күреп, ике генә сүзен ишетеп гашыйк бул
ган кешесен бик озак оныта алмады Бибигайшә. Ичмасам, исеме
генә белеп калган булсам да, бу тиклем читен булмас иде дип ачырга
ланды. Ә тужуркалы егет, уч иткән шикелле, күңеленнән китмәде, һа
ман исенә төшеп, гел күз алдына килеп үчекләп торды. Ул Бибигай
шәне әллә кайларга чакырды, ничәмә еллардан бирле ир белән яшәп т
Бибигайшә аңламаган, төшенмәгән, ләкин дөньяда барлыгын сизенгән
төсмерләгән әллә нинди рәхәткә, күзләрне чагылдырырлык нург
манчылган хыялый дөньяга өндәде. Тик кайдан һәм ничек тапсы
соң инде ул бәхетне Бибигайшә! Ул бит Йосыфны төшендә күреп га
шыйк булган, уянгач та эзләп киткән һәм эзләп тапкан әкияттәг
Зөләйха түгел, иске татар авылының гап-гади бер кызы гына иде

Тора-бара язмышына буйсынды Бибигайшә. Ләкин иренә буйсын
мады. Бер-бер артлы дөньяга килгән, берсен-берсе куышып үсеп кит
кән биш бала да аңа ире Сәйфетдинне яратырга, яратырга түгел, хөр
мәтләргә генә булса да ярдәм итмәде. Әйтерсең, ул балалар әлл
кайдан, гаептән барлыкка килгәннәр.

Гомер уза торды, тормышның ачысы-төчесе, дөнья мәшәкате, ва
кыт сөреме кайчандыр Бибигайшә күңелендә шытып чыккан, ләки
үсеп китеп, чәчәк атарга насыйп булмаган мәхәббәт төлен корыткан
шикелле булды. Аның урынына күңелендә нәфрәт агачы үсә башлады
Ул агачта җәен дә кышын да, язын да көзен дә бертуктаусыз өлге
реп торган чәнечкеле җимешләрнең бар ачысы Сәйфетдингә эләкте
Тик торганнан гына да, тик тормаганга да килеп чыга торган күңел
сезлекләрнең, борчу һәм кайгыларның һәркайсын Сәйфетдиннән ди
таба, шулар өчен иренә бәйләнә, ирен талый торган булып китте
Бибигайшә. Сәйфетдин өйгә соңрак калып кайтса: «Бу гомергә тиклем
кайда себерелеп йөрдең?» — дип канәгатьсезлек белдерде. Сәйфетди
өйгә иртәрәк кайтса: «Нигә шул тиклем ашкынып кайттың? Әллә мон
да безне бәлеш ашап утыралар дип белдеңме?» — дип бәйләнде. Сәй
фетдин берәр эшне үзенчә эшләп куйса: «Син пыразитның кулыннан
эш киләмени!» — дип сүкте. Үзе берәр эшне ялгышрак итеп эшләп куй
са: «Син пыразит белән яшәп башым миңгерәүләнде»,— дип талады
Балалар өйгә берәр шатлык алып кайтса — билгеле инде — Биби
гайшә аркасында. Балалар борчу китерсәләр — сүз дә юк — моңа Сәй
фетдин гаепле. Утырса — утырып торышларын, торса — басып то
рышларын ошатмады ул Сәйфетдиннең. Хәтта төннәрен дә — Этле
мәчеле яшәгән ир белән хатынны да беравык вакытка тынычтыра
татулаштыра, көндезге үпкә һәм ачуларны оныттырып тора торган
төннәрдә дә — Бибигайшә Сәйфетдинне ихлас күңелдән якын итә ал
мады. Ярады инде шунда, ике күзен чытырдатып йомгач...

Бибигайшә яратмады дигәч тә, тегe, Сәйфетдин болай бөтенләй
үк хатын-кызга ошамаслык ир түгел иде. Аның, иркәләп-назлап
хатын-кызны балавыздай эретеп җибәрә белә торган кайнар кочагы
кайчандыр Бибигайшәне өзелеп яраткан, бирелеп һәм онытылып
мәңге яратырга, яраткан кешесе өчен мөкиббән китәргә әзер торган
олы йөрәге бар иде. Тик Бибигайшә моны аңламады.

Бәхетле булу өчен җаның сөйгән кеше белән яшәү генә җитми, ул кешенең дә сине яратуы кирәк икән шул. Бу хакыйкатьне Сәйфетдин кешедән ишетеп түгел, китаплардан укып түгел, язмышының ачы касәсен туйганчы эчеп аңлады. Салгалап карады ул, оныта да, онытыла да алмады, язмыш ачысы аракы ачысы белән кушылып, тормышын тагын да ныграк шыксызландырды гына. Йөреп карады. Дөньяда Бибигайшә шикелле туң күчән булмаган, назга — наз, дәрткә дәрт белән җавап бирә белгән хатыннар барлыгын белде. Сәйфетдиннең бу эшен бик тиз сизеп алган Бибигайшә моңа сыңар керфеген дә селкетмәде. Йөрсен, миңа димәгәе — чукынып китсен, ул булмагач рәхәтләнеп йоклыйм, ичмаса, диде. Алай гына да түгел, әллә кайдагы өстерәлчек хатыннар мине чәйнәп ятмасыннар әле дип, Сәйфетдиннең күлмәк-ыштанын, кулъяулыкларын чистарак йөртә башлады.

Бар эшләп тапканын Сәйфетдин хатынына алып кайтып бирә, ләкин Бибигайшә уйламагандарак премия-мазар эләгеп куйса, аны эшереп калдыра, балаларга бирәр татлы алып кайту өчен тота иде. Билгеле инде, бу эш Бибигайшәгә сиздермичә эшләнә. Ихтимал шуңадыр, ата белән балалар арасында яшерен, аналарына бик үк сиздерергә ярамаган дуслык урнашты һәм бу дуслык балалар үсеп җиткәч тә бөтенләй үк бетмәде. Дөрес, әниләре әтиләрен сүккәндә алар бик катнашмыйлар, битараф калырга тырышалар, ләкин балаларның үзен яратуларын, ихтирам итүләрен Сәйфетдин сизеп яши. Бу хәлне Бибигайшә дә сизенә, бу сизенү аны тагын да ярсыта, чыгырыннан чыгара төшә. «Имансыз!», «Шадра урыс!», «Пыразит!» кебек сүзләр Сәйфетдиннең колак төбендә көне-төне яңгырый. Ул, хатын кая барырга кушса — шунда бара, ни эшләргә боерса — шуны эшли. Килешмәүнең йә булмаса — ходаем үзең сакла! — карышуның мөмкин икәнлеген Сәйфетдин уйламый да. Сәйфетдиннең үзенең ниндидер уй-фикерләре, теләк-омтылышлары бармы-юкмы — моның белән беркем кызыксынмый. Хатын нәрсә алып кайтып ыргытса — шуны кия, алдына ни чыгарып куйса — шуны ашый. Бу кичә калган аш икән, фәлән дә фәстәмән дип беркайчан да сырланмый, сырлана башлауның ничек бетәчәген яхшы белә. «Ә-ә, әле син аш тикшереп утырасыңмыни, пыразит?!» — диячәк Бибигайшә һәм, җилтерәп килеп, алдындагы тәлинкәне тартып алачак та чүп катындагы чиләккә илтеп аударачак.

Шунысы гаҗәп, үзен кешегә дә санамаган, бертуктаусыз кыерсытып һәм җәберләп торган хатын белән ярты гасырга якын яшәп, аерылу турында уйлап карамады Сәйфетдин, башка кеше белән, башкача яшәү турында хыялланмады. Менә шулай уй һәм теләк-омтылышларын үз-үзеннән яшереп, үзенең кеше икәнлеген онытып, Бибигайшәнең тиргәү-талауларын ишетеп яшәү аның өчен табигый бер нәрсәгә әйләнгән, аның ихтыяҗына әверелгән иде. Ул — хатынының күләгәсе сыман. Теләсә, Бибигайшә аңа игътибар да итми, теләсә — таптап йөри. Бибигайшә дә башкача тормышны күз алдына да китерә алмый. Тиешлегә дә, тиешсезгә дә бәйләнеп, көн-төн Сәйфетдинне сүгеп яшәү — Бибигайшә өчен җан азыгы. Алай гына да түгел, Сәйфетдин берәр җиргә китсә, озаграк юкка чыгып торса, Бибигайшә аны юксынган кебегрәк тә була, түземсезләнеп кайтканын көтә башлый. Ә кайтып кергәч, тагын үзенекенә тотына — йә берәр нәрсәдән гаеп табып, йә үзенең кәефе китеп торуны сылтау итеп, Сәйфетдингә ябыша.

Менә шулай яшәп картайдылар алар. Балалары буйга җитеп, башлы-күзле булып, үз тормышларын корып җибәрделәр. Бибигайшәнең ризасызлыгына карамастан, төпчек уллары да йортка керде. Үз йортларын сүткәч бирелгән ике бүлмәле квартирада карт белән карчык икәүдән-икәү генә утырдылар да калдылар. Хәлләре начар түгел үзләренең. Тормышлары житеш, икесенең дә пенсияләре әйбәт. Кешедә күреп: «Ah, безгә дә шушы әйбер кирәк иде ләбаса!» — дип әйтерлек

әйбер дә калмады инде хәзер. Бибигайшәнең үз сүзләре белән әйтсәң, аллага шөкер, бөтен җирләре җитеш, бөтен җирләре тулы. Дөрес, Сәйфетдин һаман да эшләп йөри, төннәрен балалар бакчасында каравыл тора. Тик бу акча җитмәүдән түгел. Ир белән хатынның сөйләшеп нитеп тормыйча гына, үзара килешеп эшләнә торган эшләре бу.

Сугыштан соң бөтәйтеп кергән йортлары Казан суы буенда гына булганга, уган керләрен гел елгада чайкап вәнәкләнгән иде Бибигайшә. Бу яңа квартирага күчкәч тә ваннада кер чайкауга күнегә алмады. Аякларыңны да, башка җирләреңне дә җебеткән һәм юган шул тагарак хәтле нәрсәдә баш куеп ята торган мендәр тышларын да, аш тастымалларын да чайка инде, имеш! Бәхеткә каршы, аларга квартираны, башка районнан булса да, тагын шул ук Казан елгасы буеннан бирделәр, ишектән чыгып ике-өч бакча хәтле ара үтсәң су буена барасың да төшәсең. Дөрес, бу җирләрдә яр буйлары бик матур түгел, талчыбык үскән. Суы да сайдан башлана. Ләкин аулак. Оят җирләренә уч төбе хәтле генә нәрсә каплап комда кызынып ятучылар юк. Ярның сөзәклегенә килгәндә, кер чайкарга уңайлы булсын өчен, Бибигайшә былтыр ук Сәйфетдиннән басма салдырды. Тотмаслар, малайшалай җимереп бетерер, дип уйлаганнар иде башта. Ходаның рәхмәте, тимәделәр тагын, басма һаман да исән-сау.

Уып бетергән керен әрҗәгә тутырып, бәләген дә алырга онытмыйча, Бибигайшә кер чайкарга төште. Рушания кертеп биргән газетаны укыгач кузгалган ачуы инде бераз басылган да кебек иде. Шул минутларда кайтып керсә, картын бәреп үтерерлек хәлгә килгән Бибигайшәнең күңелендә гаҗәп ләззәтле тынычлану урнашкан иде. Чөнки ул инде Сәйфетдинне нишләтергә кирәк икәнлеген белә. Әллә сез Бибигайшә апагызның ул гәзитләрне кайда басып чыгарганнарын белми дип уйлыйсызмы? Кәҗә бистәсендәге биек йортта басып яталар ич ул гәзитләрне! Бүген ял көне, ә менә иртәгә Бибигайшә шунда барып пратис белдерәчәк. Хәер, нигә әле аңа үзе барып, вакланып йөрергә? Сәйфетдин барсын! Барсын да, сөйләгән сүзләреннән баш тартсын. Мин сезгә ялгыш сөйләгәнмен, эшнең чын дөресе болай аның, дип, балаларның кем балалары булуын да, ике бүлмәле квартирны кем йөреп алганны да сөйләсен дә бирсен. Ийе шул!

Шуларны уйлый-уйлый, керләрен чайкап бетерде Бибигайшә. Көн гаять бөркү, кояш миләрне чатнатып кыздыра иде. «Су коенып алсаң да әйбәт буласы икән дә,— дип уйлап куйды Бибигайшә, басмага утырган җирдән салындырып суга тыккан аякларындагы рәхәтлекне тоеп.— Әнә теге бот буе ике малайдан башка кеше-кара да күренми. Су тирән микән монда? Йөзә белмәгән кеше кереп коенырлык микән?»

— Әй, малайлар! Монда су тирәнме? — дип кычкырып сорады Бибигайшә якында гына әллә балык, әллә бака тотып маташкан малайлардан.

— Юк! Шуннан гына! — дип кычкырды малайларның берсе күкрәк тиңентен күрсәтеп.

Шушы бот буе малайларның да күкрәгеннән генә булгач, Бибигайшәгә бил тиңентен генә була ич ул!

Өске күлмәген салып, эчке күлмәктән генә калган көенчә, Бибигайшә суга шуып төште. Сай икән шул, бил тиңентен дә юк икән. Өстәвенә төбе дә ләм генә икән, аяк атлаган саен болганып өскә калка. Бераз эчкәрәк кереп карарга кирәк булмаса.

Кояшның матур кыздыруыннан, җылымса суның тәненә кагылуыннан кәефе килеп, учы белән битенә су сибә-сибә, Бибигайшә берничә адым эчкәрәк атлаган иде — әнекәйгенәм! — аяк астындагы су төбе кинәт кенә юкка чыкты. Бибигайшә суга чумды. Авызына кереп өлгергән суны тиз-тиз йотып, әле бер, әле икенче аягы белән су төбен эзләп карады ул, ләкин юк, аяк җиргә тими!

«Үлемем шушы икән,— дип уйлап алды Бибигайшә.— Әҗәлем шушында булганга төшкәнмен икән!..» Аяклары белән уңлы-суллы талпынып, тагын су төбен эзләп карады, ләкин су төбе табылмады. Ике кулын күкрәк турысына китереп кушырды да, үләргә әзерләнде Бибигайшә. Күңеленнән үз-үзенә ясин укый башлады: «Ясин вәлкоръәнел хәким, иннә кәләмин әлмерсәлим...» Шушы бернічә мизгел вакыт эчендә ясин сүзләренә уралып, башына кырыкмаса-кырык төрле уй килде. Газга аш куеп киткән иде, теге имансыз тиз кайтмаса, кайнап бетеп, кәстрүл төбе көймәсә ярар инде, дип уйлап алды ул. Эчке күлмәге ертылган иде, үле гәүдәсен су төбеннән табып чыгаргач, тәнен чит кешеләр күрер инде... Иртәрәк үлеп китү була инде бу, әле тагын бер ун ел бик рәхәтләнеп яшәргә мөмкин иде... Тормышлар тәмам әйбәтләнеп беткәч, яңа квартирда тора башлагач кына үлеп китүләре үкенечлерәк шул... Үпкәсендәге һава тәмам бетеп, инде тончыга башлаган Бибигайшәнең авыз-борынынннан гөбердәп су керде. «Вәҗәгальнәмин бәйни иллә иләйһем мерсәлүн...— дип ясин укуын дәвам итте Бибигайшә.— Беттем... Үләм... Кала... Ике бүлмәле квартир да, бар булган байлык та кала... Ничек? Кемгә кала? Сәйфетдингәме?»

— Калдырмыйм! — дип кычкырып җибәрде кинәт Бибигайшә, үләргә әзерләнеп күкрәк турысына китереп кушырган кулларын болгый башлап.— Калдырмыйм ул имансызга! — һәм пылт итеп су өстенә калкып чыкты. Аяклары да су төбен эзләп тапты.

Бибигайшә батып үлә язган су, бактың исә, аның күкрәгенә дә җитми икән. Аягы кинәт таеп китүдән куркып тезләре сыгылганга күрә генә суга күмелгән икән ләбаса ул.

— Шул пыразит аркасында батып үлә яздым,— дип сукранды Бибигайшә һәм Сәйфетдин салып биргән басмага үрмәләде.

# ЯШЕН СУККАН ИМӘН

хикәя



Иделнең уң ярында татар хатын-кызларыннан иң өлкән һәм бик тә үзенчәлекле шагыйрә Газизә Сәмитова туып үскән Ташлыяр исемле авыл бар. Теплоходта Волгоград белән Әстерхан шәһәрләре арасын үткән саен күңелемдә шул авылны күрү теләге туа иде. Әмма һаман ничектер форсат чыкмый торды.

Былтыр җәй, ниһаять, җаен туры китердем: бер сәяхәтем вакытында теплоходтан төшеп калып, шагыйрә авылында, ул яшәгән йортта булдым, аны күреп белгән карчык-корчык белән очрашып сөйләштем, зиратка барып, каберенә баш идем.

Кичкырын, шуннан пристаньга кайтырга чыкканда, зират капкасы янында мин кәкре башлы тимер таякка таянган өлкән яшьләрдәге бер агайны куып җиттем. Аның бер аягы протез бугай, атлаган саен ишетелер-ишетелмәс шыгырдап куя. Елгачы киеменнән булганга, ул миңа пристаньда эшлидер кебек тоелды. Шуңа күрә, сәлам биреп исәнләшкәннән соң, турыдан-туры:

— Әйтмәссезме, Әстерханга теплоход кайчанрак булыр икән? — дип сорадым.

Абзый кеше, карасу-зәңгәр кителенең күкрәк кесәсеннән чылбырлы сәгатен алып, күзләрен кысып карады да:

— Юк, пассажир теплоходы тиз булмас әле,— диде.— Ә менә Әстерханга баручы юл участогы судносы озакламыйча килеп җитәргә тиеш. Мин үзем Владимировкага шуның белән кайтам. Бик ашыксагыз, капитаны белән сөйләшеп карагыз, бәлкем, сезне дә утыртыр.

Сизелерлек акцент белән сөйләшүеме, әллә килеш-килбәтеме ничектер таныш кебек тоелды. Ихтыярсыздан йөзенә кызыксынып карадым. Янәшә барган шәпкә ул да сораулы күзләре белән миңа текәлде. Аннары үзалдына сөйләнгәндәй әйтеп куйды.

— Әгәр ялгышсам, гафу итегез... Мин сезне кайдадыр күргән-белгән кешегә охшатам, тавышыгыз да таныш шикелле.

Шул арада мин аны үзем дә танып алдым һәм, шундук татарчага күчеп, бу көтелмәгән очрашуга бик гаҗәпләнгән хәлдә:

— Чү, Мирза дус, син ләбаса бу! — дип кочаклап алдым.— Хәтернең гаебе юк, без үзебез танымаслык булып үзгәргәнбез.

— Анысын дөрес әйтәсең,— диде ул, ябык куллары белән минем иңбашыма каккалап.— Яшь вакытта синең дә чәчең чем-кара, куе иде, кышкы суыкта да егетләнеп, яланбаш йөри идең бит. Ә хәзер әнә чаларгансың. Их-х, аннан бирле күпме гомер үтте...

Әйе, исәпләсәң искитмәле, безнең соңгы очрашуга ярты гасыр үткән дә киткән. Үзе бер гомер! Шулай да мин яхшы хәтерлим, ул вакыт-

---

Сафа САБИРОВ (1915) — *«Су өстендә акчарлаклар»*, *«Йөзмә шәһәр утлары»* *һәм башка китаплар авторы. Казанда яши.*

та Мирзаны безнең белән бергә хәрби хезмәткә алмадылар, комиссиядән үтмәде, пароходта капитан ярдәмчесе булып эшли калды. Баштарак хат язышып торсак та, сугыш елларында без бер-беребезне югалттык... Инде менә илле еллап вакыт узгач, көтмәгәндә очрашу...

Мирза — минем якын яшьлек дустым. Кытлык елларны техникумда укыганда, пароходта практика үткәндә, кем әйтмешли, барын — бергә, югын уртак итеп яшәдек. Ул, каникул вакытларында барыр җирем булмаганга, мине үзләренә алып кайта, бөтен семьялары белән якын итәләр; энесе Хәбиб әдәбиятны бик ярата. Тукай, Такташ шигырьләрен яттан белә, үзе дә язгалый, кайберләрен миңа да укып күрсәтә иде. Минемчә, анда чынлап та уй-хисләрен үзенчә әйтү сәләте, талант чаткысы бар иде.

Шуңа күрә дә, Мирзаны очрату белән, күз алдыма шул киң маңгайлы мөлаем яшүсмер килеп басты. Очрашу дулкыны бераз басылып, аны-моны сорашканнан соң, Хәбиб белән кызыксынмый булдыра алмадым.

— Карале, синең бик тә уңган энекәшең бар бит. Хәтерлим, һәр эштә синең күк булырга ярата иде. Хәзер ул нихәлдә, тормышта нинди юлдан атлап китте? — дидем.

— Ә-ә... аны-ы әйтәсеңме... Син Хәбибне хәтерлисеңмени әле? — диде дә Мирза, теле көрмәкләнгәндәй тынып калды.

Беравык сүзсез атлагач, без Идел буена килеп чыктык, биек яр өстендә чирәмдә бераз ял итәргә булдык. Мирза китель каптырмаларын ычкындырды, тирләгән ияк астын, муенын шакмаклы кульяулыгы белән ашыкмый гына сөртә-сөртә, дәшми-тынмый утыра бирде.

— Дускаем, теге чакны син Югары Идел пароходчылыгында эшли идең бит, бу якларга ничек күчәсе иттең? — дидем, озакка сузылган тынлыкны бозып.

— Әйе, шулай килеп чыкты,— диде Мирза.— Кырыгынчы елны мин эшли торган «Донбасс» пароходы Түбән Иделгә күчерелгәч, Владимировка затонында кышларга калдым, аннары бөтенләйгә шунда төпләнеп, әни белән энекәшне дә үз яныма чакырып алдым. Чөнки ул вакытта миңа Казаннан ерактарак булырга, таныш-белешләр күзенә чалынмый яшәргә кирәк иде.

Шушы урында мин Мирзадан чүт кенә: «Хатыныңны чакыртмадыңмыни?» — дип сорамадым. Чөнки мин — Мирзаның туенда кияү егете булып йөргән кеше — аның хатыны Зөлфияне яхшы хәтерлим. Безнең техникумда иң матур, иң әйбәт укучы бик тә сөйкемле ул кызга без егетләр барыбыз да сокланып карый идек. Аның әтисе — мәшһүр драматург һәм артист — безнең драмтүгәрәккә шефлык итә, репетицияләргә килә иде. Әмма, безнең барыбызны да көнләштереп, Зөлфиягә Мирза өйләнде.

Ә менә хәзер аның турында да ләм-мим. Ул елга аръягындагы томан сарган тугайларга моңсу күзләре белән карап торганнан соң авыр сулады:

— Әни бирегә бер дә теләмичә килде,— диде.— Хәер, аның сәламәтлеге инде бик какшаган иде, монда гел авылны сагынып моңайды. Ул вафат булганда мин үзем фронтта идем. Үлгәч мөселман зиратына күмегез дип васыять әйтеп калдырган булгач, аны бирегә китереп җирләгәннәр. Менә бүген шулар янына килеп, каберләрен каравым әле... Ярар, ул хакта калып торсын әле, ә син үзең монда ничек киләсе иттең, бу зиратта кемең бар?

Мин бирегә ник килүемне әйттем һәм аның үзеннән:

— Туктале, туганкай, сине ничек аңларга?! — дип гаҗәпләндем.— Башта әниеңне генә әйткән идең, инде «шулар янына» дисең. Әллә мин ялгыш ишеттемме?

— Юк, ялгыш ишетмәдең, дөресе шулай — икенче кабердә энекәш йоклый, әле генә син искә алган Хәбибрахман... Шулай да,— дип

дәвам итте Мирза, авыр көрсенеп.— сиңа әйбәт аңлашылсын өчен, сүзне бераз ерактанрак башларга туры килә. Мин боларны, якын дустым булганга, сиңа гына сөйлим, мине аңларсың дип ышанам...

Хәрби хезмәткә мине сугышның беренче көзендә алдылар. Анда миначылар отрядына эләктем. Фронтта хәлләрнең авыр чагы иде, яхшылап әзерләнергә вакыт булмады. Саратов янындагы хәрби лагерьда өч атна чамасы алай-болай өйрәттеләр дә, фронтка җибәрделәр. Ләкин миңа анда озак булырга туры килмәде. Тиздән, Мәскәү янында башланган һөҗүм сугышлары барышында аягым яраланып, кар өстендә егылып калдым: тез капкачым чәрдәкләнгән, кан тамырларым зарарланган булып чыкты.

Иртәгесен, эвакогоспитальгә эләккәч, операция ясадылар. Аннары, Чабаксардагы госпитальдә берничә ай дәваланганнан соң, кырык икенче елның язында агач аяк белән титаклап, яңадан Владимировкага кайтып кердем...

Шушы урында Мирза, фикерен туплагандай, тынып торды, авыр сулап куйды. Ә миңа аның баядан бирле хатыны турында ләм-мим әйтмәве ничектер сәер тоела башлады. Авыз йомып утыру озакка сузылгач, мин кабат сорыйсы иттем:

— Тормыш юлдашың нихәл соң, исәнлеге-саулыгы ничек?

Мирза миңа туры карамыйча, ишетелер-ишетелмәс хәлсез тавыш белән:

— Төгәл генә әйтә алмыйм, исән булса кирәк,— диде.— Без бит сугышка хәтле, өйләнгәннең икенче елында ук аерылышкан идек.

— Ничек алай килеп чыкты соң? Яратышып өйләнешкән идегез бит...

— Әйе, бик тату яшәп тә киткән идек. Әти-әнисе дә минем өчен үлеп торалар, гомумән дөнья матур, тормыш ал да гөл иде...

Әнә шундый рәхәт көннәрнең берендә һич тә уйламаганда-көтмәгәндә каенатамны, халык дошманы дип, кулга алдылар. Зөлфиянең әнисе, театрдан чыгып, каядыр Урта Азиягә китәргә мәҗбүр булды.

Ул вакытта андый кешеләргә һәм аның якыннарына нинди караш булганын үзең дә беләсеңдер... Кыскасы, миңа да Зөлфия белән аерылышырга туры килде. Бу вакытта ул йөкле иде инде... Әйе, берни эшләр хәл юк, заманы шундый иде... Дөресен әйтергә кирәк, әни дә, Хәбибрахман да минем бу адымымны өнәмәделәр. Хәбиб исә хәтта минем белән рәтләп сөйләшмәс булып үзгәрде.

Аерылышуыбызга өч-дүрт ай үткәч, шундый хәл булды: өстәл өстендә Хәбиб калдырган китапны караштыргалап утырганда арадан бер хат килеп төште. Адресын күрү белән таныдым: Зөлфия кулы... Түзмәдем, шундук кабаланып укырга тотындым. Хәбиб аңа әнинең һәм үзенең минем өчен оялуларын, борчылуларын әйтеп язган булса кирәк. Зөлфиянең җавап хатыннан шул сизелә иде. Туганнарча якын итүләре өчен аларга рәхмәт әйтелгән. Аннары төсе-бите белән миңа бик тә охшаш малай табуы турында хәбәр иткән иде... Менә шундый хәл, дускаем, теләсә нәрсә уйла, теләсәң ничек аңла...

Ярар, анысы күптән булган хәл, хәзергә калып торсын, алгарак күчик. Ул вакытта без затонга якында гына, үз өебездә тора идек. Ишегалдында Алабай дигән бик акыллы чуар этем бар иде. Бичаракай онытмаган, капкадан керүемә танып алды, чиный-чиный сырпалана башлады.

Ишекне ачып өйгә керсәм, кухняда күрмәгән-белмәгән яшь кенә бер хатын пешеренеп йөри. Ачык изүле зәңгәр халат өстеннән ак алъяпкыч бәйләгән, куе чәчләрен артка яткырып тараган. Ул мине ярдәм сорап килүче авыру кеше дип уйлады бугай, күрү белән:

— Медпунктта дежур сестра юкмыни, кай төшегез авырта? — дип сорады.

— Минем бер җирем дә авыртмый, аягым төзәлеп килә,— дидем

мин һәм үземнең кем икәнлегемне әйттем.

Ул миңа шинелемне салырга ярдәм итте. Аяк өсте генә сөйләшкән арада мин аның Елизавета Николаевна исемле икәнен, затон медпунктында дежур сестра булып эшләвен белдем. Ире Севастополь портында кранчы булып эшләгән, сугышның беренче төнендә бомба шартлаудан үлгән. Ә Елизавета үзе, бер төркем ятим балалар һәм ундүрт яшьлек энесе белән бергә эвакуацияләнеп, бирегә килгән, боларны фатирга безгә кертканнәр. Энесе Федор безнең Хәбиб белән яшьтәш, мәктәптә бер класста укыйлар икән.

Озакламыйча шау-гөр килеп, алар үзләре дә кайтып керде. Икесе дә яланбаш, үзләренчә чәч җибәргәннәр. Хәбиб сизелерлек үскән, өстендә минем иске бушлат. Кулымны кысып исәнләште, ләкин кинәт нидер хәтерләгәндәй, кашларын җыерып куйды. Аннары сабакташына борылып:

— Федя, таныш бул, бу минем абыем Мирза, фронтовик,— диде. «Һаман Зөлфия өчен гафу итми»,— дип уйладым мин.

— Шулаймы, чын фронтовикмы?..— дип зәңгәр күзләрен очкынландырып миңа карады Лизаның энесе.— Менә гаҗәп, Хәбиб, син шундый фронтовик туганың булуын нишләп бер дә әйткәнең юк?

Хәбиб дәшмәде.

Без кулларны юып өстәл янына утырышкан арада, Лиза өйгә тәмле ис таратып, тәлинкәләргә уха салырга кереште. Мин госпитальдән паекка алган икмәк белән шикәрне дә өстәдем. Шәпләп сыйландык.

Федя бик төпченүчән икән, чәй янында сугыш хәлләрен сораштыра-сораштыра аптыратып бетерде.

Хәбиб табын яныннан элегрәк торып киткән һәм без түр якка чыкканда ул инде йоклап ята иде. Шунда ачык ишектән төшкән ут яктысында аның караваты янында стенага эленгән фоторәсемгә күзем төште.

Юл кайтып арылган, күрәсең, иртәгесен соң гына уяндым. Яшьләр ашап-эчеп инде мәктәпкә киткән, Елизавета алгы якта өстәлне җыештырып йөри иде. Хәбибнең пөхтә итеп җыелган караватына карау белән, кичә кич күргән теге фотоны хәтерләдем. Әмма бүген рәсем юкка чыккан, аның урынында стенада түгәрәк эшләпәле тимер кадак кына тырпаеп тора иде. Мин Лизага:

— Кичә кич монда фоторәсем бар иде шикелле...— дидем.

— Әйе, ике хатын-кыз янәшә утырып төшкән рәсем бар иде,— диде Елизавета, караватн янына килеп карап.— Аларның берсе, инде карчык кеше, Хәбиб аны әнием дигән иде. Икенчесен — тез башына бала утыртып төшкән сөйкемле яшь хатынны — Хәбиб монысы туганыбыз дип әйтте бугай.

Елизавета эшкә киткәч, тамакка капкалап алдым да, ишегалдына чыктым; Алабай белән бергә каралты-кураны, бакчаны тамаша кылып йөрдек.

Шундый кояшлы матур көнне өйдә утырып буламыни?! Яр буйлап затонга таба киттем. Аягым юклыгы бик сизелмәсен дип, мөмкин кадәр аксамыйчарак атларга тырышам.

Борыннары белән ярга терәлеп тезелгән буксир пароходлары арасыннан үземнең «Донбасс»ны ерактан ук танып алдым. Дулкынланып палубага мендем. Ләкин бирендә таныш йөзләр күренмәде. Бөтен команда алмашынып беткән: карт-коры да хатын-кыз. Шулай да тырышканнар, пароходны ремонтлап, әзерләп куйганнар, тик Иделгә чыгарга капитаннары гына юк икән. Минем элек монда эшләгәнлегемне белгәч, әйдәгез, безгә капитан булып килегез дип, үгетләргә тотындылар. Затон капитаны да, хәл-әхвәлне белешкәннән соң, шуны әйтте. Кызыктыргыч тәкъдим бит, риза булдым. Әмма больницада врач, протезны күрү белән, башын гына чайкап куйды. Капитанлыкка рөхсәт бирү урынына, коры җирдә җиңелрәк эш сайларга киңәш итте. Кая ба-

рып сугылырга белмичә аптырап калдым, йокым качты.

Нәкъ шул чакны күршебез, яше җитмештән узган маякчы карт авырып китте. Беркөн шулай хәлен белергә кереп, сүз арасында үземнең зарымны әйткәч, киңәш итте бу:

— Безнең идарәдә миңа алмаш таба алмыйлар. Тот та шунда кер. Барып-кайтып йөрергә дә ерак түгел, рәхәтләнеп эшлә.

Мине пристаньга якында гына, Актүбә тармагы белән Идел арасындагы утрауда урнашкан постка маякчы итеп билгеләделәр. Мәктәптә укулары тәмамлангач, Хәбиб белән Федя да килеп, кул арасына керә башладылар.

Эш әллә ни авыр түгел: кич эңгер төшкәндә фонарьларны көймәгә төяп, тиешле урынга илтеп куясы да ут кабызасы; иртән яктыргач, барысын да җыеп кайтасы, куыкларны чистартасы, керосин саласы. Боларын гадәттә яшьләр башкара. Ә мин яр өстендә баганага тирәнлекне күрсәткеч сигналлар эләм, запас ишкәкләр ясыйм, талчыбыктан сөкә үрәм. Балык ярыйсы эләгә, күбрәк шуның белән туклanaбыз.

Эштән буш көннәрне Елизавета килгәли, су буенда савыт-сабаны ком белән ышкып чистарта. Ул гомумән эшкә уңган, тырыш хатын булып чыкты. Балыкны да әле кыздырып, әле каклап яки уха итеп пешерә, төрләндерә, уылдыкны тәмле итеп тозлый белә; үзебездән арткан балыкны ара-тирә пристаньга да илтеп саткалый.

Баштарак Елизавета мине читсенә, өйдә икебез генә булганда сүзсез кала иде. Шулай да тора-бара акрынлап изләште, ә бер хәтәр вакыйгадан соң ул мине бөтенләй үз итте диярлек.

Ул чакны көн буе бездә булганнан соң, Елизаветага өйгә кайтырга кирәк иде. Аны Актүбә аша көймәдә аргы якка үзем чыгарырга булдым. Җилле-яңгырлы кич булса да, яр буенда ышыкта алай хәтәр түгел кебек иде. Кузгалып киткәч, ачык су өстендә давыл көчле булып чыкты, ярсу дулкыннар көймәне чөеп уйный, баштанаяк коендыра; койрык якта ике куллап көймә читләренә ябышып утырган Лизаның куркуы йөзенә чыккан, ә Алабай шомланып шыңшый иде.

Шул мәлне нәрсәнеңдер ажгырып безгә таба якынаюын ишеттем. Нәрсә икәнен абайларга да өлгермәдем, нинди дер катер зур тизлектә барган шәпкә яны белән бәреп, көймәбезне әйләндереп үтте.

Су өстенә калкып чыгу белән көймәгә тотындым. Ә Лиза юк. Әйләнә-тирәдән эзлим, кычкырып та карыйм, ул һаман юк. Суга батты микәнни?! Карыйм, Алабай ачыргаланып, көймә астына кермәкче була. Әһә, аңлашылды. Димәк, Лиза көймә астында капланып калган. Котkарганда ул ярым һушсыз хәлендә иде, мин аны яр буена көчкә алып чыктым...

Әлеге давыллы кичтән соң Лиза сизелерлек үзгәрде. Миңа сез дип түгел, син дип эндәшә, елмаеп сөйләшә торган булып китте. Аңа карап мин дә елмаям, күңелем күтәрелүен сизәм. Яшь вакыттагы кебек дулкынланып, аның килгәнен көтәм, аргы якта яр өстеннән кул изәгәнен күрү белән, аны үзем көймәдә чыгып каршылыйм.

Безнең мөнәсәбәтләрне яшьләр, әлбәттә, сизәләр. Федя — киң күңелле егет — каршы түгел, апасы белән миңа бәхет теләве күренеп тора. Ә Хәбиб киресенчә, отыры салкыная төште, хәзер инде бер миңа гына түгел, хәтта Лизага кырын карый башлады.

Җитмәсә, үч иткәндәй, караваты янына стенага тагын теге фоторәсемне элеп куйды бу... Күрү белән күзләрем шар булды. Рәсемдәге ике хатын-кызның берсе — безнең әни, икенчесе — минем аерган хатыным... Зөлфия. Тез башына куе чәчле малай утыртып төшкән. Лиза күрмәсен дип, карточканы алып, тиз генә яшереп куйдым. Бу рәсемгә алар, мөгаен, мин фронтта чакны очрашып төшкәннәрдер.

Хәбиб, стенадагы рамның юклыгын күрүгә, кашларын җыерып:

— Әнинең сурәтен син алдыңмы?.. Хәзер үк урынына куй! — диде.

Бүтән чакны мин ул малай актыгына абыйсы белән алай дорфа сөйләшергә ирек бирмәс идем. Бу юлы хаклык аның ягында булгангамы, ничектер уңайсызланып калдым, авызын капларлык сүз таба алмадым.

— Анда... эни үзе генә түгел, читләр дә бар,— дип акланырга тырыштым.

— Нигә чит булсын... Үз улың чит була димени?.. Эни соңгы сулышына кадәр алар турында борчылды, аларны ташлама дип, миңа васыять әйтеп калдырды.

Мирза, сүзеннән туктап, елганың үр ягына борылып карады: «Әнә, безнең теплоход килә. Әйдә пристаньга төшик»,— диде.

Кичке караңгылык иңгән вакыт. Көндезге бөркүдән соң су буенда салкынча-дымсу һаваның сафлыгы тәнгә дә, җанга да рәхәт җиңеллек бирә.

Теплоход капитаны Мирзаны кадерле кунак кебек олылап каршылады һәм, палубага аяк басу белән, безне кызыл почмакка алып керде.

Кызыл почмак дигәннәрен кирәк вакытта ашханә итеп тә файдаланалар икән. Ак халатлы кок хатын безнең өстәлгә графин, ике кружка китереп куйды:

— Эссеедә тамагыгыз кипкәндер... Кичке аш өлгергәнче менә салкын квас, сусавыгызны баса торыгыз,— диде.

— Сине монда яхшы беләләр, бик хөрмәт итәләр икән,— дидем Мирзага.

— Әйе шул, үзем дә шуңа уңайсызланам,— Мирза көенечле елмаеп куйды.— Бу теплоходның исемен күрдеңме соң? Алайса ярар, ашыкма, бераздан мин сөйләгәннәрдән анысы да ачыкланыр.

...Сугышның инде икенче елы булса да, навигациянең беренче яртысы әйбәт кенә барды, пароходлар тәүлек буе туктаусыз йөри бирде, без дә зарланырлык бәла-каза күрмәдек. Әмма җәйнең икенче яртысында фронт безгә якынайды. Сталинградка килеп җиткәнче үк әле дошман авиациясе Иделнең түбәнге агымында безнең кәрваннарны аяусыз бомбалый иде. Дошман миналарына эләгеп, нефть кәрваннары шартлый, пароход тулы пассажирлар һәлак була башлады, бөтен флот төнлә эшләүгә күчте.

Мондый шартларда, табигый, безнең эш тә катлауланды, күпкә кыенлашты. Көндезләрен туктаусыз күзәтеп торырга һәм, мина төшкән урыннарны билгеләп, шундук трал базасына хәбәр итәргә кирәк. Ә төннәрендә кәрваннарны көймәдә чыгып каршылыйбыз, хәвефсез юл күрсәтеп озатабыз.

Күпертми-нитми әйтәм, җитәкчеләр дә эшебездән канәгать була, безне еш кына күршеләргә үрнәк итеп куялар иде.

Хәлләр авыр, эш күп булса да, Лиза белән мин — чиксез бәхетле. Сугыш бетүгә өйләнешергә сүз куештык. Минем исәп алай сузмаска иде. Әмма ул килешмәде: «Вакыты кулай түгел, дошманны җиңгәч тә өлгерербез»,— дип каршы төште.

Август ахырларында дошман безнең участокка бигрәк тә каныкты, көн саен икешәр, өчәр мәртәбә килеп мина ташлый башлады. Августның утыз бере көнне дә шулай булды. Төштән соң өйдә чирек сәгать черем итмәгәнмендер, якында гына самолет үкергән тавышка уянып киттем. Өйдән чыгарга өлгермәдем, Федя йөгереп керде, фашист козгынының фарватерга мина ташлавын әйтте.

Шундук Хәбибне тралчылар базасына хәбәр итәргә җибәрдем. Үч иткәндәй, нәкъ шул мәлне түбән якта борылыш артыннан зур-зур ике ак пароход килеп чыкты. Бинокльдән күрәм: икесе дә тал-чыбыкка төрүле, икесе дә гаскәриләр белән тулы. Әһә, мин әйтәм, хәйләкәр фашист миналарны боларга «күчтәнәч» итеп ташлаган икән. Пароходларга туктарга сигнал бирдек.

Озакламыйча базадан кечерәк кенә тимер баржа таккан «Маяк-

чы» теплоходында тралчылар килеп җитте. Безнекеләр яр өстендә торып калды; үзем, өлкән маякчы буларак, тралчыларга мина төшкән урынны күрсәтергә киттем. Теплоход алдан бара, корпусы магнитсыз булганга, аңа мина куркыныч түгел. Су төбендәге магнитлы минаны безнең арттан килүче трал баржасы шартлатырга тиеш.

Елга үзәге буйлап түбән таба да, агымга каршы да узабыз, тагын һәм тагын үтәбез, барыбыз да тын да алмыйча тралчы баржага карап барабыз. Мәгәр мина һаман табылмый, без түземсезлек белән көткән дәһшәтле шартлау яңгырамый.

Тралчылар командиры, запастан чакыртылган урта яшьләрдәге лейтенант, каш астыннан карап әйтте:

— Монда юк минаны эзләп су сөрүдә ни мәгънә... Әйт әле, ул минаның кай турга төшкәнен үз күзең белән ачык күрдеңме, кирәкмәскә баш әйләндермисеңме?

Уңайсыз булса да, дөресен әйтергә:

— Юк, үзем түгел, энекәшем күрде, аның вахтасы иде,— дип акланырга мәҗбүр булдым.

Эшне туктатып, кире кайтырга туры килде. Ә түбән очта без туктаткан пароходлар, кузгалырга рөхсәт сорап, әледән-әле гудок бирә башладылар.

Болай булгач, аларны тоткарлауда мәгънә юк, тегендә — фронт өстәмә көчләр көтә, корал көтә бит. Әнә шулай уйлап, мачта очына рөхсәт сигналы күтәрергә керештем.

Шунда Хәбиб каршы төште:

— Тукта, күтәрми тор... Сез анда мина төшкән урыннан читтәрәк йөздегез шикелле. Аз гына сабыр ит, мин үзем барып күрсәтим әле.

Тралчылар командиры каршы килмәде:

— Дөрес әйтәсең, энекәш, мондый эштә эштер-өштер генә ярамый... Әйдә, кузгалыйк.

Без өчебез дә будка каршында торып калдык, «Маякчы» тагын тимер баржасын өстерәп кире китте. Бу юлы ул без йөргән урыннан шактый сулданрак китеп барды һәм, ак бакен яныннан үтүгә, аның корпусы астыннан болганчык су өермәсе бәреп чыкты, шартлау дулкыны гөрселдәп һаваны тетрәтте.

Берничә минуттан без көймәдә барып җиткәндә «Маякчы»ның арткы ягы суга иңә төшкән, матрослар берсен-берсе ашыктыра-ашыктыра аның корпусындагы зур гына тишекне киндер пластырь белән каплап маташа, капитан күперчегендә тралчылар командиры, бинокльен як-якка юнәлтә-юнәлтә, су өстендә нидер эзли иде. Мин өскә күтәрелү белән:

— Менә бәла! Арткы палубада тралга карап барган җирдән синең егет юкка чыкты бит,— диде ул, дулкынланып.

— Ничек инде ул юкка чыкты?!

— Мина шартлаудан күтәрелгән өермә баганасы өстемә ишелеп мине аяктан екты,— диде тралчылар командиры, гаепле кешесыман каушап,— суга егылып төшүдән көчкә тотынып калдым. Аякка басып караганда, егет юк иде инде, ул басып торган урында теплоход борты умырылып тишелгән иде.

Ул көнне без Хәбибне караңгы төшкәнче эзләдек, әмма таба алмадык. Иртәгесен күрше участоктан килеп әйттеләр: агым су аның үле гәүдәсен бездән түбәнге участокта яр буена илтеп чыгарган иде...

Бу авыр фаҗигане башыма сыйдыра алмыйча, Мирзаның сүзен бүлеп сорадым:

— Аңлашылмый... «Маякчы»ның корпусы магнитсыз булгач, мина ник аның астында шартлаган икән?

— Әйе, барыбыз да шулай уйлаган идек,— диде Мирза.— Моңарчы фашист һаман магнитлы мина ташлады, без шуны зарарсыз-

лап килдек. Ә бу юлы, бәхетсезлеккә каршы, бүтән төр мина — мотор гөрелдәүдән шартлый торган акустик мина булып чыкты...

Безнең Хәбибебез әнә шулай үзенең үлеме белән гаскәри эшелон төялгән зур пароходны юлда һәлак булудан коткарып калды. Аның батырлыгы, телдән-телгә күчеп, бөтен Идел буена таралды, ул хакта газеталарда яздылар... Минада шартлаган теплоход ремонттан чыккач, Хәбиб истәлеген мәңгеләштерү өчен аңа «Маякчы Шәмсиев» исеме бирелде. Күрүеңчә, ул әле булса әйбәт кенә йөзеп йөри.

Мин Хәбибне Ташлыяр зиратына илтеп, әни кабере белән янәшә җирләдем... Шул көзне үк икесенең дә баш очына яшь каен утырткан идем. Хәзер алар зур булып үстеләр, бөтен әйләнә-тирәгә ямь биреп, үзара гәпләшкәндәй яфраклары белән акрын гына лебердәшеп утыралар. Быел җәй башында алар янында үземә дә урын билгеләп, барысын бергә чардуган белән ураткан идем. Менә бүген шуны буяп кайтып килүем әле...

Гаҗәп хәл, еш искә алганга булса кирәк, Хәбиб үлмәгәндер, вакытлы рәвештә берәр яры киткәндер кебек кенә тоела, аның теплоходын күргән саен, үзен очраткандай булам. Менә хәзер бирегә кереп утыргач та, йөрәк телгәләнә, әллә кайчангы хәсрәтле, үкенечле уйлар кузгала.

Мин кинәт гаҗәпләнү белән:

— Пристаньда караңгыда исеменә игътибар итмәгән идем, бу — шул теплоходмыни?! — дип кычкырып җибәрүемне сизми дә калдым.

— Әйе, «Маякчы Шәмсиев» — шушы. Аңа бу исем Флотилия Хәрби Советы приказы белән бирелде. Менә хәзер мине ник хөрмәтләүләрен аңладыңмы инде? Хәбибкә тиешле хөрмәтне, миңа кабул итәргә туры килә...

Шуның өстенә туган-тумачасыз, ялгыз яшәү үзәккә үтә.

— Нишләп ялгыз? Син Лиза белән өйләнешергә җыенганыгыз турында әйткән идең ич.

— Ул ният барып чыкмады, Лизага әллә ни булды,— дип Мирза тагын уфтанып алды.— Хәбиб һәлак булганнан соң ул безнең постка сирәгрәк йөри башлады, миңа карата ни сәбәптәндер суына башлады. Ахырда:

— Сугыш хәлләрен үзең дә беләсең, Мирза,— диде,—— мине военкоматка чакыртып исәпкә алдылар. Кичләрен медсестралар курсына укырга йөрергә куштылар. Озакламыйча алып куюлары да ихтимал.

Тиздән аны, дөрестән дә, фронтка җибәрделәр. Соңыннан медпункт кешеләреннән ишетеп белдем, Лизаны хәрби комиссариат чакыртып алмаган, ул үз теләге белән киткән булып чыкты.

Менә шундый хәл, дускаем, теләсәң нәрсә уйла, теләсәң ничек аңла.

Кичке аштан соң без, палубага чыгып, эскәмиягә утырдык. Теплоход төнге тынлыкта сиздерми генә алга шуыша! Вахта кешеләре эш белән мәшгуль: начар күренә торган маяклар очраса, туктап, баллонны алмаштыралар, давыл кузгатканнарын тиешле урынга күчереп куялар да, юл уңаена борылып, тагын китеп баралар. Мирзаның сүзсез утыруы озакка сузылгач, мин аңа:

— Сугыштан соң гомерең шул постта үттеме? — дип сорау бирдем.

— Юк, сугыш беткәнче үк әле, аннан алып, пристаньда причал башлыгы, аннары диспетчер итеп куйдылар. Байтак еллар Баскунчак тозын баржаларга төяп озатуда эшләдем. Үземчә болай тырыштым шикелле. Орден белән дә бүләкләделәр. Ул җәһәттән бер дә кешедән ким-хур түгел, зарланырга урын юк.

Әмма мин, ялга чыкканнан бирле, дәваланып булмый торган авыр чир — йокысызлык чире белән җәфа чигәм... Искитмәле хәл: башны

мендәргә тәртүгә йокыга китәм дә, шундук саташа башлыйм. Бик озак йоклаган кебек, иләс-миләс уянып китсәм, күп дигәндә ярты сәгать вакыт үткән була. Аннары инде күзгә һич йокы керми, төштә күргәннәрне төрлечә юрап, төрлечә уйлап ята-ята баш түнеп бетә.

Үзең беләсең, хәзер уйланырлык, баш ватарлык нәрсәләр аз түгел. Тормыш күз алдында үзгәреп тора. Кайчандыр без изге санаган кайбер шәхесләр яман залим булып чыкты, каторгага сөрелгән «халык дошманнары»ның гөнаһсыз корбаннар икәнлеге ачылды.

Бу искитмәле үзгәрешне мин үз күзем белән күрдем, башымнан кичердем. Шуннан әлек кенә «Зур Идел» газетасында безнең техникумга сиксән ел тулу уңае белән очрашу үткәреләчәк, анда укып чыгучыларны очрашуга чакырабыз дип язылган белдерүне күргән идем. Ничектер күңелем җилкенеп китте. Тукта, мин әйтәм, яшьлек елларым үткән шәһәрне, бергә укыган дусларны күреп кайтыйм әле. Шулай дип, Казанга бардым, үзәк мәйданда күтәрелгән «Татарстан» кунакханәсендә туктадым. Заманында мин театрал идем бит, бу юлы да беренче кичне үк театрга барырга булдым. Шул ният белән вестибюльгә төшкәч, афишада үземә каенатай тиешле драматургның исемен күреп шаккаттым. Кичен аның пьесасы куелачак икән.

— Бу тыелган пьесаны куярга ничек батырчылык иткәннәр икән?..— дип үзалдыма әйтеп куюымны сизми дә калдым.

Шунда минем белән янәшәдә афишага карап торган урта яшьләрдәге ир кеше гаҗәпләнеп:

— Белмисезмени, ул хаксызга гаепләнгән булып чыкты бит,— диде.

Бу сүзләрдән шатланырга да, кайгырырга да белмәдем, зиһенем чуалды. Бераз аңыма килгәч, әле һаман башыма сыйдыра алмыйча: дөресен әйтәсезме, чынлапмы, дип сораудан чак тыелып калдым. Моннан соң инде театрга барырга аягым тартмады. Киосктан газета алдым да, үзем генә калырга, тынычланырга теләп, бүлмәмә кереп бикләндем... Әмма барыбер тынычлык тапмадым. Бераздан, буфетта тамак ялгап кергәч, йокы алдыннан газетаны карый башлауга, тагын шул спектакльгә, тәгәлрәге, аны бик мактап язылган мәкаләгә тарыдым. Ул төнне йокым йокы булмады, әллә нинди буталчык төшләр күреп саташып чыктым.

Иртәгесен телефоннан шалтыратып белдем, очрашу кич белән театр бинасында булачак, моның өчен техникумга барып билгеләнергә кирәк икән.

Уку бинасына барып керүгә, каршы стенадагы стендларда — техникумны тәмамлаучы атаклы кешеләрнең, хезмәт алдынгыларының портретлары. Очрашуга килүче һәркем иң әүвәл үз сабакташлары янында туктала. Безнең курсташлардан Советлар Союзы Герое Михаил Девятаев белән капитан Кәбир Ибраһимов рәсемнәре куелган.

Бераз читтәрәк, махсус стендта — атказанган педагогларның рәсемнәре. Шулар арасында көтмәгәндә үземнең яшь чагымда төшкән сурәтемне күреп, бик аптырап калдым. Рәсем астындагы язуны укыгач кына ул кешенең мин түгел, хәзерге вакытта корабльләр төзү теориясеннән укытучы икәнен белдем.

Шулай да бу охшашлык бик сәер тоелды һәм дулкынландырды мине. Канцеляриядә килгән кунакларны теркәүче өлкән яшьләрдәге ханым ул педагогның үзен дә, әнисен дә якыннан белә булып чыкты. Минем читләтебрәк кызыксынып сораштыруыма, сүзчән ханым ачык йөз белән бәйнә-бәйнә тезде дә бирде:

— Хәбиб Салихович безнең студентларның иң яраткан укытучысы. Әтисе фронтта һәлак булды. Әнисе Зөлфия апай да безнең техникумны тәмамлаган кеше. Бер ялгызына кыен булса да, улын укытты, кеше итеп үстерде. Хәбиб әнисенең өметенаклады. Башта безнең техникумны, аннары су транспорты институтын яхшыга тәмамлады.

Сурәтне күргәч тә башымда шундыйрак фараз т...ган иде, фамилиясе бүтәнчә булганга гына бераз шигем бар иде. Ән...сенең исемен дә атап әйткәч, икеләнергә урын калмады: үземә охшаган б... чибәр ирегет минем улым булып чыга бит...

Минем эчке халәтем йөземә чыктымы, әллә Хәбибкә охшашлыгымны төсмерләп алдымы — ханым миңа ничектер сәерсенү белән текәлебрәк карый, кайда, ничек гомер итүемне җентекләбрәк сораштыра башлады... Ярый әле шул мәлне бер төркем кунаклар килеп керде. Ханым аларны теркәгән арада мин шыпырт кына чыгып тайдым. Бик каушаган булуыма карамастан, ишеккә үткәндә туктап, теге сурәткә кабат карадым. Хәтта бит чокырлары, ияген дәге ясмык ...тле генә түгәрәк миңе дә — барысы да минеке иде.

Анысы да монысы, сәгате-минуты белән монда Зөлфия үзе килеп чыгуы, бергә укыган сабакташлар очравы да ихтимал бит. Теге дөньядан әйләнеп кайткан тере мәет кебек, мондый хәлдә алар күзенә ничек күренәсең, ни дип әйтәсең?.. Үземне һәм улымны, элеккеге хатынымны уңайсыз хәлгә куюның, инде әллә кайчан онытылган имеш-мимеш гайбәтләрне кабат кузгатырга сәбәп бирүнең ник кирәге бар!? Һәм мин очрашуга бармаска булдым, шул ук көнне беренче очраган поезд белән кире кайтырга чыктым.

Шәһәрдә әллә ни сизелмәгән иде, поезд кузгалганда вагон тәрәзәсеннән карауга кинәт бик ямансу булып китте. Кайчандыр Зөлфия белән кулга-кул тотынып йөргән Кремль тауларын, Казанка буйларын күреп күңелем тулды. Хәзер дә, уйлап торам да, исем-акылым китә, үз бәхетемне үзем җимердем бит, адашкан эт шикелле, бер башым торып калдым, һичкемгә кирәгем юк.

Шулай да моңарчы мин бик бирешмәдем. Бер мин генә түгел, тормыш шулай кушты дип үз-үземне юата идем. Бактың исә, һәркем минем кебек коелып төшмәгән. Әнә этисе репрессияләнгән Зөлфиягә кырыкмыйча өйләнүче, баласын уллыкка алучы киң күңелле кыю кеше дә булган бит. Әнием белән энекәшем Хәбиб тә авыр көннәрдә Зөлфиягә терәк булырга тырышканнар. Зөлфия дә җавапсыз калмаган, рәхмәт йөзеннән улына Хәбиб исемен кушкан... Хәзер, ул көннәрнең аянычлы истәлеге булып, аларның әни белән бергә төшкән фоторәсеме генә калды.

Гомер онытасым юк, мин малай чакны безнең авыл читендә, яшел чирәмле калкулыкта зур ябалдашлы мәһабәт карт имән бар иде. Көндезләрен без бала-чага шунда мәш киләбез, кичләрен яшьләр җыелып күңел ачалар. Имән сәфәр чыгучыларга, хәерле юл теләгәндәй, яшел яулыгын болгап озатып кала; туган авылны сагынып кайтучыларны ерактан күреп, якты чырай белән каршылый иде. Шуңа да авыл халкы аны ярата, җырларына кушып җырлый. Безнең Хәбиб аның хакында бик матур гына шигырь дә язган иде.

Көннәрнең берендә, төгәлрәге, хәтәр җил-давыллы караңгы төнне яшен сугудан шул имән янды, өтек ботаклары як-якка тырпайган кара күмерле кәүсә генә торып калды, аннан кош-корт кына түгел, бөтен авыл бизде.

Бу вакыйга халыкта авыр тәэсир калдырды. Хорафатларга ышанучан әби-сәби аны төрлечә юрады, бәла-казасы тимәсен дип, сәдакалар бирделәр. Без, бала-чага, әлеге имәнгә карамыйча үтәргә тырыша идек... Менә хәзер, картлык көнемдә мин дә шул котсыз кара имән кебек калдым, дөньяда һичкемем юк...

Мирза соңгы сүзләрен эчке ачыну белән ишетелер-ишетелмәс пышылдап әйтте, хәле беткәндәй, башын түбән иде.

Шулчак безнең баш очында гына кинәт гудок кычкыртып җибәрде. Владимировка пристанена якынаеп киләбез икән. Сүз белән мавыгып, таң атканын да сизми калганбыз.

«Маякчы Шәмсиев» теплоходы биредә берничә минутка. Мирзаны

төшереп калдырырга гына туктады. Төнге вахтада торучы капитан аны: онытып бетермәгез, тагын килегез дип, озатып калды, кучтәнәчкә берничә сазан балыгы да бирде. Мин Мирза белән киләчәктә элемтәне өзмәскә, хат язып торырга сүз куешып саубуллаштым.

Теплоход елга уртасында агым уңаена борылгач, рубкага менеп бинокльдән караганда, Мирза инде яр өстендә тора, иртәнге алсу таң фонында аның ялгыз шәүләсе бая үзе сөйләгән, яшен суккан имән төсле караеп шәйләнә иде.

...Әстерханнан кире кайтышлый Ташлыяр буеннан узганда мин тагын шагыйрә Газизә Сәмитованы хәтерләдем: менә ичмасам каһарман зат, гадәт-йола, шәригать законнары изге саналган бер заманда хатын-кыз башы белән үзенең шәхси һәм иҗат хокукы өчен көрәшә алган бит. Ә менә минем сабакташым Мирза, авыр көннәрдә үзен-үзе ихтыяри сөргенгә дучар итеп, тормышын харап иткән, сөйгән хатыныннан, бердәнбер баласыннан мәхрүм калган. Күркәм шәфкать туташы Елизавета белән дә гаилә кора алмаган. Ник алай килеп чыккан? Моның тамыры кайда, сәбәбе нәрсәдә?.. Әнә шундый авыр уйлар, күңелсез сораулар мине әле дә борчый.

Ә вакыт дигәнең тукталып тормый, үз җае белән тәгәри бирә. Мирза белән очрашканга да инде шактый гомер. Ә мин аңа әле һаман хат яза алганым юк, дөресрәге, нишләптер һаман суза киләм. Кәгазь, каләм алып өстәл янына утырсам, ни язарга, белмичә аптырап калам. Җылы сүзләр белән юатсам, авырткан җиренә кагылып, хәтерен калдырырмын шикелле. Берни әйтмәсәм дә уңайсыз, ничектер игътибар итмәү, битарафлык күрсәтү шикеллерәк килеп чыгар сыман.

Ул хакта уйлый башласам, иң әүвәл минем күз алдыма Мирза үзе сөйләгән манзара — теге яшен сугудан кара көйгән имән килеп баса. Шул ук вакытта саф йөрәкле Хәбиб тә истә, иртән алсу таң атканда аның исемендәге ак теплоходта Идел буйлап баргандай, сулыш киңәя, күңелсез уйлар тарала.

Әмма ләкин боларны һичничек әйтеп булмый, хат тагын язылмый кала бирә...

## Гаяз Исхакый

# ИКЕ ЙӨЗ ЕЛДАН СОҢ ИНКЫЙРАЗ



Инде шул фаҗигаләрне күрдек, тукта, рәтләнмәсме, тукта, рәтләнмәсме, дип түздек. Сезнең шул начарлыкларыңызны исемемез берлән яптык. Сез һаман тәүбәгә килмәдеңез! Шуның өчен җәзасын күрдеңез! Беттеңез! Беттеңез! Ичмасам, башымыз тыныч калды, актык гомеремездә мәдрәсә дип алдап торудан котылдык!»— дигән кебек булалар иде. Җәгъфәр әфәндегә, вакыйган, боларның бу сүзләре дөрес кебек беленә иде. Ул хәтта: «Ник бездә бу мәдрәсәләр булды икән? Әгәр булмаган булса иде, милләтемез, укыр җиребез юк, дип кирәгенчә ясаган булыр иде, ясый алмасалар, икенче халыкларның ясаган җирләрендә укырлар иде. Һәммәсе бәхетсезлеккә каршы, һәммәсе бәхетсезлек!»— дип уйлый иде. Зиярәтләр[1], зиярәтләрдәге олуг кешеләр моннан ике йөз ел мөкатдәм[2] болгарларның бөтен тарафыннан зиярәт өчен килгән каберләр Җәгъфәр әфәндегә: «Нихәл? Син генә ни эшләп йөрисең инде?»— дигән кебек булган иде. Җәгъфәр әфәндenең: «Тәкъсир[3], сезне зиярәткә килдем»,— җавабына каршы көлеп: «Кем кушты? Кем чакырды? Сез олылау дисезме аны? Ул мине мыскыл итү генә! Сез мине олуглыйммыз дип минем каберем янына тезләнеп утыруыңыздан миңа ни файда? Сез мин әйткән сүзләрне ишеткән, тыңлаган булсаңыз иде, миңа гомеремә бер кешеңез килмәсә дә, һич кайгырмас идем, һәр көнне килеп, әллә нинди кылган кабахәтлекләреңезне миннән гафу кылдырмакчы булдыңыз! Үзеңез кылырга уйлаган кабахәтлекләреңезгә минем каберем янында утырган өч-дүрт гарипкә биргән садакаларыңыз берлән минем ризалыгымны, хәтта фатихамны сатып алмакчы булдыңыз! Сезгә миннән фатиха алырга кирәк дип кем әйтте? Ай-яй!! Бер төрлеләреңез, сәләфләрчә[4] буламыз дигән булып, аларның ишәкләре тычкан урынга сез дә тычтырмакчы булдыңыз! Безнең әйткән сүзнең мәгънәсе берлән йөрмәдеңез, сүзе берлән йөрдеңез! Шуның өчен сезнең тарихыңызда сүздән бүтән нәрсә булмады, җөмләңез дин кайгырттыңыз, җөмләңез милләт кайгырттыңыз! Милләткә ни эшләдеңез?! Бусы болай

---

1. Зиярәт — күрергә, күрешергә килү. 2. Мөкатдәм — элек. 3. Тәкъсир — руханиларны олылап эндәшү. 4. Сәләф — борынгы кешеләр.

Ахыры. Башы 1 санда.

кирәк, тегесе тегеләй кирәк, дип сөйләдеңез, тамакларыңызны туйдыргач, корсакларыңызны тутыргач, таралдыңызмы?!. Ай, оятсызлар! Оятсызлар!» — дигән кебек була иде. Һәм Җәгъфәр әфәнде үзе дә бу сүзләрнең дөреслеген белеп, колагыннан аягына кадәр кызарып, бер сүз әйтә алмаенча кала иде. Әстерхан янындагы мөселман авылларының хәрабәләре, җимерелгән мәсҗетләре, зиярәтләрендәге ташлары, тарих җәмгыятенең музәханәсендә китаплары, киемнәре, зиннәт әйберләре, табак-савытлары Җәгъфәр әфәнденең шулкадәр башын тутырган иде, ул һич нәрсә хакында уйлый алмый иде. Ул көнен дә, төнен дә, төшен дә шулар берлән мәшгуль иде. Бәхетсезлеккә каршы, Җәгъфәр әфәнде урамда болгар көе уйнап йөри торган органчыны күрде һәм аңардан болгар көйләрен уйнатты. Ләкин һич сабыр итә алмай үксеп-үксеп егларга тотынды. Ул, кулыннан уенчыгын алган бала кебек, тәти казакиен котлатырга барганда егылып, тәти казакиен сазга былчыраткан бала кебек, елый иде. Бу музыка Җәгъфәр әфәндегә тагы болгарның бөтен дөньяны дер селкетеп, бөтен мәдәни голәмдә сату итеп йөрүләрен, хәзер үзенең музыкасын уйнарга да кешеләре калмауларын, бер-ике елдан, белмим, бер-ике көннән музыкасын тыңларга да, тыңлагач, егларга да кеше калмаячагын уйлап-уйлап еглый иде. Бу яшьләр унтугызынчы-егерменче гасыр яшьләре яшенең калдыклары, бу яшьләр унтугызынчы-егерменче гасыр картлары тәгассыбының[5] нәтиҗәләре, унтугызынчы-егерменче гасыр голәмасының утырткан агачларының җимеше иде — зәкъкум[6] җимеше иде. Җәгъфәр әфәнде болгарларның һәр әсәрләре берлән күрешеп, мәсҗетләрен кочаклап, китапларын үбеп-үбеп күрешеп, Әстерхандагы мәшһүр шагыйрьнең каберенә йөз сөртеп, Казанга таба юнәлде. Әстерханнан китүе никадәр кәефсез булса да, пароходта аннан да кәефсез булды. Пароходның көпчәге өстендә «Гром» дигән исемнең ике ягында да саргайганрак, аз гына таныла торган мөселман хәрефе берлән язылган сүзләр күренә иде. Җәгъфәр ни кадәр ни язылганын белергә теләсә дә, пароход барганда аз гына укып аңларлык түгел иде. Шуның өчен әүвәлге пристаньдә үк, бик тиз чыгып, шуны укырга тотынды. Ал ягында «Габд» сүзе, ахыр ягында «сырый» сүзләрен укыды. Бу сүзләр Җәгъфәр әфәндегә яшен суккан кебек тәэсир кылдылар. Бу пароходның бервакытны болгарларның беренче мөхәррирләре «Габделкаюм Әл-Насыйри» исеме берлән исемләнгәнен вә мөселманнар тарафыннан тәэсис[7] кылынган «Җил» исемендәге ширкәтнең бер пароходы икәнлеген белде. Моның саргаеп, буяулары кубып, көчкә генә укылуы, гүя, шуның ачуын китерер өчен ясаган кебек күренә иде. Җәгъфәр әфәнде ни эшләргә белмәенчә, тагы бик озын-озын уйларга чумып, бик авыр сагышларга төшеп, кая барганын белмәенчә кайта иде. Үз исәбе берлән Сарайга керергә кирәк булса да, бу кайгылар берлән дә шулкадәр кәефсез уйлар уйлап, йә бөтенләй акылдан сабармын дип, кермәскә уйлаган иде. Акылдан сабуына да исе китмәс иде дә, рус тарихларында «актыккы болгар гакылдан сабып үлде» сүзен калдырасы килмәүдән иде. Шул кайту берлән Җәгъфәр шәһри Болгарга да кермәде, туптуры Казанга кайтты. Казанга менгәндә юлы Печән базарыннан үтәргә тугры килде. Әлгәреге үткән бер кешегә артыннан адресы берлән «иман» яисә «кәфер» җибәреп тора торган, киеменнән алып хәрәкәтенә кадәр булган эшләрен иләкләреннән сөзеп чыгарып тора торган болгарлар урынына ярым-ярты русча сөйләгән еврейлар белән руслар тавышы гына ишетелә иде. Казан тарихында укып, һәр кибеттә нинди кеше сату иткәнне, нинди товар берлән кәсеп иткәнне

---

5. Тәгассыб — фанатизм. 6. Зәкъкум — агулы агач. 7. Тәэсис — нигезләү.

белгәнгә, һәр кибетне күргән саен шул кибетнең хуҗалары моның күз алдында һавасызлыктан кычкырып-бакырып үлгән кебек булалар иде. Шуның өчен болар яныннан үтү, бу хәлләрне сизү Җәгъфәргә бик авыр иде. Аның берлән генә бетмәде. Печән базары мәсҗете турысына җитте. Ни күзе берлән күрсен, мәсҗетнең алдына алтын хәреф берлән «Болгарский музей» дип язган бер вывеска күтәрәләр иде. Моңарга әллә никадәр кеше җыелган иде. Ишек төбенә әллә никадәр сачәкләр утыртылган иде, кич яндырыр өчен әллә никадәр электрик лампалары әзерләнгән иде. Бу көн икенче октябрь булганга, русларның Казанга керүләре бәйрәм көне мөнәсәбәте илә болгарларның мәсҗетләренең музейга әйләнү бәйрәме шул көнгә тугры китерелгән иде. Шуның өчен хәзер бәйрәмгә әллә никадәр кеше җыелган икән дә, бер тарих мөгаллиме болгарлар хакында бераз тарихча мәгълүмат биргәч, рәсми ачылачак икән. Җәгъфәр әфәнде моны белгәч, тизрәк моннан үтәчәк булды. Ләкин халыкның тыгызлыгы сәбәпле үтү авыр булганга, халык авызыннан «бывшая мечета» дигән укларның Җәгъфәр йөрәгенә кадәр керүләренә сәбәп була иде. Мең бәла берлән Җәгъфәр бу күренештән котылды. Кабан буйлап китте. Кабан күле буенда Апанаевлар мәдрәсәсенә «Приют» дип язылган язуны күрде. Тагы бер уфлады да хәзерге Екатеринский урамга чыга башлады. Чатка җиткән иде, кыңгырау тавышы ишетелә башлады, кая икән дип караса, Апанаевлар мәсҗете час булган икән дә хәзер, пожар чыккан вакытка туры килгәнгә, шуның манарасында колоколны кагалар икән!! Җәгъфәр ни эшлисен белмәде, «уф!» дип сулады да күзен йомып тизрәк китте. Юлы Борнаевлар мәсҗетенә туры килде. Ни күзе берлән күрсен, манарасын павильон ясаганнар, ак алъяпкычлы официантлар, башларын сачәк берлән тутырган барышнялар торалар. Җәгъфәр ни эшлисен белмәде, күзен йомды, күз алдында мәсҗет эчендә мулла хотбә укый, имеш, өсте павильон, имеш, кебек була башлады. Тагы Әҗемнәр мәчете янына китсә, анда да шундый бер кәефсезлек булыр дип, атын Мещанский урамнан Печән базарына борырга кушты. Тагы бәла! Тагы кайгы!! Зәңгәр мәчет бөтенләй юк!! Кая ул?!! Ахырда бу вакытны манарасы ишелүен газетада укуы исенә төште. Зур хәреф берлән больница дип язып куйган язу күрде һәм шуның элгәреге мәсҗет икәннеген белде. Мәдрәсәнең башында «Акушерские курсы» дип язылып куелган иде. Моннан да котылды, әлхәмде лилля!! Тагы бер бәла бармыни? Субай мәчетенә «Читальня» дип язып куйганнар! Тагы арырак ничә йөз шәкертләргә урын булган Галиев мәдрәсәсенең дә тарихын, үзләренүзләре мактап язган шигырьләре янындагы ташка «Убежище для неизлечимых больных» дип язып куйган вывесканы күрде. Монысы тагы бик авыр булды. Алай булса да, бу мәдрәсәнең тарихы исенә төшкәч, кылт итеп: «Монысы ичмасам әүвәлге вазгыятен югалтмаган икән»*,— диде.

Извозчик тә, борыла-борыла арып беткәч: «Инде кая?»— дип сорады. Җәгъфәр уянган кебек булды да кая булса да бер номерга төшерүен үтенде. Болар шул урам белән барганда, бик биек бер башняның башында флаг күрде. Һәм шуның янынннан бик күп халыкның чәчәк күтәреп чыгуын күрде. Исәпләп караса, бу җир Госманов мәсҗете тирәсе икәнен белде. Һәм чынлап карагач, бу башня да аның манарасы, ул чәчәк күтәргән кешеләр дә элгәре мәсҗет булып, хәзер гөлләр, чәчәкләр кибете булган Госманов мәсҗетеннән чыгуын күрде. Монысына кайгырырга да өлгерә алма-

* «...әүвәлге вазгыятен (халәтен — ред.) югалтмаган икән»,— бу урын Күл буе мәдрәсәсе белән «Мөхәммәдия» арасындагы көндәшлек һәм җиңешүнең чагылышы булса кирәк.

ган иде, извозчик атны туктатты. Җәгъфәр дә уянып, үзен әллә кайчаннан бирле вата торган уйлардан тынычлыйм, дип номерга керә башлады. Күзе капка башына төште. «Госманов мәсҗете мәдрәсәсенең вакыфы»,— дигән сүз моның әлгәреге мәдрәсә икәнлеген белдереп, тагы моны изә башлады. Җәгъфәр әфәнде, ни булса булыр, дип номерга керде. Һәм дә бик арыдыгыннан, тиз генә йокларга ятты. Төшләрендә тагы Әстерхан халкы. «Хәзәр» идарәханәсе, Печән базары мәсҗете, Казан халкы берлән саташып бетте. Берсендә һәммә халык яланбаш, яланаяк, көзге кояшта елынган төсле күренәләр иде. Икенчесендә сачәкләр, болгар музыкалары, болгар гәзитәләре берлән бер болгар бәйрәме ясыйлар имеш кебек күренә иде. Болгарларның мөхәррирләре, әдипләре, белекләре[8] һәммәсе «Болгар мәйданы» дигән җиргә җыелганнар, имеш. Һәммәсе халыкка: «Безнең милләтемезнең бетү ихтималы бар иде, менә шул фидаилар аркасында, шул кадәр хезмәт саясендә[9] менә бүгенге көнгә килеп җиттек. Хәзер нигезәмез таза, иске черек нигезне алыштырдык, халкымыздагы чергән фикерләрне, коруне вәсата[10] уйларын бетердек; моның ике йөз ел элек милләтемезнең иң куркынычлы вакытында, милләтемезнең голәмасы исемендәге милләтемезне ашап тора торган зат галиләрне тирес иттереп, җир яхшыларга түктек. Җиремез яхшырды. Җиремездән менә сезнең кебек затлар мәйданга чыкты, мәдрәсәләремез, мәктәпләремез ислах кылынды. Әлгәреге дәвер, тәсәлсел урынына голуме риязиәт[11], схоластика урынына фәлсәфә дәресләре куелды. Шәкертләргә тәсбих урынына фәлсәфә китаплары таратылды, укытылды, укылды, бу дәрәҗәгә килде, бу көнгә җитте. Милләт тагы меңнәр яшәсен!! Яшәсен меңнәр!!»— тавышы бөтен дөньяны алган кебек була иде. Кул чабулар, болгар музыкалары, тагы «Яшәсен мөхәррирләр! Яшәсен болгарлар!!»— тавышы галәмне тота иде. Җәгъфәр дә мөхәррирләр арасында, имеш, аның кулын һәммә мөхәррир кысып, хезмәтләрен тәбрик кылдылар, имеш, ул да күргәннәренең төш икәнлеген белеп шатланды, балалар кебек сөенде, имеш. Халыкның: «Яшәсен Җәгъфәр белгуар![12] Яшәсен!»— тавышларына, болгар музыкасы тавышларына уянып китте. Үзен номерда күргәч, йөрәге шу итеп китте. Ул бәйрәмнәр төш икәнлеген белеп, әгәр дә унтугызынчы, егерменче гасырда баягы мөхәррир сөйләгәнчә кылсалар, моның көн булуы да мөмкин икәнлеген уйлап, «Ник булмаган?! Ник булмаган?!»— диде дә, күзләреннән яшьләр агызып, ятагына егылды. Бик озак балалар кебек еглады, күргән мөхәррирләрен, мәйданга җыелган әллә ничә меңнәр болгар мәдрәсәләренең шәкертләрен, икенче ягында кызлар мәктәпләреннән килгән, һәммәсе бер төрле калфаклы болгар кызларын, мәйданда сачәкләр берлән бизәлгән, флаглар берлән уратылган болгар һәйкәлләрен, болгар музыкасын — барысын да күңеленнән кичерде. Җәгъфәр әфәнденең бу төше, гүя, болгарларның икенче юл белән барсалар, голәма сүзенә карамаенча, хәмиятле кешеләр, милләт сөя торган затлар сүзенә карасалар, нинди булачакларын белдерер өчен, голәманың нинди зур җинаять кылганлыкларын күзе берлән күрсәтер өчен юри ясалган кебек иде. Гаҗәба[13], шул төшне унтугызынчы, егерменче гасыр голәмалары үзләре күрсәләр, яисә голәма сүзе берлән йөримез дип, голәмаларның милләтемезне зәһәрләвенә хезмәт итүче байлар күрсәләр, ни әйтерләр иде икән?! Голәманыкын беләм: «Шәйтани!»— дияр иде. Башкаларныкын белмим. Аларның күңеле дөрестә булганга, аңламаенча гына голәма артыннан барганга, бәлки хаталарын сизеп, хәзер тәүбә кылырлар

8. Белек — галим, ученый. 9. Сая — күләгә. 10. Коруне вәсата — урта гасырлар. 11. Голүме риязиәт — математика. 12. Белгуар — профессор.

иде. Аларның да шул голәмалар кайсысының кияве, кайсысының улы булганга, бу хакыйкатьне ачу мөмкин булыр идеме-юкмы, белмим. Җәгъфәр, болай булмый инде, дип, бик тиз генә торып, юынып, чәй эчәргә тотынды. Һәм дә чәйдән соң үзенең ни эшлисен уйлаганнан соң, хатыны Сөембикә янына кайтып, бераз тынычлап гомер үткәрергә, аннан соң Петербургка тарих җәмгыятенә барырга, хәзерләнергә вакыт икәнлеген күңеленнән кичерде һәм шул уй берлән чәй сорады. Официант та чәй китергәндә, яңа газитә дип, шул көнге Казан газитәсен дә кертте. Җәгъфәр әфәнде, никадәр арыган булса да, газитә күргәч, укырга тотыначак булды. Һәм кулына алуы берлән «Последний болгарин» исемендәге бер мәкаләгә күзе төште. Бу сүз моның тәненә әллә ни тәэсир кылды. Зыяндашлы кеше кебек, газитәне кысып тотты да шуны укырга тотынды. Мәкалә Оренбургтан язылган иде. Оренбургның бер хәстәханәсендә бер мөселман картының бик авыруын һәм дә саташып ятуын, хәзердә үзенең үлеп беткән якыннарын чакыруын, коръән укырга кеше китерергә теләүләрен, кайвакытта болгарча җырлап җибәрүләрен, шуннан соң еглап җибәрүләрен, аның артыннан хатыны, балалары, кардәшләренең исеме белән кычкыруын һәм дә, Оренбургта бер болгар да юк булганга, актык көннәрендә шул кешегә сөйләшергә кеше булмавын бик кызганыч итеп язганнар иде. Җәгъфәр газитәне күтәреп бәрде. Үзе бер нәрсә уйламаенча катып торды да, кинәттән җан кергән кебек булып: «Шул көнгә җиттекмени?! Кемнәр сәбәп булды моңарга?!! Ләгънәт аларга!!. Ләгънәт!!!»— диде дә, өстенә киенде дә, һич бер сүз әйтмәенчә, ишекне дә япмаенча, чыкты да китте. Туп-туры пристаньга төште. Һәм шул сәгатьтә Самарага китте. Үз уе берлән актыккы болгарны үлүеннән элек кенә булса да, күңелен тынычландырып, азмы-күпме милләт хәлләрен сөйләп, кирәк булса, болгарча җырлап та, үләр алдыннан авызына су салып, иман әйтеп торачак иде. Пароходка кергәч тә, бер кешегә катышмый, пристаньдә алган газитәсен укырга тотынды. Семипулаттан язылган бер мәкаләдә андагы элгәреге мәдрәсәләрнең фәкыйрьханәләр, гаҗизханәләргә әверелүен, мәсҗетләрнең тарих җәмгыятьләре тарафыннан идарә кылынуын вә иң ниһаятендә шул көндә генә больницада үлгән бер болгар кызының ничек үлүен, нинди авыру берлән ятуын, төсләрен, кыяфәтләренең нинди икәнлеген, хәтта гыйльмел-нәсәб[14], җәһәтеннән саф болгар кызы булуын, гомерендә Семидә[15], Мәскәүдә, хәтта Петербургта бик мәшһүр «туташ» булуын, вә шуннан соң безнең болгар кызларының шул туташлыкта бик тәрәккый итүләрен, гомум милләтемезнең китешенә шул эшнең ни дәрәҗәдә зарар итүен мөляхәзә кылынган иде. Җәгъфәр әфәнде моңарга да ни әйтергә белмәенчә, үзе нәрсә уйларга да аптырап, катып калган иде. Вә бик озак, әллә ниләр уйлап, дөресен әйткәндә, берни дә уйламаенча, пароходның бер башыннан икенче башына ашыгып-ашыгып йөрсә дә, бара торгач арып, аш бүлмәсенә кереп аш сораган иде. Аш өлгергәнче ни эшләргә белми йөргәндә, Җәгъфәр әфәнде музыка тавышы ишетә башлады. Бу тавышта әллә нинди бер үзлек, әллә нинди йомшаклык, әллә нинди моңлылыктан башка, бу музыкада әллә нинди әйтеп аңлатылмый торган бер куәт бар иде. Җәгъфәр үзен белербелмәс музыка уйнала торган җиргә барып кергән иде. Һәм үлгән кеше кебек, уенчы марҗа янына барып каткан да калган иде. Бу уен болгар уены, бу көй болгарларның унтугызынчы гасырдан бирле билгеле, хәзер дә бөтен галәмдә мәшһүр Тәфкилев көе иде. Бик озак тыңлап торганнан соң, Җәгъфәр әфәнде дә рояльнең капкачы

---

13. Гаҗәба — ни гаҗәп. 14. Гыйльмел-нәсәб — генекология. 15. Семи — Семипалатинск.

шап итеп каплангач, уянган кебек булган иде. Һәм үзенең болгар икәнлеген белмәсеннәр, белсәләр, сораша-сораша, моның иң әчке җәрәхәтләрен ачарлар, дип, тиз-тиз киткән иде.

Аш өлгермәгән булгач, кергәч кулына төшкән бер журналны ачып укымакчы булган иде. Моның бәхетсезлегенә каршы, шул биттә үк «Ишанизм и его последствие» исемендәге мәкаләгә күзенә ташлангач, бөтен журналны йотардай булып укырга тотынган иде. Мәкалә озын иде, төрле яктан каралган иде, ишанлыкның Һиндстан мәҗүсиләреннән исламнар арасына кайчан керүе, вә бигрәк болгар арасына ничәнче гасырда керүе, исламнарга шуның никадәр зарар итүе, бигрәк болгарларга ничек тәэсир кылуы — һәммәсе язылган иде. Мөхәррирнең сүзенә караганда, болгарларның инкыйразына асыл сәбәп шул иде, чөнки шулкадәр гайрәтле, эшлекле, тырышчан болгарларны бернигә ярамаслык ялкау сыер төсле, хәйванлык дәрәҗәсенә төшерергә ишаннар гына сәбәп булган иде, вә алардагы ут кебек гайрәтләрне сүндерергә шул зәкәрләр[16] башчы булган иде. Шулкадәр тырышчылык вә эшчелекне бетерергә, алар тарафыннан дөнья кую хакында булган сүзләр юлчы булган иде..........

«Әмма бу болгар шаннары, болгар голәмаларында, боларның диннәрендә руханият[17] дигән нәрсә булмаенча да торып, халыкның шулкадәр боларның курайларына биюләрен ,һич тәүҗия[18] кылырга мөмкин түгел, белмим, болардагы голәмалар бик хәйләкәр булганмы? Әллә, вакыйган да, боларның ишаннарында гипнотизм* куәсе булганмы? Ни булса да, болгарларга болар кадәр зарар иткән сыйныф булмаган!!!»— сүзләре берлән мәкаләсен бетергән иде. Җөгъфәр әфәнде тагы ни эшләргә белмәенчә: «Ярабби, ник мине бу көнгә калдырдың? Ник ичмасам унтугызынчы гасырның бер голәмасын гына булса да шул көннәрне күрергә калдырмадың?»— дип уйлаган иде. Һәм шуның артыннан ук яшел чапан кигән, борчак чүмәләсе төсле, төрле якка ишелгән чалма кигән, сыерылган балтырлы читектән, өстәге төймәләре чишелгән бер кеше: «Шәригать! Шәригать!»— дип, күз алдында күренгән кебек булды. Җәгъфәр әфәнде моның кыяфәтенең кабахәтлегенә, иткән хезмәтләренең начарлыгына чыдый алмаенча: «Үтерәм! Син генә бетердең»,— дип барса да, теге хәзрәт һаман: «Шәригать! Шәригать!»— дип кенә бара иде. Җәгъфәр әфәнде йодрыгын төенләп артыннан бара иде. Шул уйлардан «Аш әзер!»— дигән тавышка уянып киткән иде. Бу уйлардан котылыр өчен, башын селкеп ашарга тотынган иде, һәм дә моннан соң Оренбургка барып җитмәенчә газитә-журнал, хасыйль[19], әдәби бер нәрсә укымаска кистереп куйган иде. Һәм дә Җәгъфәр әфәнде кеше берлән катышудан да кача иде. Чөнки катышса, танышса, хәзер кем икәнлеген әйтү, үзенең болгар икәнлеген белгертү тиеш булачак иде, ул әллә никадәр сүзләр ачарга сәбәп булганга. Җәгъфәр әфәнденең ярасына кызганган булып тоз сибүләр булганга, аны табигый яратмый иде. Шуның өчен пароходта вакытта бер мәртәбә дә тышка чыкмаска булган иде. Һәм үзенең вак-төяк эшләре берлән шөгыльләнеп, шул болгарның бетү мәсьәләсен онытырга ни дәрәҗә тырышса да, авыру кешегә һәрбер сүз, һәрбер эш, хәтта исән кеше, авыру кешенең һәммәсе дә шул авыруын исенә төшергән кебек, Җәгъфәр әфәндегә дә пароходның үзеннән башлап звонoклары, чынаяклары, чәйләренә кадәр, рояльләре, пароходның

---

16. Зәкәр — ирлек әгъзасы.

* Кешенең ихтыярын үзеннән алып һәр эштә гипнотизм хуҗасына мотыйга (буйсыну) кыла торган бер куәтдер. Һиндстан мәҗүсиләре арасында күптән мәгълүм булса да, Европада соңгы гасырда гына кәшеф (ачу) кылынмыш.

17. Руханият — рухи байлык, шанлылык. 18. Тәүҗия — төшенү. 19. Хасыйль — кыскасы.

исеме, ята торган урыннары — һәммәсе шул болгарның бетүен кычкырып торган кебек булалар иде. Самарга барып җиткәч тә Җәгъфәр әфәнде, тагы бер зур кәефсезлек булмадыгы өчен, дөресе генә, болгар хакында язылган шундый кәефсез хәбәрләр, сөйләнгән сүзләрне укудан, ишетүдән тыелдыгы өчен иркенләп сулап йөргән иде. Самарның һавасы да яхшы, манзарасы да матур булганга, Җәгъфәр әфәндегә иң яхшы хиссият ачканча, Җәгъфәр әфәнде бик кәефле иде. Номерда, Казандагы кебек, мәдрәсә-фәлән булмаганга һәм дә мәсҗетләрне дә төрле-төрле бинага әверүгә очрамаганга, баргач та кәефе бозылмаган иде. Шулай кәефле генә, гәзитәгә карамаенча гына, мөмкин кадәр болгар мәсьәләсен уйламаенча гына чәй эчкәннән соң, шәһәр карарга чыкты. Самарның урамы буйлап барганда «һөнәр мәктәбе» дигән бер язуга күзе төште. Һәм дә шундагы бәгъзе ачык тәрәзәдән пар, нефть исе чыкканга, шак-шок тавыш ишетелгәнгә, Җәгъфәр әфәнде моны чынлап-чынлап карый башлады. Стенадагы караланып беткән корымнар берлән күмелер-күмелмәс кенә тора торган бер рамкада әллә нинди болгар язуы кебек нәрсә күрде. Бу язу Җәгъфәрне тагы әллә нишләтеп җибәрде. Җәгъфәр күргән уңайга ук тәрәзәдән чак сикерми калды. Бик тиз капкасын табып, бер сүз әйтмәенчә, сораганга җавап бирмәенчә, ашыга-ашыга кереп китте. Һәм эшләүчеләрнең сорауларына да илтифат кылмаенча, дөресе генә, аларның тавышларын ишетмәенчә, үзләрен күрмәенчә, машиналар, станоклар аша сикерә-сикерә барып, шул язуга барып җитте. Болгар язуы икәнен белгәч тә, укыр өчен кулы белән сөртте дә укырга тотынды. Зур хәреф берлән башына «Дәрес тәртибе» дип язылган иде. Моның астында көннәр һәм һәр көнне нинди дәресләр барлыгы язылган иде. Дәресләр арасында Кафия, шәрхы мулла, исагуҗи, шәмсия, тәһзиб, сәләмеголум, хикмәтелгаен, мохтасар кебек сүзләр язылган иде. Бу әүвәл «дәрес тәртибе» дигәч тә, дәрес программасы дип уйлаган иде. Бу ят сүзләрне күргәч, исе китеп калган иде, чөнки ул «дәрес тәртибе»ндә ни көнне ни фәннән дәрес булачагын аңлатуларын көткән иде. Монда һичбер фән исеме юк иде, бу белмәгән, әллә нинди гарәпчәме, әллә чыгтайчамы сүзләр генә күрә иде. Бу болгар язуы булганга, болгарлардан калган әсәр булганга, хәзердә болгарлардан моннан башка варис[20] булмаганга, бу нәрсәләрне алу аның хакы икәнлеген юридический яктан уйлап тормаса да, болгар әйберләрен күргәч тә, аның кулы ихтыярсыз аңарга сузыла һәм, кеше булмаса, алына, кеше булса, акча-фәлән биреп тә алына иде. Бу язу да табигый алынган иде. Ләкин эшләүчеләр әүвәлдә моның вакытсыз керүенә бик гаҗәпләнеп, янына җыелып сораша башласалар да, боларның бер сүзләрен дә ишетмәенчә һәм күрмәенчә, сораган сүзләренә җавап бирмәенчә, язуны гына алуын күргәч, таңга калганнар иде. Һәм дә боларга бер сүз дә дәшмәгәнгә, бәлки бер зур кешедер, бәлки шулай кирәктер дип, моңарчы болар күзенә чалынмаган бер әллә нинди язуны алар да артык әһәмият тапмаганга, катып калсалар да, моны тыймаганнар иде. Җәгъфәр әфәнде, чыгып китеп, бик тиз номерына кайтып, моны укырга һәм аңларга тотынды. Һичбер төшенә алмады. Әллә нинди лөгать[21] китаплары актарды, «исагуҗи» сүзен таба алмады. «Шәрхе мулла»-да[22] мулла ни дигән сүз, шәрех ни дигән сүз икәнен белсә дә, бу ике сүздән мөрәккәб[23] бер нәрсә нинди фәнгә исем булуын белми иде. Кафиянең гарәпчә ни дигән сүз икәнлеген белсә дә, тагы болгарлар тарафыннан нинди гыйлем, нинди фәнгә исем икәннеген ишеткәне дә юк иде. Китаплардан ни эзләсә дә, тапмый иде. «Шәмсия»се тагы ни дигән сүз?.. Ахырдан уйлый-уйлый, төрекләр зонтикка

20. Варис — мирас иясе.

шәмсия дигәнгә, зонтик ясау хакында бер фән, яисә шул хакта язылган бер китапка исем булуына уе китте. Ләкин ни дип ул анда, дәрес арасына кергән?.. Шул фән укылганмы?.. Һич җавап бирер хәл юк иде. Бәлки шулай булса булыр шул. Самар мөселманнарының тормышлары хакында, нинди һөнәрләр белән эш итү, нинди кәсепләр берлән мәшгуль булуы хакында язылган китапны укыса да, анда: «Мондагы болгарлар ат берлән йөк ташыйлар иде. Кай вакытта бу йөкләрне хуҗа кушкан җиргә илтү авыр булганга, үз йортларында гына туктыйлар»,— дип язылган иде. «Сәләм, тәһзиб» дигән сүзләрне тагы аңлый алмады. Гарәпчә сөлләм — баскыч икәнлеген белгәнгә, Җәгъфәр әфәнде монда язылган нәрсәләрнең һәммәсе пожар әйберләре булырга кирәк дип, аз гына бер хөкем чыгармады. «Тәһзиб» дигән сүзе тагы нәрсә?.. Монысын озак уйламады. Болгарларда унтугызынчы, егерменче гасырларда «Тәһзиб» әхлакка хезмәт итәмез дип, авызы ачыграклар кесәләр тәһзиб[24] кылган бер төрле халык булуы хакында тарихта һәм дә шул хосуста бер романда укыганга, аны бик тиз аңлады. Бусы тагы фикерне икенче якка борды. «Әллә болар никадәр бергә тора торган кешеләрнең үзләренең кешеләрен язып куйган кәгазьләре микән?»— дип уйларга тотынды. Алай дисә, көн исемнәре нәрсәгә?.. Аптырады, бетте, ахырдан күңеленә унтугызынчы-егерменче гасырда җеннән сакланыр өчен бөтиләр тагу гадәт булуы һәм дә өйләрдә шундый бәлаләрдән саклый торган догалар, тылсымнар асу могтәбәр[25] булуы исенә төште дә, бу да вакыты берлән шул җеннәрдән саклар өчен язылган «мөкселмина, чүпримә, тупрата, ямлиха» кебек мәгънәсез сүзләрнең берсе булырга кирәк, дип хөкем кылды. Ләкин «дәрес тәртибе» дигән сүз бу моталәганың[26] бик дөрес түгеллеген уйлата иде. Ахырдан арып беткәч, үзенең башка эшләре дә исенә төшеп, китәргә дә вакыт икәнлеген уйлап, китәргә әзерләнде һәм китте. Юлы тагы «һөнәр мәктәбе»ннән үтәргә туры килде. Күзе югары төште. Язылган язуына караганда, бу йортның әүвәл асты — мәдрәсә, өсте — мәсҗет икәнлеге һәм дә егерме биш елдан бирле, халык бөткәнгә, һөнәр мәктәбенә әверелгәнлеге күренеп тора иде. Җәгъфәр ни әйтергә дә, ни уйларга да белмәде. Ут чыккан кебек, авызыннан ничә еллар никадәр кешеләрне эшкә яраксыз итеп чыгарганнан соң, инде тәүбә кылган икән?!! — диде һәм шул вакытта ук кылт итеп әлгәреге болгарларда фәннәр укылмавы, төрле фәннән, төрле гыйлемнән төрле китапларның (дибаҗә[27]) башлары гына укылуы исенә төште дә, теге язуның да шул китапларның исеме икәнлеген белде. Һәм кырмыска оясына төшкән елан кебек, кая барса да, үзенә тынычлык юклыгын уйлап, тизрәк вокзалга барып, Оренбургка китте. Тагы Җәгъфәр әфәнде бер тынды. Ләкин Сакмар суыннан үтү Җәгъфәр әфәндегә бик авыр булды. Чөнки бу Сакмар моннан ничә йөз еллар болгарларның яртысын суы берлән туйдырганлыгы кебек, буйларының матурлыгы берлән болгар табигатенә әллә никадәр ләтафәт[28] биргән иде. Һәм дә бу су чын болгар калебеннән чыккан, әллә кай җирләрдән чеметтереп-чеметтереп ала торган «Сакмар» көен исенә төшергән иде. Бу уйларны уйлаганда поезд никадәр ашыкса да, Җәгъфәр әфәнденең уе аннан ашыга иде. Күзләреннән тәгәрәгән энҗе бөртеге кебек яшьләре ашыга-ашыга, Сакмар суы кебек тиз-тиз йөзеннән агалар иде. Һәм тагы ябылган «болгар» мәсьәләсенең ябуын, үзләренең тозлары берлән эреткән кебек, төрле яктан ача гына баралар иде. Ул ачылган саен аянычлана иде, аянычланган саен аның күз яшьләре күбәя иде.

---

21. Лөгать — сүзлек. 22. «Шәрхе мулла»— гарәп теле морфологиясе дәреслеге. 23. Мөрәккәб — кушылган. 24. Тәһзиб — чистарту.

Озак үтмәде, Җәгъфәр әфәнденең күз алдында Оренбург килеп чыкты. Җәгъфәр әфәнде ат алып, теге бабай ята торган больницага илтергә кушты. Барып җиткәч тә, тиз ашыгып керә башласа да, моны туктаттылар. «Ни кирәк?» — дигән сүзгә каршы бу шул кешенең исемен әйтсә дә, «Кичә үлде һәм күмелде», — диделәр. Җәгъфәр әфәнде, башына суккан кебек, борылды һәм чыга башлады. Бәхетсезлегенә каршы, күзләре вывескага төште. «Хөсәенев борадарләренең мәдрәсә вакыфы»[29] дигән сүз өстендә «больница» дигән сүз күренеп тора иде. «Хөсәеневләр, Хөсәеневләр», — дип Җәгъфәр әфәнде катты да калды. Ул болар турысында бик күп нәрсә укыган иде. Боларның халыкның уяныр вакытында, зур дәүләт иясе булып, халык өчен әллә никадәр акчалар тотып, әллә никадәр мәдрәсәләр, мәктәпләр ачуын да белә иде.

Оренбургта «яңа мәдрәсә» дип ачып, иске мәдрәсәләрдә дә укытудан чыккан фәннәр укыттыруларын һәм дә, никадәр расход тотып, әллә никадәр кешеләр китереп укыттырып, тәртипсезлек, уйлаусыз эшләнүе хакында, милләткә әллә никадәр зарар итүләре тугрысында да укыган иде. Эшләре әсаслы[30] булмаганга, үзләре үлгәч тә, һәммәсе беткән дә киткәнлеген дә белә, мәдрәсәләре бетмәсә дә, әүвәлдән никадәр кешеләрнең кесәсен тутыру берлән, ашар-эчәр өчен алданып килгән балаларның да сәламәтлеген бетерергә һәм башларына гыйлем урынына үрмәкүч оялары тутыруга сәбәп булып, милләтнең китешенә бу кешеләрнең аркылы салган киртә булулары хакында бик күп нәрсә укыган иде. Һәм дә болар хакында язган мөхәррирнең: «Хөсәеневләр милләтне сөйделәр, хезмәт итәчәк булдылар, акчалар сарыф кылдылар. Ләкин ни файда иттеләр? Аю үзенең дустын чебеннән саклаганда, ни файда итте — болар да шуны иттеләр», — дигән сүзе исенә төште. Һәм дә, вакыйган, бу сүзнең дөрес икәнлеген белде. Ләкин белеп тә ни булды? Тагы хәсрәт яңарды!! Ул ихтыярсыз: «Бәхетсез милләт! Ник синең бер дә бәхетең булмады?! Ник сиңа һәммә эш тирес килеп торды? Кирәкле кешеләр вакытсыз үлделәр. Кирәксез кешеләр, синең китешеңә зарар итә торган кешеләр, әллә никадәр яшәделәр. Кирәкле кешеләр, сиңа хезмәт итә торган кешеләр, синең дошманың күрелделәр, мөмкин кадәр аларны күздән төшерергә, аларга юл бирмәскә тырыштылар. Сиңа дәвамың өчен кирәкле эшләр һичбер илтифатка алынмады, синең йөгеңне авырайта торган йөкләр тагылды, сиңа зарарлы һәммә кешеләр сиңа файдалы иттереп күрелде, байлары шуларга ярдәм кылдылар, фәкыйрьләр итагать кылдылар, һәммә эш һәр нәрсәдә һәрвакыт кирәкмәс якка куәт алды. Ник алай булды?! Кем гаепле моның өчен? Кем?!» — дип уйлаган иде. Һәм бик озак бу бинага карап торганнан соң: «Бу бина, бу мәдрәсә, бу вакыфлар яһүдиләр, әрмәннәрдә булса иде, моннан нинди файда иткән булырлар иде. Моннан нинди кешеләр чыгарырлар иде, милләтләренә ни хезмәтләр итәрләр иде?» — дип, аларның кылачак эшләрен бик озак уйлагач, номерга китте. Һәм анда барып ашап-эчкәч тә, юлда тузанланып беткәнгә, мунчага барырга уйлады.......... Ул шул кешеләрнең*: «Төпсез эштән мәгънә чыкмый», — дип аларга сөйләгәндә, «Аллага тапшырган!» — дигән сүзләренең хәзер мәгънәсен уйлый иде.

Һәм дә хәзер ул кешеләргә ул сүзнең дөресме-түгелме икәнлеген күрсәтәсе килә иде. Шул уй белән мунчадан чыкты. Өйгә кайткач, Оренбург тарихын укый башлады. Халыкларының табигате тугрысында: «Болар Казан болгарларына беркатлылык берлән мәшһүр иде. Һәм дә боларда хәмияте миллия[31] дә Казан болгар-

---

25. Мөгтәбәр — игътибарлы, хөрмәтле. 26. Моталәга — уку, өйрәнү, эшне тикшерү. 27. Дибаҗә — китапта кереш сүз. 28. Ләтафәт — гүзәллек, матурлык. 29. Вакыф — җәмәгать файдасына бирелгән милек. 30. Әсас — нигез.

ларына караганда артыграк иде. Боларда гожеб[32] тә Казан болгарлары кадәр үк түгел иде. Боларда голәмага нәзар башка булган булса иде — аларга әллә нинди, алла тарафыннан җибәрелгән кешеләр кебек күреп, әллә нинди голәмаларның авызлары тарафыннан чыгарылган «фатиха»га ышану шул дәрәҗә куәтле булмаса иде, һәм дә эшләргә тиеш эшләрнең кирәклеген белгәннең соңында, «Ийе, кирәк иде»,— дип, авырсынып калдыру булмаса иде. Һәм шул авырлыкка сәбәп була торган бөтен болгар тарихында күренә торган бик майлы пылаулар, симез итләр ашау, һәр мәсьәләдән дә ашау мәсьәләсен артык күрү булмаса иде,— болар шөбһәсез тәрәккый итәчәкләр иде»,— дип язылган иде. Икенче җирдә монда бик хәмиятле кешеләр булуын һәм күп хезмәтләр итүләрен дә укыган вә аларга халыкның ничек карауларын да белгән иде. Тарихның сүзенә караганда, Оренбургның шулай бетүенең сәбәбеннән берсе монда кием мәсьәләсенең бик патшалык сөрүе, яхшы кеше берлән начар кеше казакиының чабуы берлән аерылуы, һәм дә хатынкызга һичбер гыйлем, һөнәр, тәрбия, хөррият бирелмәве иде. Оренбург тарихының рәсемнәре, арасында «Кәрвансарай мәсҗете» һәм «Кәрвансарай манарасы» бар иде. Моның кайчан бина кылынуы, ник салынуы хакында укыгач та, бу мәсҗетне күрәсе килде һәм ат алып, кәрвансарай тарафына китте. Манара һаман манара иде. Манараны, яңа гасыр якын булганга, болгарларның тәмам мөнкарыйз булуларын игълан кылына торган көн тиз булганга, болгар тарихына хезмәт итә торган нәрсәләрне, болгар әсәрләрен һәммәсен төзәтәләр, карыйлар иде... Мәсҗеткә «Болгар китапханәсе» дип язылган иде. Керде, китаплар карады — бик күп китап күрде, бик күбесен карады. Ләкин һичберсеннән риза түгел иде. Боларның һичберсе болгар тарафыннан язылмаган иде. Һәммәсе дә, бер авыздан чыккан кебек, дин китаплары гына иде. Җәгъфәр әфәнде: «Ник болар шул ахирәткә ышануларының йөздән бере кадәр генә дөньяга да ышанмаганнар? Ник болар ахирәткә шулкадәр тырышканның меңнән бере кадәр генә дөньяга да тырышмаганнар?! Болай булырлар идемени?»— диде дә, тагы күзләреннән яшь агарга тотынды. Чыканда гына «Әдәби, фәнни китаплар» дигән сүзгә күзе төште һәм бер якта өелгән, Оренбург болгарлары тарафыннан язылган әдәби, фәнни китаплар күрде. Боларны карады, күзен сөртте, тагы еглады, бик озак боларның баягы хәез[33] — нифас[34] хөкемен өйрәткән китапларга караганда азлыгын күреп, тагы бу болгарларның дөньяга әһәмият бирмәүләре хакында уйлаган сүзе башына килде. Тагы: «Ийе, дөньяны карамадылар, кайгыртмадылар, ахирәт артыннан гына йөрделәр, шуның өчен ахирәткә киттеләр, беттеләр!!»— диде дә, бик тиз генә чыкты да тагы башка мәдрәсәләр, башка мәсҗетләрне караса, моннан да авыр булачагын белгәнгә, номерасына кайтып китмәкче булды. Үзенең ни өчен килгәнлеге исенә төшеп, теге бабай мескенне күрә алмый калуын уйлап, аңарга ичмаса бер эш эшлим, дип, таш яздырып куймакчы булды. Һәм дә: «Оренбургтагы актыккы болгар Хуҗасәеткә бөтен болгар җирендә ялгыз калган актыккы чын болгар Җәгъфәрдән бөтен болгар йортындагы актыккы таш, болгар зыярәтендә актыккы яшь!»— дип яздырган иде. Бу ташны Җәгъфәр үз кулы белән куйды да туры ук вокзалга төште. Поезд китәргә ярты сәгать вакыт булганга, «Сакмар» исемле Оренбург газетасын укый башлады. Троицкидан бик озын мәктүп бар иде. Җәгъфәр Троицк дигән сүзне күргәч тә, катты да калды. Бу сүз моның бөтен тамырларыннан әллә нинди салкын су койган кебек ясады. Тиз

---

31. Хәмияте миллия — милләтне саклау. 32. Гожеб — масаю.
* «Ул шул кешеләрнең», дип башланган җөмлә, алда кыскарту булганга күрә, аңлашылмый.
33. Хәез — күрем. 34. Нифас — бала табу. 35. Мәсгуд — бәхетле.

генә укый башлады. Ни бар?! Әллә унтугызынчы гасырның ахырында, егерменче гасырның башында шулкадәр шаулаган Троицкида тагы бер тәрәккый хәбәреме?! Тәрәккый хәбәре!!..........

Вокзалдагы халыклар да тиз-тиз йөри башладылар. Җәгъфәр әфәнде дә тиз генә уянып киткән төсле булып, поездга утырды һәм дә, күзен югары таба күтәреп караса, тагы болгар бетүен белгертә торган бер нәрсә күренер дип, башын астан күтәрмәде. Юлда әллә нинди эшләр булмаенча гына Казанга кайтып җитте. Теге вакыттагы номерасына барып керде. Бөтен номера халкы моның югалуына гаҗәпкә калып, эшне полициягә мәгълүм иткәннәр икән. Һәм дә һәр җирдән Җәгъфәрне эзләргә тотынганнар икән. Бу хәбәрне газитәдә укып, Сөембикә дә, ирем югалды микәнни дип, Казанга белешергә килгән икән. Җәгъфәрне иң әүвәл күрүче Сөембикә булды. Ул күрү белән муенына сарылды, аңарга ире үлеп терелгән күк булганга, ни кыланасын белми иде. «Кая киттең? Ни булды?» сөальләрен сорарга теләсә дә, шундый мәсгуд[35] вакытта бер-бер кәефсез җавап алырмын дип, сорамаенча гына Җәгъфәрне: «Җәгъфәрчегем, җаным! Җаным!» — дип сөяргә тотынды. Җәгъфәр үзе дә, Сөембикәне күргәч, баягы эшләренең һәммәсен оныткан иде. Аңарда да Сөембикәгә мәхәббәт тагын ялкын кебек яна башлаган иде. Аның болгарча сүзләре, кара кашлы, кара күзле, кара туткыллы йөзләре Җәгъфәр әфәндегә башка хиссиятләр уяндырган иде. Аның күргәннәренә, ишеткәннәренә яисә болгарлар беткән дип уйлаганнарына хәзер үзе дә ышанмый башлаган иде. Сөембикәнең һәрбер әгъзасы, күз караулары: «Юкны сөйләмә, бетәмени соң бу кара күзләр, бу урак төсле кашлар, бетәме соң? Бетми, бетми, монда мин бар ич»,— дигән кебек була иде. Сөембикә иренең бүлмәсенә төшкәнгә, бу да шунда ук төшкән иде. Сөембикә шатлыгыннан ни кыланырга белми иде. Аның һәрбер әгъзасы көлә иде. Ул кайдан тотып башларга белми иде. Ул Җәгъфәрне озак кына карап тора иде дә тагы «җаным» дип барып кочаклый иде. Җәгъфәр үзе дә шат иде. Ул моңарчы Сөембикәдән хат-фәлән алмаганга һәм дә аның турысында бер дә уйларга туры килмәгәнгә, ул үзен бөтен болгар йортында ялгыз дип белеп йөри иде. Сөембикәнең тугры килүе аны йокысыннан уяткан иде, ул үзен мәсгуд дип хис кыла башлады, көләргә тотынды, сөйләргә тотынды. Сөембикәне сөяргә һәм аңардан сөелергә тотынды. Сөембикә Җәгъфәрнең иң ярата торган «болгар коймагын» китертеп, чәй дә әзерләде һәм чәй янында егерменче гасырда болгарларның бер театр уенын алган пластинканы куеп, граммофон уйната башлады. Җәгъфәр әфәнде үзен тагы болгар галәмендә, һәм дә тәрәккый иткән театрлы болгар галәмендә хис итә башлады. Граммофонга болгар музыкасы кушылды. Җәгъфәр әфәнде тагы ачылды, тагы кәефләнде. Сөембикә дә чыдаша алмады, болгарча җырларга тотынды; болгар операларыннан заманасында мәшһүр «Үги кыз» операсыннан озын бер монолог җырлады. Аның артыннан «Сөембикә» исемле бер тарихи операдан җырлады. Җәгъфәр әфәндегә болар һәммәсе шулкадәр тәэсир кылды, ул чыдаша алмады, Сөембикәне тотып үпте дә: «Яшәсен болгар!» — дип кычкырды. Бу тавыш Җәгъфәр әфәнденең үзен дә йокыдан уяткан кебек булды. Ул: «Нинди болгар яшәсен? Ничек яшәсен? Баягы мәдрәсәләре, больница, мәсҗетләре, дарелсанагатьләр[36] булган болгарлар яшәсенме? Баягы минем актыкка болгарга актыккы таш куйган болгар яшәсенме?» — дип үзенә үзе сөйләнергә тотынды. Үзенең бу хәзерге кәефләре бер ялган гына икәнлеге, хәзер шулай иттереп торырга дөньяда болгар юклыгы, Сөембикәдән башка, тагы ике кулыңа уникe шәм тотып эзләсәң дә, бер болгар табылмавы исенә төште. Һәм үзенең болай кәефләнеп, бөтенләй мөнкарыйз булмый торган бер милләт кешесе кебек булуына нәрсә сәбәп булуын

уйларга тотынды. Ахырдан аны теге фикерләреннән күчереп бу уйның төшүенә Сөембикә сәбәп булуы, үзенең йомшак сүзләре берлән һәрбер әгъзасында күренеп тора торган хәйвәт[37] галәмәте берлән тормышка өмет бирүләре хәтеренә килде. Һәм дә болгар хатыннарының шундый фикерне борырга, башка халык хатыннарына караганда артык кабилиятле булулары, шул артыклыклары берлән күп вакытта кирәкле эшләрне оныттырып калдырулары исенә төште. Һәм дә әгәр дә аларга егерменче гасырларда тәрбия бирелгән булса, бөтен болгарның китешен икенче якка борган булырлар иде,— дип бераз уйлап торганнан соң: «Әйе, булырлар иде, болгарлар бөтенләй башка болгар булыр иде»,— диде.

Җәгъфәр әфәнде Сөембикә белән Казанда берәр атна торганнан соң, һәм бәгъзе вакытларда тагы милләт тәрәккый итәр кебек булып, тагы хакыйкать искә төшеп җимерелгәннән соң, үзләренең утарларына кайтып киттеләр. Җәгъфәр бу китүендә хәбәрсез-нисез бик озак йөргәнгә, Петербургка барганда Сөембикә бергә барачак булган иде. Шуның өчен Җәгъфәр Петербургта егерменче гасырдагы болгар киемен киеп бару фикеренә килгәнгә, музейлардан формаларын алып, иске болгар рәсемнәреннән карап, Сөембикә Җәгъфәргә дә, үзенә дә киемнәр тегәргә башлады. Һәм әллә ничә тегеп, әллә ничә сүтеп төзәткәннән соң, казаки да, камзул да, җилән дә текте, ләкин киемнәре шундый булдылар — әгәр миллият[38]-фәлән дигән нәрсә булмаса, мотлак киярлек түгел иде. Үзләре киң, үзләре килешсез, үзләре кыйммәт төшә иде. Шуннан соң Җәгъфәр дә егерменче гасыр болгарларын «киемнәрен ташлаганнар» дип сүгүдән туктаган иде. Сөембикәгә хатын-кыз киеме тегүе авыр булмады. Ул вакыттагы мода, ул вакытта мәгариф, мәдәниятнең мәркәзе[39] Пекин булганга, Пекин модасы егерменче гасыр болгар хатыннарының күлмәкләренә бер дә башка түгел иде. Шуның өчен аны тегү бик җиңел булды. Калфак никадәр үзенең үлчәвен кечерәйтсә дә, егерме икенче гасырга кадәр бетмәгән иде, хәтта егерме беренче гасырда болгарлардан русларга кереп, алардан бөтен Европага күчеп, Европада патшалык та сөргән иде. Шуның өчен һәммә җирдә мәгълүм иде. Фәкать Җәгъфәр әфәнде, Европа хатыннары кигәнчә, бер кечкенә генә чәчәк иттереп кенә куйдырасы килмәгәнгә, бераз икенче төслерәк булачак иде. Киемнәр өлгерде. Ноябрь дә керде. Җәгъфәр әфәнде дә әзерләнде. Тарих җәмгыятендә укылачак әсәре русча да тәмам булды. Китәр көн якынлашты. Җәгъфәр әфәнде тәмам җыенып бетсә дә, Сөембикәнең тәмам әзер булганы юк иде, аның авыры (корсагы) барга, исәп белән, ул баладан котылгач китәчәкләр иде. Сөембикәнең исәбе дә егерменче ноябрьдә тулачак иде. Җәгъфәр дә шул көнне котәчәк, аннан соң Сөембикә бераз сәламәтләнгәч, ноябрьнең егерме сигезләрендә китәчәкләр иде. Егермесе җитте, егерме бере җитте, егерме бише җитте, бала һаман юк иде. Җәгъфәр әфәнденең эче поша башлады. Сөембикә дә, иремнән калырга туры килә, дип эченнән генә кайгырса да, Җәгъфәргә белдермәскә тырыша иде. Шуның өчен берәр көн ялгыштым, күрәсең, менә шул арада булыр инде, дип аны һаман җуата иде. Ләкин бала һаман юк иде. Җәгъфәр чыннан ук кайгырырга тотынды. Ноябрьнең егерме җидесендә китәргә ике генә көн кала башлады. Шул көндә бала туса, бәлки докторлар иҗтиһады[40] берлән барырга да ярар иде. Аннан да калса, Сөембикәнең бара алуында шөбһәләнә башлады. Докторлар китереп караттылар. Тәмам утызынчы ноябрьдә туачак, диделәр. Хәзердә Җәгъфәр белән Сөембикә бергә бара алмаулары беленде. Җәгъфәр егерме

---

36. Дарелсанагать — һөнәр йорты, предприятие. 37. Хәйвәт — хәят, тормыш, тереклек. 38. Миллият — миллилек. 39. Мәркәз — үзәк.

тугызында үзе генә китмәкче булды һәм, Сөембикә баладан котылгач, барырга кушып китте. Сөембикә бик барасы килгәнгә, җәмгыятьтә укыр өчен болгар хатыннарының мәгыйшәтләре[41], бала тәрбияләре, ирләренә нисбәтләре, киемнәре, гадәтләре хакында бер рисалә дә язган булганга, аның да вакытында укылмый калуына бераз эче поша иде. Җәгъфәр җәмгыятьтә эшнең ничек икәнлеген тәмам аңлатырга һәм өч-дүрт көннән соң сөйләнә торган речьләр, болгарлар хакында була торган докладлар арасына Сөембикәнең речен дә яздырырга кушты. Сөембикә бик моң гына Җәгъфәр белән күрешеп, хәтта күзләреннән яшьләр дә мөлдерәтеп, Казан вокзалында калды. Җәгъфәр шул көнне үк барып җитте. Юлда бер дә башын чуалтырлык нәрсә булмады. Москва мөселманнары хакында бәлки хәбәр алган булса, яки Москвадагы галереяга кереп, унтугызынчы, егерменче гасырлардагы Москва болгарларының аркаларына дүртбиш пот әйбер күтәреп, сатып йөрүләренең рәсемен күрсә, яисә «Иске тавышлар» музейсына кереп, аларның, «Старья бирум!», «Шара-бара!!» — дигән тавышларын ишетсә, ябылып яткан хәбесе[42] тагы уяныр иде. Ләкин шулай буласын белгәнгә, Җәгъфәр әфәнде анда төшмәгән иде. Петербурга туп-туры киткән иде. Петербурга төште. Тарих җәмгыятенең рәисе берлән (килгән) кешеләр һәм Петербургның башка халкы берлән, хатыннары берлән бөтен вокзал тулган иде. Юлда килгәндә болгар киемендә булмаса да, Петербургка җитәр алдыннан болгар киеменә киенгән иде. Җәгъфәрне күрү берлән бөтен халык моңарга таба килә башладылар. Тарих җәмгыятенең рәисе кулыннан кысып күреште һәм дә Сөембикә килә алмавын бик аяды. Башкалар да сәламләштеләр, Җәгъфәр әфәндегә төрле яктан чәчәк ата башладылар. Бөтен дөньясын чәчәк берлән тутырдылар, Җәгъфәр әфәнде чәчәккә аз гына күмелмәде. Һәммә җирдән: «Яшәсен Җәгъфәр, яшәсен Сөембикә!» — дигән тавышлар ишетелә башлады. Һәммә кеше Җәгъфәргә якынрак килмәкче була иде. Һәммә кеше Җәгъфәрне күрмәкче була иде. Һәммә кеше — Җәгъфәр берлән сөйли торган, хәтта кулларын кыса торганнары үзләрен бәхетле саныйлар иде. Хатыннарга Җәгъфәрнең кара күзләре, кара чәчләре, түгәрәк сакаллары гаҗәеп сабган[43] галәмнән кебек күренә иде. Аның төсе бик матур, бөтен кешене гаҗәпкә калдырырлык Йосыф гам[44] кебек беленә иде. Шуның өчен һәммә кешенең уенда, телендә Җәгъфәр генә иде. «Яшәсен» тавышы берлән бөтен вокзалны күтәрәләр иде. Җәгъфәр бу тавыш, бу тыгызлыктан көчкә котылды. Рәис берлән бер хатын аны каретага утыртып алып китә башладылар. Диңгез кебек халык тагы болар артыннан китте, «яшәсен» тавышлары тагы гөрләде. Озак үтмәде. Җәгъфәр әфәнде үзенә әзерләнгән йортка барып җитте һәм, китерүчеләрдән аерылып, истирәхәткә[45] мәшгуль булды. Бераз йоклаганнан соң моңарга тәгаен кылган хезмәтче поднос берлән бер куча хат, әллә никадәр визитная карточкалар кертте һәм, бер карточкага күрсәтеп, шул кешенең күптән көтеп торуын аңлатты. Карточкадагы исемгә караганда, «князь Гиреев генерал-мр[46]» иде. Җәгъфәр: «Боерсын», — диде. Генерал керде һәм дә исәнләшкәннән соң, үзенең «Болгар музыкасын химая»[47] җәмгыятенең әгъзасы һәм дә рәисе, җәмгыять тарафыннан Җәгъфәр әфәнде исеменә биреләчәк мәҗлескә аны чакырырга мәэмүр[48] икәнлеген бәян итте. Генералның әйтүенә карагандa, барырга вакыт җиткәнгә, элегрәк әйтә алмавы өчен генерал гафу үтенде. Җәгъфәр әфәнде барырга әзерләнәчәген вәгъдә кылып, үзенең әсәрләреннән бер китапны биреп: «Сезнең шуны укый торуы-

40. Иҗтиһад — тырышу. 41. Мәгыйшәт — тормыш. 42. Хәбес — ябып кую. 43. Сабигъ (сабган) — җиденче. 44. Гам — галәйһиссәлам. 45. Истирәхәт — ял итү.

ңызны үтенәм, мин берәр минутка гына сезне ялгыз калдырырга мәҗбүрмен»,— дип чыгып, киемнәрен рәтләп керде. Һәм генерал китапны куя башлагач: «Сезгә ядкәр булсын»,— диде. Генерал бик шатланып кабул итте. Һәм һәдиә[49] икәнлегенең мөмкин кадәр болгарча язылуын һәм үзенең исеменең язылуын үтенде. Җәгъфәр әфәнде үтенечне кабул итте. Ишектән чыктылар, Җәгъфәр әфәндене күрергә килгән урам тулы халык «яшәсен» тавышлары берлән каршы алдылар. Чәчәкләр берлән бөтен дөньясын тутырдылар. Җәгъфәр әфәнде баш иде һәм бер-ике сүздә рәхмәт укыды да, каретага утырып, генерал берлән китте. Кара болыт төсле халык тагы кузгалды, тагы «яшәсен» тавышы гөрләде, тагы шул халык диңгезе Җәгъфәр артыннан хәрәкәт итә башлады. Җәгъфәр әфәндене тагы урамда моның килүенә җыелып куйган халык «яшәсен» тавышлары берлән каршы алды. Аларның тавышларыннан, чәчәкләреннән көчкә котылып, мәҗлес өенә керде, һәммәсе бердән каршы алдылар, бик күп кеше берлән күрештеләр. Бик күп кеше берлән баш иеште, һәммәсенә рәхмәт укыды. Утырыштылар. Музыка тавышы ишетелә башлады. Җәгъфәр әфәнде ирләр, хатыннардан мөрәккәб[50] бер оркестр күрде. Музыка әллә нинди таныш музыка, әллә нинди тәэсирле иде. Җәгъфәр әфәнде бик тиз музыканың болгар музыкасы икәнлеген, егерменче гасырда мәшһүр бер болгар музыкантының «Уй» исемендә бер романсы уйналдыгын аңлады. Уен бетте. Бөтен салонда кул чабу тавышлары, «браво» тавышлары дөньяны күтәрде. Бераз вакыт үтте, һәммә кеше болгар музыкасы тугрысында сөйли башлады. Менә оркестрга скрипка берлән бер хатын чыкты һәм дә «Чегән хатыны» дигән болгар операсыннан бер романсны уйнады. Осталыгы, музыкасының тәэсирлеге берлән халыклар шулкадәр оедылар, залда бер кеше юк кебек, аһ дигән тавыш ишетелми иде. Музыка туктады. Баягыдан битәр кул чабарга (керештеләр), баягыдан битәр «браво» тавышлары чыгарга тотынды. Җәгъфәр әфәнде моның берлән шулкадәр тәэсирләнде, һич әйтеп бетерерлек түгел. Тагы музыкалар уйналды. Тагы тәбрикләр, тагы «браво»лар!

Озак үтмәде, аш бирелә башлады. Ашлар болгарларча әзерләнгән иде. Иң әүвәл салма, аның артыннан куллама, аның артыннан бәлеш бирелде. Аның артыннан башка ашлар китерелде. Аш арасында сүзләр болгар музыкасыннан болгар ашына күчте. Һәммәсе болгар ашын мактыйлар иде, куллама килгәч һәм дә рәис җәмгыять Җәгъфәр әфәнде хакына моның кул берлән ашалуын бәян кылды. Куллама дигән сүз дә кул белән ашаудан икәнлеген белдереп, әгәр кашык берлән ашасалар, болгар ашы булмавын сөйләде. Һәм дә болгарларда кул берлән ашый торган ашлар алдыннан кул юылуын сөйләп бетермәс борын, хезмәткәрләр кечкенә-кечкенә комганнар берлән кулларр юдыра башладылар. Болар һәммәсе мәҗлестә кылынды.

Рәиснең бу сүзенә һәммәсе каршылык кылмаенча, ул кушканча эшләделәр һәм куллама ашарга тотындылар. Ләкин куллама ашау бик авыр булды, бик күбесе бармакларын пешерделәр, киемнәренә майлар тамыздылар, кулларын буяп бетерделәр. Нә исә ашап бетерделәр, тагы кул юылды. Икенче ашлар килде, мәҗлес ахырына җитә башлады. Арадан бер кеше торды да сүзгә башлады (бу кешене Җәгъфәр әфәндегә Петербургтагы музыка академиясе мөгаллиме дип таныштырганнар иде). «Әфәнделәр, безнең мөкатдәс җәмгыятемезнең гаразы[51] болгар музыкасын саклау, аның ләтафәт табигасын[52] җуймау идеке һәркемгә мәгълүм. Без бу хезмәтне (тәкъдир) итәмез, үземезнең өлешемезгә шундый мөкатдәс хезмәт төштеге өчен, бик шатмыз. Һәрвакыт җәнабе хактан[53] шул хезмәте-

---

46. Мр — майор булса кирәк. 47. Химая — саклау. 48. Мәэмүр — йомыш үтәүче. 49. Һәдиә — бүләк. 50. Мөрәккәб — кушылган, җыелган.

мездә дәвам итәргә ярдәм итүен телимез. Безнең бу эшемезнең кирәклегендә һичкемнең шөбһәсе булмаса да, һәм дә болгар музыкасының галилеге хакында бераүнең дә шиге булмаса да, мин болгар музыкасының бу көннәр әһәмиятле көннәре булганга, хосусан, безнең арамызда безне үзенең безнең җәмгыятемезгә килүе берлән шат иткән Җәгъфәр әфәнде булганга, безнең болгар музыкасы хакында булган фикеремезне сөйләмәкче булам, һәм дә Җәгъфәр әфәндедән җәнабе галиеннән[54], әгәр безнең аңлавымыз ялгыш булса, дөресләвен үтенәм. Чөнки бер милләтнең милли музыкасын милли кеше кадәр һичкем аңлый алмыйдыр. Болгар музыкасы Европа музыкаларыннан бөтенләй башка. Европа музыкасы калебнең бер ягыннан чыкса, болгар музыкасы икенче ягыннан чыга. Европа музыкасы күңелгә бер яктан рәхәт бирсә, болгар музыкасы икенче яктан рәхәт бирә. «Болар кайсысы гали?» — дигән сүзгә мин җавап бирә алмыйм, минемчә болар икесе дә гали, икесе бер-берсеннән башка ярты гына, икесе дә бер-берсен камилли. Европада музыканың тәрәккый итүе, музыкамыз тәмам мөкаммәл дию, минемчә, болгар музыкасын без аңлый башлаган һәм дә аңардан файдалана башлаган көннән булырга кирәк. Болгар музыкасы унтугызынчыегерменче гасырларда артык моң, бик бертөсле, дип яманлана иде. Шуның өчен аңарга ул вакытта әһәмият бирелмәгән иде. Ләкин хәзер шул сүзләр, ягъни бик моң, бик бертөсле, дигән сүзләр мактау өчен әйтеләдер.

Аның моңлыгы үзенә бер ләтафәт бирә, безне үзе белән әллә нинди ерак-ерак истикъбальләргә[55] һәм дә үткән хисләргә алып китә. Безне егерме ел мөкаддәм[56] булган кешеләремез берлән, дусларымыз берлән күрештерә, сөйләштерә, ниһаять, еглаштыра, куркынычлы киләчәкләр, яхшы киләчәкләр арасындагы пәрдәне күтәрә, безне тагы анда илтеп куя, андагы эшләрне, андагы хәлләрне күрсәтә. Аның бертөслелеге безнең табигатемезгә мантыйкыйлык[57] бирә, фикерләремезне, уйларымызны акыртын гына йомшата, үземезгә сиздерерсиздермәс кенә үзенә кирәк якка алып китә. Аның моңлылыгын, бертөслелеген гаеп иткән кешеләр, сандугачның тавышын ишетеп, әтәчтән өйрәнергә кушкан кешеләр иде. Аларда музыканы аңлау, аның файдасын белү бик аз иде. Шуның өчен аларны гаепләргә дә ярамый. Болгар музыкасының бер артыклыгы, һәм дә, минемчә, иң әһәмиятле артыклыгы аның бөтен тамырлардан йөрүе һәм дә кирәкле җирләрен чеметтереп-чеметтереп алган төсле булуыдыр. Бу хисне аңлатырга сүз юк. Һәммәңез дә, әлбәттә, үзеңез татыгансыз! Болгар музыкасы бу хасыяте берлән һичбер вакытта үз исемен югалтмаячак, һәм дә болгарларның да йөрәкләреннән чыккан исемнәрен үзе берлән бергә кыяматкә кадәр алып барачактыр!»...... Бу сүзләргә тагы «браво» тавышлары берлән бөтен дөнья тулды. Мөгаллимне әллә ничә мәртәбә торып рәхмәт укырга мәҗбүр иттеләр. Җәгъфәр әфәндегә бу сүзләрне ишетү әүвәлерәк яхшы булса да, актыккы җөмләләре бик каты тәэсир кылды. Алай булса да, боларга каршы бер сүз әйтергә һәм боларның сүзләрен тәсдыйк[58] кылырга, йә тәнкыйть кылырга кирәк иде.

Бераз тавыш беткәч, Җәгъфәр әфәнде торды. Аның торуын күргәч, һәммә зал тып-тын булды. Һәммәсе дүрт колак берлән тыңларга әзерләнделәр. Җәгъфәр әфәнде акыртын гына, күзләреннән чыгарчыкмас яшьне тотып кына сүзгә башлады. «Әфәнделәр! Сезнең иткәнеңез хезмәтләр өчен, безнең үземез саклый алмаган музыкамыз-

---

51. Гараз— максат. 52. Ләтафәте табига — табигый матурлык. 53. Җәнабе хак — алла. 54. Җәнабе гали — өстенлек иясе. 55. Истикъбаль — киләчәк. 56. Мөкаддәм — элекке, әүвәлге. 57. Мантыйкый — логик.

ны сакладыгыңыз өчен һәм дә миңа хосуси шулкадәр илтифат кылдыгыңыз өчен бик рәхмәт! Сезнең бу хезмәтләреңез бик мөкатдәс. Сезнең безнең үзебез саклый алмаган музыкамызны саклавыңыз өчен, безнең музыкантларымыз, безнең бабаларымызның рухлары сезгә рәхмәт укыйлар, сезгә һәрвакыт ярдәм итәләр. Һәм дә сез безнең музыкамызны саклавыңыз белән безнең исемемезнең үзен-үзе саклый алмаган бер милләтнең исемен генә сакламыйсыз, бөтен дөньяга ничә мең еллар үткәч, болгарларның һәммә нәрсәләре беткәч тә, аларның исемләре дә югалгач та киләчәк торган миллионнар-миллионнар кешеләргә файда итәсез. Һәм дә үзеңезне исме мөкатдәсеңезне[59] кыямәткә кадәр калдырасыз. Болгар музыкасы хакында минем фикерем бәлки мөбаләгаледер[60]. Чөнки болгар хәмиятлесе булганга, миңа болгарның һәммә нәрсәсе башка халыкларныкыннан артык күренәдер. Шуның өчен минем фикерем тәнкыйтьне күтәрерлек булмаганга, музыка хакындагы фикеремне сөйләмим, фәкать шунысын гына әйтәм: минемчә, мөгаллим әфәнденең безнең болгар музыкасы хакында сөйләгән сүзе бик дөрестер. Аңарга үзләрен белмәгән, милләтләрен белмәгән, музыкаларын белмәгән бер халыкның музыкасы хакындагы бәяны өчен бик мөтәшәккирмен[61]. Тагы шуны гына әйтмәкче булам: болгар музыкасында моңлык, бертөрлелек, минемчә, болгарларның табигатьләренең моң икәнлеген, бетә торган халык икәнлеген белдерә торган бер хассасыдыр[62]. Бертөрлелеге болгарда тормышның бертөрлелегеннән, ягъни бу көнгесе кичәгесенә, кичәгесе өченче көнгесенә охшавыннан булырга кирәк дип уйлыйм. Бу сүзләремнең дөрес, дөрес түгел икәнлеге хакында һичбер низагым юк, мин музыкант булмаганга, музыка хакында минем фикерем унтугызынчы-егерменче гасырда тиречеләр, итчеләр гыйлем мәсьәләсенә катышу кебек булганга, ул мәсьәләне әһеленә[63] тапшырам, сездән шул мөкатдәс хезмәттә дәвам итүеңезне үтенәм! Үзе беткән милләтнең исеме югалмасын! Үземез беттек, әсәремез калсын! Үземез саклый алмаган эшне сезнең шикелле әмин[64], хыянәтсез милләткә бөтен бабаларымыз тарафыннан васый[65] булып сезгә калдырам, файдаланыңыз!.. Башкалар да файдалансыннар, чыгаручылар төсле булып музыкамыз бетмәсен!!» — диде дә, сөйләргә сүзе бик күп булса да, күзләренә бик яшь тулгач һәм тавышлары үзгәрә башлагач, утырды.

Моңарга да куллар чаптылар, моңарга да «браво» кычкырдылар. Сачәкләр ыргыттылар, ләкин болар һәммәсе дә Җәгъфәр әфәндегә мыскыл итү кебек күренә иде. Аштан соң тагы музыка башланды. Тагы болгар көйләре уйналды. Народный көйләрдән «Сакмар» көе һәм соңгы көйләрдән «Язмыш» дигән бер операдан романслар уйналды, һәм дә бер кеше белән бер барышня моңарга болгарча җырладылар. Җырлары да бик яхшы чыкты, ләкин әйтүләрендә руслык беленеп тора иде. Бу җырлар Җәгъфәр әфәндегә тагы бик каты тәэсир кылды. Озак үтмәде, болгарларның «Талныш» исемле операларыннан бер пәрдәсен синематографның мөкәммәле[66] берлән күрсәттеләр (ул вакытта алар бик мөкәммәл булганнар иде, бар эшләрне, хәрәкәтләрне, кыланышларны, тавышларны — һәммәсен күрсәтә беләләр иде). Талныш ролендә егерменче гасырда үзенең тавышы берлән дан тоткан Ләлә исемле кыз иде (бу кыз руслар арасында Лилия исеме белән мәшһүр иде). Ләләнең тавышларының яхшылыгыннан һәм Талнышның көрәшүләренең тәэсирлегеннән һич егламыйча торырлык түгел иде... Җәгъфәр әфәнде бара-тора бетә-

58. Тәсдыйк — раслау. 59. Исме мөкатдәс — изге исем. 60. Мөбаләгә — арттыру, күпертү. 61. Мөтәшәккир — рәхмәтле булу, кадерен белү. 62. Хасса — үзенчәлек. 63. Әһеле — иясе. 64. Әмин — ышанычлы. 65. Васый — васыять итүче.

бетә бу көнгә калуны уйлап, изелеп киткән иде. Аның артыннан болгар драмасыннан — «Теләнче кыз» дигән бер драмадан бер пәрдә күрсәттеләр. Моның күренешләре, өй җиһазлары, уенчыларның киемнәре һәммәсе болгарча булганга, Җәгъфәр әфәндегә боларны карау, үзенең милли драмасын актык мәртәбә күрү әллә нинди хисләр уяндырды: үлә торган кешеләрнең җан чыгар алдыннан балаларына, сөекле хатынына, зур музыкантларның музыка кораллырына күзләрен тутырып-тутырып караганы кебек карый иде. Боларга әллә нәрсә әйтергә теләгән кебек тә була иде, әллә нәрсә сорарга да теләгән кебек була иде, үзенең ни эшләгәнен белми иде. Бу мәҗлестән соң, бу кайгыларны яңартудан соң сәгать сигезләр булганга, сәгать унда тарихи җәмгыять тарафыннан яңа гасырны каршы алырга чакырылган булганга, Җәгъфәр әфәнде тагы бер мәртәбә җәмгыятькә рәхмәт укып, бик күбесе берлән күрешеп, җәмгыять тарафыннан бирелгән болгар музыкасын уйный торган машинаны алып, һәм дә җәмгыять тарафыннан тәклиф[67] кылынган фәхри[68] әгъзалык исемен кабул итеп, өенә кайтып китте. Күргән, белгән, ишеткәннәрен бераз рәткә салганнан соң, самавыр китерергә кушты. Җәгъфәр әфәнде чәй яратмаса да, болгарларның чәй яратуларын белгәнгә, һәм дә болгар романнарында шундый чәй эчеп кенә гомерен үткәрә торган кешеләр тасвирына да туры килгәнгә, самавырдан булар чыгарып чәй эчү аның һушына бик китә иде. Өйдә вакытта алар Сөембикә берлән дә шулай утырышып, озын иттереп болгарча, һәммә нәрсәне онытып, чәй эчәләр иде. Бу юлы да Җәгъфәр әфәнде шулай бер болгарланып алмакчы булган иде. Һич ашыйсы килмәсә дә, кондитердан болгар «как төше» китергән иде (бу как төш егерме беренче гасырларда руслар арасында бик таралган иде)...

...Килгән русларга* болгар тормышын күрсеннәр өчен, һәм дә табигате дә шуны теләгән өчен, шулай җыештырткан иде. Сөембикә булса, бу өй бөтенләй болгар тормышының нәмүнәсе[69] булачак иде. Һәм өйдә шулай уйланган иде. Ләкин аның булмавы аркасында шулай бер төрле генә җыелган иде. Чәй эчте, болгарлар төсле озын эчте, мөмкин кадәр болгарлар төсле үткән эшләрне, хәзерге хәлләрне чагыштырмаска тырышты, мөмкин кадәр һәммә эшне аллага тапшырам дип бетерергә теләде. Ләкин алай булса да, күңелендә янган утны һич сүндерә алмады. Һәммә күргәннәрен, хәтта күрәчәкләрен күз алдыннан җибәрә алмады. Вакыт җитә башлагач, киенергә әзерләнә башлады, киенеп беткәч, Сөембикәнең килә алмавы, бәлки аның хәзер авырып ятуы, үлү ихтималы да барлыгы хәтеренә төште һәм эчен пошыра башлады. Альбомны алып, бер мәртәбә бик озак Сөембикәгә карап торды. Сөембикә моң, кайгылы, авыру төсле күренә иде. Икенче караганда «Миңа карама инде, бар инде, үземезнең бетүемез шатлыгын күтәреш инде!»— дигән төсле була иде. Караган саен Сөембикә төрлечә сөйләгән төсле була иде, караган саен кәефсезлек арта бара иде, актык караганда Сөембикә: «Җитәр инде»,— дигән кебек булды. Җәгъфәр дә: «Җитәр»,— диде дә тиз генә чыгып китте. Озак үтмәде, Җәгъфәр әфәнде үзен зур зал эчендә әллә никадәр кешеләр арасында күрде. Бик күп кешеләр күрештеләр. Бик күп галимнәр килүе өчен рәхмәт укыдылар. Бик күп хатыннар моның әсәрләре хакында фикерләрен бәян кылдылар. Бик күп кеше моның белән сөйләшүне бик зур сәгадәткә саяп, сөйләгән сүзләрен дә үзләренең хатирә дәфтәрләренә «Ике мең бер йөзенче елның актык сәгатьләрендә, егерме икенче гасырны көткән вакытта язмыш мине

---

66. Мөкәммә — камилләшкән. 67. Тәклиф — кушылган, тәкъдим ителгән. 68. Фәхри — мактаулы. 69. Нәмүнә — үрнәк.

* «Килгән русларга...» дип башланган җөмлә моннан алдагы кыскартулар аркасында аңлашылмый.

бер зур мәҗлескә тугры китереп, шул болгарларның мәҗлестә булган иң мәшһүр мөхәррирләреннән, галимнәреннән Җәгъфәр әфәнде берлән күрешү, хәтта бер-ике сүз сөйләшү сәгадәтенә дә наил[70] итте»,— дип тә язганнар иде. Бу кешеләргә бу эшләр, бу сүзләр никадәр шатлык булса да, Җәгъфәр әфәндегә шулкадәр хәсрәт иде, шулкадәр авыр иде, авыр булган саен авырлыгын белдермәс өчен тырышу авырлыгыннан да авыр иде. Залның бер ягында зур бүлмәдә болгарларның рәсемнәре ачык куелган иде. Җәгъфәр әфәнде боларны күрүдән качса да, Җәгъфәр әфәнде белән сөйләшә торган бер тарих галиме болгарларның хатыннардагы өрпәгенең[71] кайвакыт башланып, кайвакыт бетүен белмәгәнгә, Җәгъфәр әфәндене алып кереп, өрпәкле бер болгар карчыгының дога кылуын тасвир кылынган бер рәсемне күрсәтте һәм сораячак сүзен сорады. Җәгъфәр әфәнде җавап биргәннән соң чыгачак булса да, күзе әле бер рәсемгә, әле бер рәсемгә төшеп, Җәгъфәр әфәндене ихтыярсыз калдырган иде. Рәсемнәр берлән зал тулган иде. Һәм дә һәммәсе дә болгар тормышыннан булганга, болгар мөхиббанына[72] күп мәгънә алырлык иде. Унтугызынчы гасырдан башлап беткәнчегә кадәр килгән болгарларның зур кешеләре, мөхәррирләре, әдипләре, галимнәре, шагыйрьләре, драматурглары, хәкимнәре, музыкантлары, народниклары — һәммәсе үзләренең иң мәгълүм вазгыятьләрендә[73] төшерелгәннәр иде. Аңарга башка йөзек салып уйный торган кызлар-егетләр җыены, унтугызынчы-егерменче гасырда «Сабак абыстайның кулына чыбык тотып сабак бирүе», «Болгар кызларының ярыктан берсе өстенә берсе менеп егетләрне караулары», «Болгар балаларының әйлән-бәйлән уйнавы»... ...вә боларга да башка да әллә никадәр рәсемнәр бар иде. Җәгъфәр әфәнде бик озак карап йөрде. Бу рәсемнәр арасында Җәгъфәр әфәнденең бер дә күрмәгән рәсемнәре дә бик күп иде. Болар арасында егерменче гасыр рәссамнарыннан чыккан «Болгар уе» дигән, ага торган су буенда яшел үләндә яңагына таянып уйлый торган егет тасвир кылынган рәсем моның һушына бик китте. Җәгъфәр әфәнде моңарга карап, рәсемдә тасвир кылынган егеттән дә битәррәк уйга чумды. Бу егетнең ни уйлавы ихтималы барлыкларын, һәммәсен хәтереннән кичерде. Иң актыктан гына егерменче гасырда бер болгар мөхәррирен, динсез дип кыйнап, бөтен дөньясы канга буялып бетүен, күзен акайткан бер кешенең тегене типкәләвен, икенчесенең кесәләреннән язган нәрсәләрен алып ерткалавын, бер иске генә чапан кигән мулланың тегене кыйнарга төртеп күрсәтеп торуы, һәм дә ерактанрак кайсы себерке, кайсы агач күтәреп, әдипне кыйнарга килүләрен тасвир кылынган рәсемне иң соң күрде. Бу рәсемгә карап, Җәгъфәр әфәнде ни әйтергә дә белмәде, йөзе ут кебек кызарды. Бу рәсемдәге кабахәтлек өчен руслардан оялды. Хәтта рәссамны гаепләмәкче булды. Ләкин бу эш вакыйг[74] булганга гаеп рәсем түгеллеге хәтеренә төшеп, моны ничек тә таэвил кылырга белмәде. Үзе ни эшли белмәсә дә, күңеленнән: «Начар халыкмыни соң, ник бу эшне эшләгәннәр?»— дия иде. Руслардан берсе-берсе моңарга даир[76] бер-бер сүз ачмасын дип, тиз генә икенче якка чыкты. Зал тулы халыклар рәсемнәрне карыйлар иде. Рәсемнәр хакында мөхакәмәләр[77] кылалар иде. Әллә ни кадәресе шул рәсемнәрнең копияләрен алу тиешлекләрен сөйлиләр иде. Икенчеләре болгар мөхәррирләренең рәсемнәре хакында, аларның төсләре хакында, тәрҗемәи хәлләре[78] турында сөйлиләр иде. Җәгъфәр әфәнде икенче залга чыкты. Анда болгарларның әйберләре куелган иде. Монда тарих белгән заманнан бирле булган болгарларның әйберләре бар иде. Акчалары, киемнәре, зиннәтләре, өй җиһазлары, хатын-кыз зиннәтләре, табак-савытлар — һәммәсе бар иде. Җәгъфәр әфәнде боларны тагы бик озак карап торды. Болар арасында үзбәк ханга Мисыр хәлифәләреннән җибә-

70. Наил — ирешү. 71. Өрпәк — яулык (Монда — битне каплау мәгънәсендә). 72. Мөхиббан — яратучылар. 73. Вазгыять — торыш, халәт.

релгән кылыч та бар иде. Монда бик озак торды. Монда да болгар хакында, аларның киемнәре хакында, аларның торулары хакында бик күп сүзләр ишетте. Болар арасында йөргәндә звонок тавышы ишетелә башлады. Һәм анда да, монда да хезмәткәрләр залга җыелырга вакыт икәнлеген белдереп йөри башладылар. Җәгъфәр әфәнде дә су кебек ага торган халык берлән бергә чыкты. Аны каршы залга рәис янындагы үзенә хәзерләнгән урындыкка утырттылар. Залдагы халык бик кызу-кызу урынлаша башладылар. Җәгъфәр әфәнде бер якта бик күп ирләр, хатыннардан мөрәккәб[79] оркестр күрде. Озак үтмәде, тагы звонок булды һәм яңа гасыр керергә биш кенә минут калганлыгы белдертелде. Халык һәммәсе дә «ура» дип кычкырырга әзерләнеп, тамакларын рәтләргә тотындылар. Тамак тавышы аз гына безнең унтугызынчы-егерменче гасырда мулла хотбә укып бетергәндә бөтен мәчетне күтәрә торган тамак кыру тавышы булмаенча калды. Һәммә кешенең, менә җитә, менә җитә, дип йөрәкләре леп-леп итә башлады. Менә кинәттән оркестр да гөрләп китте. Бөтен залны музыка тавышы алды. Һәммә кеше бу моңны — болгарларның тормышларының ничек икәнлеген күрсәтә торган шаһидны бик ихлас берлән, һәр тавышыннан әллә нинди уйларга чумып тыңларга тотындылар. Бу көй болгарның соңгый[80] көйләреннән егерме беренче гасырда чыккан «Өмет бетте» дигән көй иде. Бу көй шул кадәр тәэсирле иде, нинди җиңел уйлы җилбәзәкләрне дә бик тирән фикерләргә чумдыра иде. Ниндәй каты йөрәкле кешеләрнең дә күзләреннән яшьләр агыза иде. Җәгъфәр әфәндегә бу алай тәэсир кылмады. Ул хәзер шулкадәр кәефсез, шулкадәр авыр хәлдә иде — һичбер нәрсәгә кайгыра белми иде. Музыка туктады. Бөтен залны «ура» тавышлары тутырды. Һәммә яктан: «Яшәсен, яңа гасыр яшәсен!» — тавышлары ишетелә башлады. Бердән музыка гөрләде. Оркестр баягыдан да гайрәт берлән русларның «Барабыз» дигән уенын уйный башлады. Бу көй шулкадәр кәефле, шулкадәр моны тыңлавы җиңел иде, нинди кайгылы кешенең дә кайгыларын Каф тавы артларына таратырлык иде. Музыка туктады. «Ура», «Яшәсен» тавышлары тагы дөньяны күтәрде. Электрик утлары бөтен дөньяны алган иде. Урамнан да «ура» тавышлары ишетелә иде. Озак үтмәде, тагы «яшәсен» тавышлары күтәрелә иде. Җәгъфәр әфәндене рәис яңа гасыр берлән тәбрик кылып, «Яңа гасыр мөбарәк булсын», дигән сүзгә Җәгъфәр әфәнде: «Өмет бетте, сезгә мөбарәк булсын, барыгыз», — диде. Һәм күзләреннән яшьләр ага башлады. Кешеләр бер-берсе берлән күрешә, тәбрик кылыша башладылар. Бер чирек сәгать үткәннән соң рәис, кафедрага чыгып, кыска гына яңа гасырның гомум бәни бәшәр[81] өчен сәгадәт гасыры булуын теләп, ашка чыгарга үтенде. Һәм Җәгъфәрне алып зур залның ишеген ачып җибәрде. Тагы музыка гөрелдәде, болгарларның «Агач башы» дигән көе уйнала башлады. «Браво»-лар, «ура»лар, «яшәсен»нәр берлән тагы бер зал гөрләгәннән соң, һәммәсе урынлы-урынына утырдылар. Җәгъфәр тагы иң түргә утырды. Аш килә башлады. Ашлар арасында вак-төяк сүзләргә башка, арада килә торган болгар ашлары хакында сөйләнә иде. Кайсы — болгар ашын яхшы, кайсылары бик майлы табалар иде. Хәтта кайсылары шул майлы ашларның болгарларның рухларын үтерүгә сәбәп булуын, аларны дорфаландыруын, ашларны ашап йөрүне үзләренә вазифа ясаган муллаларның бигрәк тупас булуларына кадәр барып җитәләр иде. Ни сөйләсәләр, ни кылансалар да, Җәгъфәр әфәндене иң авырта торган җиренә тия иде. «Ура, яшәсен яңа гасыр!» — дип бокаллар күтәрелгәннән соң, рәисе җәмгыять аяк үзрә торып

---

74. Вакыйг — барлыкка килгән. 75. Таэвил — юрау, аңлату. 76. Даир — бәйләнешле. 77. Мөхакәмә — хөкем чыгару. 78. Тәрҗемәи хәл — биография. 79. Мөрәккәб — җыелган. 80. Соңгый — ясалма.

сүзгә башлады. Бу көнге көн үткән заманда мисалы күрелмәгән көндер, бу вакытка кадәр нинди зур вакыйгалар булса да, нинди зур бәлаләрдән дөнья котылып калса да, аларның шатлыклары да бу көнге көннең шатлыгына нисбәт кылырга түгелдер. Үткән егерменче гасырның бәни бәшәр тарихында нинди әһәмиятле мәүкыйглар[82] иттихаз[83] иттеге мәгълүмдер. Бу гасырның ихтирагаты[84], бу гасырның кәшфияте[85] унтугызынчы-егерменче гасырларны гына түгел, егерме беренче гасырның үзенең халыкларын да хәйрәттә[86] калдырмыштыр. Безне чолгап алган нәрсәләр, күзебез күргән нәрсәләр һәммәсе егерме беренче гасырда кәшеф кылынмыш, яисә егерме беренче гасырда тәшкил кылынмыштыр. Егерменче гасырда тәдавиясе[87] мөмкин түгел дип фараз кылынган авырулар, егерменче гасырда иң куркынычлы дошман саналган микроблар, егерменче гасырда уйлый алмаган фикерләр — һәммәсе егерме беренче гасырда мәйданга чыкмыштыр. Минем максудым бу гасырның кәшфиятен санау түгел, фәкать яңа гасырга керер өчен бер мөкаддимә генәдер, бу гасырда бөтен бәни бәшәрдә үзгәрүләр булдыгы кеби, без русларда да бик күп тәбдилат[88] булмыштыр, руслар тагы үзләрен галәмгә таныттылар. Русларүзләренең саф дәрунлыклары[89] берлән, обломовлык лязим[90] берлән мәлзумә[91] төсле түгеллеген исбат иттеләр. Эшләгән эшләре берлән бөтен дөньяны хәйрәткә калдырдылар. Голум, фөнүн[92], сәнагатьтә, санаигы нәфисәдә[93] руслар бик күп хезмәт иттеләр. Һәр фәндә рус галимнәренең исемнәре фәннәрне бизәкли башладылар. Гыйльме мәгыйшәт бәшәрдә[94] дә русларның әһәмиятләре бик зурдыр. Аларның иткән тәбәдделләр[95]булдыгы кебек, безнең күршеләремез, дөресен әйтсәк, безнең мөгаллимнәремез болгарлардагы бәхетсез тәбәддел бер халыкта булмады. Бу халык нинди иң мөһим эшләрендә йөргәннән соң, тарих бәшәрдә бик зур вакыйгаларга сәбәп булганнан соң, янып беткән шәм кебек, эределәр дә беттеләр. Уникенче-унөченче гасырларда болар, русларга караганда бик зур милләт һәм бик тәрәккый иткән халык булдыклары кеби, Азиядән килгән татарларга кушылганнан соң, безнең милләте хакимемез дә булганнар иде. Бара-тора бездәге иттифак[96], алардагы ихтилаф[97] дөньяның китешен үзгәртте. Без акыртынлап аларга мөкавәмәт[98] кыла башладык. Бара-тора аларга галиб[99] тә була башладык. Ахрында уналтынчы гасырда, бөтенләй галиб булып, милләт мәхкүмәмез[100] арасына керделәр, болар шул вакыттан бирле тәмам биш гасыр ярым безнең тәхет итагатемездә тордылар, табигатьләрендәге сабырлыктан, болар бик тиз безнең гадиләнә[101] идарәмезгә иялəшеп киттеп, һичбер вакытта истикълалларын[102] кайтару фикеренә килмәделәр. Болар төрки нәселенә мәнсүб[103] бер халык иделәр. Боларның телләре дә төрек телләренең бер төрлесе иде. Болар төрки нәселенә бер халык иделәр. Боларның телләре дә төрек телләренең бертөрлесе иде. Болар тугызынчы яисә сигезенче гасырда ук исламият кабул итеп, мөселман булганнар иде. Шуның өчен безнең белән аларның арасында дин башкалыгы күп вакытта үзенең тәэсирен белдерә иде. Алай булса да, ике якның да инсафы аркасындамы, әллә замананың тәэсире сәясендәме, боларның гомуми торышларына бу дин башкалыгы тәэсир итмәгәндер. Фәкать болгарларның хосуси үзләренә караганда, бик күп зарар иткәндер. Болар безнең белән диннәре башка булу җәһәтеннән актыкка гасырларына кадәр балаларын безнең мәктәпләремездә укытырга шикләнәләр иде. Шуның өчен

---

81. Бәни бәшәр — адәм балалары. 82. Мәүкыйг — урын. 83. Иттихаз — алу, тоту. 84. Ихтирагат — уйлап табулар. 85. Кәшфият — ачышлар. 86. Хәйрәт — аптырау. 87. Тәдавия — дәвалау. 88. Тәбдил — үзгәртү. 89. Дәрун — йөрәк, күңел. 90. Лязим — тиеш. 91. Мәлзум — кирәк. 91. Голум, фөнүн — гыйлемнәр, фәннәр. 92. Санаигы нәфисә — сәнгать. 94. Гыйльме мәгыйшәт бәшәр — кеше тормышы турындагы фәннәр. 95. Тәбәддел — алышыну, үзгәрү.

һәр вакытта безнең мәктәпләремездә болгарлар бик санаулы гына булмыштыр. Болгарларның үзләренең китешләре бу заманга яраклы түгел иде. Шуның өчен аларга нигезләрен төзәтер өчен, искергән өйләрен сипләр өчен, яңа мәгариф алырга кирәк иде. Аны алуның иң җиңеле безнең аша булса да, алар безгә үзләренең ышанмаулары хакында файда итә алмадылар. Шуның өчен, аларны төзәтер өчен йә үзләренең мәктәпләрен ислах[104] кирәк иде, я безнең мәктәпләргә керү кирәк иде. Болар берсен дә эшләмәделәр. Шуның өчен чергән өй чергәннән-чери башлады. Ниһаять, җимерелде. Бу көнге көндә Россиядә Җәгъфәр әфәнде, аның хатыны Сөембикә ханымга башка бер болгар да калмагандыр. Боларның үзләренең тормышлары, үзләренең культуралары булганга, үзләре бетсәләр дә, безгә бик күп әсәрләр калдырдылар. Боларның бөтен авылларында, шәһәрләрендә булган исәпсез-хисапсыз мәдрәсәләр, мәктәпләр, мәчетләр — боларның иң зур ядкәрләредер. Болар үзләре бик кабилиятле, үткен һәм тере халыклар иде. Болар табигатьне сөя торган, сәнагъ нәфисәдән ләззәт ала торган, әхлак кагыйдәләрен бик ригая[105] кыла торган, һәммә кешеләр берлән дусланырга бик ярата торган, кунак сыйлар өчен яратылган кебек бик күп әхлак хәмидәгә[106] малик[107] бер кавем иде. Боларның табигатьләрендә тиҗарәткә[108] рәгъбәт[109] һәм дә тиҗарәткә осталык булганга, болар бик күп вакыт дөньяның иң тиҗҗәр[110] халык булган яһүдиләр берлән рәкыйб[111] була алганнар. Ләкин боларда булган җилбәзәклекме дим, әллә өстән уйлаумы, болардан акыртын-акыртын гына дәүләтләрен ала башлаган. Болар унтугызынчы гасырның актыккы яртысында фәкыйрьләнә башлап, бу көнге көндә шул фәкыйрьлек аркасында бөтенләй бетмешләрдер. Боларның соң заманнарына араларында әхлак бозыклыгы бик таралмыштыр, болар үзләре бик мөтәддәйин[112] күренсәләр дә, һәм һәрвакыт үзләрен «ислам саклаучылар» дип йөрсәләр дә, болар арасында исламның хакыйкатен аңлаган кеше бик аз булганга, боларның мөселманлыклары истибра[113] корыту, намаз укуда гына калгандыр. Исламның әхлакый мәгыйшәти мәсьәләләрен голәмалары кайсысын тәэвил[114] кылып, кайсысын бөтенләй исламияттән чыгарып, игътибардан төшергәннәрдер. Боларда хатын-кызга тәрбия бирү булмаганга, әүвәл хатыннарны качырып тоткан вакытларда әхлакларын югалтмасалар да, замана үтә-үтә ул пәрдәләр ертылганга, пәрдә астыннан, чылбырдан котылган этләр кебек, болгар хатыннары килеп чыкмышлардыр. Һәм дә әбиләренең файдалана алмаган хөрриятләреннән берьюлы файдаланмакчы булып, әхлаксызлыкка салынмышлардыр. Унтугызынчы, егерменче, егерме беренче гасырларда боларның хатыннары фәхеш галәмнәрендә бик зур роль уйнамышлардыр... Һәм икенче яктан, мәгариф тәрәккый иткән саен, галим кешегә тору никадәр җиңел булса, надан кешегә шулкадәр авыр буладыр. Бу авырлыкны болгарлар да күтәрмешләрдер. Бервакытны болар һөнәрсез, гыйлемсез, дәүләтсез булып, калын кара хезмәтләрдә генә гомерләрен үткәрмешләрдер. Шул сәбәптән фәкыйрьлек саясында[115] кими-кими, һәм дә алла тарафыннан җибәрелгән бәла — авыру аркасында, дөресен әйтсәк, наданлыклары саясында үзләренең һәлакәтләренә үзләре сәбәп булмышлардыр. Болар һәммә эшне эшләргә яратсалар да, боларда сәбат[116] булмаганга, күп эшләр сүз берлән генә калмыштыр. Шуның өчен болгар тарихы сүз

---

96. Ихтифак — бердәмлек, берлек. 97. Ихтилаф — ызгыш. 98. Мөкавәмәт — каршы тору. 99. Галиб — җиңүче. 100. Мәхкүмә — буйсынучы. 101. Гадиләнә — гаделлекле. 102. Истикълал — бәйсезлек. 103. Мәнсүб — караган. 104. Ислах — үзгәртү. 105. Ригая — хөрмәтләү, кайгырту. 106. Хәмидә — мактаулы. 107. Малик — ия. 108. Тиҗарәт — сәүдә. 109. Рәгъбәт — теләк, омтылыш. 110. Тиҗҗәр — сәүдәгәр. 111. Рәкыйб — көндәш.

берлән тулыдыр. Болар һәр мәсьәләне әллә ничәшәр мөләхәзә[117] кылганнар, әллә ничәшәр мөхәкәмә[118] кылганнар. Ләкин һич берсен дә эшләмәгәннәр. Боларның тагы бер табигатьләре бар. Болар бик һавалы булганнар. Шуның өчен, үзләрен бик зур күреп, сөйләгән кешенең сүзенә бер дә илтифат кылмаганнар һәм аларның киңәшләренә дә карамаганнар, һәммә нәрсәдә «үзем беләм» дәгъвасында булганнар. Боларның тарихлары һичбер халыкның тарихына охшамый. Боларда голум, мәгариф низагларына тиречеләр катышканнар. Дин мәсьәләләренә эшчеләр катнашканнар. Мәдрәсә-мәктәп эшләрен укымаган, яза белмәгән кешеләр йөрткәннәр. Хасыйлы, боларда кем нинди эшне белмәде — ул шул эшнең башчысы булган. Шул сәбәптән боларга алга китәргә мөмкин булмаган. Боларның мөкәммәл музыкалары, яхшы гына тәрәккый иткән әдәбиятлары калмыштыр. «Болар бәни бәшәргә ни файда итте?» — сөаленә мин җавап бирә алмыйм. Әгәр боларның тынычлык сөю сәбәпле, дөньяда әллә нинди фетнәләр чыгуына сәбәп булмауларын файдага санамасак, боларның иткән хезмәтләре юктыр. Фәнгә хезмәтләре юк. Чөнки болар фәнне белмәделәр. Һөнәргә, сәнәгатькә[119] тагы юк иде. Гыйльме мәгыйшәт бәшәргә[120] тагы юк, шуның өчен боларның исемнәре дөньяда үзләренең музыкалары берлән генә сакланмаса, сакланмаячактыр. Боларның хәлләренә караганда, без, руслар, тагы шатланамыз. Чөнки безнең дә болар хәлендә булуымыз, бу көнге көннәрне яисә иртәрәк, яисә соңрак күрүемез, дөнья белән бөтенләй күрешүемез[121] ихтимал иде. Ләкин ул көн хәзер үтте. Үземезнең гайрәтемез, тырышлыгымыз саясендә әүвәл авыр эштән котылдык. Моның соңында руслар яшәячәкләр, яшәсен руслар!» Бөтен залдан «яшәсен» сүзләре ишетелде дә рәис туктады. Бөтен зал «яшәсен» тавышы берлән тулды. Бу сүзләрдән соң һәммә кеше Җәгъфәр әфәнденең каршы берәр сүз сөйләвен көтәләр иде. Өметләре бушка китмәде. Вакыйга Җәгъфәр әфәнде торды. Рәис мәҗлеснең сүзләре берлән бөтен каннары уйнагангамы, әллә болгарларның шул җәмгыятьләрдә сүзләр сөйләвенең актыгы буласы хәтеренә килгәнгәме, әллә тыңлый торган халыкка бу никадәр яхшы-яхшы сөйләсә дә, начар сөйләсә дә, бер булуын белеп, аларның максудлары минем сүземнән файда алу булмаенча, актыккы болгарның сүзендә ишетү генә кебек уйлар хәтеренә килгәнгәме, йөзенә көчләнү әсәре чыккан иде. Ул һәрвакыт үзенең әсәрләрендә болгарны яхшы итеп күрсәттеге кебек, аларның начарлыкларын да мөмкин кадәр тәэвил[122] кылып, фәлән итеп күрсәтергә тырыша иде. Бусында актыккы сүзләр булганга, тагы болгарларны матуррак күрсәтмәкче иде. Ләкин матур күрсәтергә теләгән саен күз алдына болгарларның начарлыклары күренә бара, ямьсез яклары юри кыйлынган кебек, хәтеренә килә бара иде. Шулай булса да, озак басып торырга ярамаганнан, Җәгъфәр әфәнде сүзгә башлады: «Әфәнделәр! Шундый җәмгыятькә мине чакыруыгыз өчен бик мөмнүнмен. Бу сезнең илтифатыгыз саясында, мин үземезнең мөнкарыйз[123] булган милләтемез хакында үземнең фикеремне бәян шәрәфенә наил[124] булдым. Хәзер йшетә торган сүзләреңез бөтен дөньяны дер селкетеп, меңнәрчә еллар торган бер милләтнең актык баласының актык сүзе, меңнәрчә елларда үзгәрүне кабил[125] булмаган бер милләтнең үзгәрмәгән актык бер углының фикере һәм дә тугры фикередер. Без болгарларның кайчан җир йөзендә, кайвакытта патшалык сөрә башлавымыз хакында мин бер сүз дә әйтмәячәкмен. Моны беләсе килгән кешеләргә меңнәрчә җилдләр[126] тарих китаплары ха-

---

112. Мөтәддәйин — диңле кеше. 113. Истибра — бавелдән соң юыну. 114. Тәэвил — ялгыш аңлату. 115. Сая — күләгә, ышык. 116. Сәбат — нык тору. 117. Мөләхәзә — игътибар белән уйлау. 118. Мөхәкәмә — хөкем чыгару. 119. Сәнәгать — промышленность. 120 — Гыйльме мәгыйшәт бәшәр — кеше тормышы турындагы фән. 121. Күрешүемез — саубуллашуыбыз мәгънәсендә булса кирәк.

зирдер. Аларның нинди нәселгә мәнсүб[127] икәнлекләре хакында бер сүз дә димәячәкмен. Анысы да гыйльмелнәсаб[128] китапларында туптулы бер мәсьәләдер. Бу мөнкарыйз булган халыкның болгарлар икәнлеген сөйләргә дә ихтыяҗ юктыр. Чөнки бу хакыйкать унтугызынчы гасырның ахырларында мөсбәт[129] булып, Русиядәге мөселманнар татарлар берлән катышсалар да, алардан күп гадәтләр алсалар да, татарларның каннары тәэсир итеп, элгәреге болгарларның ләтафәт табигатьләрен югалтсалар да, болгарлар һаман болгар көенчә калмый, татарлар акыртын гына болгарларга кушылып бетеп китмешләрдер. Русиядә мөселманнарга ул татар дию шаигъ[130] булса да, бара-тора болгарга әйләнгәнгә күрә, без дә болгар дип сүз сөйләячәкмез. Болгарларның табигате сабыр, һәр нәрсәне күтәрә торган, үткен, һәр нәрсәне белергә кабил, яхшылыкка мәйяль[131], бераз фанатик, кунак сөяр, тынычлык өчен җан бирә торган, яисә һәр нәрсәнең һәр ягын уйлап бетермәенчә эш кыла торган, яисә һәр ягын уйлаган булган булып, бер эш тә кылмый торган, фәлсәфә сөйләргә ярата торган, тик торуны ярата торган бер табигатьтер. Боларда җилбәзәклек булганга, боларның тарихларында тиздән генә зур мәсьәләләр чыгу һәм зур тавышлар чыгу бик күп булдыгы кеби, боларның тарихларында уйлап, төпле иттереп эшләнгән эшкә очрау да бик аздыр. Болар һәммә нәрсәне төпсез эшлиләр иде, һәр бинаны нигезсез эшлиләр иде. Болгарларның: «Иртәгә өчен ишәк кайгырткан»,— дигән мәкальләре боларның никадәр киләчәк хакында уйлаганлыкларын белгертәдер. Боларның тарихларында парлак заманнар күренсә дә, болар да бер уйланып эшләүдән хасыйл булган нәрсәләр түгел иде. Фәкать тәсадефән[132] генә тугры килгән иде. Болгарлар татарларга катышмастан борын мондый халык түгелләр иде. Болар җитди, һәр эшне уйлап, алдын да, артын да белеп, ник, ни өчен икәнлеген тикшереп эшли торган халык булсалар да, Азия сахраларында иркенлектә торып, бу көн тамагы туйса, иртәгә туярын уйларга өйрәнмәгән татарлар боларга үзләренең табигатьләрен бүләк итеп калдырмышлардыр. Һәм дә болгарларның тора торган җирләре иркен һәм мөнбит[133] булганга, күрше халыклары боларга караганда да түбән булганга, дөньяның алга китә торган халыклары берлән мөнәсәбәтләре киселгәнгә, болар «Аллага тапшырдым» дип ятуга салынмышлардыр. Һәм, вакыйган да, боларга тамак туйдыру өчен әллә нинди белүләр, уйлап, план корып эшләнгән эшләр кирәк булмагандыр. Шуның өчен еллар, йөз еллар үтә-үтә боларның бу эшләре икенче табигать хәлен алмыштыр. Боларның бу хәлдә дәвам итүләренә голәмасының наданлыгы һәм дә сатучыларының үзләреннән дә арттагы сарт, кыргыз кебек халыклар берлән генә эш итүләре дә бик зур сәбәп булмыштыр. Болар аларның һәммә начарлыкларын күреп, үзләреннән зур милләт юк казыясын[134] чыгаруларына һәм үзләрен һәр яктан мөкәммәл дип уйлауларына башчы булмыштыр. Тагы бу халыктагы үткенлек, аның нәтиҗәсе булган үзен зур тоту, боларның башка халыкларга кечкенә итеп каравына сәбәп булмыштыр. Димагларында[135] куәи хыялиянең[136] куәтлеге саясында болар һәммә нәрсәдән әллә нинди булмый торган фаразларга китеп, уйларга чумып, эшләргә вакытлары калмагандыр. Тагы боларның табигатьләрендә әллә нинди сүзгә, ләфызга[137] әһәмият бирү булган. Бу noksан[138] бөтен шәрекъ халкының гадәте булса да, безнең болгарларда бигрәк каты падишаһлык сөрмештер. Шуның өчен укый торган

122. Тәэвил — ялгыш аңлату. 123. Мөнкарыйз — сүнгән, юкка чыккан. 124. Наил — ирешүче. 125. Кабил — кабул итүче. 126. Җилд — том. 127. Мәнсүб — караган. 128. Гыйльмелнәсаб — нәсел турындагы фән. 129. Мөсбәт — исбат ителгән. 130. Шаигъ — таралу. 131. Мәйяль — һәвәс, оста. 132. Тәсадефән — очраклы. 133. Мөнбит — уңдырышлы. 134. Казыя — хәбәр, җөмлә. 135. Димаг — ми. 136. Куәи хыялия — хыял куәте. 137. Ләфыз — сүз. 138. Ноксан — кимчелек.

фәннәренең мәгънәләренә барып җитмәенчә һәм барырга да тиешлеген уйламаенча, лафыз низаглары белән гомер үткәргәннәр. Шул сәбәптән боларда никадәр мәктәп, мәдрәсәләр булса да, уку никадәр халык арасында таралса да, боларның белгәннәре фәлән сүзнең фәлән сүздән ник элек әйтелүе, ник ул сүзнең әйтелмәенчә, бу сүзнең әйтелүе кебек юк эшләр генә булмыштыр. Боларда лафызга әһәмият шулкадәр булган, хәтта коръән кебек дини китапны укуда, фәлсәфи никадәр гали[139] хөкемнәрне[140] шамил[141], җанаб алла тарафыннан җибәрелгән хикмәтне өйрәнүдә дә лафыздан үтә алмаганнар. Коръән уку боларда аны тәҗвидләп[142] укып, авызны төрлечә борудан гыйбарәт булып калган. Боларның «лафызыйлыклары һәрвакытта үзен күрсәткән. Боларның тарихларында һәр нәрсәне эшләргә планнар кору кадәр күп нәрсә юклыгы, боларның лафызый холыклыгыннан нишандыр[143]. Һәр нә исә боларның алга китмәүләренә сәбәп үзләре төсле генә күренсә дә, иң зурысы кәлимәте[144] һәм дә күрше халыкларыдыр. Югыйсә болар һәр нәрсәгә кабилиятле[145]. Дәхи[146] дә башлык булмавы, руслар берлән динән[147] башкалык, руслардан бәгъзе дөньяның китешен аңламаган папасларның[148], вакыйган[149], болгарларны христиан итү фикеренә килүләре, болгарларның һәммә руска алдакчы күзе берлән каравына сәбәп булмыштыр. Шул саяда богарлар руслар аша да мәдәниятне ала алмамышлардыр. Боларның тарихларындагы фанатик, дин химая[150] кылу фикере болгарларга поплар берлән мөкавәмәт[151] өчен чыкмыш исә, надан халык һәммә урында истигъмаль[152] кылмышлардыр. Шул сәбәптән болгарларның мәдәнияттән гафил[153] калуларына вә шуның саясында мөнкарыйз булуларына ярты сәбәп русларның поплары булмыштыр. Болгарлар һичбер вакыт руслардан курыкмамышлардыр. Фәкать христианлыкка гына рази булмамышлардыр. Боларның әхлаксызлыклары, боларда хатын-кызның фәхеш юлына китүләре, боларда спиртлы эчемлекләр истигъмаленең таралуы, минемчә, тагы боларның үзләренең табигатьләрендә шундый эш булудан түгел — фәкать боларда кирәгенчә (эш) кылу булмаганлыгыннан, күңел ачар өчен әхлакый урыннар булмадыгыннан, боларны тәрбиясезлек, эч пошу, эшсезлек фәхеш юлына тартмыштыр. Эч пошуны бетерер өчен исерткечләр дә истигъмаль кылынмыштыр. Бара-тора боларны истигъмаль кылу да икенче табигать булып калмыштыр. «Бәни бәшәргә ни файдалары булды?» — сөаленә мин дә җавап бирә алмыйм. Чөнки бу сөальгә җавап өчен аларның һәммә эшләрен дә берәм-берәм тикшерү кирәкдер ки, бу да хәзерге мәҗлестә мөмкин түгелдер. Фәкать калдырган музыкалары, әдәбиятлары, тарих бәшәрдә[154] әһәмияттән хали[155] булмас дип уйлыйм. Әммә фәнгә, санәгатькә хезмәтләре юклыгында һич шөбһәм юктыр. Фәкать боларның сәнаигы нәфисәгә[156], художествога иткән хезмәтләрен һәр монсыйф[157] икърар кылыр хөсне занындамын[158]. Боларның болай бу дәрәҗәдә төшеп калуларына һәм дә бетүләренә баш сәбәп бик күп кешеләр ислам булды диләр. Ислам манигъ тәрәккый[159] диләр. Боларның бу фикерләре, минемчә, бөтенләй хата түгел. Хәзрәт Мөхәммәт (галәйһи эссәлам) тарафыннан өйрәтелмеш исламның манигы тәрәккый түгеллегендә һичкемнең шөбһәсе юктыр. Фәкать болгарлар бу ислам диненә керделәрме? Минемчә, юк! Боларда исламиянең өске кабыгы берлән япкан бер мәҗүси дине бар иде. Тышын караганда никадәр исламияткә охшаса да, эченә керсәк, мәҗүсилектән башка нәрсә түгел иде.

---

139. Гали — бөек. 140. Хөкем — уй йөртү. 141. Шамил — эченә алган, туплаган. 142. Тәҗвид — коръәнне дөрес итеп уку кагыйдәләре. 143. Нишан — билге. 144. Кәлим — үз-үзенә сөйләүче. 145. Кабилиятле — сәләтле. 146. Дәхи — янә. 147. Динән — дин ягыннан. 148. Папас — поп. 149. Вакыйган — чыннан да. 150. Химая — саклау. 151. Мөкавәмәт — каршы тору. 152. Истигъмаль — куллану. 153. Гафил — сизми калу. 154. Бәшәр — кеше. 155. Хали — буш. 156. Сәнаигы нәфисә — матур сәнгать. 157. Монсыйф — инсафлы кеше. 158. Хөсне зан — яхшы уй.

«Исламият манигъмы, түгелме?»[159] — сөален биргән кешеләр бу ике исламны аермыйлар иде. Җавап бирүчеләр дә әле берсен, әле берсен күрсәтеп бирәләр иде. Шуның өчен бу мәсьәлә унтугызынчы гасырда ук мәйданга атылса да, бу көнгә кадәр тәмам ачык беленмәмештер. Болгарлардагы дин манигы тәрәккый иде. Болгарлар шуны саклыймыз дип, рус мәктәпләренә кермәделәр, рус теле белүдән качтылар, руслар берлән якынлашудан курыктылар, болар һәммәсе аларның исламият кабыгы берлән капланган, татар-болгар халкының кушылуыннан хасил булган бер мәҗүсилекне саклау намына[160] кылынмыштыр. Һәр нә исә, хакыйкать — болгарлар яхшы бер халык иде, тагын бер сүзем бар — бу болгарлар бәхетсез халыклар иде. «Бәхет нәрсә соң? Ул бармы, юкмы?» — мәсьәләләрен хәл кылмаенча гына мин болгарларның бәхетсезлекләрен күрсәтәм. Болгарларда милләтнең алга китү мәсьәләсен тәмам аңлап, шул юлда эш эшли башлаган кешеләре ник бик тиз үләләр иде? Яисә мондый кешеләр фәкыйрьлек-фәлән берлән ник бик тиз үзләренең мөкатдәс хезмәтләрен ташларга мәҗбүр булалар иде. Шагыйрьләрнең вакытсыз үлүләре, болгарга ярдәм итә торган байларның яшьли үлүләре нидән иде? Болгарларда тәрәккый итәр алдыннан мәгариф таратылыр вакытта әллә кайдан килеп чыккан коруне восата[161] мәҗүсилеге булган «ишанлык» ник ул кадәр тиз тарала иде? Икенче яктан эш эшләргә ярарлык кешеләр, милли мәсьәләләрне аңлаган кешеләр, ник һәрвакыт ярлы булып, хезмәте миллия урынына көнлекче кебек тамак туйдырырга гомерләрен сарыф итәләр иде? Минемчә, болар һәммәсе бәхетсезлектән иде. Тагы болар арасында килеп чыккан авыру бәхетсезлектән булмый нидән? Дөрес, наданлыктан, тыйбка[162] ышанмаудан, пакьлеккә әһәмият бирмәүдән, дияргә дә мөмкин, ләкин һаман бәхетсезлекнең дә катышында шөбһә юк. Нә исә болар беттеләр. Тарихта халыкның бетеп китүе бик күп күрелгән мәсьәлә булса да, финикәләр[163] заманасында нинди мөтәрәккый милләтләр булсалар да, бабилиләр[164], асуриләр[165] инкыйраздан котыла алмадыклары мәгълүм булса да, бу замандагы инкыйразга бер дә охшамый иде. Шуның өчен бу кадәр зур милләтнең шул кадәр мәгариф, голүм тәрәккый иткән гасырда инкыйраз гаҗәп булачак һәм бөтен галәмне хәйрәткә[166] калдырачактыр. Һәм калдырмактадыр. Бүгенге көндә болгарларның никадәр асаре гатикалар[167], никадәр фәлсәфәләре, фикерләре сезгә калачактыр, сезгә боларны саклау инсаниятеңез вазифасыдыр. Тагы бер мәртәбә әйтим, болар начар халыклар, тәрәккыйны кабил түгел бер милләт түгел иде. Фәкать бәхетсезлек, урынның иркенлеге, тормышның җиңеллеге, күршеләренең наданлыгы, мөтәрәккый[168] милләтләрдән ераклыгы сәбәп булмыштыр. Бу сүзләрне Җәгъфәр әфәнде бик кызып, бик ачык иттереп, гүя, икенче милләт хакында сөйләгән кебек сөйләсә дә, бу җиргә җиткәч, кылт итеп хәтеренә үз милләте — болгар хакында сөйләве исенә төште дә, яшен суккан кебек булып, ни әйтерен дә белмәенчә: «Әйе, беттеләр! Өмет бетте!» — диде дә бераз ни әйтергә белмәенчә торды. Бераздан тагы икенче төрле тавыш берлән сөйләргә башлады. «Мин болгар милләтенең актыккы баласы, актык болгар Җәгъфәрнең сездән хосуси бер үтенечем бар. Без беттек. Безнең никадәр әйберләремез, әсәрләремез калды. Аларны сез кадерләп, хөрмәт итеп саклаңыз. Һәм саклаячаксыз, минем монысында һич шөбһәм юк. Фәкать минем үземнең актыккы болгарның китапларын, асаре гатикам, киемнәрем, өй әйберләрем, хатыным Сөембикәнең китаплары, үз әсәрләреннән шигырьләре, иске музыка аләтләре[169], хәзерге музикә аләтләре вә минем өемдәге әй-

---

159. Манигъ тәрәккый — алга китүгә киртә. 160. Нам — исем. 161. Коруне восата — урта гасырлар. 162. Тыйб — медицина. 163. Финикә — финикилле. 164. Бабили — вавилонлы. 165. Асури — ассирияле. 166. Хәйрәт — аптырау 167. Асаре гатика — борынгы әйберләр, истәлекләр. 168. Мөтәрәккый — алга киткән. 169. Аләт — корал. 170. Могальмәминуният — зур шатлык.

берләрнең һәммәсен, Сөембикә берлән безнең икебез дә үлгәч, үземезнең химаяңызда булган җәмгыятькә алып саклавыңызны үтенәм. Әгәр сез минем шул үтенечемне кабул итсәңез, мине бик шат иткән булырсыз. Һәм дә актыккы болгарның актыккы гомерләрендә актыккы үтенечне кабул иткән буласыз. Һәм дә хәзер дә алып килгән әсәремне кабул итүңезне үтенәм» (шул вакытта Җәгъфәр әфәнде кесәсеннән чыгарып рәискә бирде),— диде дә утырды. Халык кул чабудан туктагач, рәис чыгып: «Мин үземнең иптәшләрем — тарих җәмгыятенең әгъзалары авызыннан Җәгъфәр әфәндегә рәхмәт укыйм. Һәм дә ул калдырачак әйберләрне мөгальмәмнүният[170] кабул итәчәклегемезгә һәм дә саклавымызга вәгъдә бирәм. Җәгъфәр әфәнде һәрвакыт безнең җәмгыятемезгә бик зур хезмәтләре өчен җәмгыять моннан ун сәнә[171] мөкатдәм[172] аның хезмәтләрен тәкъдир кылып, аны фәхри[173] әгъза ясаган иде, бу көн миңа мәгариф нәзарәте[174] җәнабеннән[175], безнең җәмгыятемезнең соравы берлән бирелгән тарих профессоры» дәрәҗәсе берлән тәбрик кылдым, ура»,— дип сүзен бетергән иде. Халык та: «Ура, тарих профессоры!»— дип тагы бөтен залны гөрләткәннәр иде. Җәгъфәр әфәнде моңарга каршы бик мәмнүн[176] икәнлеген сөйләгәннән соң һәм шулкадәр илтифатларына рәхмәт укыганнан соң, профессор исемен болгарча бер исем иттереп бирү мөмкин түгелмелеген сорап, әгәр мөмкин булса, профессор дигән сүз урынына белгивар (белкивар) яисә белкибарга күчерүне үтенде. Рәисе мәҗлес актыккы болгарның актыккы үтенечен кабул иткәнлеген, һәм дә белкивар исеме профессор дәрәҗәсе берлән биреллдеген белгертте. Халык тагы: «Яшәсен Җәгъфәр белгивар!»— дип кычкырырга тотынды. Икенче якта болгар музыкасы гөрелдәргә тотынды. Халык та торып, берсе анда, берсе монда йөри башлады. Җәгъфәр әфәнде дә, рәсми мәҗлес беткәнне белгәч, өенә китте. Бик арып беткәнгә, йокларга дип ятса да, башыннан кичкән фикерләре берлән бик озак йоклый алмады. Күз алдына болгар мөхәррирләре, болгар муллалары, байлары, болгар ханнары, болгар хәерчеләре киләләр иде. Һәммәсе, Җәгъфәрдән әллә ни сораган кебек, тик торалар иде. Күңеленә тагы Сөембикә килеп төште. Ул тагы күз алдында торган кебек була башлады. Ул авыру төсле күренә иде, елый, кайгыра төсле беленә иде. Болар артыннан тагы икенче фикерләр килә иде. Аның артыннан — башкалары. Ләкин тыныч йокы һаман юк иде. Урамнан ишетелгән «ура» тавышына Җәгъфәр әфәнде шул арлы-бирле йокысыннан уянып китте. Ул әллә нинди арыган, кәефсез иде. Башы, тубал кебек, бер нәрсә дә уйлый алмый иде. Уянганын белгәч, хезмәтче дә килеп керде. Юынырга су әзерләгәннән соң, чәй китерергәме яисә башка әйберме, дип сорап чыгып китте. Җәгъфәр әфәнде чәй китерергә кушты. Үзе юынып киенгәнче чәй дә килде. Авырсынып кына, кай төшеннән тотып уйларга белмәенчә, Җәгъфәр әфәнде чәй эчәргә тотынды. Менә озак үтмәде, хезмәтче поднос берлән визитная карточка кертте. Җәгъфәр әфәнде: «Боерсыннар!»— диде. Һәм дә хезмәтче артыннан яшь кенә бер кеше кереп, күрешеп, Җәгъфәр әфәнде күрсәткән урынга утырды. Җәгъфәр әфәнденең: «Ни хезмәткә кушасыз?»— дигән сөаленә әдипләр җәмгыяте тарафыннан сәгать бердә биреләчәк ашка чакырырга килүен сөйләде. Җәгъфәр әфәндедән вәгъдә алгач, теге әфәнде чыгып китте. Чәйдән соң ни эшләргә дип белми торганда, Җәгъфәр әфәндегә поднос берлән өч хатын-кыз карточкасы керттеләр. Җәгъфәр әфәнде: «Керсеннәр»,— диде. Керделәр. Җәгъфәр әфәндегә кичә үзләренең моның яхшы сөйләвенә гаҗәпкә калуларын бирсен-берсе бүлә-бүлә сөйлиләр иде. Һәм Җәгъфәр әфәндегә: «Болгарларда өч ха-

171. Сәнә — ел. 172. Мөкатдәм — элек. 173. Фәхри — хөрмәтле. 174. Нәзарәт — идарә, министрлык. 175. Җәнаб — олылау сүзе. 176. Мәмнүн — шат. 177. Тәгаддеде зәүҗәт — күп хатын алу.

тын алу бик күп булган, хатыннар ничек тордылар икән?»— дип, тәгаддеде зәүҗәт[177] мәсьәләсен ачтылар. Берсе хәтта Җәгъфәр әфәндедән дә: «Сезнең хатыныгыз ничә?»— дип сорады. Болар берлән шундый мәсьәләләрне сөйләгәндә тагы карточкалар китерделәр. Карточкаларда әдипләр икәнлеге мәгълүм иде. Җәгъфәр әфәнде: «Боерсыннар»,— диде. Бу сүздән соң хатыннар да, китәргә вакыт, дип рөхсәт алып чыга башладылар. Әдипләр Җәгъфәр әфәнде берлән болгарларның психологияләре хакында сүзгә керештеләр. Берсенең сүзенә караганда, болгарның психологияләре гаҗәп дәрәҗә мантыйкый[178], имеш, икенчесенекенә генә караганда, димаглары[179] мөкаммәл булса да, хисси[180] димаг булмаган, имеш. Бу мәсьәләне Җәгъфәр әфәндегә сөйләделәр. Ул да болгарларның димаглары гали булуны һәм дә бик зур мәсьәләләрне аңларлык булуны, бераз гына укыган болгар малаеның мәгыйшәтнең һәммә мәсьәләләре хакында мөхакәмәгә кадир[181] булуын шуның соңында бер зур болгар агаеның бер кечкенә генә немец малае кадәр эшкә ярамавын сөйләде. Икесе дә Җәгъфәрнең сүзен тәсдыйк[182] кылдылар. Икенче мәсьәләгә күчәр вакытта гына тагы әллә нинди хатыннар карточкасы кертеп бирделәр. Болар императорский театрның артисткалары иде. Алар да керделәр. Җәгъфәр әфәндегә болгар драматургларының кабилиятләре хакында (сөйләп) аларның уеннарын уйнау актерларга бер ләззәт бирә, дип мәшһүр уеннардан ничәсен санап вә ничәсен бик мактадылар. Җәгъфәр әфәнде һәркайсысының мөхәррирләренең нинди кеше икәнлеген, язган галәмен бик белүләрен сөйләде. Шуның артыннан болгарларда хатыннарның качу мәсьәләсенә барып җитте. Һәм дә болгарларны, хатыннарының хокук табигыйләрен бирмәгәннәр, дип гаепләргә тотындылар. Җәгъфәр әфәнде: «Качу мәсьәләсе бездә булса да, рәсми генә иде, әмма асылда кача торган хатын-кыз һичбер вакытта йөзгә биштән артмамыштыр. Авылда хатыннар ирләр берлән бергә эшлиләр иде, бергә ашыйлар иде, сөйләшәләр иде, уйлашалар иде. Хәтта егетләр берлән кызларның бергә җыелып-җыелып уйный торган уеннары да бик күп иде. Качу бер төрле мулла хатыннарында һәм дә, мулла хатыннарына ияреп, үзләрен олуг күрсәтер өчен тырышкан бай хатыннарында, һәм дә мулла хатыннары булырга хәзерләнә торган бай кызларында гына иде. Ул да бара-тора бетте, безнең болгарларның хатыннарына иткән җинаятьләре аларны качыру түгел, бәлки аларга кирәгенчә тәрбия кылмау, аларны гыйлемнән мәхрүм калдырудыр»,— диде. Бу сүзләрдән соң хезмәтче тагы карточкалар кертте. Җәгъфәр «боерсыннар» сүзенә егерменче гасыр болгар хатыннары киемен киенгән ике хатын керделәр. Әдәп рәсмияне ифа[183] кылгач та, болгарларның киемнәре матурлыгын сөйләргә тотындылар. Болар художницалар иде. Болгарларның художестволарына сүзне бордылар. Берсе Җәгъфәр әфәндегә үзенең рәсемен дә күрсәтергә китергән иде. Рәсем кияүгә яңа бирелгән кызның кияүне көтүе иде. Рәсем яхшы эшләнгән иде. Ләкин иске фикер берлән кызның йөзен качырган иттереп эшләнгән иде. Җәгъфәр әфәнде монсын әйтте, өйдә болгар хатыннарының һичбер качмауларын... һәм хөр икәнлекләрен сөйләде. Болардан соң тагы әллә нинди музыкантлар килделәр. Алар болгар музыкасы турысында сүз ачтылар, аның артыннан тарих галимнәре, гыйльме әнсаб[184] галимнәре, алардан соң башкалары берсе артыннан берсе керепчыгып, Җәгъфәр әфәндедән төрле соальләр сорап, Җәгъфәр әфәндене сәгать бергә кадәр бушатмадылар. Җәгъфәр әфәнде, вакыты җиткәч киенеп, әдипләр җәмгыятенә китте. Халык тәмам тулган иде. Рәисе мәҗлес Җәгъфәрнең кулын кысып: «Безне йөзегезне күрү сәгадәтенә наил[185] итдекеңез өчен мәмнүнмез...— диде. Бик күп әдип-

---

178. Мантыйкый — логик, эзлекле. 179. Димаг — ми. 180. Хисси — сизгер, тойгылы.
181. Кадир — булдыра алучы. 182. Тәсдыйк — раслау.

лар курештеләр. Җәгъфәр әфәнденең әсәрләре хакында мөхакәмәгә керештеләр. Мөнтәкыйтьләрен[186] гаепләделәр. «Менә мин фәлән урнын аңламыйм»,— диеп, «фәлән җире шулай булырга кирәк?»— дип әдәби мәсьәләләр ачтылар. Бер шагыйрә хатын: «Сез шулкадәр кабилият (талант) белән ник шигырь язмадыгыз»,— диде. Җәгъфәр әфәнде шигырьне яратмавын, егерме икенче гасырда шигырь берлән уйнар вакыт түгеллеген белдерде, теге даманың бер дә һушына китмәде. Ашлар бирелә башланды. Җәгъфәр әфәнде иң түр урынга утырды. Мәҗлестә төрле мәсьәлә хакында сүз ачылды. Аш вакыты булганга, табигый буларак, болгарларның ашавы мәйданга чыкты. Җәгъфәр әфәндедән: «Бертөрле кешеләр көненә ун мәртәбә ашаганнар, имеш»,— дип тә сорадылар. Җәгъфәр әфәнде корбан бәйрәме дигән бәйрәмдә һәм мәүлет бәйрәмнәрендә муллалар ун җирдә дүртбиш төрле блюдадан ашауларын сөйләде. Бөтен мәҗлес гаҗәпкә калдылар. Бер дама: «Хатыннарда чәйне дә бик күп эчү гадәте булган имеш,— диде. Җәгъфәр әфәнде мулла хатыннарында көненә унар мәртәбә берәр чиләкле самавырдан чәй эчкән хатыннар бик күп булуын сөйләп, хәтта шундый ашап — эчүдән бушамый торган кешеләр тасвир кылынган, егерменче гасыр мөхәрриренең әсәрләреннән булган бер романның да исемен әйтте. Бик күбесе романның исемен язып та алдылар. Аш беткәннән соң, бер картрак хатын кафедрага чыгып сөйләргә башлады: «Бу аш безнең иптәшләремездән болгар мөхәррирләренең иң зур кабилияткә малик[187] булганнарыннан иң актыккы болгар мөхәррире, иң актыккы болгар Җәгъфәр әфәнде исеменә бирелмештер. Җәгъфәр әфәнде болгар мөхәррирләренең берсе булганган, шул арада шулкадәр сөйләнгән болгар әдәбияты, әдипләре хакында мин дә бераз сүз сөйләмәкче булдым. Болгарларның калдырган нәрсәләре бик күп булса да, моның да иң әһәмиятлесе, иң файдалысы — болгар әдәбиятыдыр. Болгар әдәбияты болгарлар тарафыннан язылганга күрә, болгарларның әсәр кадимәләреннән[188] берсе булдыгы шикелле, фикер (әйтергә) теләп, аңлап язылганга күрә, файдалы бер әдәбияттыр. Болгар әдәбиятында без ачык болгар тормышын таптыгымыз кебек, бик ачык әхлак дәресе дә алачакмыз. Боларның психологияләре ачыклыкны теләгәнгә, боларның әсәрләрендә һәммә фикер ачык иттереп сөйләнмештер. Әдәбиятта беренче дәрәҗәдә санала торган психологиянең тугрылыгы, тормышка муафыйклыгы тәмамән болгар әдәбиятында ригая[189] кылынгандыр. Шуның өчен болгар әдәбияты безнең арамызда һәм башка кавемнәр арасында әһәмиятле мәүкыйг[190] иттихаз[191] итәчәктер. Болгар әдипләре дә, әдәбиятлары кеби, җитди кешеләр генә булгангамы, болар арасыннан да, бәгъзе француз романнары кебек, мәгънәсез, кәгазь әрәм иткеч хикәяләр бер дә булмадыгы кеби, болар үзләренең карендәш госманлы төрекләре кебек, тормышларын тасвир урнына әллә нинди... ят халык тормышын тасвирлар күренмидер. Хәтта болар әдәбиятында тәрҗемә дә бик аздыр. Болгар әдипләре, тәрҗемәләр милли әдәбиятка зарар итәчәген белеп, милли рухны саклар өчен, мөмкин кадәр тәрҗемәдән сакланганнардыр. Болгарларның табигатьләрендәге үзләрен сөю тәрҗемәләргә бик аз кешене генә укырга бушатмыштыр. Болгар әдипләре аңлаган фикерләрен бик зур мәшәкатьләр берлән тапканга, халыкларын, начарлыкларын үз тәҗрибәләре берлән кәшеф[192] кылганга, боларның әдәбиятларында үзсүзлелек («самостоятельность») һәм дә курыкмый әйтү кебек артыклыклар бардыр.

Болар үзләре никадәр җилбәзәк халык булсалар да, боларның мөхәррирләре һәммәсе җитди кешеләр булмышлардыр. Болгарның әдәбияты булса да, әдипләре булса да, әдәбиятлары тәрәккый иткән,

183. Ифа — эшне үтәү. 184. Гыйльме әнсаб — нәселләрне өйрәнү фәне. 185. Наил — ирешү. 186. Мөнтәкыйть — тәнкыйтьче. 187. Малик — ия, хуҗа. 188. Кадимәләре — борынгы.

дию мөмкин түгелдер. Боларда китап басу, китап нәшер кылу бик күп булса да, боларның йөздән берсе генә китап исемен күтәрерлек иде. Калганнары файда урынына зарар китереп, болгарларның димагларын гына пычраталар иде. Боларның әдипләре һәрвакыт бик зур мәшәкатьләр күрмешләрдер. Һәрвакытта халык арасында бер көлке кеше кебек, яисә җүләр кебек, бер дә булмаса, динсез кебек тотылмышлардыр. Боларның әсәрләрен тәкъдир кылучылар да итчеләр, тегүчеләр, күмәччеләр берлән боларга һәрвакыт дошманлык күзе берлән караган голәмалар иде. Шуның өчен болар туры бер сүз ишетүдән, үзләренең хезмәтләре өчен рәхмәт ишетүдән, үз эшләрен ташлап, милләт хезмәтен иттекләре өчен олылаудан-фәләннән һәрвакыт тыныч булмышлардыр. Боларның тормышлары фәкыйрьлектә үтеп, шул фәкыйрьлек саенда эшли алачак бик күп нәрсәне эшли алмаенча калмышлардыр. Болгарлар әдәбияты, болгар әдипләре башка халык әдәбияты кебек, һичкем тарафыннан химая кылынмамыштыр. Болгарларда милләт юлына акчалар сарыф кылу булса да, бу милләт юлын алар мәктәпләр ачу, үлгәннәргә кәфен бирү, тап-таза егетләргә, япь-яшь кызларга бушлай акча өләшүдән уздырмаганнардыр. Боларда әдәбиятның иң әһәмиятле нәрсә икәнлеге, әдәбиятсыз милләт җансыз тән кебек икәнлеге, әдәбиятсыз милләтнең тәрәккые мөмкин түгел икәнлеге беленсә дә, илтифатка алынмамыштыр. Иштә[193] Җәгъфәр әфәнде шул милләтнең әдипләренең берсе һәм дә иң зур кабилияткә малигыйдыр[194]. Бик күбемезнең күргән, укыган болгар китапларымыз бу гасырда бөтенләй мөнкарыйз булган болгарларның җаннары, ягъни аларны хәрәкәткә китерә торган кешеләр тарафыннан язылмыш кыйммәтдар әсәрләредер. Боларның арасында бик гали фәлсәфә берлән тулы китаплар, бик саф көлке белән зиннәтләнгән хикәяләр, бик ачы-ачы күз яшьләре тасвир кылынган романнар бик күптер. Шушы җәмгыятьтә хазир[195] булган иптәшләрем тарафыннан Җәгъфәр әфәндегә безнең мәҗлесләремезгә килеп безне шат иттеге өчен рәхмәт укыганнан соң, җәмгыять тарафыннан аңарга тәкъдим итәр өчен әзерләнгән «әдәбият профессоры» исеме берлән тәбрик кылам», — диде дә дөньяны кузгата торган тавышлар арасында урыныннан төште.

Җәгъфәр әфәнде... болгар әдәбиятына болгарларның үзләренең иң кирәкмәс эш, эшсезләр генә эшли торган нәрсә, дип карауларын уйлап гаҗәпкә калды. Бу даманың әйткән сүзләре һәммәсе Җәгъфәр әфәндегә шулкадәр тәэсир кылды, ул болгарларның Габделкаюм-әл-Насыйри, Шиһаб әл-Мәрҗанидән үзенә кадәр булганнарының һәммәсен хәтереннән кичерде. Аларның күргән мәшәкатьләрен, эшләгән эшләрен, ярдәм булса, кыла алачак эшләрен — һәммәсен уйлады. Һәммәсе Җәгъфәр әфәндегә кызганыч күренде. Һәммәсе өчен күңеленнән җылады. Җәгъфәр әфәнде теге дамага каршы кыскача гына: «Сезнең миңа шулкадәр илтифатыгыз өчен бик рәхмәт. Хосусән[196] без болгарларның иң мәкатдәс, иң зур болгарлык көзгесе булган әдәбиятымызны саклау вазифасын өстеңезгә алуыгыз өчен бөтен болгар әдипләре тарафыннан сезгә рәхмәт укыймын. Үземез саклый алмаган әдәбиятымызны сез сакладыңыз, үземез тәкъдир кыла алмаган әдәбиятымызны сез тәкъдир кылыңыз, үземез аяк астына таптадыгымыз әдәбиятны сез баш өстенә күтәреңез. Болгар әдипләренең рухларын мәмнүн итеңез. Үз гомерләрендә күрмәгән һәм күрүне уйлый алмаган дәрәҗәдә, аларны сезнең олылавыңыз өчен мөтәшәккирлегемне[197] әйтеп бетерә алмыйм. Болгар әдәбияты хакында сезнең асраган фикерләреңез, хосусән, мадам «Дәрест»* тарафыннан сөйләгән сүзләр болгар әдәбияты, болгарлар бер вакытта нә болгар авызыннан,

189. Ригая — игътибар итү, кайгырту. 190. Мәүкыйг — урын, җир. 191. Иттихаз — кабул итү. 192. Кәшеф кылу — ачып ясау. 193. Иштә — менә, шушы. 194. Кабилияткә малик — сәләткә ия.

нә икенче милләт әдипләре авызыннан ишетелмәмеш иде. Аның галилеге, җитдилеге моннан ике йөз ел мөкатдәм[198] дә шул дәрәҗәдә булса да, ул әдәбият гаепле нәрсә кебек, пәрдә астында торган иде. Болгарларның фәхеш юлына хезмәт итүчеләре мәсләкләренә ачык хезмәт итсәләр дә, бөтен болгар милләте булмаса да, бик күбесе итәк астыннан шуны химая[199] кылсалар да, болгар әдәбияты үзенә арка таяначак җир тапмамыш, үзен мәйданга чыгарырлык җәсарәт[200] тә хасыйл итә алмамыш иде. Сез аны чыгарып, шәрык хатыннары кебек пәрдә астына качкан шул гүзәл нәрсәнең һәм дә кешегә ләззәтләндерерлек итеп йөзен ачтыңыз, матурлык оят түгеллеген, хаклык гаеп түгеллеген бәян итеп, аларны каплаган үрмәкүч оялары бетердеңез. Рәхмәт сезгә! Яшәңез!» — диде дә утырды. Бу сүздән соң башка мөхәррирләр дә речьләр сөйләделәр, болгарларның нәмүнә[201] мөхәррирләренең әсәрләреннән кыска-кыска мәкаләләр укыдылар. Зур мөхәррирләренең тәрҗемәи хәлләрен сөйләделәр, рәсемнәрен күрсәттеләр, соңыннан да һәммә җирдә сүз шул хакта булды. Җәгъфәр әфәндегә шул җәмгыятьнең «болгар әдәбият музее исемендә болгарларда матбагачылык башланганнан бу көнгә кадәр килгән болгар китаплары илә тулы музейга, эстәсә, керергә рөхсәт бирделәр... Җәгъфәр әфәндегә күрсәтеп йөрергә бик күп кеше үзенең хезмәткә әзер икәнлеген бәян кылсалар да, Җәгъфәр әфәнде ялгыз гына барачак булды. Һәм дә китте. Музейда, телефон берлән әйтелгәнгә, Җәгъфәр әфәндене каршы алып, музейның һәммә бүлмәләрен ачык куйдылар. Ә музей күптән түгел генә Әдипләр җәмгыятенә бирелгәнгә, ислах кылынып җитмәгән иде. Бик зур залның һәммә тарафында китап тулган иде. Бер почмакта бик биек иттереп өеп куйган китаплар янына барды. Өстенә зур кәгазь берлән нинди китап икәнлекләре, нинди фәннән икәнлеге язылган булса да, Җәгъфәр әфәнде, анысына карамаенча, бер китапны алып ачты. Күзенә «Нифас[202] хатыннарның рәхемнәреннән[203] килә торган кан...» дигән сүзне күргәч тә, нинди китап икәнлеген белде. Тиз генә икенчесен алды. Моны да ачты. Күзенә, «кыш көне истинҗаны[204] артка таба кылырга», дигән сүз чагылгач, баягыдан да кәефе китеп, аз гына ыргытып бәрмәде. Өченчесен алып ачса, «җимаг[205] вә госел[206]» дигән сүзне күргәч тә, ансын да ташлады. Җәгъфәр әфәнде бу кадәр күп, тау кебек тора торган китапларга карап, тагы карасa да, «зина», «ливата[207]» чыгар дип курkып, карамаска башлады. Һәм күңеленә болгарларның к... мәсьәләләреннән үтә алмауларына бик гаҗәпкә калды. Һәм дә вакыйгда[208], әллә болар шундый к...тән башканы белми торган сәфил[209], халык микән, дип тә уйлады. Исәпләп кенә моннан киткәндә, бер җиргә бәрелде дә, әллә нәрсәләр дөбердәде, карарга өлгерә алмады. Җәгъфәр әфәнде үзен китаплар астында хис итте. Селкенергә тотынды. Чыгарга тырышты, булмады. Тын алырга һава кирәрлек тишекләр генә калганга, Җәгъфәр әфәнденең шул тишек турысында ята торган бер китапка күзе төште. «Сарыф лисан гарәби»[210] дип язылган иде. Никадәр маташса да, чыга алмады, тирләде, пеште, ачуы килде. Һәммә тишектән моны мыскыллаган кебек, «Гарәпче сарыф», «Сарыф Әхмәтҗани», «Сарыф Әхсани» кебек сүзләр күренәләр иде. Тагы бераз булса, бәлки Җәгъфәр әфәнде, үлмәсә дә, бераз авырлыкта булган булыр иде. Бәхетенә каршы, хезмәтче килеп җитеп, Җәгъфәр әфәндене чыгарды. Җәгъфәр әфәнде чыкты да, бераз селкенгәннән соң, китапларны карарга тотынды. Боларның һәммәсе гарәп лисаnының сарыфы иде. Һәммәсе дә эшкә ярамаган һәм ярарлык булмаган

---

195. Хазир — күз алдында булган. 196. Хосусән — бигрәк тә, аеруча. 197. Мөтәшәккир — рәхмәт әйтүче. 198. Мөкатдәм — элек. 199. Химая — яклау, саклау.
* «Дөрест» — шулай язылган.
200. Җәсарәт — батырлык, кыюлык. 201. Нәмүнә — үрнәк.

китаплар иде. Болар шулкадәр күп иде, әгәр дә боларның гадәден[211] бер француз статистигына әйтсәң, гарәп сарыфына шулкадәр китап язылган, русчага, әлбәттә, артык фарсычага моның яртысы гына булсын, французча, немецчә, әлбәттә, фарсычадан ким түгел, үз телләре эченә, әлбәттә, гарәпчә кадәр икедән ким булмаска кирәк дип, болгарлар хакында гыйльме лисанның ни дәрәҗә тәраккый итүе хакында бер бик ялгыш кагыйдә чыгару ихтималы бар иде. Монда гарәп «Сарыф» дигән сүзләргә изафәсе[212] мөмкин булган сүзнең берсе дә калмаган иде. Болар үзләре төрлесе төрле гасырда төрле кешеләр тарафыннан язылса да, «Тәрбиятел әтфаль[213]»гә мөхәләфәте[214] белән бер авыздан чыккан кебек иде, боларның исемнәре, кәгазьләре, мөхәррирләре башка булса да, мәелләре[215], әлеге «фәрра», әлеге «Баг», иске «Акшыгарра»[216] иде. Болар һәммәсе дә «Шәрхе Габдулла»ны бутап — чутап үз исеме өстенә «мөхәррире Әхмәтҗан», яисә «мөәллифе[217] Мөхәммәтҗан», яисә «Каделфалгабид әлфәкыйр Габдулла бине фәлән» дигән кебек сүзләрне куяр өчен башын к...кә, к...ен уртага китергәннәр иде. Җәгъфәр әфәнде бу кадәр күп бертөрле китапның язылуын һич аңлый алмады. Гарәп теле шулкадәр мөгтәбәр булган, күрәсең, дияр иде тарихта күреп болгарларның иң зур голәма, мөдәррисләренең дә гарәпчә бер авыз сүзгә икътидарлары[218] юклыгын бик яхшы белә иде — хасыйле[219] бу табышмакны ничек тә таба алмый иде. Ахырдан мәсләксез-нисез «Шәрхе Габдулла»сы бар һәр кеше: «Кеше китап яза, мин дә языйм», — дип язганлардыр, диде дә эчкә таба китте. Күзенә борчак чүмәләсе кадәр өелгән китаплар күренде. Карый башлады. Ни күзе белән күрсен — тәҗвид[220] «Мифтахел Тәҗвид», «Тәҗвид Зыяйи», «Тәҗвид әхвәл», «Мөфассал[221] тәҗвид», «Балаларга тәҗвид», «Мохтасар[222] тәҗвид» вә моның төсле йөзләрчә исемнәр илә тәҗвид китаплары өелгән иде. Монда нәсер берлән, шигырь берлән язылган сәальле-җаваплы, бәянлылары, тышына авыз сурәте төшерелгәннәре, һәм «хокукы мөхәррирена махсус», дип язылганнарының исәбе-хисабы юк иде. Карый башлады, һәммәсе «кара баш»тан күчергән дә, үз исемен язып куйган иде.

Җәгъфәр әфәнде: «Бу ник безнең халык эшләмиенчә шөһрәт тотарга ярата икән», — диде. Һәм дә тәҗвидләргә карап: «Әгәр коръән лафзына[223] биргән әһәмиятнең йөздән берен генә мәгънәсенә бирелсә иде, бу көн болай булмас идек, лафыз харап итте безне, лафыз», — диде дә тагы эчкә китте. Күзенә әллә нинди зур табак кәгазьгә эшләнгән Истанбул сурәтләре, Мәккә, Мәдинә сурәтләре, кыямәт агачлары, сидрәтелментаһа[224] башмак шәрифләр, таяклар, яшь ага торган күз сурәте бик биек иттереп өелгән иде... Боларны күргәч, Җәгъфәр әфәнде, менә болгарларның сәнаигы нәфисәсе[225] диде дә, карап та тормады. Тагы эчкә китте. Күз алдына килгән өем кәгазьне карый башлады: «Җен бөтие», «Пәри догасы», «Сөйдергеч», «Байлык догасы», «Тылсым», «Сарымсак догасы», «Догаикадәри»[226] вә башка әллә нинди догалар тулган иде. Боларның һәммәсенең башына хәз-

---

202. Нифас — аналык каны. 203. Рәхем — аналык. 204. Истинҗа — тәрәттән соң пакьләнү. 205. Җимаг — җенси акт. 206. Госел — коену. 207. Ливата — Мифик Лут кавемендә таралган бозыклык. 208. Вакыйг — чын, чынлык. 209. Сәфил — түбән, хур. 210. Сарыф лисан гарәби — гарәп теле морфологиясе. 211. Гадәд — сан. 212. Изафә — кушу, тоташтыру. 213. Тәрбиятел әтфаль — балалар тәрбияләү. 214. Мөхәләфәт — каршылык. 215. Мәел — күңел кую, мәхәббәт. 216. «Фәрра», «Баг», «Акшыгарра» — «Шәрхе мулла»га ияреп язылган дәреслекләрдән котылу өчен кулланылган мәгънәсез сүзләр. 217. Мөәллиф — төзүче. 218. Икътидар — сәләт, көч. 220. Тәҗвид — коръәнне дөрес укучы турындагы кагыйдәләр. 219. Хасыйле — кыскасы. 221. Мөфассал — җентекләп аңлатылган. 222. Мохтасар — кыскартылган. 223. Лафыз — сүз. 224. Сидрәтелментаһа — күкнең җиденче катындагы бер урын (миф). 225. Сәнаигы нәфисә — сәнгать.

рәт рәсүлулладан риваятьләр язылган иде. Һәм шулай дөрес чыгуына әллә нинди вәгъдәләр кыйлынган иде. Җәгъфәр әфәнде боларны күргәч тә, менә ул безне алдап эштән калдыручылар, безне ялкаулыкка өйрәтүчеләр, диде дә, кулына эләккәннәрен бик каты күтәреп бәрде. Моның артыннан күзенә аз гына китап күренде, боларны барып караса, гарәп нәхүе[227] булып чыктылар. Боларны күргәч, Җәгъфәр әфәнде ихтыярсыз көлде. Күңеленнән генә булса да гарәпнең нәхүен шуннан артык белгән булмаган икән, булса, мотлак язмый калмаслар иде, диде. Бер төштә «мантыйк» дип язып куелган китаплар янына барды, ачты, карады, һич мантыйк диярлек бер китап күрә алмады. Һәммәсендә әллә нинди низаг лафызлары тулган иде, актара-актара ватылган гарәп теле берлән язылган, бер-ике мең ел мәкатдәм мәгълүм булган мантыйк кагыйдәләрен кайсысын да тапты. Һәммәсе искергән, черегән, эштән чыккан иде. Болар арасында болгарча язылганы булса да, һәммәсе дә бер хәерче капчыгы иде. Боларга карап, Җәгъфәр әфәнде: «Безнең голәмәмезнең калебләрен зәһәрләүгә болар кадәр хезмәт иткән нәрсә булмаган, халыкны җаһил мәркәб[228] итеп тота торган, башка нәрсәне уйларга башының кабилиятен калдырмауга болар төсле хезмәт иткән нәрсә булмаган», — диде дә тагы башка китаплар янына китте. Юлда күп кенә китаплар булса да, Җәгъфәр әфәнденең күзе болгар гәзитәләре дигән кәгазьгә төште дә, ашыга-ашыга шунда таба китте. Монда болгарларның төрле гасырда төрле исемнәрдә чыгарылган дәвери[229] әдәбияты җыелган иде. Иң әүвәл Җәгъфәр әфәнденең күзе «Тәрҗеман»га төште. Җәгъфәр әфәнде ихтыярсыз зур кочак «Тәрҗеман» гәзитәләрен кочаклады да, күзендин теләр-теләмәс яшь ага башлады. Саташкан кеше кебек, боларның аерым номерларын алып ачты. Йөзенә сөртте, күзләреннән аккан яшьләр берлән «Тәрҗеман»ның каләме очыннан чыккан яшьләр бергә кушылды. Иң беренче гәзитә мөхәррире, иң беренче милләтпәрвәр, иң беренче хәмия миллия[230] уяткан, иң беренче мәңгелек йокыдан уянып, иптәшләрен уяткан, бөтен болгар галәменә мәгариф, гыйлем зыясын[231] сачкан Исмәгыйль бәк* берлән сөйләшкән кебек булды. Аның берлән болгар мәсьәләләрен мөхәкәмә кылган кебек булды. Аның күңеленә Исмагыйль бәкнең.... туңган, каткан башлар «Тәрҗеман»ның электрик җылысы берлән эрүләре, үлгән, беткән җаннарның терелүләре, хәрәкәткә килүләре, хасыйлы болгарлар арасында бүген сөйләгән, бүген мактанган һәм макталырга сәләхиятле нәрсәнең һәммәсенең дә мөәссисе[232], сәбәпчесе «Тәрҗеман» мөхәррире икәнлеген уйлап болгарлардан да шулкадәр гали кешедәр чыккан, ник бу беткән соң? — дип хәйрәткә[233] калды. Бу гәзитәләргә карап, бик озак катып торды. Моңарга гәзитәнең теле, язуы, рәвеше һәммәсе мөкатдәс кебек күренә иде. Боларны карады, укыды, һәр сүзе алтыннан кыйммәтле, һәр сүзе хакыйкать, һәр сүзендә калебтән[234] чыканлык беленеп тора иде. Әгәр унтугызынчы гасыр халкы кебек, яхшы сүзләрне язып эчүнең авырудан файдасы булуына һәм бөтиләрнең җеннән саклавына ышанса иде, Җәгъфәр әфәнде боларны җиде көн, җиде төн җидешәр тәрилкәгә генә язып эчмәенчә, җитмеш ел буенча, җитмеш тәрилкәгә язып эчәр иде. Һәм дә шундагы мәкаләләрне карындык, сәхтияннәргә[235] төрәп берне генә такмаенча, бөтен җирен шуның берлән тутырыр иде. Һәм дә шул «Тәрҗеман» мәкаләләреннән генә истиганә[236] таләп кыйлыр иде. Моның күршесендә Казанда

---

226. Догаикадәри — тәкъдир догасы. 227. Нәху — синтаксис. 228. Җаһил мәркәб — атланып йөри торган надан хайван. 229. Дәвери — периодик. 230. Хәмия миллия — милләтне яклау, милли патриотизм. 231. Зыя. — яктылык. 232. Мөәссәс — нигез салучы. *Исмәгыйль Гаспралы (1861-1914) — язучы, журналист, җәмәгать эшлеклесе, Бакчасарай шәһәрендә чыккан «Тәрҗеман» газетасының (1883-1918) нәшире һәм редакторы. 233. Хәйрәт — аптырау. 234. Калеб — йөрәк.

чыккан «Кабан» дигән гәзитә өелгән иде. Бу гәзитә «Тәрҗеман»ның баласы һәм аның хезмәтчесе иде. Бу гәзитә дә егерменче гасырның башында ук чыга башлап, утыз бишенче елга кадәр дәвам иткән һәм дә халык арасында бик яңа мәсьәләләрнең ачылуына сәбәп булган, туңган димагларны эреткән, халыкка гайрәте хәмият, садакат[237] бергән иде. Моның да янында бик озак торды, мәкаләләрен укыды, тәфрика[238] сурәтендә язылган хикәяләрен, романнарын карады. Һәммәсеннән болгар исе чыга, һәммәсе дә болгарлыктан хәбәр бирә иде. Моның янында Казанда егерменче гасыр башларында ун сәнә генә дәвам итеп, алучылары булмаенча ябылган «Игенче» дигән гәзитәне карарга тотынды. Бу гәзитә болгарлар арасында игенчелекне ислах кылу фикеренә хезмәт иткән иде. Һәм дә болгарлар арасында төрле укулар, һөнәрләр таратырга да бик иҗтиһад кылган иде. Моның соңыннан Оренбургта нәшер кылынган «Сакмар» гәзитәләрен, Әстерхандагы «Хәзәр», «Барабыз» исемендәге гәзитәләрен һәм дә болгарның «Уку», «Дин» исемендәге журналларын «Мулла» исемендәге көлке гәзитәләрен — һәммәсен карады. Һәммәсенә исе китте. Һәммәсенең мөхәррирләренең рәсемнәре һәм дә кайсысының каләме, кайсысының кара савыты, зур кешеләр берлән язышкан хатлары да бар иде. Һәммәсеннән бер дәрт, өмид, ләкин үлә торган ис чыга иде. Һәммәсе бер нәрсәдән зарланалар иде — һәммәсе милләтнең китешеннән һәм үзләренең тормышларыннан разый түгелләр иде. Болардан китте. Кечкенә генә өеп куйган китапларны карый башлады. Болар романнар, хикәяләр, театр китаплары иде. Кайсысын укыды, кайсысын карады. Бик күбесе үзендә барлар, укылганнар, бик ачы күз яшьләре тасвир кылганнары — тормышымызга бик каты-каты һөҗүмнәр, тормышларымызның начар якларын күрсәтүләр, тормышны ислахка юллар күрсәтүләр, идеаллар берлән тулганнары бар иде. Ләкин болар никадәр яхшы булсалар да, шул кадәр аз таралганлыклары боларның ничә мәртәбә нәшер кылынуларыннан күренеп тора иде. Боларның күбесе начар кәгазьгә эшләнелгән, начар типографияләрдә начар хәрефләр берлән басылган иде. Тышларында: «Һәр хокукы мөхәрриренә гаидтер» сүзләре, сирәк-сорак кына мөхәррирләреннән башкаларның «нашире — фәлән» дигән сүзләре күренде. Бу сүзләр болгарларда рәтле нәширләрнең булмавын, булганнарының «фәзаиллешшоһүр» наширеннән узмауларын күрсәтеп тора иде. Җәгъфәр әфәнде шулкадәр зур халык арасында милләт өчен никадәр маллар кызганмаган кешеләр була торып, иң беренче кирәкле эшкә тотынучысы табылмавына моңгарча да гаҗәпкә калса да, бу вакытта бигрәк гаҗәпкә калган иде. Моның артыннан музыка ноталарын карады, шагыйрьләр кыйсмен карады. Болгар шагыйрьләренең шигырьләре Җәгъфәр әфәндегә тагы тәэсирле, болгар шигыренең рәвеше, «силлабическое» бигрәк табигый, төпле күренә иде. Бик күп шагыйрьләрнең әсәрләрен карады. Бик күбесенең тормышы хакында уйланды, бик күбесенең нинди мәшәкатьләр күргән көнеленнән кичерде. Моннан да борылды, нишләсен. «Ысул җәдид — ысул гатыйк[239] низаглары» дигән сүзгә күзе төште. Өелгән китапларны карый башлады. Җыен мәгънәсез мәсьәләләрне әллә нинди мәгънәсез сүзләр берлән сөйләнгән иде. Кайсысында «ля» кирәклеге бик зур бер мәсьәлә итеп язылган, кайсысында әбҗәтнең диннең әсасы булуын дәгъвә кылынган иде. Монда һич диндә эше булмаган, әхлаксызлыклары берлән бөтен дөньяда шөһрәт тоткан фәхеш галәменең каһарманнары һәм әфьюн тәэсиреннән рамазанда да котыла алмаган, вак[240] баласеннән мәсҗеттә дә аерылып тора алмаган кешеләр дә үзләрен бик диндар итеп күрсәткән булып, үзләренең кыйлганнарын бер дә күрмәенчә, тавыш берлән укытуда көфер барлыгын, дингә ярамавын кычкырып-

---

235. Сәхтиян — йомшак күн. 236. Истиганә — ярдәм. 237. Садакат — тугрылык. 238. Тәфрика — төрлеләр мәгънәсендә. 239. Гатыйк — иске, кадим.

бакырып сөйләгәннәр иде. Һәм дә болар арасында болгарларда җүләрханә (сумашедший дом) булмау сәбәбеннән гакыллылар арасында йөреп, үзен гакыллы диеп белеп, шундый эшләргә катышкан кешеләрнең мөхакәмәләре бар иде. Җәгъфәр әфәнде боларны карый-карый бик арган иде. Бөтенләй карап бетермәсә дә, хәзер бу китаплар һәммәсе күзенә төтен берлән капланган кебек күренгәнгә, номерына кайтып бераз хәл җыйгач, яңадан килеп караячак булып кайтып китте. Күргәнен, ишеткәнен тәртипкә салып бетерә алмаенча бик арганга күрә, бераз хәл җыяр өчен ятып алмакчы булды. Һәм дә ятты. Башы тулып беткәнгә, рәтләп йокыга китә алмады. Китсә дә, йокысының рәте булмады. Әллә нинди болгар музыкалары, болгар әдипләре, болгар галимнәре берлән башы әйләнеп бетте. Һәммәсе берлән бергә әллә нинди судан бер пароход берлән китәләр, имеш. Пароходта озын көйгә болгарча: «Калган хәтер, үткән гомер, егласаң да, кайтмыйдыр», — диеп җырлыйлар, имеш. Көн матур, имеш. Кояш ялтыраган, имеш, җир һаман караңгылана, имеш. Капитан болгар, имеш. Ул бер мулла төсле чалма-чапан кигән, имеш. Лоцманнар бик зур корсаклы унтугызынчы гасыр байлары төсле кешеләр, имеш. Һаман баралар, имеш, баралар, имеш, боларга юлда бозлар очрый, имеш. Казан караңгы, кояш тотылган, имеш. Күк йөзендә йолдызлар да ялт-йолт итеп күренеп китәләр, имеш. Менә Сөембикә манарасы тугрысында булдылар, имеш. Манара селкенә, имеш. Манара — кеще, имеш, манара авырый, имеш, баягы капитан янә килде, имеш, ул хәзер кара чалма, сары чапан кигән, имеш, күзләре ялт-йолт итә, имеш. Ул манараны караучы, имеш, ул аны аударпмаска тырыша, имеш. Манара селкенгән саен, күтәрелгән җиренә чапан кыстыра, имеш, менә манарага керде, имеш, менә тагы селкенә, менә ава, менә бетә, имеш. Менә башындагы ае селкенә, имеш, менә актык селкенүе — ауды, ае да күздән югалды, теге капитан да ут булып югалды, имеш, караңгы, имеш, күзгә төртсәң күренмәс, имеш. Менә Җәгъфәр белгуар[241] арык атка атланып, Гаязетдин үзбәк хан берлән очып килделәр, имеш. Намаз укымакчы булдылар, имеш, бер нәрсә дә юк, имеш. Менә бер яктан Олуг Мөхәммәт хан чыкты, имеш, озак үтмәде, өрпәк сарган, кара күлмәк кигән Сөембикә чыкты, имеш. Һәммәсе Сөембикәне күргәч, аңарга килделәр, имеш, ул: «Килмәгез, килмәгез, мин беттем», — ди имеш тә, Җәгъфәр белгуар да ташка әйләнде. Олуг Мөхәммәт күздән югалды. Үзбәк хан да шунда егылып үлде, имеш. Менә Сөембикәгә әллә кайдан: «Үзбәк тә үлде, Олуг Мөхәммәт тә үлде, Җәгъфәр белгуар да үлде инде, син генә калмакчы буласыңмы», — дигән тавыш та ишетелде, имеш. «Бетте», — диеп Сөембикә дә егылды, имеш. Бу тавышка Җәгъфәр уянып китте, шыбыр тиргә баткан иде. Ни күргәнен рәтләп уйларга башы да юк иде. Уянып китүенә, «Сөембикә үлде», — дигән тавыш ишетелгән кебек булды, һәм күңеленә жу итеп Сөембикә үлүе урынлашты. Һич хәбәр-фәлән алмаса да, Җәгъфәр әфәнде Сөембикә үлде дип, кистереп куйды. Әйберләрен дә карамады, бик тиз вокзалга чапты. Анда очраган кешеләрнең сүзләренә җавап бирмәенчә, вокзалдагы кешеләрнең моны төрлечә тәгъзим[242] кылуларын күрмәенчә, шул сәгать поездга утырып китте. Һәм шул көнне Казан аша утарына китте. Казаннан үткәндә Сөембикә башнясын күрде, вакыйган[243], селкенеп тора төсле иде. Вокзалдан атлар алып, бик ашыгып, бер нәрсә күрмәенчә өенә кайтып керде, тишенмәде-нитмәде, тугры Сөембикә бүлмәсенә керде. Сөембикә сары киемдә иде. Бүлмә караңгы гына иде, лампа яктысы да, аз гына төшеп, Сөембикәнең йөзен моң иттереп күрсәтә иде. Җәгъфәрне күрү белән күзе аңар төште. Теле тигәнгә[244], кулы берлән, күзе берлән тизрәк кил, дигән кебек була иде. Җәгъфәр янына барып тезләнде, ку-

---

240. Вак — тел астына сала торган тәмәке. 241. Белгуар — профессор.

лын үпте. Күзеннән аккан яшьләр дә Сөембикәнең салкын кулыннан ага башладылар. Сөембикә бик озак Җәгъфәрнең күзенә карап торды да: «Бетте!» — диде дә җан бирде. Җәгъфәр дә, кулын тотып үбеп, еглады-еглады да, хәле беткәч, үз бүлмәсенә чыгып, бераз хәл җыйды. Җәгъфәргә баланың үле тууын һәм Сөембикәнең кушуы буенча «Туктамыш» исеме кушылуын белдерделәр. Җәгъфәр баланы китерергә кушты. Китерделәр. Җәгъфәр әфәнде: «Актык болгарның актык баласы, актык үлек», — диде дә һушсыз булып егылды.

Иртәгесен Җәгъфәр әфәнде зират казытып, Сөембикәне күмде. Казаннан вә башка җирләрдән бик күп кешеләр җыелган иде. Һәм дә Петербургтан да бик күп җәмгыятьләр тарафыннан тәкъзиягә бик күп кешеләр килгәннәр иде. Җәгъфәр әфәнденең үтенүе буенча, тәмам мөселманча кәфеннәр тегелеп вә зират казылып, мөселманча күтәрелеп барылып күмелде. Җәгъфәр әфәнде үзенең кая барасын, ни эшлисен белмәенчә, өйдә тора алмаганга, Казанга китте. Бару берлән Сөембикә манарасына барса да, манараның төбеннән ишелүен, һәм дә манараның ташларын арчуларын күргәч, нишләргә белмәенчә, шәһре Болгарга юнәлде. Анда барды.

Болгарларның зиратларында ташларын карап, аларның ничәнче елларда торуларын исәпләп һәм ул вакытта аларның нинди шәһәрләре барлыгын уйлап торып, йөреп арып беткәннән соң, манарага менеп, Болгарның әтрафын[245] карарга тотынды. Манараның ташларында әллә никадәр язулар язылган иде. Һәммә ташта бер кешенең фәлән ел килүе, фәлән кеше берлән килүләре язылган иде. Җәгъфәр әфәнде манарага карап, һич караучысыз, җансыз нәрсә ничә йөз еллар торуын, болгарларның никадәр эшләр эшләгәннең соңында, нинди зур халык булып торганнан соң да бетүенә гаҗәпкә кала иде. Ахырында, бу манараның шул нигезе таза салынгандыр, безнең һәммә эшемез төтен өстенә корыла иде, шул сәбәптән беткән, диеп хөкем чыгарды. Җәгъфәр әфәнде, күп уйлый-уйлый, бераз саташа да башлаган иде. Аның күзенә һаман баягы капитан, муллалар, лоцманнар, болгар мөхәррирләре, болгарлар, марш музыкасы күренгән кебек була иде. Сөембикә күренгән кебек була иде. Төн булды. Җәгъфәр әфәнде һаман манарадан төшмәде — һаман уйлый, үзе белгән болгар көйләрен җырлый иде, еглый иде. Менә бара-тора ай туды. Ул әлгәре кызарып чыкса да, бара-тора бөтен дөньяны нурлатты. Җәгъфәргә ай яктысында Болгар зиратына болгар гаскәрләре килгән кебек була иде. Менә озак үтмәде, әллә кайдан кап-кара болыт килеп айны каплады, җил чыкты, манара ыж-ыж сызгыра башлады. Җәгъфәр әфәнде бераз туңа башлады. Ул үзенең киемнәренә төренебрәк бер почмакка утырып, тагы уйларга тотынды. Менә моңлы җил тавышына калгый башлады. Күзен бер ача, бер яба иде. Шул арада болгар мөхәррирләре күренгән кебек була иде. Сөембикә дә күренгән кебек була иде. Менә тагы җил ыжгырырга тотынды. Менә манара селкенде. Менә купты, менә тагы Җәгъфәр әфәнде калгый башлады. Менә Сөембикә: «Әйдә, беттеме?» — диде. Менә тагы ыжылдау, менә Җәгъфәр күзен ачты, ни күзе берлән күрсен — манара авып бара иде. Җәгъфәр «бетте» дияргә өлгерә алмады, ташлар басып, җаны чыкты.

Тарих җәмгыяте Җәгъфәрне казып алып күмделәр. Китапларын, әйберләрен музейларына алдылар. Болгарлар хакындагы сүзләр йөз елларга кадәр онытылмады. Аларның әдәбиятлары, музыкалары да ничә йөз елларга кадәр китте. Үзләре, унтугызынчы гасырда унбиш җирдән аштан кайтып хәл җыярга яткан мулла кебек, каберләрендә тыныч-тыныч йокладылар.

---

242. Тәгъзим — олылау. 243. Вакыйган — чыннан да. 244. «Теле тигәнгә» — ялгыш басылган булып, «теле беткәнгә» дигәнне аңлатса кирәк. 245. Әтраф — тирә-як. 246. Мөляхазә — фикер йөртү.

Укучы! Сез мине хәзер бу киләчәктән хәбәр бирә, тәкъдиргә ышанмый, дип яисә бу фалчы, багучы икән, кешеләрне алдарга тели, югыйсә ничек алдан хәбәр бирүе мөмкин, дип гаепләрсез, ничек уйласагыз да уйлагыз! Фәкать китабымны укыгыз да тасвир кылган тормышның китешләрен мөляхазә[246] кылыгыз.

Дөрес, мине сүгәрсез, бәлки кяфер диярсез, аннан зур сүз тапсагыз, анысын да, бәлки, әйтерсез, китапны да күтәреп бәрерсез. Аларның һәммәсенә дә мин бик разый, фәкать уйлаңыз да укыңыз гына! Бу китапны язудан максудым сезгә яхшы күренеп, сездән үземнең тормышым өчен бер файда итү түгел, бәлки хакыйкатьне күрсәтеп, сезне шул мәсьәлә хакында бераз уйлату һәм җитди тарызда[247] хезмәте миллиягә тотынырга тиешлелекне белдереп, безнең «милләт хезмәте» дип йөри торган нәрсәләремездән мәгънә чыкмавын күз алдына китереп аңлату өчендер. Дөрес, мондагы сүзләр бик каты сөйләнгәндер. Мондагы мәгънә бик авырдыр. Боларны ишетү дә бик кәефсездер. Ләкин бу — хакыйкатьтер, һәм дә пәк ачы хакыйкатьтер. Әгәр милләттемез шул юл берлән китсә, ике йөз елдан соң булмаса да, бер вакытны инкыйраздан котылу ихтималы юктыр. Бездә милләт булып торырлык нәрсәләрнең уникедән берсе дә юктыр.

Хәзер дә һәммә эшкә назар инсаф[248] берлә үзеңезгә бик ышанмаенча гына эшләгән эшләрнең ни файда иттекләрен вә эшли торган эшләреңезнең ни файда китерәчәген уйлаңыз әле. Әгәр әллә нинди хыялларга мөбтәлә[249], үзенә-үзе бик ышанган кеше булмасаңыз, дөньяның китешеннән хәбәрсез, гыйльме-мәгыйшәт, «социологические науки» хәлләреннән белемсез кеше булмасаңыз, минем сүземдә хакыйкатьтән башка нәрсә тапмассыз. Бу — хакыйкатьтер, булачак хакыйкатьтер. Ләкин мәшрут[250] хакыйкатьтер. Әгәр дә тормышымызны, китешемезне, кыйланышымызны хәзер үзгәртсәк, бөтен киләчәгемез икенчегә әверелүе ихтималы да бик якындыр. Бер төрләләреңез, язуын язсын иде, ник бу кадәр ачы лисан истигъмаль[251] кылган, яхшылап аңлату гына кирәк иде, диярсез. Бу да бер мәсьәлә, әмма минем мәсләгемә бөтенләй башка мәсьәлә. Минемчә, үлек кеби йоклаган кешене уятыр өчен, аны бишектә тирбәтүдән бер нәрсә чыкмый, аны тиз уятасың килсә, аның кабыргасына бик каты төртергә кирәк. Хәтта ике кабыргасы бер-берсенә ябышсын. Ул, тиздән уянып китеп, йокы ачуы илә уятучыны шулкадәр тәмле йокыдан уятуы өчен, сугып екса да егар. Ләкин икенче вакытта алай вакытсыз ятып йокламас. Менә минем мәсләгем шул!... Һәм шуның берлән барам. Тагы мине болай каты язудан зарар булса да, үземә булачак, уянган милләт мине бик каты сугып егачак. Ексын! Мин анысыннан курыкмыйм, минем тагы аякка басарга куәтем калыр. Мин аның йокыдан торган көенчә күзләренең бетәшүенең ямьсез идекен күрсәтермен, ачуланыр, тагы сугып егар. Мин гакылы юклыгын, яхшылык кылган кешегә зарар итүен, начарлык кылган кешене якын күрүен әйтеп көләрмен. Ул тагы ачуланыр, мине тагы сугып екмакчы булып, ләкин вөҗданы бу юлы сугарга җибәрмәс, ачуланып калыр. Мин аның шул кадәр гасабил мизаҗ[252] икәнлегеннән, шундый эш өчен кәефе китүеннән көләрмен, аңарга салкын су илә юынырга киңәш бирермен. Ул минем алдымда разый булмаган төсле булса да, мин югында бер мәртәбә генә сынар өчен, минемчә кыйланып карар, яхшы чыккач, икенче мәртәбә шулай итеп, өченче, дүртенче мәртәбә кыйлып, бөтенләй башка кеше булып калыр. Минем махсудым да шул. Бик

247. Тарыз — рәвеш. 248. Назары инсаф — инсафлы караш. 249. Мөбтәлә — дучар булу. 250. Мәшрут — шарт. 251. Истигмаль — кулланган. 252. Гасабил мизаҗ — гасаби (нервалы) табигатьле.

күп кеше: бу фикер минем башыма кайдан килгән, бу һич булмый торган нәрсә, моңарчы килгән, моннан соң да торырсыз, диярләр.

Бу фикер хата, һәм бик зур хата! Безне моңарчы кадәр алдап китергән һәм хәзер дә алдап тота торган хата!! Бу гасырда башка халыклар гакыллар ышанмаслык машиналар иҗат кыйлганда безнең димагысыз уйлый алмас дәрәҗәдә фәннәрне тәрәккый иттергәндә, бик кечкенә генә нәрсәләрдән бик аз эш, бик аз вакытта бик күп файда хасил иткәндә, һәм көннән-көн халык күбәюе сәбәпле, тормыш кирәклеге кыйммәтләнгәнгә, әлбәттә, шулар арасында, шул хәлдә торыр өчен, башкалар кадәр булырга, башкалар кадәр эшләргә кирәктер.

Әмма бездә берсе дә юктыр. Һәм болай китсәк, бер нәрсә дә булмаячактыр — иске заманнарда торуларымызга кыяс кылырга[253] ярамый. Чөнки мәшәкать азайды. Һәм дә күршеләремез хәзерге кебек электрик, пар, һава куәтләрен үзләренә хезмәтче итә алмаганга, һәммәмез бер дәрәҗәдәрәк идек. Хәзердә алар мең чакрым алга китмешләрдер. Бу гасырда, нинди милләт булса да, үзенең әүвәлге китеше берлә китсә, заманга карамаса, зәгыйфьләнәчәк һәм бара-тора фәкыйрьләнә-фәкыйрьләнә бетәчәк, башка милләтләргә кушылачактыр. Шуның өчен безгә дә хәзерге китешемезне сакларга тырышудан вә саклаудан һичбер файда чыкмаячак. Китешемез һаман үзгәрәчәктер. Ләкин үз ихтыярына бирсәк, бик тупас иттереп, иң кирәкмәгән ягыннан үзгәрә башлаячактыр. Хасилы гына[254] дөньяда торасыбыз килсә, әгәр нәселемез бетмәсен дисәк, үземезнең Конфуций* игътикады берлән кереп калган, «яңалык харам», дигән сүзне үзгәртергә кирәктер һәм, башка халыклар ни беләләр, безгә дә шулар белгәнне белергә тырышырга, тотынырга кирәктер. Шуның өчен безгә хәзердә рус мәктәпләрендә бик күп укырга кирәктер.

Рус мәктәпләрендә укыган кешеләремезнең русча киенүләре һәм дә безнең Конфуций игътикадымызда бик мөкатдәс саяган нәрсәләремезне сүгүләре өчен ачуланмаска кирәк. Ачулансак та, ачуны йотып калырга өйрәнергә кирәк. Замана аларныкы! Кашгар, Сатыш гасыры үтте. Һәм дә халкымызда фәкыйрьлек күбәю мәсьәләсен мөляхазә кылып, халыкны баету фикеренә чынлап тотынырга кирәк. Бу безнең хәзер әле Әхмәтҗан абзый бөлгәч, ул үзе хаҗда вакытта[255] җыйган управляющиенең баюы баю түгел, тик бармак санаш уены кебек, әйләндереп йөртү генәдер. Бер халыкның бай булуы ул халыкның никадәре эш кыйлуы берлән үлчәнгәнгә, эш кыйлыр өчен аны эшли белү кирәк булганга, безгә хәзер эш эшләргә өйрәнергә кирәк. Беләмез, дип һаваланып утырмаска кирәк. Безнең белүемез башка халыкка караганда һич чагыштырырлык та түгелдер. Шуның өчен һөнәр мәктәпләренә керик, балаларымызны кертик, карендәшләремезне кертик, фәкыйрьләрне кертик, хасилы, эшкә яраклы кеше булыйк. Әгәр акча булса, һөнәр мәктәпләре ачыйк, булмаса, хөкүмәтнекенә кертик, хасилы, өйрәник, белик, белүемез киләчәктә ярарлык булсын! Тиҗарәт[256] мәктәпләренә керик, тиҗарәт фәнен укыйк, аны белик, яхшылап сату итә башлыйк, бүрек берлә кәләпүштән үтик, гомум халык арасында үтә торган нәрсәләргә күчик, эшне белеп йөртик, расходны чаклап тотыйк, хөкүмәт мәктәпләренең башка бүлемнәренә дә керик, университетның һәммә факультетларын тутырыйк, доктор булыйк, юрист булыйк, мөәррих[257] булыйк, риязый[258] булыйк, фән мигъмар[259] мәктәпләренә керик, сәнаиг нәфисә мәктәбенә керик,

---

253. Кыяс кылу — чагыштыру. 254. Хасилы — кыскасы.
*Конфуций — кытайларның мәшһүр хакимләре һәм диннәренең вазыйгы (башлаучы — төз). Миладидән дүрт гасыр элек булган (Г. Исхакый искәрмәсе).
255. «Вакытта» сүзеннән соң «акча» яки «байлык» сүзе төшеп калган булса кирәк.
256. Тиҗарәт — сәүдә.

хасилы, һәр нәрсәне укыйк, һәр нәрсәне белергә тырышыйк, белик, эшлик, ул вакытта эшкә өйрәнермез, акчамыз булыр. Кирәк урыннарга сарыф кыла алырмыз. Һәм дә хәзерге кебек хәер сорашмамыз! Бу китешчә китсәк, дәүләт бик тиз бетәчәктер. Дәүләт бетсә, һәммә нәрсә бетә. Әүвәл әхлак бозыла, икенче, дин бетә, өченчедән, ул халык үзе бетә. Бу тарих берлә кырык мәртәбә мөсбат[260] бер мәсьәләдер. Хәзердә дөньяның иң тәрәккый иткән халыклары иң бай халык һәм иң мөтәмәтдин[261] халыклардыр. Дәүләт бетте, мәдәният бетте. Гарәпләр габбасый хәлифәләре* заманасында иң бай халыклар иде. Иң мөтәмәтдин халыклар иде. Дәүләт бетте, тәмәтдин бетте, үзләре дә эләгеп кенә калдылар. Шуның өчен, милләтне алга җибәрер өчен, акча кирәктер ки, ул эш белү берлә генә буладыр. Шуның өчен хәзер бер мәктәп ачтыкмы, аның янына бер һөнәр шөгъбәсе[262] ясарга кирәк. Мәктәптә ни нәрсә укылса да, тормышында бернигә ярарлык нәрсә булсын! Халкымызның иң курка торган нәрсәләре — укыган кешедә диннең бетүедер. Бу мәсьәлә бик күп сөйләнә торган һәм дә голәма тарафыннан үзләренең «җәһаләт»ләрен саклый торган бик куәтле бер коралдыр. Хәзер бер эш булдымы, голәма сыйныфы, алар артыннан гавам халкы укыган кешеләрдә әхлак миллиянең югалуын һәм диннең зәгыйфьләнүен сөйләргә тотыналар. Бигрәк хөкүмәт мәктәпләрендә укыган кешеләрнең яманатларына кереп, аларга эшләре төшкәндә, мирза әфәнде, дип сөйләсәләр дә, күңелләреннән аларны мәкруһ[263] күрәләр. Бу да, минемчә, безнең исламиятне белмәвемез. Һәм дә Чыңгыз заманында Каракорым[264] сахраларында бабаларымызның алып килгән Конфуций игътикадының[265] исламнан таза итеп урынлашуындадыр.

Без билетларымызга «мөселман» дип яздырсак та, исламиятка тияләр, дип зур тавышлар чыгарсак та, тәхлил[266] кылып караганда, боларның бик күбесе баягы Конфуций мәзһәбендәге[267] мөкатдәс нәрсәләремезгә тигәнгә генә булып, исламият бөтенләй читтә каладыр.

Хәзер дә русча укырга ярамый, русча киенергә ярамый, мәсьәләләре дә исламиятнең рухын һичбер вакытта кабул итми торган нәрсә булганга, боларны «дингә мөхалиф»[268] дигән сүзне ишеткәндә, диннән морат ислам булмаенча, Конфуций игътикады икәнлеге һәркемгә белергә тиешле бер эштер. Моннан мең өч йөз ел элек мөкатдәм гыйлемне фарыз иткән дин ничек ул Волга буендагы Әхмәтҗан абзый углы Кышкарда укып мулла булгач, яисә Фәхри мөәзин углы Бохарга барып, көтү көтеп кайтып, Казанга мулла булгач, яисә Дәмин хәзрәт углы Мисырга барып, әллә нинди ишанлый алып кайткач, хәрамга әйләнгән?! Бик гаҗәп бу! «Бу — дин дә хәрам!» — дигән сүзне дә, Конфуций игътикадына багышламыенча, исламиятка аудару иҗтимагыйльнәкъзаиннән[269] ничек гакыл кабул итә! Хәер, сез иттихад[270] заман шарт, фарыз мең өч йөз ел мөкатдәм хәрам булган бу елларда, диярсез, яисә иттихад мәкян[271] шарт, фарыз булган Азиядә хәрам булган Европада, диярсез, ни әйтсәңез дә әйтерсез, бу игътикадыңыз, сездә булса да, Конфуций игътикадыдыр, ислам әйтә дисәңез, исламга бик зур ифтира[272] һәм дә кыямәт көнендә сезне бик зур мәсъүлияткә[273] илтә торган ифтирадыр..... Европаның һәр зур мәктәпләрендә әллә никадәр шәкертләре укыйлар, әллә никадәр кешеләре бөтен дөньяда шөһрәт тоттылар һәм тоталар. Балкан болгар-

257. Мөәррих — тарихчы. 258. Риязый — математика. 259. Мигъмар — архитектор. 260. Мөсбәт — исбат ителгән. 261. Мөтәмәтдин — мәдәниятле, культуралы. 262. Шөгъбә — бүлек.

*Гарәбстанның Багдад хәлифәтендә сигезенче-унөченче гасырларда хакимлек иткән нәсел.

лары бер уч халык, бөтен дөньяга үзләренең барлыгын исбат иттеләр. Бөтен дөньяга шәкертләрен җибәрделәр. Дөньяның һәр кыйсмендә, һәр зур мәктәпләрдә болгар шәкертләре тутырдылар. Көннән-көн эш башында эшкә сәлахиятле[274] кешеләр мәйданга атылдылар, көннән-көн милләтнең истыйкбален[275] тәэмин иттеләр. Без ни эшлимез? Безгә шундый кешеләр кирәкмимени? Әллә безнең шундый кешеләремез һаман шул ярты муллалар тарафыннан идарә кылына торган Кышкар, Сатыш, Саба, Казанның чүплек башына бина кылынган мәдрәсәләрдән чыгармы? Шул педагоглар, ниһаять, шул дин галимнәре моннан ике мең ел мөкатдәм вафат булган Әфләтун*, Арсту** фәлсәфәләрен аңлар-аңламас язылган китапларыннан, суфистларның шул мөгалашларыннан[276] чыгармы? Вакыт-вакыт күзне ачып карарга вакыт! Ләфыз[277] низагларына, ниһаять, (бәя) бирергә вакыт җиткән! «Сөлес»[278] низагысыннан бер нәрсә чыкмаган кебек, үзенең белмәгән гыйлем мәсьәләсеннән дә бер нәрсә чыкмадыгы мәгълүмдер. Чыкса, шул биш-алты гасырда чыгар иде. Европалылар бу юлга ничек килеп төшкәннәр? Аларның бу көнге тәрәккыйләренә ниләр сәбәп булган? Зинһар шуны гына, тарих гомумиянең бер битен генә укысаңызла! Ярабби, бу ни сукырлык, ярабби, шулкадәр кояш кебек ялтыраган мәдәниятне күрми, аңламый торган нинди наданлык? Әгәр европалылар безнең хәзер мөбтәлә булган схоластиканы тәмам башлары әйләнгәннән соң ташламасалар иде, бүген алар безнең кебек ризаләт[279], сәфаләт[280] астында изелерләр иде. Кайчанга кадәр шул кәгазь капчык ясарга гасырлары җиткән казый тәһзип[281], мөбәян[282], тарыбларны[283] кулдан-кулга йөртермез? Кайчанга кадәр моннан тәмам бер мең ике йөз сиксән биш ел элек беткән хәварижларның[284] бәхәсләре берлән башымызны катырырмыз? Кайчанга кадәр үземезнең шул наданлыгымызны күрмәенчә, сукыр төсле, мәсләксез хәрәкәт итүемезне саклармыз?........ Әгәр бездә аз гына гайрәт, аз гына хәмият булса, безнең һәр эшемездән ике өлеш файда чыгуында һич шөбһә юктыр. Безнең болгарлардагы кабилият бик аз халыкта бардыр. Безнең шул вак-төяк рус мәктәпләренә кергәнемез дә, укысалар, һәрвакыт алдынгы шәкертләрдән саналалар, фәкать безгә хәзер үземезнең эшемезнең ничек икәнлеген белергә кирәк, халкымызны ислах кылырга ничек тотынырга кирәк булса, шулай хәрәкәт итәргә кирәк. Ләкин мотлакан[285] хәрәкәт кирәк. Бәгъзе кеше, «замана берлә үзе булыр», фикерендәдер. Алар яисә эшне аңламыйлар, аңлаганнары әйтсә, үзләренең гарзы шәхсияләрен[286] химая өчендер. Иген сатмаенча замана берлән[287] булмаган кебек, милләт кирәкләре дә укымаенча булмаячактыр. Шуның өчен укырга кирәк, укырга кирәк. Үз мәктәпләремездә мәгълүмат ибтидаиәдән[288] артык нәрсә алу булмаганга, рус мәктәпләрендә укыйк, караламыз икән, каралыйк. Аңлаган кеше каралса да, тиз кайтып төшәр.

Әмма безнең мәдрәсәләремездә башы черегән кеше һичбер вакытта эшкә керерлек булмаенча, милләткә бер бәла генә булуында шөбһә юктыр. Бәгъзеләре төрек мәктәпләренә барып уку фикерен алга тотар. Һәм тугры килгәндә димләүдән дә качмыйлар. Алар бик зур хата итәләр, чөнки төрекләрнең мәдрәсәләре ислах кыйлыну мәсьәләсе әллә кайчан мәйданга чыккан эш булып, ислах та кыйлынган бул-

263. Мәкруһ — ярап җитми торган. 264. Каракорым — Чыңгыз хан заманында монгол дәүләтенең башкаласы. 265. Игътикад — ышану. 266. Тәхлил — тикшерү. 267. Мәзһәп — секта. 268. Мөхалиф — каршы. 269. Иҗтимагыйльнәкъзаин — каршылыклар берлеге (мантыйк атамасы). 270. Иттихад — фикер бердәмлеге, берләшү. 271. Мәкян — урын, җир. 272. Ифтира — яла ягу. 273. Мәсьүлият — җаваплылык. 274. Салахият — сәләт. 275. Истыйкбал — киләчәк. 276. Мөгалаш — буташтыру.
*Әфләтун — Платон, **Арсту — Аристотель.

са да, алар да бөтен исламның башына бәла булган голәмаларның тәхте асарәтләреннән[289] котыла алмаганга, кирәгенчә ислах кыйлынмаганнар. Һәм дә безнең Россиядә тора торган кешеләргә рус мәктәбендә уку, рус рухын белү кадәр файдалы эш бармы? Монда кемнең шөбһәсе бар?

Безнең һәрвакыт төзеп куйган фикеремез «Русия мөселманнары» булудыр. Руҫиядәге шулкадәр безгә бирелгән иркенлек, безнең хактагы гадәләт һичбер мәмләкәттә һичбер милләт мәхкүмәгә[290] бирелмәгәндер. Шуңардан да файдаланырга гайрәтемез җитми, хәмиятемез калмаганмыни? Ярабби, шул схоластиканың тәхте тәсаррыфыннан[291] коткар да, безне дә мәгариф-мәдәният юлына күндер. Безнең шулкадәр тарих бәшәрдә нам казанган бабайлар безне үзләренең угыллары дияргә хурланырлык булмасын!

*1903 сәнә.*

*Текстны әзерләделәр — И. Нуруллин, И. Сәйфуллин.*


---

277. Ләфыз — сүзнең аваз ягы. 278. Сөлес низагы — изге өчлек бәхәсләре. 279. Ризаләт — түбәнлек. 280. Сафаләт — бозыклык. 281. Тәһзип — төзәтү, пакьләү. 282. Мөбәян — ачыклаучы. 283. Тарыб — туфрак. 284. Хәвариҗ — ислам динендәге борынгы секта тарафдарлары. 285. Мотлакан — абсолют, чиксез, шартсыз. 286. Гарзы шәхсия — үзен күрсәтергә тырышу. 287. Замана берлән — бу урын аңлашылмый (текстны әзерләүчеләр). 288. Ибтидаиә — башлангыч. 289. Әсарәт — әсирлек, коллык. 290. Мәхкүмә — хөкем астындагы. 291. Тәсаррыф — ия булу, кулда тоту.

**Флүр Баһаветдинов,**
ТАССР прокуратурасының аеруча мөһим эшләр буенча тикшерүчесе

# КӘРИМ ТИНЧУРИННЫҢ СОҢГЫ КӨННӘРЕ

Бу — 1936 нчы ел иде. Кәрим Тинчуринның эшчәнлеге бу вакытларда күтәрелеш кичерә, үз йөзен ачык билгеләгән иҗат булып таныла. Аңа, сәхнә һәм каләм остасы буларак, инде кайбер йомгаклар ясарга да мөмкинлек туа. Илле яшенә якынлашып килүче драматург — Татар академия театрының баш режиссеры, утыздан артык пьеса авторы, Татарстан Язучылар союзы идарәсе әгъзасы. Пьесалары бөтен ил буенча барлык татар театрларында куела. Шушы елда Татарстан аның иҗади эшчәнлегенә 25 ел тулуны зурлап уздыра. Әдипкә бик күп котлау хатлары, телеграммалар килә. Укучылар, эшчеләр, колхозчылар, хәрбиләр — бөтенесе дә аннан яңа пьесалар, яңа ачышлар көтә. Республика хөкүмәте аңа язу машинкасы бүләк итә: янәсе, яз, иптәш Тинчурин, туктама! Казан хәрби гарнизоны исә ау мылтыгы бирә: пьесалар яза-яза, ялны онытып җибәрмә, иптәш Тинчурин, ауга да чыккала!



Аның язу өстәлендә яңа пьеса ята, «Йомгак» исемле. «Кандыр буе» пьесасындагы кебек, монда да утызынчы еллар уртасына иң хас мәсьәлә — колхоз тормышы сурәтләнгән. Эчтәлеге дә көн таләбенә туры килә, пьесаның геройлары да — яңа дәвер кешеләре: парторг, агроном, колхозчы, тракторчы һәм комбайнчылар. Руслар да, татарлар да бар. Бергәләп яңа тормыш коралар. Алар, парторг ярдәме белән, араларына кереп оялаган шпион, троцкийчы, милләтче һәм аның тәркемдәшләрен фаш итәләр. Колхозчылар Сталин конституциясен хуплыйлар. Автор фикеренчә, яңа Конституция совет халкының социализм төзү өчен алып барган көрәшенең йомгагы булып тора.

Драматург, әлеге пьесаны язган вакытта, озакламый үзен дә «халык дошманы», «милләтче», дип гаепләячәкләре турында һич уйламагандыр, әлбәттә. Рәхимсез тикшерүчеләр, рәхсәтсез-нисез килеп кереп, аның иҗат юлын үзләренчә «йомгаклап» куярлар дип башына да китермәгәндер.

...Кәрим Тинчурин артыннан 1937 елның көзендә, 17 сентябрь көнне киләләр. Кулга алу турындагы карарда болай язылган: «Тикшерү җыйган материаллар нигезендә, Кәрим Тинчурин түбәндәге хәрәкәтләрдә фаш ителә: ул кулга алынган халык дошманнары Салах Атнагулов, Фатыйх Сәйфи-Казанлы, Гомәр Толымбай, Кави Нәҗми һәм башкалар белән бергә культура-идеология фронтында һәм башка тармакларда корткычлык эше алып бара...»

Тикшерү бик озакка — бер ел да ике айга сузыла. Бу вакыт эчендә, Тинчуринны кулга алганда, әле сержант кына булган тикшерүче Гатин эшне тәмамлау вакытына кече лейтенант дәрәҗәсенә кадәр үсеп җитә! Ул, күрәсең, үзен уңай яктан күрсәтер өчен, тикшерүне бик тә «тырышып» алып барган...

1939 елда, НКВД хезмәткәрләре тикшерү законын тупас рәвештә бозган өчен кулга алынгач, НКВДның тикшерү бүлеге секретаре менә мондый күрсәтмәләр бирә:

«Тикшерүче Гатинның бүлмәсе минем бүлмә каршында гына иде. Гатин үзе тикшерә торган кешеләрне кыйнавын гел дә яшерми, киресенчә, ул моның белән масая иде. «Халык дошманнары мине озак искә төшерерләр әле»,— дип мактана иде ул. Әмма кулга алынган Кәрим Тинчуринны күпме генә кыйнаса да, кирәкле күрсәтмәләрне ала алмады, әдип һичнинди гаебен танымады».

Дөрестән дә, сорау алу беркетмәләре Кәрим Тинчуринның тикшерү вакытында үз-үзенә хыянәт итмәвен раслый.

«Юк, мин бернинди контрреволюцион оешмада да тормадым, бернинди корткычлык эше алып бармадым. Әсәрләремдә кайбер ялгышлар һәм хаталар бармы? Монысыннан мин баш тартмыйм, әмма ләкин мин үз әсәрләремдә беркайчан да милләтчелекне хупламадым. Сез хата тапкан әсәрләрнең барысы да диярлек революциягә кадәр язылган. Сез ул әсәрләрне яхшылап укып чыктыгызмы соң? Мин бит үз пьесаларымда һәрвакыт ярлы халык ягында, мин бит байлар, буржуйлардан һәрвакыт көләм! Башка халыкларны (чувашларны, русларны, кыргызларны) пьесада мыскыл иткәнмен? Булды, моннан баш тарта алмыйм. Әйе, «Казан сөлгесе»ндә чувашларга берничә җирдә катырак сүктердем бугай. Ләкин бит мин моны явыз уй белән эшләмәдем, моның белән милләтчелекне алга сөрәм, дип һич тә уйламадым! Бу сүзләр ул елларда, чыннан да, әйтелде бит, халык әйтте аларны, мин бары тик кәгазьгә генә салдым!..»

Бу сүзләр җинаять эшендәге сорау алу беркетмәләренә кертелмәгән, ләкин аларны Кәрим ага тикшерүчегә, шиксез, әйткәндер — монысына шикләнмәскә мөмкин.

Тикшерү беткәндә, Кәрим Тинчуринга җиде пункттан торган гаепләү белдерәләр. Менә ул:

1. Татарстанда советларга каршы хәрәкәт итүче буржуаз-милләтче оешманың актив вәкиле була, совет властен корал көче белән юк итү һәм СССРда капитализмны яңадан торгызу өчен актив көрәшә;

2. Советларга каршы оешманың актив вәкиле буларак, язучылар союзында, культура һәм идеология фронтында астыртын корткычлык алып бара;

3. 1917 елда, вакытлы хөкүмәт дәверендә, «Ил» газетасы редакциясендә эшли; контрреволюцион милләтче буржуазия органы булган бу газетаның редакторы Гаяз Исхаков кулы астында коммунистлар партиясенә каршы көрәш җәелдерә;

4. 1918 елда Казанда ак бандаларны куган чакта, алар белән бергә Тәтешкә, аннан соң Самарага, Г. Исхаков, З. Вәлиди, Ф. Сәйфи-Казанлы һәм башкалар янына чигенә;

5. Буржуаз милләтче, ак эмигрант Гаяз Исхаков белән хат алыша, аннан ак эмигрантларның «Милли юл» журналын алып тора һәм советларга каршы көрәштә махсус йөкләмә ала;

6. Япон шпионы Хәсән Исхаков белән бәйләнештә була, аның аркылы театрда куяр өчен Германиядәге Гаяз Исхаковның пьесаларын ала;

7. 1910 елда Казанда патша жандармнары кулына эләгә, аларга татар интеллигенциясе арасында провокаторлык эше алып барырга йөкләмә ала...

Бу коточкыч, башка сыймаслык гаепләрнең берсе генә булса да дөреслеккә туры киләме соң?

Юк. һич юк! 1955 елда Кәрим аганың тормыш иптәше Заһидә ханым Тинчурина ирен аклауны үтенеп гариза яза. Бу үтенеч буенча уздырылган өстәмә тикшерү Кәрим Тинчуринга сылтанган гаепләрнең барысының да уйдырма, ялган икәнен ача.

Күргәнебезчә, Тинчуринга бирелгән гаепләрнең күбесе Гаяз Исхаков исеме белән бәйләнгән. һәрбер сорау алу вакытында бу сорау кат-кат бирелә: Гаяз Исхаков белән нинди элемтәдә тордыгыз, аннан нинди задание алдыгыз?

...Алар беренче тапкыр 1914 елда очрашалар. Бу вакытта Габдулла Кариев җитәкчелегендәге театр труппасы Нижний Новгород ярминкәсендә Гаяз Исхаковның «Мөгаллимә» дигән пьесасын сәхнәләштерә. Спектакль беткәч, автор артистлар янына керә, аларны котлый. Артистлар арасында Кәрим Тинчурин да була.

1917 елда, Г. Кариевнең «Сәйяр» труппасы Мәскәүгә килә. Бу вакытта Керенский хөкүмәте элек төрле сәбәпләр белән армиядән калдырылган ир-атларга («билетлыларга») мобилизация белдерә. Кәрим Тинчурин алдында да герман сугышына китү куркынычы туа. Талантлы артист һәм драматургны коткарып калу өчен, Габдулла Кариев Мәскәүдә Гаяз Исхаковка мөрәҗәгать итә. Исхаков артист Тинчуринны «Ил» газетасы

редакциясенә «сыендырырга» ризалык бирә. Шулай итеп, Тинчурин, труппадан аерылып, Мәскәүдә кала.

Бу редакциядә Кәрим Тинчурин нибары дүрт ай эшли. «Ил» газетасын татар буржуазиясе 1913 елда башта Ленинградта, аннан соң Мәскәүдә чыгарта, Гаяз Исхаков газетаның беренче редакторы була, аннан соң актив хезмәткәрләрнең берсенә әйләнә. «Ил» башка буржуаз-демократик милләтчелек рухындагы газеталардан иң «сул»ы булып санала. Шунлыктан патша цензурасы редакцияне бик еш борчый, хәтта газетаның кайбер саннарын конфискацияли. Шулай да газета татар буржуазиясен бер тапкыр да үпкәләтми, аңа тел-теш тигезми.

Дүрт ай эчендә Тинчурин газета битләрендә берничә генә чыгыш ясап өлгерә. Патша тәхете җимерелгәч, азатлык шартларында беренче тапкыр ураза бәйрәмен уздыру турында публицистик хикәя бастыра, аннан соң ике хикәядә сугыш инвалидларының авыр язмышын тасвирлый.

Октябрь революциясе җиңгәч, Тинчурин шундук Казанга кайта һәм шуннан соң Гаяз Исхаков белән яңадан очрашмый. Дөрес, эмиграциядән (Германиядән) Г. Исхаков аңа бер хат язып җибәрә. Бу хатта ул совет татар театры өчен кулай булган пьеса язуы турында хәбәр итә. Тинчурин бу хатка җавап бирми. Озак та үтми, аның бертуганы Хәсән Исхаков Тинчуринга бу пьесаны тапшыра. Баш режиссер Тинчурин, өлкән артистлар белән бергә, пьесаны укып чыгалар һәм аның театр өчен ярамаганлыгы турында нәтиҗә ясыйлар. Моннан тыш, көтмәгәндә почта аша Тинчуринның өенә «Милли юл» журналы килеп төшә.

Мондый журнал алуын Тинчурин беркемнән дә яшерми. Хәтта язучыларның бер җыелышында, ак эмигрантларның явыз эшләре турында сүз чыккач, ул, нәфрәтләнеп, үзенә дә журнал җибәрүләре хакында белдерә.

Инде килеп, аклар белән бергә Тәтеш һәм Самарага чигенү, патша жандармнарына провокаторлык хезмәте күрсәтү мәсьәләсенә кагылыйк. Бу гаепләүләр дә — тикшерү органнарының оятсыз уйдырмалары гына. Җинаять эшен ничә тапкыр актарып чыксам да, моны исбатлый торган бер генә документ, бер генә күрсәтмә дә тапмадым. Казан жандарм идарәсе архивында да бу факт бер җирдә дә теркәлмәгән һәм һичничек раслана алмый.

Хәер, ул елларда дәлилләр эзләп бик интекмәгәннәр. Кешеләрнең язмышын хәл итү өчен төрле ялган, уйдырма да җитә торган булган.

...1938 нче елның 2 ноябрендә тикшерүче Тинчуринны соңгы тапкыр сорау алуга чакырта. Таләп һаман бер үк була: «Контрреволюцион эшегез турында сөйләгез!..»

Төрмәдә йончып беткән, кыйналган һәм күп кенә мәсхәрәләүләр кичергән драматург һаман да үз сүзендә тора: «Халкым, илем алдында бернинди гаебем дә юк!»— дип кабатлый.

Кәрим Тинчуринның язмышына бәйле бу эш ТАССР Эчке эшләре халык комиссариатының өч кешелек махсус комиссиясенә тапшырыла. 14 ноябрь көнне (1938 ел) Тинчуринны атарга карар чыгарыла...

Ул чор законнары буенча, ату турындагы хөкем карары кичекмәстән үтәлергә тиеш, хөкем ителгән кешенең дәгъва белдерергә хакы юк. Җинаять эшенә теркәлгән акт буенча, хөкем карары шул ук төндә, бер сәгать илле минутта җиренә җиткереп үтәлгән...

Бу вакытта инде яңа көн, 15 ноябрь туып килә. Әмма яктырырга вакыт бар әле, шактый әле. Коточкыч карарны тормышка ашыручылар исә ашыгалар. Явызлыкларын яшерергә тырышкандай, драматургның тормышын тәүлекнең дөм-караңгы сәгатендә өзәләр. Сәхнәдә ут сүнә...

...«Сүнгән йолдызлар» пьесасын карагач мин көчле тетрәнү кичердем. Хәзер аңлыйм: пьеса авторының язмышы Сәрвәрнең, аның сөйгәне һәм бичара Мәхдүмнең язмышыннан да ачырак. Бу язмыш фаҗигасе трагедиядәге кызганыч хәлләрне каплап китә...

НКВД хезмәткәрләре Кәрим Тинчуринның һәлакәте белән генә чикләнмиләр, аның исемен халык хәтереннән дә, тарихыбыздан да чыгарып ташлауны максат итеп куялар. Драматургның барлык китаплары кибетләрдән, китапханәләрдән җыеп алына, пьесаларын сәхнәләштерү катгый рәвештә тыела. Аның тормыш иптәше Заһидә ханым Тинчуринаны да эзәрлекләргә тотыналар: педагогия институты аны эшеннән куып чыгара, сугыш вакытында исә бөтенләй Казаннан сөрәләр, шулай итеп, ул фатирын да югалта...

Ниһаять, тормыш барысын да үз урынына куйды. 1955 елда, республика прокуроры протесты буенча, Кәрим Тинчуринның эше яңадан каралды һәм 14 октябрьдә әдип тулысынча акланды. Пьесалары яңадан татар сәхнәсенә әйләнеп кайтты. Афишаларда яңадан Кәрим Тинчурин исеме балкый башлады. Г. Камал исемендәге Ленин орденлы Татар дәүләт академия театры һәр сезонын аның Салих Сәйдәшев музыкасы белән баетылган үлмәс «Зәңгәр шәл»е белән ачып җибәрә.

Әле күптән түгел Татар дәүләт драма һәм комедия театрына Кәрим Тинчурин исеме бирелде. Бу шатлыклы хәбәр килгәндә, Заһидә ханым әле исән иде — аның күзләрендә шатлык яшьләре җемелдәде: «Бу көннәрне дә күрәсем бар икән!»— дип кат-кат такърарлады ул.

Әйе, ул көннәр килде! Татар халкының мәшһүр драматургы Кәрим Тинчуринның данлы исеме, бай иҗаты халыкка кире кайтарылды, тарихыбызда аңа тиешле урын билгеләнде!

Мөхәммәт Мәһдиев

# ЕВРОПА — БЕЗНЕҢ ХАКТА...

Киң катлау укучылар, ихтимал, белеп бетермиләрдер: татар халкының үткәне, бүгенгесе турында Европада байтак телләрдә очерклар, гыйльми хезмәтләр, фольклор җыентыклары, белешмәлекләр чыгып килгән. Әле дә шулай. Ул хезмәтләрнең дусларча язылганы бар, башыннан ахырына кадәр безнең системаны тәнкыйтьләп язылганнары да аз түгел. Татар тарихына, әдәбиятына, халык иҗатына багышланган китаплар Көнбатышта рус, немец, инглиз, мадьяр, француз телләрендә басылып килгән. Татар телендә басылганнары да очрый. Әле 1980 елда гына Хельсинкида «Финляндия төрекләре берлеге» татар телендә «Безнең җырлар» исемле зур күләмле бер җыентык чыгарды. Аңа кадәр француз галимнәре Парижда француз телендә революциягә кадәрге татар матбугатының тарихын яктырткан белешмәлек чыгарганнар иде (авторлары — А. Беннигсен һәм Л. Келькеже). Шул ук нәшрият билгеле бер сериядә татарларның мәшһүр кешеләренә, «Солтангалиевчелек»кә һ. б. күренешләргә багышланган берничә хезмәт бастырды.

Европа галимнәре безне белә! Бу кызыксынуның тарихы бик еракларга китә. Моның — бу кызыксынуның бер юнәлеше Европаның экспансив максатларда эчке Россия, бигрәк тә мөселман-төрки халыкларының мәдәнияте, икътисади (экономик), социаль хәле белән **стратегик** кызыксыну булса, икенче бер юнәлеш саф гыйльми максатларда, ә кайбер очракларда турыдан-туры туганлык, кардәшлек җепләрен эзләү максатында алып барылган. Шуңа күрә бу мәкаләдә без соңгы юнәлешне генә күзәтеп чыгуны максат итеп куйдык. Югыйсә, немец галимнәре Отто Гётч, Готһольд Вайль, фин галиме Һ. Паасонен һәм башкаларның тирән экономик очеркларын, фольклор, тарих буенча хезмәтләрен дә тикшерергә булыр иде.

Шулай да «тугандашлык» принципларыннан чыгып язылган, кан-кардәшлекне эзләгән хезмәтләргә тукталыйк әле.

Безнең фольклор хезмәтләрендә бик еш кына мадьяр, ягъни венгр галиме Балинт телгә алына, аның Казан губернасында халык иҗаты әсәрләре җыйнап йөрүе әйтелә. Кызганычка каршы, монда кайбер төгәлсезлекләр китә. Әйтик, Балинт «1870 елларда Казанга килә» диелә. Дөресе исә — 1871 елда.

Балинт Габор 1844 елда туган[1]. Вена һәм Будапешт университетларының хокук факультетында укыган чагында, ул бар булган буш вакытын телләр өйрәнүгә багышлый, бигрәк тә көнчыгыш телләре белән кызыксына. 1870 елда ул күп санлы мадьяр сүзлекләренең редакторы булган академик Фогараши Янош белән таныша. Аның киңәше буенча Балинт монгол һәм рус телләрен өйрәнә башлый. Фогараши ярдәме белән Балинт Россия һәм Азиягә өч еллык сәяхәткә китә, аның юл расходларын Венгрия Фәннәр Академиясе күтәрә. Балинт Казанга 1871 елның 17 июнендә килеп җитә, тиз генә эшкә керешә. Казанда ул иң әүвәл миссионер Ильминский белән таныша, керәшен татарлары укыган мәктәпләргә йөри башлый. Тел үрнәкләре язып алу өчен иң уңай алым — халык иҗаты әсәрләренә мөрәҗәгать итү икәнен Балинт

[1] Мадьяр телендәге әдәбиятта кешенең фамилиясе башта, исеме икенче булып китерелә.

яхшы аңлый. Ул Лаеш, Мамадыш, Казан өязләрендә йөри, халык иҗаты әсәрләрен язып алуда аңа Гаврила улы Борис исемле керәшен ярдәм итә. Ул җыйган материаллар 1875 елда Будапештта аерым китап булып басылып чыга[2]. Балинтның китабына барлыгы 144 мәкаль, 46 табышмак, 64 кыска җыр, 4 бәет (кайберләрен Ильминскийның шәкерте Тимофеев Игнатий Бачкей улы әйтеп яздырган), 34 әкият һәм керәшен татарларының ышана торган кирәмәтләре тупланган. Болардан тыш китапка изгеләр сүзләре, дини риваятьләр дә кертелгән.

Балинтның бу китабы — безнең чорга унтугызынчы йөзнең халык җәүһәрләрен түкми-чәчми алып килгән искиткеч зур хәзинә. Бу китапның 1875 елгы басмасының бердәнбер нөсхәсе Казан университетының гыйльми китапханәсендә саклана. Фольклорчы галимнәр арасында бу хезмәткә һәрвакытта да игътибар зур булды, моны кулына алган һәркем мадьяр галименә — олы җанлы Балинтка рәхмәт укый. Соңгы елларда Венгрия безнең татар халык авыз иҗаты белән шөгыльләнгән галимнәренең хезмәтләрен кабат бастыра башлады. 1980 елда Кәкук Жужа ханым немец телендә «Казан татарларының халык җырлары» дигән китап бастырып чыгарды[3]. Бу — Кунош Игнацның 1915—1918 елларда Австро-Венгриядә яшәгән татар әсирләреннән язып алган җырлары. Куношның әлеге җыентыгына 634 татар җыры тупланган. Текстка параллель рәвештә татар җырларының немецчә тәрҗемәсе дә бирелеп барылган (Балинт китабында да татар текстлары немец теленә тәрҗемә ителгән). Мондый алым Европа галимнәренең бик күбесенә халкыбызның акыл байлыгы, эстетик фикерләү дәрәҗәсе белән танышырга мөмкинлек бирә.

Инде менә тагын бер шатлык: Венгриянең Сегет (мадьярча — Сәгәт) университетындагы Алтаистика кафедрасы мөдире Берта Арпад 1988 елда Балинтның татар халык иҗатын туплаган барлык хезмәтләренең яңа басмасын чыгарды. Берта (күптән түгел генә ул Казан университетының татар теле кафедрасында эшләп киткән иде) халкыбыз өчен зур эш эшләгән: яхшы, затлы кәгазьдә 412 битлек бу саллы китапка Берта сүз башы язган. Моннан без Балинтның тулы биографиясен беләбез. Хезмәтнең фәнни аппаратында татар халык авыз иҗатына багышланган Европа чыганаклары искә алынган. Татар телендәге җыр, әкият, бәет, табышмак текстлары китапның икенче өлешендә немец теленә әйләндереп бирелгән. Китапның ахырында татар-мадьяр-немец сүзлеге (Балинт үзе төзегән) урнаштырылган[4]. Мондый хезмәтне халыклар арасындагы игелекле хезмәттәшлек үрнәге дип ничек атамыйсың?

Балинт татар халкының шулкадәр затлы җырларын, мәкаль-әйтемнәрен җыйган ки, хезмәт халкының акылына, эстетик фикерләү дәрәҗәсенә таң каласың. Әле бит 1905 ел революциясе дә булмаган, татар халкының газета-журналлары да, театры да юк. Ә халык үз язмышы турында фәлсәфи фикер йөрткән, сөю-нәфрәт хисләрен — җырларында, акылын, тормыш тәҗрибәсен — мәкаль һәм табышмакларында, матур хыялын — әкиятләрдә, моң-зарын бәетләрдә гәүдәләндергән. Балинт язып ала:

*Кара да постау чикмәнемне*
*Кара ефәк белән бөккәндәр;*
*Тәрәзәләреннән карый-карый*
*«Әллә кайтыр» диеп көткәндәр.*

Сиздегезме? Халык гел чабата-башмактан гына йөрмәгән, ямаулы күлмәктән генә дә түгел. Постау — «Бостон» — костюм тектерә торган югары сыйфатлы чын йон материал, гадәттә кара төстә була. Моны Америкадагы Бостон шәһәре тукучылары эшләп чыгарган. Татар агаеның чикмәне әнә шул «бостон»нан. Алай гына да түгел, ул әле бөрмәләрендә кара ефәк белән дә бизәлгән... Балинтта тагын ниләр бар?

---

[2] Kazani tatar. Nyelvtanulmányok. Szövegek és forditas. Gwüjtötte es forditotto szent katolnai Balint Gabor. Budapest, 1875.
(Чит телләрне өйрәнү. Текстлар һәм тәрҗемә. Җыючысы һәм тәрҗемә итүчесе Балинт Габор.)

[3] Kazantatarische volkslieder. Auf Grund der Sammlung von Jgnac Kunos herausgegeben von Zsuzsa Kakuk Budapest, 1980.

[4] Wolgatatarische Dialektstudien Textkritusche Neuausgabe der Originalsammlung von G. Balint 1875—76. hrsg. von A. Berta. Budapest, 1988.

*Теш караларын бик сөям,*
*Тиерәсем килми тешемә;*
*Сөймимен түгел, бик сөям,*
*Белгертәсем килми кешегә.*

Теш карасы? Ул нәрсә? Бүгенге буын бу турыда нәрсә белә? Теш бит ак булырга тиеш... дип уйлыйбыз. Ләкин унтугызынчы гасырда, ихтимал, элегрәктер дә, егерменче гасыр башында затлы гаиләдәге татар кызлары тешләрен кап-кара ялтыравыклы лакка (сөрмә) буяганнар. Бу — помада, пудра, ислемайлар сөртү рәтеннән йөргән. Фәннәр еракка китеп булса да әйтим инде: әниемнең теш төпләрендә кара кыйгач сызыклар бар иде. «Болар нәрсә?» — дип сорагач, ул: «Безнең заманда бай кызлары, мулла, сәүдәгәр, таза тормышлы крестьян кызлары шулай тешләрен сөрмәгә буйыйлар иде, болар — шуның эзе»,— дип авыр сулап искә ала иде, сугыш вакытында тешләребезгә шөгыль беткәч...

Безнең егет-кызлар и сөешә дә белгәннәр инде!

*Тартар кычкырадыр куактан,*
*Таңнар сызыладыр ерактан;*
*Кысма, җаныкаем, беләктән,*
*Дәрткенәем китми йөрәктән.*

*Ак каеннарга ник мендем?*
*Җилбердәп торган туз өчен;*
*Быеллай җәйне мин саргайдым,*
*Аклы яулык япкан кыз өчен...* һ. б.

Хәер, җитәр. Балинт китабын үзебезнең нәшриятта татарча-немецчә-мадьярча сүзлек, сүз башы, фәнни шәрехләр белән чыгарып халкыбызга кайтарып бирергә кирәк, дигән фикер бу мәкаләне укыган кешенең күңелендә болай да туды инде.

Берта Арпад бу китапны кабат бастырып чыгарганда бер сүзгә тукталган. Мәкальләр арасында. Балинт латин алфавитында, халыкара кабул ителгән нормативларга нигезләп язган. «Борынгылар әйткән сүзләр» дигән бүлектә Балинт татар мәкалләрен һәм әйтемнәрен бирә. «Бу борынгылар әйткән сүзләрне Симон Гаврила улы Борис җыеп язды»,— дип күрсәтә ул әлеге бүлекнең ахырында. Йөз кырык дүрт берәмлек мәкаль, әйтемнән торган бу бүлектә Берта Арпад, 70 нче санлы текстка тукталып, астына сызган һәм сорау билгесе куйган (минем өстәлемдә — Бертаның 1988 ел, 7 декабрь тарихлы автограф белән профессор М. Госмановка бүләк иткән әлеге хезмәте). Мәкаль мондый: «Күргәнне кютләгеп (ишеткән) җиңгән». Берта кызыксынган: бу ни булыр? М. Госманов та китабын миңа биргәндә сорау катыш карап алды. Ачыклый алмассыңмы? Белә инде — мин тел галиме түгел. Тел галимнәренең байтагына мөрәҗәгать итеп карадым. Иң әүвәл мәкальне тегe, аңлашылмаган сүздән арындырып «күргәнне ишеткән җиңгән» дигән вариантта уйлап, тикшереп карадым. Бу — сатирик мәкаль. Ягъни, берәү бер эшне, вакыйганы күргән, ул инде белә, ләкин телгә оста түгел, полемист түгел, ихтимал, сөйләргә дә яратмыйдыр. Ә менә икенче берәү «орып та бирми», кешедән ишеткән буенча сөйли һәм бәхәстә, телгә маһир булганлыктан, җиңеп чыга. Күргән кеше, бичара, җиңелә. Монысы аңлашыла. Ә теге сүз? Балинтка бит моны ишетеп түгел — «Симон Гаврила улы Борис җыеп» язганнан күчерергә туры килгән. Әнә шул урында, минемчә, хата киткән. Дөресе болай булгандыр: «Күргәнне киртләгән җиңгән». Балинт, әлбәттә, күчереп язганда «киртләгән» сүзен аңламаган һәм «Гаврила улы»ннан сораган: «Бу ни дигән сүз?» Тегесе әйткән: «Киртләгән — ишеткән, колакка киртләгән, дигән сүз». Балинт шуннан дәфтәрендәге текстка җәяләр эченә өстәп язган: «ишеткән». Чит ил галиме өчен ят инде ул, әмма бит шундый гыйбарә бездә бар: «Колагыңа киртләп куй». Мин моны үзем өчен ачыш дип санадым. Колакка киртләп куй? Ул — нәрсә? Киртекләү, киртәләү, кире, киртек — алар каян? «Кирт»,— ди «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»нең икенче томы (1979 ел),— «агачка яки башка нәрсәгә үткен әйбер белән кисеп яки чабып ясалган эз, тамга; сыр» (104 бит, аңлатманың авторы — Мәхмүт Мөхәммәдиев).

Хәер, болар турында бик иркенләп тә сөйләшеп булыр иде. Мәкаләмнең исә максаты башка.

Сегет университеты соңгы елларда тюркология фәненә, гомумән, зур игътибар бирә. Аның Урал-алтаистика кафедрасында әле күптән түгел генә «Татар

этимологиясе» дигән җыентык басылып чыкты. (Сегет, 1988)[5]. Татар һәм башкорт телләренең кайбер мәсьәләләрен тикшерүгә багышланган бу җыентыкта Венгрия галимнәре Й. Торма, А. Рона-Таш, Л. Тардь, немец галиме К. Шёниг, татар галимнәре А. Халиков, Р. Әхмәтҗановларның да гыйльми эзләнүләренең кайбер нәтиҗәләре аерым бүлек итеп бирелгән, профессор Рона-Ташның сүз башы урнаштырылган.

Йомгак ясап шуны әйтергә кирәк: Европа безнең хакта күп яза. Телебез, әдәбиятыбыз, тарихыбыз, яшәү рәвешебез турында. Безне яратып язучылар күп, яратмаучылар да җитәрлек, дидек. Ләкин, фән, гыйлем андый симпатия, антипатияләрдән өстен торырга тиеш. Без исә үзебез турында кайда нәрсә чыкканын белмичә яши бирәбез. С. Рәмиев әйткәнчә, «татар йоклый». Без һаман әле уяна алмыйбыз, авырлык белән генә күзне ачабыз да яңадан ойыйбыз. Югарыда китерелгән хезмәтләр безне дә активлыкка чакырмыймыни? Татар теле галиме дигән төшенчә галимнең рус, гарәп, немец, төрек, мадьяр, инглиз, француз телләре белән эш итә алучы кеше икәнлеген таләп итмимени? Кайда безнең мадьяр телен өйрәнгән тел галимебез? Ә бит мадьяр Балинт, рус Чернышевский татар телен белгәннәр. Кайда немец телен, инглиз, гарәп, төрек, француз телләрен иркен белгән тюркологларыбыз? Ә бит профессор Н. Ф. Катанов сигезләп телне белгән, татар галимнәренә гарәп шрифтында татарча хатлар язган...

Халкыбыз, аның мәдәни омтылышы яңа галимнәр көтә. Болар, яңа галимнәр, Европа һәм Шәрык академияләре, академиклары белән әвәрә килеп, аралашып, фикерләшеп яшәргә тиешләр. Телләр белергә тиешләр. Булган бит безнең бабалар: Исмәгыйль ага һәм Касимов фамилияле агай дәүләт миссиясе белән Һиндстанга барганнар. Алар, шәт, телләр белгән кешеләр булганнардыр?

Мадьяр галимнәренең безнең халкыбызга карата булган шундый зур игътибарын күргәннән соң туган уйлар болар. Аянычлы уйлар. Күпме гомеребез Сталин, Жданов, Маленков докладларыннан өзек китереп әдәбият тикшерүгә сарыф ителде. Татар әдәбиятын анализлаганда Сталин, Маленков сүзләрен генә түгел, Мао-Цзе-дун сүзләрен дә нигез итеп алдык. Галимлек урынына фәннәр докторы, профессор дигән исемнәр, дәрәҗәләр культы ясалды. Гыйлемлелекне тирәнәйтәсе, гыйлем белән коралланасы урында кандидатлык, докторлык шаукымы тудырылды. Колхозлашу елларындагы канатлы фразаны («в колхозы пошел середняк») искә төшерсәк, фәндә дә шулай булды: «середняк» докторлыкка таба юл алды. Кандидат кеше кандидат булмаган кешедән (әйтик, тел галиме И. Абдуллиннан), доктор булган галим докторлык дәрәҗәсе алмаган галимнән (әйтик, кандидат Х. Курбатовтан) өстен тора итеп карала башлады. Әсәрләреннән бөтен дөнья халкы файдаланган Аристотель, Н. Буалоның гыйльми дәрәҗәләре бөтенләй булмаганын, гаҗәеп талант иясе әдәбиятчы М. Бахтинның нибары кандидат кына икәнлеген без искә алмаска тырыштык. Тарихыбызны хәтерлик: Җ. Вәлиди, Г. Ибраһимов, Г. Рәхим, Г. Шәрәфләр арасында социаль-сәяси аллә никадәр бәхәс, ызгышлар булса да, ул бәхәсләрдә профессорлык-докторлык яки кандидатлык яссылыгында бер сүз дә әйтелмәгән. Безгә гыйбрәт бу!

...Европаның гыйлем учаклары безгә таба йөз бара. Европа гыйлеме безгә күз тутырып карый, әлемтә әзли. Безгә таба каршыга килә башлагыз, ди. Ә без... качабыз, оялабыз. Безнең филология галимнәренең Европа белән аралашырлык, аңлашырлык көчләре, куәтләре юк. Физиклар, математиклар, химиклар ул өлкәдә безнең филологлардан күп өстен. Алар — татар егетләре — Африка, Азия илләренә барып физика-химия, математикадан югары уку йортларында француз, инглиз телләрендә лекция укыйлар. Физика һәм математика фәннәре буенча ике тапкыр доктор Рәис Бохараев әле Лондонда, әле Америка Кушма штатларында, әле Коньяк Америкада лекцияләр укып йөри. Мин академиклар Р. Сәгъдиев, К. Вәлиев, М. Мәхмүтовларны әйтмим дә инде...

...Мадьяр галимнәре безнең гыйльми, мәдәни үсешебез өчен нинди игелекле эшләр башкарып яталар икән! Аларның гыйлем дөньясында безнең татар халкының акылы, эстетик фикере, мәдәнияты шаулап яшәп ята икән.

Безнең халкыбызга, тарихыбызга ихтирам саклап, безнең белән аралашырга колач җәеп әзер торган бу галимнәргә халкыбыз исеменнән рәхмәт! «Казан утлары» журналының укучылары да бу фикеремә бердәм кушылырлар дип өмет итәм.

[5] Tatarische Etymologische Studien II. Szeged. 1988.

**Ленар Җамалетдинов,**
филология фәннәре кандидаты

# ВЕНГР ГАЛИМЕ ТАТАРЛАР АРАСЫНДА

Татар фольклорын җыюда һәм бастырып чыгаруда чит ил тикшеренүчеләренең дә лаеклы өлеше бар. Бу өлкәдә бигрәк тә венгр галимнәре тырышлык күрсәткәннәр.

XIX гасырның җитмешенче елларында Г. Балинт һәм XX гасыр башында Ю. Месорошның татар фольклоры белән бәйле эшчәнлекләре безгә күптәннән билгеле иде. Соңгы елларда исә И. Кунош эшчәнлеге турында да шактый гына мәгълүмат тупланды.



*Венгр галиме И. Кунош*

Инде билгеле булганча, венгр галиме лингвист Игнац Кунош татар фольклорын Беренче бөтендөнья сугышы елларында (төгәлрәк әйткәндә — 1916—1918 елларда) хәрби әсирләр арасында җыйган. Беркадәр элегрәк без ул язып алган «Ак бүре» әкиятен генә белә идек. Бу әкиятне Куношның «Төрек халык әдәбияты» (Истанбул, 1925) дигән китабыннан Г. Толымбай күчереп алган булган. Әмма Кунош эшчәнлегенең конкрет детальләре безнең өчен озак вакытлар билгесез булып калды. Бары тик 1963 елда, венгр галиме Жужа Кәкүкнең Будапештта чыга торган «Акта Ориенталия» журналында Кунош архивындагы татар фольклоры материалларына багышланган мәкаләсе басылып чыккач кына, безгә кайбер яңа фактлар мәгълүм булды. Без бу турыда «Ак бүре»нең илгә кайтуы» дигән мәкаләбездә язган идек инде («Казан утлары», 1987, 8 сан).

Ниһаять, соңгы вакытта, Будапешт университетының яшь галиме Имре Башки ярдәме белән, безнең Куношка бәйле мәгълүматларыбыз бермә-бер артты.

Кунош шул чорда үзенең хәрби әсирләр арасындагы фәнни эшчәнлеге турында мәкаләләр дә язган. Аның «Татар хәрби әсирләре» лагеренда. Мөселман хәрби әсирләре лагерьларындагы тикшеренүләр турында хисап» дип исемләнгән бер мәкаләсе 1916 елда «Будапешт күзәтүчесе» дигән журналда дөнья күргән[1]. И. Башки безгә венгр телендә басылган бу мәкаләнең эчтәлеген язып җибәрде. Анда түбәндәгеләр хәбәр ителә. Мөселман хәрби әсирләре өчен ике лагерь була: берсе — Эстергом шәһәреннән ерак түгел Кеньермезье дигән венгр поселогы тирәсендә, икенчесе — Австриядәге Эгер шәһәре янында. (Бу шәһәрләр хәзерге Венгриянең төньягында урнашканнар). Беренчесендә Кырым һәм Казан татарлары тотылган. Кунош биредә беренче чиратта Кырым татарларының фольклорын һәм телен өйрәнгән, әкиятләр язып алган. Икенче лагерьда, Кырым һәм Казан татарларыннан тыш, Кавказ халыклары, төрекмәннәр, башкортлар, нугайлар һ. б. булган. Монда Кунош Кырым татарларына караган материаллар җыюны дәвам иттергән, шуның белән бергә, башка халыкларның, аерым алганда Казан татарлары һәм мишәрләрнең, җырларын һәм әкиятләрен язып алган.

Куношның бу мәкаләсендә Казан татарларының әсирлектәге тормышы турында игътибарга лаек мәгълүматлар бар. Менә Башки хатыннан бер өзек: «Лагерьда татарлар үзләренең әдәби һәм мәдәни тормышларын югары дәрәҗәдә оештырганнар. Аларның «Кечерәк юаткыч» дигән әдәби газеталары була. Куношның белдерүенә караганда, башка татарларның (ягъни башка төрки халыкларның — Л. Җ.) фольклоры

[1] Kúnos. Ignacz. Tatar foglyok táborában. Felentés a mohamedán fogolytáborokban végzett tanulmányokról: Budapesti Szemle CLXV(1916). 3—21



*Татар әсирләреннән бер төркем.*

арасында иң кыйммәтлесе — Казан татарлары фольклоры. Аларның теле исә әдәби тел дәрәҗәсенә күтәрелгән».

Галим үзенең хезмәтендә бик мавыктыргыч «Ак бүре» әкиятен язып алганлыгын һәм фольклор материалларын җыюда аңа Казанлы Вәлиевнең (Шәһит Вәлиев) ярдәм иткәнлеген дә билгеләп уза.

Әсирләрдән җыеп алынган музыкаль материал нигезендә Вена Академиясенең «тавышлы архив»ы өчен, бирedә австралиялеләр егермеләп пластинка да эшлиләр. Ул пластинкаларның язмышы мәгълүм түгел. Һәрхәлдә татар җырлары турындагы хезмәтне язганда Австрия галимнәре Лах һәм Янски[2] алардан файдаланган булырга тиеш.

Куношның әсирләр арасындагы эшчәнлеген яктырткан икенче хезмәте «Төрек халык әдәбияты» китабында аерым бүлек итеп урнаштырылган (7 бүлек, 156—206 битләр). «Мөселман хәрби әсирләре лагерьларындагы эш турында» дигән бу бүлектә автор безне кызыксындырган мәсьәләләргә киңрәк тукталган.

Куношь әлеге хезмәтнең беренче юлларында бөтендөнья сугышының зур бәла булуын, шул вакытта күрелгән авырлыкларның хәтердән беркайчан да чыкмаячагын әйтә.

Әсирләр арасында эшли башлаганда (1916 елда) галим 56 яшендә була. Әмма ул үзе: «Сугыш башланганда 60 яшемә бастым»,— дип яза (157 бит). Бу безнең өчен киләчәктә ачыкланырга тиешле факт булып кала. «Венгр биографик энциклопедиясе»ндә Куношның 1860 Хайдушамшонда туганлыгы әйтелә. 1882 елда ул, Будапешт университетын тәмамлап, укытучылык дипломы һәм магистрлык дәрәҗәсе ала. 1885 елдан биш ел буена Истанбулда яши. Шул чорда ул Кече Азия һәм Балканга да сәяхәт ясый, төрки халыкларның фольклорын җыя. 1890 елдан галим Будапешт университетында төрек теле һәм әдәбиятын укыта башлый, бер үк вакытта Коммерция академиясенең шәрык курсында да төрек теленнән дәресләр бирә. Соңрак, 1899 елда, Куношь әлеге академиянең директоры була. Шул ук елдан ул, лингвист һәм этнограф Бернат Мункачи белән бергә, «Келети семле» («Шәрык күзәтүчесе») журналын редакцияли. Куношь 1945 елның гыйнварында Будапештта үлә.

Галимнең күп кенә хезмәтләре немец, инглиз һәм төрек телләрендә басылган. Аның без сүз алып бара торган хезмәте дә төрек телендә. (Аны укуда безгә Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты фәнни хезмәткәре С. Гыйләҗетдинов ярдәм итте).

Әсирләр арасында эшләргә Куношь Венгрия Фәннәр академиясе үтенече буенча керешә. Өлкән яшьтә булуына карамастан, иленә файда итү, шәрыкны өйрәнүгә өлеш

[2] Lach R., Jansky H. Volksgesänge von Völkern Russlands aufgenommen von Robert Lach. II. Turktatarische Völker: Kazantatarische, mischärtatarische, westsibirisch-tatarische ... Gesänge. — SWAW. Bd CCXXVII, Wien, 1952. Abh. 4.

кертү хакына галим әлеге җиңел булмаган эшкә ризалык бирә. Бу максатка Кунош өч елның (1916—1918) өчәр аен багышлый. «Һәр иртә таңнан калкып, тимер юл илә Әстәргумга китәр, анда ахшамга кадәр калыр идем. Татар әсирләре илә күрешкәнче иң әүвәл бераз татарча үгрәндем»,— дип яза ул (157 бит).




Кунош татар хәрби әсирләренең саны биш меңнән артык булганлыгын әйтә. Ләкин ул «татарлар» дигәндә, гомумән, төрки халыкларны күздә тота. Әйткәнебезчә, аларның күбесе Казан татарлары була.

Кунош Казан татарлары теленең иң мөһим тел булуын әйтеп, халкының күплеге өстенә, бу телнең, матур һәм бизәкле булуы сәбәпле, Россиядәге төрле төрки милләтләр өчен әдәби тел вазифасын үтәгәнлеген кабат билгеләп уза.

Эгер шәһәре янындагы лагерьда 2 мең кеше тотылган.

Кунош бик итагатьле, әсирләрнең хәлен ихластан аңлый һәм аларга теләктәшлек күрсәтә торган йомшак күңелле, нечкә хисле кеше булып күз алдына килә. Татар әсирләре турында ул болай дип яза: «Еллар дәвамында ят җир икмәген ашаганга күрә, бәхетсезлек яшьләре түгелер иде... Кошлар очып үткәндә туган җирләреннән хәбәр булып тоелыр иде. Лагерь янындагы Эгер елгасының агымына хәйран калып, Идел һәм Агыйдел елгаларының агымнарын ишетерләр иде. Моңлы бер җыр җырлаганда күзләреннән йөрәкләренә каннар агар иде» (167 бит).

Биредәге татар гаскәриләре арасында офицерлар булмый. Әсирләр гади хезмәт кешеләре булганлыктан, арада төрле һөнәр ияләре дә күп була. Венгр галиме алар турында сокланып яза. Буш вакытларын әсирләр төрле кул эшләре эшләп, балалар уенчыклары ясап үткәрәләр. Татар йортлары, тройкалы арбалар, җил һәм су тегермәннәре, чатырлар, төрле-төрле кошлар, еланнар һәм башка хайваннар сурәтендәге уенчыклар «шул хәтле маһирлык белән эшләнәләр иде ки, лагерь командалыгы остаханәләр кордырды, бу сурәтләрдән күргәзмә ачылды» (167 бит). Көмешчеләр, тегүчеләр, буяучылар һ. б.лар эшләгән нәрсәләрне, йорт кирәк-яракларын Эгер шәһәрендәге зур кибетләр сатып ала. Кунош үзенең эшчәнлеге дәвамында меңнән артык шундый этнографик материалларны туплап, сугышның дүртенче елында Пешт шәһәрендә (хәзерге Будапештның бер өлеше), шәрык ысулы белән салынган бер бинада, «Татар әсирләре музее» дип атап, күргәзмә оештыра. Соңыннан андагы экспонатлар Пешттагы Шәрык академиясе (икенче исеме: Экономика университеты) музеена күчерелә.

«Әсирләрнең икенче иң яраткан шөгыле театр уены иде»,— дип яза Кунош (168 бит).

Әсирләр гади хезмәт кешеләре булсалар да, арадан әдәби иҗатка маһир затлар да чыга. Шундыйлардан бер укымышлы хәтта тарихи темага пьеса яза. Шунда ук утызлап татар яшьләреннән бер төркем төзелеп, репетиция башлыйлар. Арада тегүче дә, балта остасы да табыла, кирәкле костюмнар тегелә, бик матур сәхнә ясала. «Ниһаять, бер җомга көнне уен башланды,— дип яза Кунош.— Ачык бер мәйданда булган сәхнә меңнәрчә әсирләр белән тулы иде. Меңнәрчә иреннәр тетри иде. Меңнәрчә күзләр яшьләнер иде. Меңнәрчә «аһ» авазлары күкләргә чыгар иде. Бу уеннарның сәхнәсе, аның башкарылуы хәзер дә күз алдымдадыр» (168—169 битләр).

Биредә барысы ничә пьеса иҗат ителгәндер — анысы мәгълүм түгел. Әмма шулар арасыннан иң яхшысы дип санаганын Кунош берничә әсирдән күчертеп яздырган һәм, бөтендөнья сугышының бер ядкаре итеп, үзенең китапханәсендә саклаган.

Биредә укымышлы татар яшьләреннән янә бер төркем төзелә. Бу яшерен төркемнең төп максаты турында Кунош болай ди: «Тоткынлык ачысын татыган кайгылы йөрәкләрне тынычландыру һәм йөрәкләрендәге хисләрне, миләрендәге фикерләрне күрсәтү».

Шушы ниятләрен тормышка ашыру өчен әлеге яшьләр яшерен рәвештә алдарак телгә алынган «Кечерәк юаткыч» дип аталган кулъязма газета чыгара башлыйлар. Газета айга бер мәртәбә бер нөсхәдә чыга һәм

| | |
|---|---|
| 310. | |
| bijėk tauniñ bašında | Auf dem Gipfel des hohen Berges |
| bürülėp* üsken br boγdaj | wuchs der Weizen schwellend; |
| bürülėp üsken boγdaj kübük | als schwellend wachsenden Weizen |
| bijüktire** bzni br γodaj | lässt Gott auch uns aufwachsen. |
| 311. | |
| bijėk tauniñ bašında | Auf dem Gipfel des hohen Berges |
| elle pičen elle ülen | ist vielleicht Heu, vielleicht Gras; |
| elle kürem elle kürmim | vielleicht sehe ich sie, vielleicht nicht |
| aχrı kürmiče ülem | wenn nicht, dann sterbe ich schliesslich. |

*И. Куношның 1980 елда Будапештта басылып чыккан җырлар җыентыгыннан үрнәк.*

кулдан-кулга йөри. Мондый эшләр лагерьда катгый тыелганга күрә, газетаның кемнәр тарафыннан чыгарылганы беленми кала. Куношны дус дип санаганлыктан, аңа газетаны ара-тирә күрсәтә торган булганнар. Галим әсирләрнең бу фидакарь эшенә дә гаҗәпләнә һәм соклана. «Бу әдәби вә фольклор газеты булып, анда әсирләрнең үз темалары, халык шигырьләре, әсирлек хатирәләре һәм ара-тирә бөтендөнья сугышы турындагы фикерләре бар иде,— ди Кунош.— Боларны шулхәтле камил бер сурәттә бәян итәрләр иде ки, мин укыган вакытта хәйран кала идем. Язган шигырьләре, халык рухыннан купкан җырлары шулхәтле хәйран калдырырлык иде, үз мәмләкәтләрен искә төшергән хатирәләре шулхәтле тәэсирле, бөтендөнья сугышына караган фикерләре шулхәтле тирән мәгънәле иде ки, журналист булсалар да, моннан да яхшырак итәп яза алмаслар иде» (169 бит).

Газетаның кушымтасы да була. Анда, гадәттә, фольклор материаллары урнаштырыла. Алар арасында, Кунош сүзләре белән әйткәндә, «бәхетсез татар әсирләренең йөрәкләреннән купкан», «укучыларның йөрәкләрен телә» торган җырлар күпчелекне тәшкил иткән булса кирәк.

Дүртьюллык җыр үрнәкләрен галим бу хезмәтендә күрсәтеп тә уза. Анда Казан татарларының алты (172—173 битләр), Кырым татарларының сигез (170—171 битләр), мишәрләрнең биш (171—172 битләр) җыры теркәлгән. Менә шуларның икесе:

*Солдат чәче урга карый,*
*Көн дә бер майлап тарый;*
*Туган җире исенә төшсә,*
*Кайтыр юлына карый.*

(Казан татарлары җырларыннан)

*Ике юлның арасы —*
*Без каеннан барасы.*
*Бара-тора исемә төште*
*Туган илнең калясы.*

(Мишәр-татар җырларыннан)

Куношның әсирләр белән мөнәсәбәте бик дустанә була. Әсирләр аңа үзләренең хәсрәтләрен сөйлиләр, хаҗәтләрен әйтәләр. Галим аларга мөмкин булганча ярдәм итә: авыруларны врачка күрсәтә, Әгер шәһәренә барырга теләгәннәргә атнага бер тапкыр начальстводан рөхсәт ала. Үз чиратында әсирләр дә аңа ачык чырай, илтифат күрсәтергә тырышалар. «Мәмләкәтләреннән чәй вә ашамлыклар, сугыш сәдакасы алганда мине чакырырлар иде. Җомга вә бәйрәм көннәре булганда аш өсталләрендә минем дә урыным бар иде»,— ди ул (174 бит).

Кунош кайбер айлы кичләрдә венгр офицерлары белән лагерь бакчасында утырганда әсирләрнең скрипка һәм башка уен коралларына кушылып җырлаган моңлы тавышлары ишетелеп торуын аеруча тәэсирләнеп яза. «Без аларның кайгыларын эчтән генә кичерә идек. Бәхетсез әсирнең гөнаһсыз йөрәк ачыларына бик күп кайгырдык, әмма ни чара — кулыбыздан берни дә килми»,— ди ул (174 бит).

Кунош сүзләренә караганда, «ислам әсирләре маҗар офицерлары тарафыннан бик әйбәт багылалар, аларга аеруча диннәренә вә гадәтләренә ярашлы ашамлыклар бирелә. Имамнары бар, намазларны кылалар... Мөәзиннең сүзе ишетелгәндә, 5 мең мөэминнең намаз укыганы, «амин» сүзенең йөрәкләрнең тирәнлегеннән чыгуы җир тетрәве кебек йөрәкне тетрәтер иде» (166, 174 битләр).

Ниһаять, әсирләр белән саубуллашу көне дә җитә. Татар егетләре Куношка «Кечерәк юаткыч»ның барлык нөсхәләрен һәм әсирләрнең лагерьда төркемләп төшкән фоторәсемнәрен бүләк итәләр. Сүз уңаенда шуны да әйтик, фотоларның кайберләре Куношның 1980 елда Будапештта басылып чыккан җырлар җыентыгында дөнья күрде. Ә «Кечерәк юаткыч»ның бер санын галим 1925 елда Әнкарә шәһәрендә «Төрек учагы» җәмгыятендәге очрашу вакытында, бөтен-

дөнья сугышының бер ядкаре буларак, шул җәмгыятькә бүләк итеп бирә.

Әсирләр белән хушлашу галимгә нык тәэсир итә, ул аларның киләчәк язмышлары турында борчыла: «Кем белә, аларны тагын бер күрерменме? Кем белер, алар Ватаннарын, гаиләләрен һәм балаларын күрерләрме?.. Сугыш ул вакытта әле дәвам итә иде. Өметләре дә кисела башлаган иде. Җырлары, көйләре, әкиятләре бездә калды. Кайгылары-хәсрәтләре очып... илләренә җитешерме?»

Куноги үзенең хезмәтен түбәндәге юллар белән тәмамлый: «Бөтен дөнья канлы бер давылга тап булып, без ул давыл эченә эләгеп, бәхетсез әсирләрнең күз яшьләрен «халык әдәбияты» исеме астында дәфтәребезгә язып саклыдык. Бу хезмәтемә өстәмә итеп, Казан татарларының иң гүзәл бер әкияте булган «Ак бүре» әкиятен укучыларымның игътибарына тәкъдим итәм» (175 бит).

Шуннан соң бу китапта «Ак бүре»нең тексты китерелә.

Йомгаклап әйткәндә, Куношның әсир бабаларыбыз теленнән язып алган фольклор материаллары — әкиятләр һәм җырлар белән бергәттән, галимнең шул әсирләр тотылган лагерьлардагы эшен, гомумән, лагерь тормышын чагылдырган хезмәтләре дә зур әһәмияткә ия. Аларда халкыбызның асыл сыйфатлары бик ачык күренә. Хезмәт сөюче гади халык уллары экстремаль шартларда да югалып калмаганнар, үзләренең тоткынлыктагы газаплы тормышларына ямь өстәү юлларын тапканнар: кул эшләре, җыр-музыка, әдәби иҗат белән шөгыльләнгәннәр, спектакль куйганнар, яшерен рәвештә газета чыгарганнар, бәйрәмнәрен билгеләп узганнар...

Килер бер көн, тарихчыларыбыз, сәнгать белгечләребез арасыннан күп телләр белүче яшь фидакарьләр чыгып, әсир бабаларыбызның каннары һәм күз яшьләре тамган җирләргә сәяхәткә юнәлерләр, алар күргән җир-суларны күрерләр, алар ясаган уенчыкларны, алар чыгарган газеталарны эзләп табарлар, алар турында һәм шулай ук Венгрия Фәннәр академиясенең член-корреспонденты, танылган тюрколог, саф күңелле гуманист Игнац Кунош турында бай мәгълүматлы гүзәл хезмәтләр иҗат итәрләр.

---

## *Котлыйбыз!*

### Хәсән Хәйригә 80 яшь



Әдәбият галиме һәм тәнкыйтьче Хәсән Хәйри (Хәсән Фәхретдин улы Хәйруллин) 1910 елның 5 февралендә элекке Урал губернасы Лбищенск өязендә (хәзерге Казахстанның Уральск өлкәсе, Чапаев поселогы) туа. Сигез-тугыз яшендә ул әти-әнисез калып, Җаек шәһәрендәге балалар йортында тәрбияләнә. Шунда башлангыч белем ала.

1934 елда Х. Хәйри Казанга килә, укытучылар институтына укырга керә. Аннары ул «Уку ударнигы» газетасында һәм «Совет мәктәбе» журналында эшли. Сугыш алды елларында Татарстан китап нәшриятында хезмәт итә. 1941 елда аның әдәби тәнкыйть мәкаләләрен туплаган «Эзләнүләр» исемле беренче җыентыгы басылып чыга. 1942—43 елларда Х. Хәйри Тел, әдәбият һәм тарих институтының әдәбият секторы мөдире, ә 1944—48 елларда КПССның Татарстан өлкә комитетының пропаганда бүлеге инструкторы булып эшли.

Сугыштан соңгы чорда Х. Хәйри әдәбият белеме һәм әдәби тәнкыйть өлкәсендә актив эшли.

Х. Хәйри 1936 елдан бирле Язучылар союзы члены. Ул — Татарстанның атказанган фән эшлеклесе.

Татарстан Язучылар союзы идарәсе һәм «Казан утлары» журналы редакциясе юбилярны чын күңелдән котлый. Аңа яңа иҗат уңышлары, озын гомер тели!

## Ләбибә Ихсанова

# ЧИШМӘ ҖЫРЫ

БЕР ХАТИРӘ

Илленче еллар башында мин Татарстан радиокомитетының балалар редакциясендә бераз эшләп алдым. Тәбәнәк, ләкин шактый иркен, бервакытта да кояш төшмәгән, шунлыктан караңгырак һәм салкынча бүлмәдә әдәби, музыкаль һәм балалар өчен тапшырулар редакцияләре урнашкан. Көннең көнозын язучылар, композиторлар, артистлар өзелеп тормый ул бүлмәдән. Йомышлары булса да, булмаса да керәләр, фикердәшләрен очратсалар, озаклап сөйләшеп утыралар. Без аларга өйрәнгән, эшләгәндә комачауламыйлар, киресенчә, берәр төрле информация йә белешмә кирәк булганда «аяклы энциклопедияләр» янывызда гына.

Бер көнне машинкада бастырган кулъязмаларымны алып бүлмәгә керсәм, ишек кырыендагы кара дермантин диванда бер егет утыра. Мин аңар артык игътибар итмәдем, баш кагып кына дигәндәй, исәнләштем дә, утырып, кәгазьләремне укый башладым.

— Гафу итегез, миңа әдәби тапшырулар редакторы кирәк иде.

Башымны күтәреп карауга әлеге егетнең мөлаем йөзенә, яшькелт зәңгәр күзләренә, бик итагатьле итеп эндәшүенә һәм түгәрәкләп төргән кәгазь тоткан бармаксыз кулына игътибар иттем.

Кулъязмаларын мин күрсәткән өстәл өстендә калдырып киткәч, бу әдәпле кешенең кемлеген беләсем килеп, төргәкне сүтеп карадым. Кулдан язган шигырьләр астына Мәҗит Рафиков дип куелган иде. Сугыштан кайтып Казан дәүләт университетына укырга кергән шагыйрь белән мин шулай таныштым.

Соңыннан аның язганнарын калдырмыйча укып барырга тырыша идем. Ошата идем мин аларны, укыганда күңелем ял итә, сусаганда салкын чишмә суын эчкән кебек рәхәтлек тоям, күкнең зәңгәрлеген, кояшның яктысын, җилләрнең җылылыгын ачыграк сизәм кебек. Еллар үткәч шигырьдән прозага күчте ул. Прозасы да аның эчке бер аһәңгә корылган, үзенә бер агым белән язылa иде. Чишмәләр кебек, һәр әсәренең үз тәме, үз тавышы бар, укучы күңелен үзенчә сугара. Чишмәләрнең дә бит төрлесе була, ташлар ярып чыкканы, шаулап, чәчрәп акканы була, куе үләннәр арасыннан тавышсыз-тынсыз, ашыкмый-кабаланмый гына юл ярганы була. Алары болын чишмәләре, сулары саф, салкын, мөлдерәмә тулы. «...бер өем таллык. Анысы да куак кына. Куе яшел кайрылы кәүсәләре, ботак-тармаклары, вак кына тоньк, яшел яфраклары барлы-юклы җилдә кыймылдашып, тирбәлешеп куялар. Шушы куакның тамыр төпләреннән саркып кына чыккан чишмә суы үлән арасыннан шау-шусыз гына җәелә-тарала биреп, әкрен генә, тыныч кына ага да ага икән... Куагы да чишмәсен яман күзләрдән саклаган, кемнәндер алган шикелле куерып, өстән каплап тора...»

Мәҗит Рафиков тасвирлаган бу күренештә мин аның үз иҗат алымын күрәм. Ул шулай тыныч кына, артык күзгә бәрелмичә, әдәбият дөньясында шау-шу тудырмыйча язды да язды.

Шигырьгә тартым бер моң белән, кешене рухландыра, канатландыра торган күтәренкелек, тормышка, дөньяга, балаларча соклану белән карап иҗат иткән Мәҗиткә күңел нечкәлеге, үткен тойгылар кайдан килгән соң? Кайдан алган ул әсәрләрендәге үзәк өзгеч моңны? Мәҗит үзе булса: туган җир туфрагы, җаным яралган якның табигате, дигән булыр иде, мөгаен. Урал-тау итәгеннән бәреп чыккан салкын чишмәләр, котырып үскән куе таллыклар, болыннардагы аллы-гөлле чәчәкләр күңел нечкәлеге биргәндер аңар, кыя таш өстендәге мәгърур нарат соклану гыйлемен өйрәткәндер.

Үзенең бер тәнкыйть мәкаләсендә Фәрваз Миңнуллин Мәҗитне матурлык эзләүче

дип атаган иде. Әйе, ул матурлык эзләүче. Туган кырларыннан, якташларының эзләреннән, хәтта авылының ерак тарихыннан да матурлык эзләүче. Шуны табып укучысына күрсәтеп бирә белүче. «...Урталыкның һавасын иң нечкә хуш исләр симфониясе диярсең. Һәрбер чәчәге, һәрбер яфрагы һавага үзенең баллы-шифалы сулышын өстәп кенә тора. Башыңны күтәреп, төпсез, чиста зәңгәрлеккә кара — бу юмарт кояшлы дөньядан мәңге-мәңге аерылмас булырсың...»

Бу юлларны укыганда мин туган ягым Вятка (Нократ) буйларын сагындым. Чикләвек куаклары үсеп утырган тау битләрен, кәрәкәле түгәрәк күлләрен, югары карасаң башларың әйләнеп китәрлек нарат урманын сагындым. Инде күптән аяк басмаган туган өемнең ишекләрен ачып керәсем килде. Сагыш кына түгел, тормышка сусау уятты ул юллар миндә.

Туган җирнең йомшак туфрагында яланаяк йөргән, җиргә ятып салкын, саф суларын эчкән, табигать кочагында үскән кешенең күңеленнән мәрхәмәтлелек ташып тора. Мәҗитнең бит аның туган авылы да шигъри исем йөртә — Күгәрчен авылы. Күгәрчен районы. Яшьлегендә ул дөньядагы иң гуманлы профессияләрнең берсе — медицинаны сайлый. Яшәү көченең ныклыгына инанган, якты күңелле, туган җиргә бөтен күңеле белән гашыйк булган яшь фельдшер егет фронтта үлем белән күзгә-күз очраша. Ләкин шул кан-сөрем арасында йөргәндә дә ул туган авылы Күгәрчененнән, Аллагыват, Ишгилде авылларыннан, илебезнең йөзләгән-меңләгән авыл-шәһәрләреннән килгән егетләрнең туган ил хакына эшләгән батырлыкларын күрә. Шулай итеп, туган ил табигате аңар күңел нечкәлеге, якты тойгылар бүләк итсә, аның арсландай кыю егетләре булачак язучыда гражданлык хисләре тәрбияли. Яраланып госпитальдә ятканда кешеләргә тән саулыгы гына түгел, җан саулыгы да кыйммәт икәнен төшенә. Кайвакыт яралыларга, даруларга караганда да, шигърият дөньясындагы тылсымлы сүзләрнең файдасы күбрәк булуын белә. Балачактан үзенә тартып, мавыктырып килгән бу сихри дөньяга керергә батырчылык итүе дә аның менә шушы елларда була. Егет күңелендәге уй-хисләрен, ашкынулы теләкләрен шигъри юлларга сала башлый. Шигырьләрдә утны-суны кичкән яшь солдатның туган ягын сагынуы, югалту хисләре, көрешү шатлыгы... ул елларны ил кичергән тойгылар. Шигырьләр җылы гына, хисле генә язылсалар да канатларны нидер тота, һавадагы кош кебек иркенләп, очып китә алмый егет. Мәҗит укырга кирәклеген аңлый.

Менә ул Казан дәүләт университеты студентлары арасында. Аңар кадәр үк инде университетның татар теле һәм әдәбияты бүлеге каршында шактый көчле әдәбият түгәрәге эшли. Түгәрәк утырышларында Афзал Шамов, Гомәр Бәширов, Әхмәт Ерикәй, Латыйф Җәләй, Гали Хуҗиев, Шәраф Мөдәррис кебек танылган язучылар катнаша. Ә түгәрәккә йөрүчеләр инде әдәбият дөньясында тавышларын ишеттерә башлаган яшь шагыйрьләр, прозаиклар, әдәбият белгечләре. Шулар арасында тыйнак, сабыр холыклы, акрын тавышлы,иптәшләре белән вәземләп, тәмләп сөйләшеп утырырга яраткан ачык йөзле Мәҗит тә бар. Иптәшләре аның шигырьләрен ратканнар. Остазлар да кулъязмаларны тикшергән чагында, өметле генә фикерләр әйткәннәр. Шул өлкәдә туктаусыз эшләсә, бәлки ул, әйбәт шагыйрь булып китәр иде. Әмма ул еллар Мәҗитнең эзләнү еллары булган күрәсең. Язмышыңны тапканчы эзлә, дигән бит картлар. Шуның кебек Мәҗит тә проза өлкәсендә көч сынап карарга уйлый. Прозага ул әйләнгеч юллар белән, тәрҗемә аша килә. Габдулла Тукай, Шәриф Камал кебек классик язучыларны, рус телен никадәр генә яхшы белсәң дә рус укучысына җиткерү ансат эш түгел. Моның өчен иң элек ул ана теленнең байлыгына, аның барлык мөмкинлекләренә ия булу кирәк. Мәҗит иң элек әнә шул гыйлемне өйрәнергә тырыша. Аның кулы аша үткән татар әсәрләрен бөтенсоюз укучысы яратып кабул итте. Инде Язучылар союзы каршындагы тәрҗемәчеләр секциясен җитәкли алырлык, тәрҗемә әсәрләр турында төпле тәнкыйть фикерләре әйтә алырлык белемле, абруйлы Рафиков әкренләп, повесть һәм хикәяләр язуга керешә. Әсәрләренең сыгылмалы, лирик тел белән язылуы, музыкальлеге, халыкның күңел байлыкларыннан килгән моңга юмартлыгы язучының тәрҗемә эшендә алган тәҗрибәсеннән дә килүе бәхәссез.

Повесть һәм хикәяләрдә баш җуярлык вакыйгалар да, гайре табигый эшләр дә, даннары еракларга киткән кешеләр дә юк. Әсәрләр табигатьнең бер күзәнәкле җан ияләре кебек гади, самими. Ләкин аларның гади күзгә күренмәгән бик үзенчәлекле, кызыклы тормышы бар. Бу тормыш зур һәм катлаулы дөньяның бик зарури бер кисәге. Ә язучы ул, әйтерсең лә, микроскоп янындагы бер галим. Ул теләсә кем күрә алмаган шул гадәти тормыштан берсен сайлап ала да, аның бар үзенчәлеге, кызыклыгы белән укучы алдына китереп сала. Автор көчәнми, укучы кәефен табыйм дип, матур сүзләр эзләп интекми, гади генә хәлләр турында, гади генә кешеләр хакында тыныч кына сөйли бирә. «Безнең Рәхмәтулла абзый да Бөек Ватан сугышында катнашкан икән ләбаса. Миннән сорасалар, юктыр, эләкмәгәндер, авыруы белән алмаганнардыр, дигән булыр идем»,— дип башлап китә ул бер хикәясен. Әйтерсең лә җәйге бер тымызык кичтә, капка төбендәге бүрәнә өстендә, тәмәке төтәтә-төтәтә, сөйләшеп утыралар. Ә бит ул гомере буе сәламәтлеккә туймаган гади, юаш бер авылдашының тимер булып тимер чыдамаган Курск дугасын-

да сугышуы турында сөйләргә җыена.

«Сәлим абый миңа ни туган түгел, ни бергә уйнап-үскән яшьтәш түгел, ул минем Фатыйх иптәшнең абыйсы гына», дип башлана икенче хикәясе. Һәм шулай җай гына, кабаланмый гына авылдашы Сәлимнең егет чактан алып алтмыш яшькә җиткән гомерен сөйләп чыга. Ялыктырмый. Чөнки ул Сәлимнең кеше күңелен җәлеп итәрлек якларын гына тотып алган, башка авылдашлары белән мөнәсәбәттә сурәтли, ярылып яткан характерын бирә. Һәм без Кызыл Армия сафларыннан буденновка киеп кайткан кече командир Сәлимнең Ватан сугышында яралануын, фронттан кайткач, кая кушсалар шунда эшләп, намуслы гомер итүен күрәбез. Мәҗит әсәрләрендәге геройлар — аның авылдашлары. Укытучы Хаҗи Зәетов, Хәлимәләр, колхозның беренче партия җитәкчесе Төхфәтуллин, авылга трактор кайткач, заман ахыры җитте, дип кайгыга калган Маһирәттәйләр, юл йөрер Фатыйма түтиләр һ. б. һ. б. Алар турында укыганда аз гына булса да язучы фантазиясе кушылгандыр, дип уйламыйсың. Автор аларның төс-битләрендәге характерлы сызыкларын, кием-салымнарындагы үзенчәлекләрне, гадәт-фигыльләрен очерктагы төгәллек, документаль дөреслек белән сурәтли. Хикәяләрдәге аерым характерлы, аерым чорда яшәгән күп төрле кешеләрне берләштергән уртак сыйфатлар да таба автор. Ул — аларның җыр, музыкага гашыйк булулары. Тәнкыйтьче әйткәндәй, матурлык яратулары. Әнә егетләр җыр җырлап фронтка китеп баралар. Менә аның чишмәләр ачып йөргән былбыл Хәбире. Әнә Рәхмәтулла солдат. Граммофон сатып ала да ул, тәрәзәсен ачып куеп, бөтен Түбән очны моң дәрьясына сала. Менә «Илһам авазы» дигән повесть. Ерак Урал итәгендә үскән Галимҗан белән Исмәгыйльнең музыка мәктәбенә укырга кереп, оста гармунчы булырга хыялланулары һәм сугыш аркасында бу матур хыялның өзелеп калуы.

Әйе, сугыш кыя тау итәгендә, яшел аланнар уртасында яшәп яткан шигъри исемле Күгәрчен авылына да зур хәсрәтләр китерә. «Әрекмән яфрагына юл тузаны төреп, «бомба» атышып уйный-уйный үскән малайлар Европаның төрле җирләрендә, солдат каберләрендә ятып калалар». Бер ишләре — колхоз бухгалтеры Исмәгыйль кебекләре, сугышта алган яраларыннан айный алмыйча, өйләренә кайтып дөнья куялар. Исән калганнарының да балалары җиде төн уртасында сискәнеп уяна торган була. Әнә аның кызыл кояш, зәңгәр өйләр ясаган нәни улы. Бала кулы өйләргә кызыл флаглар элә, өй янына зәңгәр агачлар утырта. Болар әле кәгазьдә генә, әле бала хыялы гына. Әнә ул эшеннән канәгать булып йокларга ята, нәни кулларын бит астына куя да күзләрен йома. Ә төшендә самолетлар... бомбалар... шартлаулар...

— Әти! Әти! Өйләрем! Аларга бомба ташламаслармы?

Дөнья тыныч түгел. Гамьсез, исәпсез генә яшәргә ярамый. Матурлыкны сөюче, җыр яратучы табигать балаларын уяу булырга чакыра язучы. Сизгер йөрәкле кешеләр ишетәләр аның тавышын. Мәҗитнең китапларын үз илебездә генә түгел, кайбер әсәрләрен Һиндстанның унике милли телендә, инглиз һәм непал телләрендә дә укыйлар.

Мәҗит, герое Исмәгыйль кебек, үзе дә сугышта алган җәрәхәтләреннән гомере буе җәфа чигеп яшәде. Гәүдәсен гадәттәгедән турырак тотып, кыенлык белән атлап йөрүеннән без аның хәлен аңлый идек. Ләкин ул горур кеше булды, бер вакытта да зарланмады, чытык йөзен күрсәтмәде. Очрашканда яшькелт-зәңгәр күзләрен нурландырып, елмаеп күрешер иде. Бары бер генә тапкыр мин аның авыруы турында телгә алганын ишеттем. Кайсыдыр бер сайлау алдыннан булды ул. Мәҗит белән без агитпунктта сайлаучыларга әдәбият турында сөйләргә тиеш идек. Төне буе кар явып торганга тротуарлар ерып йөрерлек түгел, урам уртасындагы машиналар да кыенлык белән бара. Такси алырга теләдек, ул да барып чыкмады. Җәяүләп, Профсоюз урамыннан Куйбышев мәйданына таба барабыз. Мәҗиткә караганда минем адымнар кызурак, бераз гына алга китәм дә, туктап көтеп алам. Узып китәм дә, көтеп алам. Мәҗит миңа җәфа булам дип уйлады ахрысы уңайсызланып:

— Мин алай кызу йөри алмыйм инде, аякларым авырта,— дип әйтергә мәҗбүр булды.

Бу вакыттан соң да әле ул, үз аягында, арабызда шактый озак йөрде. Ләкин авыруы елдан ел көчәя барып, соңгы елларда әдип гел өйдә генә утырып эшли башлады. Аның соңгы тапкыр Язучылар союзының Тукай клубына килүе 1985 елның 6 маенда Бөек Җиңүгә 40 ел тулган көнне булды. Сугыш ветераннары хөрмәтенә ул көнне бик матур кичә оештырганнар иде. Каләмдәшләре Мәҗитне күреп, сугышлардан йөреп кайткан язучылар янына, сәхнәгә алып менделәр. Хәрби комиссариаттан килгән майор бүләкләнүчеләргә «Ватан сугышы» орденнары тапшырды. Язучылар союзы идарәсе кыйммәтле бүләкләр бирде. Яшь буын шагыйрьләр һәр ветеранга багышлап шигырь укыдылар. Аннан соң бөтенебез, автобусларга утырып, Бөек Ватан сугышында һәлак булган язучыларыбыз истәлегенә салынган монумент янына барып, чәчәкләр салдык, бергәләп, фоторәсемгә төштек.

Бу Мәҗитнең соңгы рәсеме, соңгы зур бәйрәме булгандыр, бәлки.

Мөршидә Вилданова-Хәкимова

# ШАГЫЙРЬ ХАТЫНЫ БУЛУ АВЫРМЫ?

Миңа еш кына шушы сорауны бирәләр. Бу сорауга җавап бирү бик үк җиңел түгел.

Без Сибгат белән 47 ел гомер иттек. Таныш булуыбызга да ярты гасыр булды. Бу бик озын гомер, бер-беребезне сынарга җитәрлек еллар, ә алар гел уңайлы гына булмады. Күп сикәлтәләрне узарга туры килде. Шулай да без бер-беребезне аңлап, бер-беребезне ихтирам итеп яшәдек. Ике арада булган чын мәхәббәт тә сүрелмәде.

Сибгат киң холыклы кеше иде. Күз карашыннан бер-беребезне аңлый идек. Без бер-беребезне бик яшьли таптык. Миңа бары 17 яшь иде. Яшьтән үк шигъриятькә гашыйк идем. Хатын-кыз өстенә төшкән көндәлек эшләр: балалар тәрбияләү, өйне чиста тоту, ашау-эчүне вакытында булдыру, иреңнең өс-башын чиста йөртү һәм башка бик күп эшләрдән тыш шагыйрь хатыннарына өстәмә эшләргә дә күнәргә туры килә. Мин Сибгатнең яңа язган шигырьләрен иң беренче тыңлаганда, яхшы һәм ярамаган якларын күрүче тәнкыйтьче дә булдым. Күп вакыт шигырьләренә исемнәрне дә бергә сайлый идек. Шатланып әйтә алам, аның иң матур шигырьләре миңа карата язылган. Матур, тату тормышыбызның җимешләре булды алар.

Сибгат күп вакыт шигырьләрен яттан укый иде. Очрашуларга барыр алдыннан бергә хәзерләнә идек. Миңа кат-кат укып күрсәтә иде. Үзенең иҗатына багышланган шигырь кичәләрендә ике, өч сәгать буена шигырьләрен яттан укыган чаклары булды.

Ярдәмең тигәнне күреп шатланасың, матур шигырьләр туа тора, күрәсең, ирең дә күңеле шат. Шагыйрь хатыны икәнсең, көчеңне дә, назыңны да кызганмаска кирәк — сиңа булган, гаиләсенә булган мәхәббәтләрен ул артыгы белән шигырьләрендә әйтеп бирә.

Шагыйрьләрнең бераз сәеррәк яклары да бар, минемчә. Андый якларын кимчелек дип карамаска кирәктер. Минем Сибгатнең дә андый яклары күп иде. Ләкин мин аларга кеше алдында, бигрәк тә балалары, туганнары, каләмдәшләре алдында бер кайчан да игътибар бирмәдем, уздырып җибәрдем.

Сибгат нечкә күңелле кеше иде. Аз гына мактасың да аның күңеле күтәрелә, кәефе яхшыра, эшкә дәрте арта иде. Гомәр абый Бәширов, Хәсән ага Туфан, Афзал абый Шамовлар гел миңа әйтә иделәр: «Сибгатеңне мактый-мактый мактаулы кешегә әйләндереп бетердең инде» дип. Чыннан да, минем Сибгат мактаулыга әйләнеп бетте. Бик авыру булуына карамастан, күбрәк яза башлады, китаплары ешрак чыга башлады, җәмәгать эшләрендә һәрвакыт бик актив катнашып килде. Аның шундый эшләр күрсәтә алуына мин бик тә шатмын һәм горурланам да, чөнки шагыйрь хатыны буларак минем дә көчем кергән.

Әле тагын бер ярдәмем белән горурлана алам. Мин урта медицина белгече генә булсам да, гомер буена аның «өй врачы» вазыйфаларын да үтәдем. Сибгат сугыштан бик авырып кайтты. Ул сугышның башыннан ахырына кадәр пехота офицеры иде. Җилкәдә бик күп авыр әйбер күтәреп йөргәнгә ике аягында да кан тамырлары шеште — тромбофлебит булды. Үпкә, бавыр, ашказаны, эчәкләренә салкын тигән, бар да авырта... Шул кадәр авыру булса да, сугыш беткәч тә кайтармыйлар, тагын бер ел Кишинев шәһәрендә хәрби газета редакциясендә эшләтәләр. 1946 елның язында гына кайтты ул. Кайтканда карарга куркыныч иде — коры тире дә, сөяк кенә. Күзләре эчкә баткан, йөзе сап-сары. Икенче көнне үк участок врачын чакырдым. Ул да «хәстәреңә керә торыгыз, бик бетерешкән, бер айдан артык яшәмәс» дип куркытты. Үземнең таныш врачларга да күрсәтеп карадым, берсе дә җылы сүз әйтмәде. Кайнанам гына: «Күзләрендә нур бетмәгән әле, алла бирсә терелер»,— дип юатты. Рәхмәт аңа, канатландырып җибәрде, авыр туфрагы җиңел булсын. Шушы көннәрдән башлап Сибгатнең

сәламәтлеген ныгыту өчен бөтен көчемне биреп тырыша башладым. Бик тә ябык, хәлсез булгач, врачлар иң элек Сибгатнең үпкәләрен ныгытырга кирәк диделәр. Ныгыту өчен майлырак ризыклар ашатырга, дуңгыз мае эчертергә куштылар. Елларның бик авыр чаклары, дуңгыз маен да табуы бик кыен. Кирәк булгач, табасың икән. Дуңгыз майларын да, балык майларын да табып эчерттем. Сибгатнең генә хәле рәтләнмәде. Начарланганнан-начарлана барды. Бик авырлыклар белән Ессентукига путевка табып, санаторийгә алып киттем. Үзем дә бардым. Бер дә бармас идем, артык расход та, ләкин үзен генә җибәрерлек түгел, бик тә хәлсез. Ессентукида Сибгаткә дөрес диагноз куйдылар. Аның бавыры бик начар булган, безнең дуңгыз майларын эшкәртә алмаган. Ессентукиның минераль суларын эчеп, диета буенча гына ашый башлагач, Сибгат күзгә күренеп рәтләнә башлады. Бер ай эчендә бераз төс керде, хәл керде. Минем дә санаторийга килүемнең файдасы булды: Сибгаткә яраклы ризыкларны күреп, ничек хәзерләргә өйрәнеп кайттым. Аңа кирәкле уколларны, зарядка, массажларны — барысын да өйрәндем. Шул еллардан алып гомеренең актыгына кадәр бөтен уколларын үзем ясадым. Еш кына организмы массаж сорый иде, аны да үзем ясадым. Үпкәләренә аз гына салкын тисә, банкалар кирәк була иде. Аларны да үзем салдым.

Сугыштан кайтканнан соң гына да биш операция кичерде Сибгат! Ике мәртәбә йөрәгенә инфаркт булды. Дүртесендә аның белән больницада ятарга туры килде. Бигрәк тә гомеренең соңгы аенда больницада ятканда хәле авыр булды. Кузгалмыйча аркада гына ятса бер җире дә авыртмый. Ләкин аркада гына күп ятып булмый, арыта. Әз генә кыймылдаса, йөрәк авырта. Миңа шул чакларда бик тә булышырга кирәк булды.

Яшьрәк вакытта мин үзем дә шигырьләр яза идем. 7-8 классларда укыганда район газеталарында, Казанга укырга килгәч «Азат хатын», «Совет әдәбияты» журналларында, «Яшь сталинчы», «Яшь ленинчы», «Кызыл Татарстан» газеталарында шигырьләрем чыга башлады. Әдәби альманахларда чыкты, «Чиккән яулык» исемле шигырь китабын да чыгарган идем. Мине шигырь яратуым шагыйрьләр арасына кертте дә. Гомерлек ярымны да шагыйрьләр арасыннан таптым.

Безнең Казанда укыганда башланган дуслыгыбыз мин авылга эшкә киткәч тә дәвам итте. Ул Дөбьяз районындагы Өнсәгә бик еш килеп йөрде. Бик күп матур шигырьләрен шул елларда язды. Мәсәлән: «Яратам мин», «Зәбәрҗәт, алтынчарың», «Кышкы салкын иде», «Яр читенә басып уйга чумдым» һ. б. лар. «Пар ат» поэмасын да шушы Өнсә белән Казан арасында йөргән елларда язды. Кияүгә чыгарга сорап йөрсә дә, риза булмыйча күп йөрттем мин аны шәһәр белән авыл арасында. Канатлы яшьлек белән хушлашасы килми иде әле. Шундый ялындырып йөргән чакларда яшьләр газетасында Сибгатнең «Юксыну» шигыре басылып чыкты. Халык ул шигырьне сугыш вакытында музыка язылганнан соң (Шакир Мәҗитов музыкасы) сугыш еллары җыры дип кабул итсә дә, ул шигырь миңа карата 1939 елда язылган шигырь иде.

*Бакчаларда шомырт агачлары*
*Җәй буена сине көттеләр;*
*Син килмәдең, көзге җилләр инде*
*Яфракларын җиргә сиптеләр.—*

дигән юллар бар анда.

Үз-үземне әрләп ташладым. Күп тә үтмәде, сабан туйлары вакытында Сибгат Хәсән абый Туфанны безнең авылга алып килде. Хәсән абыйга әйтә икән: «Син, Туфан, авыл сабан туен бик яратасың, әйдә минем белән Өнсәгә, сабан туен да карарбыз, син Мөршидәне дә үгетләрсең. Һаман ялындырып йөри бит, шәһәр белән авыл арасында йөреп, тәмам арыдым инде», дия икән...

Хәсән абый мине күндерде. «Юксыну»ның да тәэсире бик нык булды. Без 1939 елның җәендә өйләнештек. Өйләнешү белән икебезгә дә Язучылар союзы путевка бирде. Беренче аебызны без Кара диңгез буенда, язучыларның иҗат йортында уздырдык. Нинди бәхетлеләр без!

Ялдан кайту белән туй хәстәренә керештек. Ләкин без уйлаганча туйны тиз генә ясый алмадык. Сибгатне кайту белән хәрби сборга чакырып алдылар. Мине авылдан яңа фельдшер килмичә җибәрмәделәр. Туйны без 31 декабрьдә ясадык. 1940 елны каршы алдык. Безнең туебыз бик тә истәлекле булды. Анда күп язучылар булды: Муса Җәлил, Хәсән Туфан, Гадел Кутуй, Шәйхи Маннур, Нур Баян, Гали Хуҗи һ. б. язучылар. Сибгат бу туй турында бик матур истәлекләр язып калдырды. Шушы туй турындагы Сибгатнең истәлегеннән берничә юл китерим әле: «Бу туй — сугыш алды туе. Шатлыклы да, үкенечле дә. Тышта буран дулый. Шыксыз декабрь бураны дулый. Туфан көлми дә, еламый да... Соңгы очрашу. Язмыш безне Бөек Ватан сугышы алдыннан махсус очраштырды шикелле. Яшьлек белән хушлашу. Фронтларга таралдык».

Дуслар таралыштылар. Муса, Кутуй, Нур Баян һ. б. сугыштан әйләнеп кайта алмадылар. Хәсән абыйны да яман газаплар көткән икән...

Без Сибгат белән икебез дә хәрби учетта тора идек. Сибгаткә сугыш башлануның икенче көнендә үк чакыру килде. Китеп тә барды. Миңа да сугышның өченче көнендә чакыру килде. Ләкин мине Казан шәһәрендә оешып кына килә торган госпитальгә шәфкать туташы итеп җибәрделәр. Шулай итеп безнең төзелеп кенә килә торган матур тормыш чәлпәрәмә килде. Мин яшь бала белән фатирсыз, акчасыз, ягарга утынсыз — нишләргә дә белмичә, аптырап калдым. Без өйләнешкәч Тукай урамындагы бер хуҗаның кечкенә генә йокы бүлмәсендә тора идек. Бәхет өстенә бәхет булган улыбыз Ростәмебезне дә шушы фатирга алып кайткан идек. Беренче улыбызны бала табу йортыннан алып кайту тарихын языйм әле.

Без больницага бик якын тора идек. Бервакыт больница ишек төбенә кыңгыраулы пар ат килеп туктады. Без, ирләребезне көтеп ятучы бала тапкан хатыннар, тәрәзәгә ябырылдык. Нәрсә булыр икән бу? Берәр күрше йортка килеп төшәме әллә? Атлар туктап, матур итеп буялган тарантастан минем Сибгатем төшмәсенме! Кулында чәчәк бәйләме, күңел шат. Бәхетле яшь эти кеше. Минем күзләремнән яшьләрем атылып чыкты шатлыктан. Менә шагыйрь хатыны булуның зур шатлыгы, нинди бәхет! Моны бары ул гына чыгара алган, нечкә күңелле шагыйрь генә! Миңа да гомергә онытылмаслык истәлек ясаган. Шулай итеп без кыңгыраулы пар атта улыбызны больницадан алып кайттык. Менә шушындый матур башланган бәхетле тормышны сугыш какшатты. Менә хәзер күрсәт шагыйрь хатыны булуыңны: сыгылып төшмә, юллар тап, тормышыңны юлга сал.

Бәхетем бар икән. Минем әни Комсомольск шәһәреннән безгә кунакка килгән иде. Сугыш башлану белән юллар ябылды да, әни кире китә алмый калды. Берәздән аны мех фабрикасына надомница итеп эшкә керттем. Өйдә генә хәрби киемнәр тегә, баланы да карый. Минем эш — хәрби госпитальдә, көненә 12 шәр сәгать.

Рәхимсез сугыш елларындагы авырлыкларны ул чор кешеләре барысы да хәтерли. Ашарга юк, киярга кием юк, ягыйм дисәң, утын табып булмый. Безнең кебек яшь гаиләләргә бигрәк тә авыр булды. Сибгат фронтка киткәнче торырга үзебезнең куыш булмау сәбәпле мин бик тә какшадым. Кечкенә генә булса да, ярый әле яшәү өчен бер кухня ала алдым. Аны бер елдан бер бүлмәле аерым ишекле фатирга алмаштым. Ашау ягын да рәтләп җибәрдек. Мин авылда үскәч, бер эш тә куркытмый иде. Бер көнне таныш хатынны үзем белән алдым да, госпиталь начальнигына керергә булдым. Безгә аз гына булса да бәрәңге утыртырга җир кирәк иде. Шул турыда начальник белән киңәштек. Ул сорап карарга булды. Ул елларда халыкка җир бирү юк иде әле. 1943 ел, җәй, сугышның бик каты вакыты. Безнең начальник йөри торгач, җир алды. Ул җир бик аз иде, берәр сутый гына булса кирәк. Бәрәңге бик уңа иде. Җиребез шәһәр халкы гомере буе чүп түккән Бакалтайда иде. 1944 елларда булса кирәк, Язучылар союзыннан да бераз җир бирделәр. Безнең эшләр җайланып китте. Ике җиргә бәрәңге утыртабыз, ә орлыклык бәрәңгене саклап кына булмый, яз саен сатып алырга кирәк. Яз көне бәрәңге бик тә кыйбат була. Аның да җаен таптык: берәр кешедән әҗәткә акча алып торып, орлыклык бәрәңгене алабыз да, бер-ике буразнага иртә өлгерә торган бәрәңге утыртабыз, аны тавык йомыркасының сарысы кадәр булу белән базарда сатып, бурычка алган акчаны түлибез. Ул бәрәңге июльнең уннарында сатарлык була иде, бәрәңгенең иң юк вакытында. Эшнең берсе дә куркытмый, Сибгатнең исәнлек хатлары килеп торганда куана-куана йөрисең. Еш кына хатлар килми тора иде. Яки: «Без алгы сафта, иртәгә һөҗүмгә, исән чыга алсам хат язармын», дигән хат килә. Хатны икенче көнне үк көтә башлыйсың, хат юк, ай үтә, ике, өч ай үтә — хат юк. Борчу баса, күзләргә йокы керми, сугышның авыр еллары, башка төрле уйлар килә. Тагы: «Мин исән-сау, күп язарга вакыт юк, алгы сызыкта, ике-өч көннән атакага керәбез», дигән хат килеп куандыра. Сибгат, гомере бетмәгәч, алгы сафта күп йөри.

Хәзер сугышны телевизордан гына да тыныч карый алмыйбыз. Ул мескенем әллә ничә контузия ала, әллә ничә чолганышта калып чыга ала.

Миңа да Татвоенкомат еш кына чакыру язулары җибәреп тора, чөнки фронтка медиклар күп кирәк. Улыма 3 яшь тулганчы, бик аптыратмадылар. 3 яшь тулганнан соң сугыш актыгына кадәр сигез повестка килде. Сигез мәртәбә бала белән, әни белән хушлашып, рюкзагымны күтәреп Татвоенкоматка барырга туры килде.

Башка тагын бер кайгы төште: безнең үзебезнең тегү машинабыз юк иде. Ә әниемә өйдә хәрби кием тегү өчен көн саен машина кирәк. Нишләргә дә белмим, бөтен нәрсәгә баш ватып карыйм. Үзем белән эшли торган бер дустымның күпне күргән, тормышның ачысын-төчесен күргән этисе миңа юл күрсәтте. Аның өйрәтүенчә, минем хәрби кибеттән сатып алган товарны энем авылга алып барып ашау әйберләренә алмаштырырга булды. Шулай итеп без энем белән әниебезгә базардан онга, майга алмаштырып тегү машинасы алып бирдек. Ул игелекле машина хәзер дә хезмәт итә әле...

Шулай тырыша-тырыша авыр сугыш елларында исән калдык.

Сибгат, шөкер, исән-сау кайтты. Сугыш бетеп 1 ел үткәч кайтты ул. Ә 1946 елда без Тукай урамындагы тәрәзәләре мехчылар клубына карап торган иркен, биек ике бүлмәле фатирга күчтек. Йокы бүлмәсен Сибгаткә эш бүлмәсе ясадык. Кечкенә иде ул бүлмә, шулай да анда бер кровать, бер язу өстәле, бер кечкенә китап шкафы, бер урындык сыя иде.

Сибгат шушы кечкенә бүлмәдә иҗатының сугыштан соңгы чорын башлап җибәрде. Бер-ике ай ял иткәннән соң сугышка кадәр эшләгән эшенә — «Совет әдәбияты» журналы редакциясенә йөри башлады. Ул елларда редакциядә бары өчәү эшлиләр. Эш күп, хәле юк, бик каты авырый, авыртмаган җире юк. Редакция эшен өйгә дә алып кайтып эшли. Үз шигырьләрен язарга бөтенләй вакыты калмый. Төннәрен йокламыйча шигырь язып утырган була. Берничә сәгать кенә йоклаган көе эшкә китә. Бер-ике айдан Сибгат бөтенләй хәлсезләнде. Өстә язганымча, бик нык дәваларга, курортларга алып барырга туры килде. Сибгат белән киңәштек тә, бераз эшне ташлап торса, сәламәтлеге рәтләнмәсме диеп уйладык. Ләкин ничек яшәргә? Минем эш хакына гына яшәп булмый. Шигырьләр дә бик ашыгып язылмыйлар, бик азлар. Минем башка уй төште. Теге вакытта киңәшләре белән безгә зур ярдәм иткән игелекле абыйга киңәш иттем. Киңәше һәм булышуы белән бик тә ярдәм итте ул. Миңа товар табып бирә бу абый, без әнием белән телогрейкалар тегәбез. Бу абый аларны сата да — безгә дә, үзенә дә бераз акчасы була. Нишлисең соң, эшнең гаебе юк дип әйтергә генә кала иде. Бу урлау яки кеше талау түгел. Үз кул көчең белән эшләнә торган эшләр.

Сибгат шул китүдән, яңадан редакция эшенә бармады. Еллар бик авыр булса да, минем эш хакы өстенә Сибгатнең шигырьләре дә басылып куя, телогрейкалардан да бераз акча керә, бәрәңге утыртуны да дәвам итәбез... Тормыш, авыр булса да, бара. Сибгатнең дә күзгә күренеп сәламәтлеге рәтләнә башлады. Китаплары да чыга. Тагы бер малай да алып кайттык.

Мин 35 ел мех фабрикасында төнге дежурда эшләдем. Сәламәтлек өчен начар икәнен дә белдем. Башкача чара юк иде. Сибгаткә булышырга кирәк иде. Ике баланы да үстерәсе бар.

Бик каты авыру елларында Сибгатне врачлар җәйләрен нарат урманында торарга куштылар. Шактый эзләргә туры килде нарат урманлы җирдән дача. Займище, Обсерватория, Васильеволарда торып карадык. Күңелгә ошаганы булмады. Бер җәйне сугышка кадәр торган фатир хуҗасы Сәрвәри апаның туган тиешле кешесе урманда торуын ишеттек. Шуны эзләп киттек. Барып таптык, матур урман. Төп-төз, тезелеп киткән ак каеннар. Зур, зур күлләр. Дөньяның оҗмахы, диярсең. Каен төпләре тулы каен җиләге, төрле кошлар сайрый. Безгә бик тә ошады. Хуҗа апа бер җәйгә бүлмә дә бирде. Бу оҗмахка ошаган җир — Аккош күле иде.

Мин икенче көнне үк Сибгатне, балаларны, әнине алып килеп урнаштырдым. Аларга да бик ошады. Шул килүдән без Аккош күлендә 40 ел инде яшибез. Ун ел шушы апаларда тордык. Аннан соң язучылар безгә кунакка килеп күрделәр дә, Аккош күлен бик ошаттылар. Язучылар союзының иҗат йортын да Аккош күле аланына салырга булдылар.

Хәсән Туфан да гомеренең соңына кадәр Аккош күлендә торды. Бик күңелле, бик тә матур яшәдек без анда. Ирләребез яңа язган әсәрләрен һәр җомгада беседкага җыелып укыйлар. Без, хатыннар, аларның әдәби җомгаларына самовар кайнатып, тәмле бәлешләр пешереп, җиләк вакытында табак-табак кызыл җиләкләребез белән катнашабыз. Әдәби әсәрләр укылганнан соң җыр, гармун да кушыла. Кичкә таба бергәләп су коенулар, хуш исле себеркеләр белән мунча керүләр китә. Көзгә таба уңыш бәйрәме ясыйбыз, уңыш бәйрәменә кунаклар да (башка дачалардан һәм шәһәрдә торучы язучыларны) чакырабыз. Чәчәк күргәзмәләре ясыйбыз, балалардан концертлар оештырабыз.

Мин өстә шагыйрьләрнең сәер яклары да була дигән идем. Сибгатнең берничә сәер ягын языйм әле. Бер вакыт обкомга чакырганнар. Бик әйбәтләп кырынды, юынды, ак күлмәк, кешелеккә кия торган костюмын киде дә, чыгып китте. Ә кияргә дип әзерләп куйган туфлиләре калган. Өйдә кия торган башмаклардан чыгып киткән. Обкомның ишек төбенә барып та җиткән. Артыннан чабып җитеп, аяк киемнәрен алмаштырдым. Урамга чыккач да, аягында өйдә кия торган йомшак башмаклар икәнен сизмәгән дә. Ярый әле күп кеше күрмәгән, чөнки без обком янында, якын гына торабыз.

Тагын бер вакыт, минем җәйге пальтоны киеп Бауман урамындагы китап кибетенә барган, китаплар алган, ничәдер сәгать йөргән, аннары Язучылар союзына кергән. Кызлар моны күреп, көлешәләр дә, «яңа пальтосы» белән котлыйлар. Шунда гына пальтосының үзенеке түгеллеген күреп ала. Пальтоларның төсләре бер төсле булу аны бутаган. Аерма күп инде үзе. Минекенең җиңнәре кыскарак, кесәләре башкача, элэктергечләре башка якка.

Тагын бер вакыт Язучылар союзыннан, җыелыштан озын пальто киеп кайткан. Ул елларда кыскартылмаган озын пальтолар бар иде әле. Ә мин Сибгатнең пальтосын күптән кыскарткан идем инде. Ишектән керүгә «кем пальтосын кидең, әллә пальтоны да салдырдылармы?» дидем. Чөнки шул елларда аның башыннан ике мәртәбә бүреген алдылар. Күп еллар Батулла, Мәхмүт Хөсәеннәр анекдот итеп сөйләп йөрделәр. Сибгат уйлап та карамый: «Үземнең пальто, менә уң як кесәсенә сетка сумка тыккан идем, анысы да бар» ди. Чыннан да пальтоның төсе ошаган, уң як кесәдә сумка да бар. Пальто аяк йөзеннән бит, шуны сизмәгән. Кайтып 15 минут та үтмәде, телефон шалтырый: «Сибгат кеше пальтосын киеп киткән, хуҗасы көтеп тора, тиз китерсен», диләр.

Сибгат сабан туйларын бик ярата иде. Бигрәк тә авылда, Күлле-Киме сабан туен. Сабан туена бүләк әзерли иде — анысы арттан килгән ат өчен. Артка калган атны ул бик тә кызгана иде. Ат чабышларын карарга бик ярата иде ул. Гадәттә, ат чабышлары иң соңыннан була, аларны карамыйча, бүләкләрен бирмичә мәйданнан алып китеп булмый иде аны. Соңгы елларда бигрәк тә дәртләнеп китте. Элекке көнне Киме сабан туен карый да, егетләр-кызлар тәялгән, төрле аллы-гөлле тасмалар, чәчәкләр белән бизәлгән, сабан туена махсус хәзерләнгән машинага утырып Арча сабан туена килә. Арчада аны — олы кунакны — көтеп кенә торалар. Кода, кодагыйларыбыз шунда тора. Арчада мунча ягылган, тавык пешкән, тәмле бәлешләр пешкән. Бергәләп мәйданга барабыз. Бусы тагын да күңеллерәк. Уеннарның ниндие генә юк. Монда да Сибгат өчен иң кызыгы атлар чабышы. Арчада да артка калган атны онытмый, бүләген әзерләгән була. Чабыш аты өстендә гадәттә 12-13 яшьлек авыл малайлары була. Аларны да онытмый иде. Яки үзенең китабын, яки конфет, прәннек бирә.

Беркайчан да сабан туе көнне Арчада кунарга калмады ул. Кодалар ни кадәр кыстасалар да калмый иде. Чөнки иң кызыгы шул көнне кайтканда. Һәр вагонда яшьләр, гармун, җыр, моң була. Сибгаткә шул гына кирәк. Гомере буена гармунга, җырга гашыйк кеше ул. Бер елны вагон эчендә җыр тыңлап кайтабыз. Бер төркем егетләр, кызлар (барысы унбишләп) шундый матур җырлыйлар. Иң элек Хәсән Туфан сүзләренә язылган җырлар диеп берсе белдерде. Хәсән абыйның җырлары бетүгә Сибгат Хәким сүзләренә язылган җырлар китте. Җыр бөтен вагонны яңгырата, биеп тә җибәрәләр. Бер җырны җырлап бетерүгә, бөтен вагондагы халык гөрләп кул чаба. Бик тә күңелле, тәмам шатлыктан оеганбыз. Без аларга арт белән утырган, берсе дә безне күрми. Сибгат алар янына рәхмәт әйтергә барса, шак катып калдылар. Аны һәммәсе дә чорнап алдылар. Яңабаштан Сибгат сүзләренә язылган җырларны җырлый башладылар. Сибгат үзе дә кушылып җырлый. Вагондагы башка кешеләр дә Сибгатне танып алдылар. Бөтен вагонда җыр, бию китте. Бу күңелле җырлашу Сабан туеның дәвамы кебек булды.

Сабан туйлары үтүгә ныклап, дәртләнеп эшкә утыра иде. Әллә ни кадәр шигырьләренә материал алып кайта иде. Ә теге бер төркем егетләр, кызлар авыл хуҗалыгы институты студентлары булып чыктылар. Бу яшьләр поездан төшкәч тә, безне өебезгә кадәр гармун, җыр белән озата килделәр. Сибгаткә болар бик тә кадерле, җанын эретә иде. Аның бөтен барлыгы — җаны, акылы, күз карашлары, сөйләшүләре — туган җиренә, басуларына, тауларына, урманнарына, чишмәләренә, карт өянкеләренә, шул җирдә яшәгән кешеләр күңеленә килеп кушыла иде. Әлеге гармун моңнары моны тагын да тулыландыра иде.

*Бөтенләем белән җирнекемен,*
*Минем барлык нәсел-нәсәбем*
*Игенчеләр. Җирдән тәртеп чыга*
*Һәрбер юлым, һәрбер әсәрем.*

Олыгайса да тыныч кына ял итеп ятуны башына да китермәде ул. Гел хәрәкәттә, гел юлда, гел иҗат үрләрендә булды. Әлегрәк елларда тынгысыз күңеле аны кайчандыр фашистларга каршы үзе сугышып йөргән Курск дугасына, герой-шагыйрь, үзенең яшьлек дусты, каләмдәше Муса Җәлил эзләреннән ике мәртәбә Германиягә дә илтте.

Сибгат соңгы елларда бик күп эшләде. Күп шигырьләр, поэмалар язу өстенә, җәмәгать эшләрендә дә күп катнашты. Олыгайган — яше шактый зур булса да, җаны аның яшь иде. Хәрәкәтләрендә яшьләрчә, кәефе яшьләрчә иде. Һәр иртә иртәнге зарядкасын 30-40 минут ясый. Аннан массажер белән массаж ясый, аннан соң салкын сулы сөлге белән сөртенә, өч көн саен ваннада юына. Көненә ике мәртәбә һавада йөри. Бу эшләрен ул бер дә соңгармыйча, кайда булуына карамастан эшли иде. Авылдамы, курорттамы, аның өчен барыбер иде. Яңгырлы, буранлы көннәрдә дә һавага чыга иде. Шушындый режим саклавы бәлки аны яшь күрсәткәндер. Аның битләрен дә җыерчык басмаган иде, ак чәчләре дә аз иде әле. Соңгы елларда үзенең олыгая төшкәнен шигыре

итеп яза башлады, шул шигырьләрне укыгач кына олыгая икән инде дип уйлый идек...

*Сезгә эндәшми мин кемгә*
*Эндәшим, өянкеләр?*
*Житте минем дә, сезнең күк*
*Картайдым, дияр көннәр.*

*Кайда ул бергә ашкынган,*
*Бергә шаулаган көннәр?*
*Минем таныш өянкеләр,*
*Сезгә баш ияр кемнәр?*

Шагыйрь хатыны буларак тагын бер нәрсәне язмый булмый әле. Безнең өйдә гомеребез буена килем-китем бик күп булды. Алар күбесе Сибгатнең каләмдәшләре — яшь дуслары иделәр. Аларны иң элек хуҗа хатын буларак миңа каршы алырга туры килә иде. Безгә килгән кешеләрне мин гомер буена якты чырай белән каршыларга тырыштым. Килгән кунакны сыйларга һәрвакыт сыем да булды. Запас белән торырга тырыша идем. Пешкән әйберләрем дә (чәкчәк, өчпочмак, гөбәдия һ. б.) холодильникта өзелмәде. Бөтен кешене куанып каршыладым, бөтен эшемне куанып эшләдем. Эш өчен яратылган кулларым, мәхәббәт, тормыш өчен яратылган йөрәгем беркайчан да арымады. Безне якын итеп, киңәш сорарга килүчеләр күбесе шигърият, сәнгать кешеләре була иде. Сибгатнең күңеле киң, йөрәге сизгер, гаиләдә аксакал шикелле, әдәбиятта да һәркемне барлап, кайгыртып яшәде. Аның әйткән җылы сүзләре, чын күңелдән биргән киңәшләре шигърият яки сәнгать дөньясына җыенган яшь кеше өчен пар канат булды.

Шагыйрь хатыны буларак шагыйрема — сөекле иремә — карата чыгарган сагыну җырым белән тәмамлыйсы килә бу язманы.

*Яшьлекләр дә бергә үткән иде,*
*Авыр көннәр бергә үзган иде.*
*Алтын туйга кадәр яшәрбез дип*
*Өметләрем минем зурдан иде.*

*Китеп бардың безне калдырып,*
*Пар канатлар иде, каерылды.*
*Сагынабыз сине иртә, кич,*
*Безнең башлар бик тә кайгылы.*

*Анда киткәч кайтып булмый икән,*
*Булмый икән инде, юк икән.*
*Сагынуларны бераз баса торган*
*Дөньяларда дару юк микән?*

*Син яраткан ап-ак пионнарның*
*Исерә идек бергә исенә.*
*Аларны мин хәзер илтәм инде*
*Зираттагы каберең өстенә.*



# КЕНӘРИ — ЧИТЛЕК КОШЫ

Хөрмәтле Ринат!

Яңарак кына, бер тында дип әйтерлек, «Кенәри»еңне укып чыктым. Әсәрдәге теге яки бу хәл-әхвәл, герой исемнәре хакында сөйләргә дә түгел... Әмма шуңа да карамастан, «кенәри»ләрең мәхәббәт ярымутравында гына түгел, минем хәтер тирәгемдә дә инде атналар буе чут-чут килиләр. Чөнки анда һәр нәрсә ачык, төгәл, чамалы. Тормышыбыздагы һәркемнең күз йөзенә бәрелеп торган дөньяви булмышның шундый кинәттән зәвыклы бер роман булып гәүдәләнеше үзе үк гыйбрәтле. Атлаган юл-сукмаклары-бызны һәрчак кара мәче булып кисеп үткән «арысланнар» безгә нинди таныш! Әмма... аларны әсәр биеклегенә күтәрүе генә җиңел түгел. Ә син исә шундый «җиңел» күтәргәнсең, хәтта «буыннарыңның шыгырдавы» да тоелмый. Афәрин!

Моннан тыш, минемчә, иң әһәмиятлесе — һәр геройның үз атмосферасы, социаль фәлсәфи нигез ташы булуындадыр. Нәкъ шуңа күрә аларның һәркайсында да үзгәлекле характер, көчләп тагылмаган адәми сыйфатлар бар. Моны мин бер Арыслан белән Асия язмышына кагылып кына әйтмим. Ә Капкаев? Ә Җантимер? Әт атучы Гыйлемең мине дә бала чагымдагы Ак колагыма алып кайтты. Шул Ак колактай үрсәләнгән җаным әченеп-ярсып Санияне, Фидаилны язмыш тозагыннан курчаларга тырышты.

Уйлап карасаң әсәрдә һич тә түбән дәрәҗәле, ягъни «булышчы» образ юк кебек... Һәр исем артында характер, язмышы шатлык һәм хәсрәтләрдән үрелгән шәхес бар. Тагын шунысы гаҗәп: әсәрдәге һәр эпизод, хәл-әхвәл тирәсендә синең үз тының, әрнүле үз моңың барлыгы сизелә. Прозага карата «моң» сүзен куллану бәлки сәеррәк тоеладыр. Әмма «Кенәри»еңдә бар ул андый моң. Әсәрдәге синең тел дулкыннарыңа колач ташлап, бер тын чумып-чумып алгаласам, бәлки ул моңны мин өскәрәк калкытып, исбатлап та күрсәтә алыр идем. Ләкин чумарга форсат юк.

Уңышлы романың белән үзеңне ихлас күңелдән котлыйм. Иделләр, яшел аланнар аша дуслык сәламнәре юллап, бәхетле илһам сәгатьләре теләп,

**Муса ГАЛИ.**
Уфа шәһәре.

* * *

Журналның 4-5 саннарында басылган Р. Мөхәммәдиев романын зур дулкынлану белән укып чыктым. Кешеләр язмышын, тарихны һәм бүгенге көнне бергә бәйләп сурәтләгән вакыйгаларга бай бу әсәр беркемне дә битараф калдырмастыр. Яшьләргә дә картларга да, балаларын тәрбияләүдә тәҗрибәгә мохтаҗ әти-әниләргә дә зур ярдәм итәр дип уйлыйм. Рухи түбәнлеккә төшкән кешеләр, аларның корбаннары язмышын укыганда журнал битләренә күз яшьләрем тамдырырлык әсәре өчен авторга рәхмәт белдерәм.

Мин гади эшче. Милләтем — татар. Уфа каласында яшим. Өч ел «Казан утлары»н алдырмаган идем. Бәлки шул еллардагы саннарда язучының биографиясе басылгандыр? Мөмкин булса, киләсе саннарда бу язучы турында, аның әсәрләре турында бер мәкалә бастырып чыгарырсыз әле. Тагын бер зур теләгем бар. Казан китаплары бездә бөтенләй сатылмый. Р. Мөхәммәдиевнең китапларын үз кулларым белән тотып, тагы бер кат яңабаштан укып чыгасым килә.

**Гөлнур РӘХМӘТУЛЛИНА.**

* * *

Гаиләдә каршылыклы тәрбия алган төп герой Асия үз язмышын үзенчә корырга, буйсынмыйча яшәргә тели. Намусы тапталып кияүгә чыккач та, ул Фидаилгә тугры калырга теләми. Авырлыклар күреп үскән ире аны гафу итми. Ләкин шартлап өзелергә торган кыл һаман сузыла әле...

...Табигать кочагында азгыннар кәеф-сафа кора. Ә табигать җирәнә алардан... Кайбер җитәкче креслосында утыручыларның шундый кәеф-сафа корып яшәүләренә әсәрдә дөрес бәя бирелгән.

Фидаилнең изгелеге әт атучы Гыйлемгә дә тия. Аңа бердәнбер улы Җантимерне табышырга булыша. Атасы җилкәсендә укып врач булган Җантимер (исеме гаҗәп дөрес куелган) наркоманга әйләнгән. Тик бабасының «халык дошманы» булуы гына шулкадәр түбәнчелеккә этәрер иде микән?! Әтисенең йомшаклыгы, өметсезлеге дә балага тәэсир итми калмаган, минемчә.

Мәчет карты белән очрашкан эпизод бик уңышлы. Аның: «Күңелең изгелектә булуда... Үч һәм ачу сакларга ярамый дөньяга»,— дигән сүзләренә Фидаил колак салган шикелле.

Тулаем алганда, язучыга зур рәхмәт. Әсәрне укыган һәркемнең күңелендә «җиңел» тормышта яшәүче адәмнәргә карата нәфрәте уяна. Теләгем шул: дөнья гыйбрәтләре әдәбиятта күбрәк фашлансын иде. Яшьләргә оятсызлыкның чигенә чыккан Асияләр, Арысланнар хакында әсәрләр бик кирәк. Бүген әхлагыбыз югала түгелме? Кеше бит хайваннан әчке хисләре, уй-кичерешләренең тирәнлеге, омтылышларының зурлыгы белән аерыла лабаса.

**Әнисә ЯГЪФӘРОВА,**
Башкортстан.

**Нурия Гәрәева**

# КЕМ УЛ МОРАД РӘМЗИ?

Татар романнарының бер герое булырлык катлаулы һәм гыйбрәтле язмышка ия тарихчы Морад Рәмзи хәзерге галимнәргә гарәп телендә дөнья күргән «Тәлфикъ әл-әхбар вә тәльких әл-асарь фи вәкаигъ Казан вә Болгар вә мөлүк әт-татар»[1] (Оренбург, 1908) исемле ике томлы хезмәт авторы буларак билгеле. Әмма аның тормышы һәм иҗаты әлегә кадәр киң катлау укучылар өчен билгесез булып кала бирде. Ул гына да түгел, хәтта тарихчы галимнәргә шушы көнгә кадәр М. Рәмзи хезмәтләренең тулы исемлеге дә мәгълүм түгел.

Заманында Морад Рәмзи төрле исем астында билгеле булган: Мөхәммәдморад Рәмзи, Морад Мәкки, Мөхәммәд Морад бәк, шәех Мөхәммәд Морад, шәех Мөхәммәт Морад Казанлы, Морад әфәнде, Бәдәлче Морад, Шәех Морад һәм Морад. Әгәр дә аның әсәрләрен дөньяга чыгарганда куйган барлык исем — тәхәллүсләрен җыйсак, түбәндәге «чылбыр» хасил булыр иде: Мөхәммәдморад әр-Рәмзи, әл-Мәкки, әл-Мәдәни, әл-Минзәләви, әл-Казани, әл-Болгарый, Жандарм идарәсе архивы материалларына караганда, ул — Морадшаһ Баһадиршанов[2]. Үзенең шәҗәресен М. Рәмзи түбәндәгечә теркәп калдырган: Морадулла бине Баһадиршаһ Габдулла бине Гаделшаһ бине Ихсак бине Тукал бай бине Яңа Ураз бине Морзакол Бине Баглай бине Мирдәш бине Мимеҗ бине Мнкра бине Габдулла бәк бине Бикчура хан. Иҗтимагый — сәяси мәсьәләләргә багышланган мәкалә — хезмәтләрен бастырганда ул Тутый, Гандәлиб, Әбелхәсән, Акмал, М. М. Р., Рәмзи кебек псевдонимнардан да файдаланган. Бала вакытында аны Мәрдәншаһ дип тә атаганнар.

Морад Рәмзи 1855 елның 25 декабрендә (кайбер чыганаклар буенча 1854 елның 10 октябрендә) Татарстанның хәзерге Сарман районына кергән Әлмәт авылында дөньяга килгән. Рәмзинең әтисе Баһадиршаһ (Батыршаһ) Габдулла, бала чагында ятим калып, яхшы белем ала алмаган. Күренекле татар язучысы, галим һәм мәгърифәтче Риза Фәхретдиневкә ерак туган тиешле әнисе исә тирә-якта укымышлы хатын буларак дан тоткан. Замандашлары тарафыннан самими бер җылылык белән «Абыстай», «остабикә», яисә «могаллимә» дип телгә алынган бу ханымның әтисе һәм әнисе дә Бөгелмә, Минзәлә якларында укымышлы галим һәм педагог буларак танылганнар. Дүрт балалы гаиләдә үскән М. Рәмзине тәрбияләүдә һәм белем бирүдә атаклы мулла Исмәгыйль әл-Кашкарның шәкерте, Әлмәт мәдрәсәсе мәдәррисе һәм мәхәллә имамы, әнисе ягыннан туган тиешле мулла Хәсәнетдин зур роль уйнаган.

Әнисе йортында кызлар өчен ачылган башлангыч мәктәптә М. Рәмзи алты яшеннән укырга-язарга өйрәнә башлый. Сигез яшендә ул Әлмәт авылы мәдрәсәсенә укырга керә һәм тиз арада яшьтәшләре арасында зирәклеге белән дан казана. Кыска вакыт эчендә шәкерт Рәмзи гарәп һәм фарсы телләрен яхшы гына үзләштерә. Үз авылы

[1] «Казан, Болгар һәм татар ханнарының тарихы турында хәбәрләр һәм әсәрләр».
[2] Татарстан АССР үзәк дәүләт архивы, 420 ф., 115 эш, 107 б. (Алга таба — ТАССР УДА).
М. Рәмзи биографиясенә караган мәгълүматлар 1899-1900 елларда Мәккәдә гарәп телендә дөнья күргән «Муарраб ән-мәктубат әш-шәрифә ән-мәрсүм би-д-дүрәр әл-мәкнүнат ән-нәфисә» исемле хезмәтеннән һәм Төркиядә Әнкара университеты профессоры, чыгышы белән татар булган Әхмәт Тимернең төрек телендә басылган мәкаләсеннән Doğumunun 130. Ve ölümünün 50. yılı dolayısıyla Kazanlı Tarihci Remzi (1854—1934) — Belleten. C. L., Sayı: 197 (Ağustos 1986), һәм утызынчы елларда Японияда чыгып килгән татар журналындагы мәкаләдән алынды. (Әлиф. Гаен. Мәрхүм Морад әфәнде Мәкки — Яңа япон мөхбире — 1935, март, 27 сан, 32-35 бб, апрель, 28 сан, 36-44 бб.)

мәдрәсәсендә алырлык гыйлемне үзләштереп бетергән унсигез яшьлек егетне, мулла Хәсәнетдиннең Шиһабетдин Мәрҗанигә һәм аның бер мөдәррисенә тәгаенләнгән юллама хаты белән, 1873 елның яз башында укуын дәвам итү өчен Казанга озаталар.

Ш. Мәрҗани мәдрәсәсендә М. Рәмзи озак укымый, белемен тагын да тирәнәйтү максатыннан Бохарага юл тота. Әмма юлда Троицк шәһәрендә тукталып, ике ел мулла Мөхәммәдҗан мәдрәсәсендә укый, формаль логика-мантыйк фәненнән белемен күтәрә.

Соңыннан ул Ташкент юлы буйлап Бохарага юнәлә. Ташкентта ике ай дәвамында шәһәр галимнәреннән белем ала һәм 1877 ел башында гына Бохарага килеп җитә. Бохарада ул Габдаллаһ әл-Мөфти әс-Саратави (Саратовлы), әл-Казани һәм Габдешшәкүр әт-Төркманиләрдә мантыйк гыйлемен үзләштерүен дәвам иттерә. Шул ук елның яз башында М. Рәмзи яңадан Ташкентка юнәлә һәм ике ел буе шушы шәһәрдәге галимнәрнең дәресләренә йөри. Берара Ташкент тирәсендәге бер шәехнең юлаучылар йортында үзе дә дәрес бирә. Шунда ул очраклы рәвештә тәсауыф һәм пәйгамбәрләр турында гарәп, фарсы телендә язылган бик күп китаплар табып, аларны мавыгып өйрәнә. 1878 ел уртасында М. Рәмзи, дусларының киңәшен тотып, Сәмәрканд-Карши-Изар Бәлх-Кабул-Җәлалабад-Пишавар-Лаһор-Амратсар маршруты белән Хиҗазга юл тота. Амратсарда тимер юл күпере җимерелгән булу сәбәпле, юлдашлары белән Лаһорга әйләнеп кайта һәм Мултан — Сакрбакр — Хәйдарабад — әс-Синд — Карадист — Бомбей маршруты белән яңадан юлга чыга. 1878 елда алар Җиддәгә, ә шул ук елның октябрь ахырында Мәккәгә килеп җитәләр. Хаҗ кылганнан соң М. Рәмзи Мәдинәгә юнәлә һәм башта «Әмин ага», бер айдан «әш-Шифа», ә сигез айдан соң «әл-Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә күчеп белем ала. Мәдинәгә килгән елны М. Рәмзи Коръәнне ятлавын тәмамлый һәм шәһәрнең күренекле галимнәреннән иҗазанамә, ягъни аттестат ала. Мәдинәдә ул шәех Мөхәммәд Мәзһар җитәкчелегендәге суфичылыкның нәкышбәнди тарикате, ягъни юнәлеше тарафдарлары сафына баса.

М. Рәмзи белем алуын Мәккә шәһәрендә шәех Габделхәмид әд-Дагстани җитәкчелегендә дәвам иттерә, ислам дине нигезләреннән тыш төрле халыклар тарихы белән кызыксына, китап җыя.

Шәех Габделхәмид әд-Дагстани 1884 елда вафат булгач, М. Рәмзи аның эшен дәвам иттерүче шәех Мөхәммәд Салих әз-Завави дәресләренә йөри башлый. 1885 елны шәех әз-Завави Мәдинәгә күчеп киткәннән соң М. Рәмзи нәкышбәнди тарикате тарафдарлары арасында киң таралган «Рәшахат гайнелхәят» («Яшәеш чыганагының изге тамчылары») исемле әсәрне фарсычадан гарәп теленә тәрҗемә итә.

1886 елда шәех әз-Завави Мәдинәдән сәүдә кәрваны белән М. Рәмзигә иҗазанамә җибәрә һәм аны Мәккәдә үзенең дәвамчысы, варисы итеп билгели. М. Рәмзи өчен мондый дәрәҗәле исем — вазифа көтелмәгәнчә килеп чыга, чөнки ул үзен әле бу урынга әзер түгел, дип санаган. Әмма остазы шәех әз-Завави 1887 елда Мәккәгә килгәч, аның дәлилләрен кире кага. Үзенең карарын тарикать тарафдарлары алдында тагын бер кат ачыктан-ачык раславын белдерә.

Остазның тәкъдиме белән М. Рәмзи нәкышбәнди тарикате тарафдарлары тарафыннан аеруча хөрмәт ителгән «Әл-Мәктубат әш-шәрифә әл-мәусум би-д-дурәр әл-мәкнунат ән-нәфисә» («Күңел түрендәге энҗедәй мөкаддәс серләр белән индерелгән игелекле хатлар») исемле әсәрне фарсычадан гарәпчәгә тәрҗемә итә. Шунысын да әйтеп үтәргә кирәк, бу елларда Мәккәдә татар мәчете дә эшләп килгән.

Морад Рәмзинең тарих белән кызыксынуына Гәрәй шәех Габделмөмин ишан Алтайлы аеруча зур тәэсир иткән укымышлылардан санала. Ташкентта танышкач, алар Сәмәркандтан Бохарага кадәр юлны бергәләп узалар. Соңыннан үзенең хатларында М. Рәмзи аны «минем газиз атам» дип олылый, үз нәүбәтендә Гәрәй шәех тә аңа «улым» дип мөрәҗәгать иткән. Тарих буенча әңгәмә-бәхәсләрен алар 1880 елларда — Гәрәй шәех Алтайлы хаҗ кылырга Мәккәгә килгәч тә дәвам иттерәләр.

Хиҗазда укыган елларында М. Рәмзи мөдәррисләрдән, китапханә һәм торак шартларыннан да канәгать була, әмма мәдрәсәгә бирелә торган вәкыфлардан (ягъни берәр кеше тарафыннан киперен мәдрәсә файдасына тоту өчен бирелгән малдан) ул бик аз күләмдә генә ярдәм алган. Шуның аркасында фәкыйрьлектән бик иза чиккән. Россия белән Төркия арасындагы сугыш елларында Казаннан һәм Төркстаннан хаҗга килүчеләр булмаганлыктан, ватандашлары ярдәменнән дә мәхрүм булган. Соңрак, сугыш тәмамлангач кына, хәл уңай якка үзгәрә. Истәлекләренә караганда, М. Рәмзи бу елларда Мәдинәдә якташлары белән очрашып торган, Габдерәшид Ибраһимов һәм Семипалатинскидан Габделхак Йосыф турында ул аеруча җылы хисләр белән искә алган.

1880 елларда Мәккә белән Мәдинәгә хаҗ кылырга килүчеләрдән М. Рәмзи әнисенең, бер ел узгач әтисенең вафат булуын ишетә.

М. Рәмзи якташларыннан берничә сәүдәгәрнең Мәккәгә килүе дә мәгълүм. Шуларның берсе — Германия, Австрия һәм Төркия арасында сәүдә итү белән шөгыльләнгән Габдрахман Җәдид — Мәккәдә аеруча еш булган һәм шәһәрдә күчми торган милек тә

сатып алган. Габдрахман Җәдид М. Рәмзи белән танышкач, аның белән дустанә мөнасәбәтләрне туганлык җепләре белән ныгыту өчен Мәккәгә үзенең бертуган сеңлесе Әсманы алып килә. Тәтеш өязенең бер татар авылыннан чыккан Шаһмөхәммәд ага кызы Әсма белән М. Рәмзи 1895 елда өйләнешәләр. Бу никахтан туган тугыз баланың дүртесе яшьли вафат була. 1899 елларда хаҗга килгән җизнәләре Йосыф Дебердиев аларда туктала һәм өйдәге кысынкылыктан гаҗиз булып, Истанбулга күчеп китүче доктор Мостафа Хәйринең яңа гына салынган йортын вәкыфкә сатып алып, М. Рәмзи һәм аның варислары милкенә тапшыра.

М. Рәмзи берничә тапкыр Россиягә дә кайтып килә. М. Рәмзинең истәлекләренә караганда, Россиягә кайткан чакларында ул тарихи хезмәтләренә материал җыю максатыннан төрле җирләргә бара, Төркстанда була. Үзен тарихчы итеп таныткан «Тәлфикъ әл-әхбар вә тәлкъих әл-асарь фи вәкаигъ Казан вә Болгар вә мөлүк ат-татар» исемле хезмәтен ул, үз сүзләренә караганда, 1892 елда яза башлаган һәм, вакытлыча башка эшләр белән шөгыльләнүләрне исәпкә алмаганда, 1907 елның 4 ноябрендә тәмамлаган. Истәлекләргә караганда, М. Рәмзи Петербург цензурасында бу хезмәтен бастырырга рөхсәт ала алмаган. Бары тик Казан университеты профессоры Н. Ф. Катанов һәм тарихчы Гайнетдин Әхмәрев ярдәме белән генә ул хезмәтен дөньяга чыгаруга ирешә. Бишенче елгы революция нәтиҗәсендә китап бастыру хокуклары шактый киңәюгә карамастан 1905 елның 17 октябрь Манифесты татар китабына башлангыч цензураны йомшартмаган. Шуңа күрә милли басмаханәләр, халык өчен файдалы әсәрләрне цензура үткәрмәячәген алдан ук белгәнгә күрә, андый китапларның кульязмаларын Матбугат эшләре буенча инспекциягә биреп тормыйча гына нәшер иткәннәр. Әнә шулай 1908 елда Оренбургта «Кәримов, Хөсәенов һәм К.» ширкәте М. Рәмзинең гарәп телендә язылган тарихи хезмәтен ике томда бастырып чыгара. Басма Троицк шәһәре мәчете имамы Зәйнулла ишанның булышлыгы һәм матди ярдәме белән нәшер ителә. Әлеге хезмәтнең дөньяга чыгуы киң татар җәмәгатьчелеге, бигрәк тә зыялылар тарафыннан бик хуплап каршы алынган булса, патша цензурасының мөнәсәбәте, әлбәттә, тискәре була. Күренекле татар галиме Риза Фәхретдинев әлеге тарихи хезмәтнең дөньяга чыгуы уңаеннан «Шура» журналында басылган анонста: «Ниһаять, безнең милләт тә бу асарь йөзендә үз тарихының лаеклы чагылышын тапты»,— дип язды. («Шура», 1908, 6 сан, 145 б.). Патша цензурасы исә М. Рәмзи хезмәтендә матбугатта чагылырга тиешле булмаган фикерләр — монархиягә, христиан диненә каршы һәм милләтчелек рухындагы фикерләр таба. Казандагы матбугат эшләре буенча вакытлы комитет составында эшләгән профессор Н. Ф. Катанов үзенең цензорлык бәяләмәсендә бу хезмәтнең беренче томы «Казан һәм Болгар патшалыкларының Россия тарихы белән бәйләнгән гражданлык тарихыннан гына түгел, ә бәлки аларның рухи тарихы турындагы мәгълүматларны да үз эченә ала»,— дип билгеләп уза. Хезмәтнең икенче томы турында сөйләгәндә профессор,бу том Россиядәге төрки һәм мөселман халыкларының тарихын һәм хәзерге хәлен бәян итә, дип яза.

М. Рәмзи, дип дәвам итә цензор, «ультрамилләтчелек позициясендә» торган хәлдә тарихтагы барлык фактларны татарларны гына мактау һәм аның мәнфәгатьләрен кайгырту максатыннан чыгып яктырта һәм шуңа күрә җае туры килгән саен рус тарихындагы бөек вакыйгаларның әһәмиятен кечерәйтеп күрсәтергә тырыша. Ул русларның мөселман татарларны изүеннән зарлана һәм русларга каршы шикләнүчәнлек, дошманлык хисе тарата[3]. Профессор Н. Ф. Катанов М. Рәмзи хезмәтенә әнә шундый бәя бирә. Н. Ф. Катанов «Тәлфикъ әл-әхбар...»ның нинди чыганакларга нигезләнүен ачыклаганда авторның гарәп чыганакларына, Н. Карамзин хезмәтләренә, татар басмаларына, һәм шулай ук татар газеталарындагы мәгълүматларга, төрле риваятьләргә нигезләнеп язганлыгын искәртә. Казанның Матбугат эшләре буенча комитетына юллаган бәяләмәсендә Н. Ф. Катанов М. Рәмзи хезмәтенең христианнарга, русларга, хөкүмәткә, хәтта патша гаиләсе әгъзаларына карата нәфрәт һәм ачу белән язылган урыннарын тәрҗемә итеп өстәп куя.

Ике томлык бу хезмәтнең язмышы уңышсызлыкка очрый: ул замандашларына да, киләчәк буыннарга да чагыштырмача аз билгеле хезмәт булып кала. Казанның Матбугат эшләре буенча вакытлы комитеты бу басманың тиражын конфискацияли. Аны бастырып чыгарган басмаханә вакытлыча ябылып тора, ә авторына карата хөкем эше кузгатыла. М. Рәмзи кулга алынудан чит илгә качып кына котыла. Татар галименә карата кузгатылган хөкем эше материалларына караганда, цензорлар аны «Аларның (рус самодержавиесенең) максаты... христианлаштыру өчен мөселманнарга рус юлыннан тыш, гыйлем һәм белем юлын ябу»,— дип раслаганы өчен гаепliләр. Аның хезмәтендә цензорлар император Александр III һәм императрица Мария Федоровнаны мыскыллау, христиан динен хурлау, мөселманнарны русларга каршы котырту да табалар. Әмма 1908-1915 елларда бу эш белән шөгыльләнгән Саратов хөкем палатасы, Матбугат

[3] ТАССР УДА, 420 ф., 1 тасв., 124 эш, 79 б.

эшләре буенча Дәүләт идарәсе һәм Казан комитеты басымына карамыйча, җинаять составы булмау сәбәпле, аңа ташланган гаепне һәм басмага салынган арестны расламый[4]. Ләкин бу вакытта басма тиражының зур өлеше юкка чыгарылган була. Бары тик наширләрнең цензура рөхсәтеннән башка әлеге китапның ике йөзгә якын нөсхәсен сатып өлгерүләре нәтиҗәсендә генә аның берничә дистә нөсхәсе сакланып кала.

Шул ук вакытта, бу хөкем эше ябылганчы ук, Романовлар династиясенең 300 еллык юбилее уңаеннан М. Рәмзинең «гафу ителүен» әйтеп үтәргә кирәк.

М. Рәмзи әлеге хезмәтен язганда XIX гасыр ахыры-XX гасыр башында гарәп-фарсы телләрендә билгеле булган тарихи чыганаклар һәм фәнни басмалардан файдаланган. Асылда гарәп-фарсы тарих фәненә хас иске традицияләр тәэсирендә калган хәлдә дә ул XX йөз башы гарәп-төрек тарих белемендәге яңа алымнардан да йөз чөермәгән. Ике китаптан торган бу хезмәтендә М. Рәмзи гомум тарихи процесс фонында татар халкы тарихының тулы бер картинасын тудырырга тырыша. Шуңа күрә ул татар халкы тарихына бәйле рәвештә карала торган гомуми мәсьәләләрне Ш. Мәрҗанигә караганда да киңрәк куя. Хезмәтнең икенче томындагы дүртенче бүлек, татар тарихының Казан яулап алынганнан соңгы дәверен беренче тапкыр системага салып, эзлекле рәвештә эшләнгән тикшерү үрнәге, дип бәяләнергә хаклы. Шуны да истән чыгармаска кирәк: тарихчы М. Рәмзи бу хезмәтен Россиядән читтә яшәүчеләргә, ягъни татар тарихы турында бик аз, дәресрәге гомумән мәгълүматсыз мөселманнарга адреслап язган.

Татарларда дини-идеологик әдәбиятның тууы һәм үсүе, татар галимнәренең бу өлкәдәге казанышлары — болар барысы да әлегә кадәр бик аз тикшерелгән мәсьәлә булып кала бирә. Бу җәһәттән караганда да М. Рәмзи иҗаты игътибарга лаек.

1914 елның язында ул гаиләсе белән кыска вакытка Россиягә кайтып килә. Бу вакытта аның хатыны Әсма ханым яшь балалар белән Татарстанның хәзерге Тәтеш районына кергән туган авылында кунак була, ә М. Рәмзи олы улы Фәһим белән Төркстанга китә һәм Ташкент, Бохара, Куканд, Наманган һәм Әндиҗан шәһәрләрендә була. Яңадан бергә җыелып Төркиягә китү өчен Одессага килеп җиткән М. Рәмзи гаиләсе белән Россиядә кала, чөнки бу вакытта Беренче бөтендөнья сугышы башлана, төрек хәрби кораблары портны утка тота. М. Рәмзигә гаиләсе белән яңадан Казанга кайтып шунда кыш чыгарга туры килә. Төрек гражданы исәпләнгәнгә күрә, М. Рәмзи башка исем астында яшеренеп яшәргә мәҗбүр була.

1915 елның язында М. Рәмзи Оренбург ягындагы Тоз-Түбә шәһәрендә яшәүче туганы Мөслехетдин Нугайбәк янына китә. Бирәдә ул гаиләсен калдыра һәм, олы улын алып, Иран аша Төркиягә бару нияте белән юлга чыга. Әмма юлы уңмый: төрекмәннәрнең баш күтәрүе аркасында ул тоткарлана һәм төрле хәлләрдән соң рус властьлары кулына төшә Өч ай буе Дүрт күп төрмәсендә тоткач, аны Себергә сөрү өчен тоткыннар вагонында Чарджоу, Ташкент һәм Самара аша Уфага китерәләр. Латыйф хаҗи Хәким, Хәсән Кәрими, Гыймай Мирза, Мәрьямбикә Солтанова һәм башка дуслары аны коткару хәстәренә керешәләр. Хәсән Акчура Петроградка барып эчке эшләр министры белән очраша һәм күпләр тырышлыгы белән М. Рәмзи азат ителә. Аңа гаиләсе янына Оренбург губернасына китәргә рөхсәт ителә һәм ул анда сугыш беткәнче гражданский әсир сыйфатында полиция күзәтүе астында яшәргә тиеш була.

Февраль революциясеннән соң М. Рәмзи, Оренбург делегаты сыйфатында, 1917 елның июлендә Казанда булып узган Мөселман руханиларының Бөтенроссия съезды эшендә катнаша. Съездан соң ул Оренбургка кайта, ә бераздан Хиҗазга китү хәстәрлеге белән яңадан Казанга килә. Әмма бу вакытта Казанга ак чехлар керү сәбәпле, аңа паспортын озайту өчен Мәскәүгә төрек консулына барырга мөмкин булмый. Сугыш барган җирдә калмас өчен, ул, авылдан-авылга күчә-күчә, Бәйрәкәгә килеп җитә һәм Мәсгуд хәзрәт белән авыл мәдрәсәсендә дәрес бирә башлый.

1919 елның язында М. Рәмзи Уфага бара, аннан соң Кызылъяр (Петропавловск) һәм Семипалатинск аша бик зур кыенлык белән Чүгүчәккә барып җитә. Шәһәр халкы аңа имам-мөдәррис вазифасын тәкъдим итә һәм акча җыеп барлык кирәк-яраклары белән йорт та җиткереп бирә.

1921 елда ул Өремче һәм Турфанга сәяхәт кыла.

1923 елда катаракт нәтиҗәсендә сукыр калган М. Рәмзи олы улы белән Истанбулга бара һәм уңышлы үткән операциядән соң яңадан Чүгүчәккә әйләнеп кайта. 1927 елда М. Рәмзи уллары белән Россия аша хаҗга китә. Әмма Гарәбстанда хаҗиларның хәле авыр була, чөнки М. Рәмзинең Мәдинәдәге йортлары төрек-гарәп сугышы вакытында яраксыз хәлгә килгән. Гаиләсе белән Хиҗазда төпләнергә уйлаган М. Рәмзи акча юнәтү уе белән Чүгүчәккә кайта һәм андагы йортын сатарга ниятли. Ләкин йортын алучы табылмый. Шулай итеп, ул Хиҗазга китү уеннан кире кайтырга мәҗбүр була.

Кайбер мәгълүматларга караганда, М. Рәмзи Шәркый Төркстандагы мөселманнар арасында зур абруй казанган. Мәдрәсә өчен махсус бина булмау сәбәпле, Базар мәче-

---

[4] Каримуллин А. Г. Татарская книга начала XX в. — Казань, 1974, 145-146 бб.

тендә алып барган дәресләренә шәкертләр генә түгел, Чүгучәкнең башка муллалары да йөргән. Чүгучәктә төрки-татар телендә беренче хөтбә М. Рәмзи тарафыннан укылган. Аның хөтбәләре зур уңыш казана. М. Рәмзи килгәнче ярым буш булган Базар мәчетенә агыла, ә җомга намазларында бина эченә сыймаган халык ишек алдында җыелып аны тыңлаган. Татарча әйтелгән хөтбәне ишетер өчен хәтта салкын көннәрдә дә мәчет ишеген ачып куйганнар.

М. Рәмзинен Чүгучәктә һәм, гомумән, Шәркый Төркстанда абруе үсү Кытай властьларын хафага сала. Чүгучәкнең шәһәр башлыгы аңа, төрек гражданинына Кытайда яшәү тыела, дип белдерә һәм илдән китәргә куша. Чүгучәк, Голҗа, Өремче һәм Мәгтабаран халкы властьларга М. Рәмзине Кытайда калдыруны сорап үтенеч белән мөрәҗәгать итә. Шуннан соң властьлар, М. Рәмзинең бу халлардән элек үк тартып алынган паспортын һәм башка документларын кире кайтармыйча, аңа Кытай гражданлыгына күчәргә тәкъдим итәләр. Мәскәүдәге төрек илчелеге аша М. Рәмзи Әнкарәгә шикаять юллый. Әнкарәдән Нанкинга җибәрелгән протест та бу мәсьәләдә файда бирми. Бу турыда белеп алган җирле чиновниклар аңа тагын да ныграк бәйләнә башлый. М. Рәмзи бик авырлык белән генә Кытай властьларының тәкъдименә күнәргә ризалык бирә.

Галимнең Шәркый Төркстандагы тормышы хакындагы материалларда аның иҗат эшчәнлеге чагылыш тапмаган диярлек. Шулай да М. Рәмзинең абруйлы дин галиме икәнлеген белеп алган властьларның аңа Коръәнне җирле төрки телгә тәрҗемә итәргә тәкъдим итүләре мәгълүм. Бу тәкъдим аның үз ниятенә дә туры килгән. Моннан тыш «Тәлфикъ әл-әхбар...»ның төрки-татар теленә тәрҗемәсе булуы да мәгълүм. Тәрҗемә Чүгучәктә эшләнгән, мөгаен.

Шәркый Төркстанда милли-азатлык көрәше кабынган елларда М. Рәмзи бердәм фронт булып Кытайга каршы чыккан төркиләрне һәм дунганнарны[5] яклый. 1933 елның октябрь башларында Чүгучәккә дунганнар кергәч, М. Рәмзи шәһәр мөселманнарын дунганнарга кушылырга өнди. Чүгучәктә һәм аның тирәләрендә дунганнар белән конфликт булдырмауга күп көч түгә. Шәһәрнең берничә татар бае баш күтәрүчеләргә матди ярдәм күрсәтә.

Шинҗаң-Уйгыр автономияле районның административ үзәге Өремчедән Чүгучәккә бик тиз арада кытайларда хезмәттә булган акгвардиячеләр отряды килеп җитә. Дунганнар тар-мар ителә. Шәһәрдә калган җәмигъ мәчет ахуны Хәсән ахун, байлар һәм аларның туганнары үтерелә, мал-мөлкәтләре талана. Шәһәрнең татар мәхәлләре имамнарыннан Хафиз Гәрәй, Морад Рәмзи һәм аның кияве кулга алына. Сорау алу вакытында М. Рәмзинең ачу китерерлек кыю җавап бирүе карательләр гаскәренә җитәкчелек иткән акгвардияче офицерны чыгырыннан чыгара һәм ул ярсып китеп М. Рәмзинең чалмасын сугып төшерә, күзлеген вата. Сорау алудан соң дүрт кешене азат итеп, калганнарын үлем җәзасына хөкем итәләр. Әмма мондый карар җирле халыкның ачуын кабарта һәм карательләр, баш күтәргән халык нәфрәтеннән куркып, үлем җәзасына тартылган өч кешене дә иреккә чыгаралар.

Әнә шундый давыллы елларда катлаулы тормыш һәм каршылыклы иҗат юлы узган татар галиме Морад Рәмзи хәзерге Кытай Халык Республикасының Шинҗаң — Уйгыр автономияле районындагы Чүгучәк шәһәрендә 1934 елның 2 апрелендә вафат була.

Морад Рәмзинең катлаулы тормыш юлын һәм иҗатын җентекләп тикшерү, галимнең татар тарих фәненә керткән өлешен тагын да тирәнрәк ачыклау, халкыбызның иҗтимагый фикер үсеше тарихындагы үзенчәлекле урынын билгеләү — киләчәктәге бурычларның берсе булып кала.

---

[5] Дунганнар — мөселман динендәге кытайлылар.

# АЛТЫНЧЫ ДӘРЕС

*Тиздән яз килер,*
*Ап-ак кар эрер.*
*Тышта балалар*
*Күлмәкчән йөрер.*

Әхмәт Ерикәй

Татарча җөмләләр төзеп сөйли башлаганда авазларны дөрес әйтү, сүзләрнең төгәл мәгънәләрен аңлау белән бергә, җөмлә төзелешенә, андагы сүзләрнең урнашу тәртибенә дә аерым игътибар итәргә кирәк. Безнең телебездә, мәсәлән, хәбәр һәрчак диярлек җөмләнең ахырында килә. Телне камил белмәгән яисә әле татар теленә өйрәнә генә башлаган балалар, рус теленә ияреп, бу җәһәттән шактый гына хата ясыйлар. Мәсәлән:

— Әни әйтте, без иртәгә кунакка барабыз.
— Ул миңа әйтте, син яхшы кыз дип.
— Мин күрдем, ул ничек очып китте,— рәвешендә төзелгән җөмләләрне балалар теленнән еш ишетергә мөмкин. Ә дөресе болай:
— Әни, без иртәгә кунакка барабыз, д и д е.
— Ул миңа, син яхшы кыз, д и п  ә й т т е.
— Мин аның ничек очып киткәнен  к ү р д е м  һ. б.

Бары тик шигъри юлларда гына хәбәр җөмләдә төрлечә урнашырга мөмкин:

МӨНИР МАЗУНОВ

*Февральдә, февральдә*
*Җилләр  у й н ы й  кырларда,*
*Көртләр  ө е л ә  юлларга.*
*Кар таулары шәп булса да,*
*Суык  б у л а  урамда.*

ГАБДУЛЛА ТУКАЙ

*Бар җир карланган,*
*Сулар бозланган,*
*У й н ы й  җил-буран,*
*Бу кайчак, туган?*

Игътибар итегез, гадәти сөйләмдә без ул җөмләләрне болай төзибез:

*Кырларда җилләр  у й н ы й.*
*Юлларга көртләр  ө е л ә.*
*Урамда суык  б у л а.*
*Җил-буран  у й н ы й.*

2. Авазларның дөрес әйтелешен кабатлыйбыз:

## БАЛ КОРТЫ

ӘХМӘТ ФӘИЗИ

*Чәй эчәбез бал белән*
*Бала-чагалар белән.*
*Бала-чага алты җан:*
*Әхмәт, Нәҗип, Закирҗан,*
*Зәйнәп белән Галия,*
*Иң соңгысы Асия.*
*«Бал дисәң, бер кими,*
*Кашык тыксаң, өч кими.*
*Алты кашык тыгылса,*
*Иртә тия, кич тими.*
*Нигә дисәң, бал татлы,*
*«Юкә бал» дип атаклы.*
*Кәрәзләре сап-сары,*
*Саркып тора аслары.*
*Кашык белән аласың,*
*Тел өстенә саласың.*
*Эреп китә авызда,*
*Кара аны, сак кылан,*
*Ашъяулыкка тамызма!*
*Чәй эчәбез бал белән*
*Бала-чагалар белән.*
*Балны кем бигрәк сөя?*
*Иң кечкенә Асия.*

**Искә төшерик: б авазы йомшак, иреннәрне йомар-йоммас әйтелә, ч, җ авазлары да йомшак, өрелеп әйтелә, к (ҡ), г (ғ) авазлары тирән тел артында ясала.**

**Бүгенге дәрес — өс-баш, аяк киемнәре турында. Түбәндәге сүзләрне отып калыйк: күлмәк, тасма, тун, чалбар, бүрек, чүәк, оек, киен, чишен һ. б.**

**1. Башлап, матур итеп киенгән курчакның өс киемнәрен атап чыгарга мөмкин.**
**— Яле, карыйк, Айсылу ничек киенгән икән?**
**— Айсылу матур күлмәк кигән.**
**— Чәченә алсу тасма бәйләгән.**
**— Аягына чүәкләр кигән.**

**2. «Курчакны киендерү» уены уйнала. Бу уенны магнитлы курчакны киендерү, чишендерү рәвешендә яки шул ук курчак белән уздырырга мөмкин.**
**Курчакка чалбар (итәк) кидерелә.**
**— Курчак нәрсә киде?**
**— Ул нинди төстә?**
**Курчакка кофта кидерелә.**
**— Ул тагын нәрсә киде?**
**— Кофта нинди төстә?**
**Шул рәвешле, һәр кигән кием исеме берничә тапкыр кабатлана.**
**3. «Тиз әйт!» уены уйнала. Балага өс-баш, аяк киемнәре сурәтләнгән рәсемнәр күрсәтелә. Бала тиз отып, аның исемен әйтергә тиеш.**
**— Бу күлмәк, бу тун, бу чалбар, бүрек, итек һ. б.**
**«Биредә нәрсә юк?» уены уйнала. Өстәлгә өс киемнәре куела. Уенда катнашучы бала аларга арты белән борыла. Өстәлдән бер кием**

алына. «Биредә нәрсә юк?» соравына бала тиз генә җавап бирергә тиеш.

### ЯҢА КИЕМНӘР

ПЛАТОН ВОРОНЬКО
*(Зәки Нури тәрҗемәсендә)*

*Мин бәйрәмгә мәчемә*
*Итек алдым, мәче, мә!*
*Тарадым мыекларын,*
*Ямадым оекларын.*
*Бүләгем булсын, дидем —*
*Трусик та тегеп бирдем.*
*Ләкин кидерә белмим, уйлыйм:*
*Койрыгын кая куйыйм?*

Шигырьнең эчтәлеге буенча әңгәмә үткәрелә, өс киемнәренең исемнәре таптырыла.

### АВЫРАЯК

ИДРИС ТУКТАР

Авыраяк озак йоклады. Ахырда уянды. Иснәде. Киерелде. Тәрәзә аша тышка карады. Тышта тәрәзә каршында боз каткан.

Авыраяк:

— Әнкәй, минем тимераякларым кайда икән?— диде.

Әнисе белән бергә тимераякларны эзләп таптылар.

— Әнкәй, минем тимераякларымны бәйләш әле.

Әнкәсе тимераякларны бәйләште.

— Әнкәй, минем туным кайда?

Авыраякның туны үз урынына эленмәгән иде.

— Әнкәй, әнкәй! Минем бүрегем кайда соң?

Авыраякның бүреге су кисмәге артыннан табылды.

— Әнкәй, әнкәй! Баядан бирле әнкәй, дим!.. Минем бияләйләрем кайда икән инде?

Бияләйләре берсе караватастында, икенчесе диван астында яткан. Әнкәсе аларны таяк белән өстерәп чыгарды.

Авыраяк авыраеп кына ишегалдына чыкса: әлеге боз эреп беткән.

Авыраяк авыраеп кына өйгә керде:

— Әнкәй, тимераякларымны чиш!

Тимераяклар чишелде.

— Әнкәй, тунымны салдыр!

Тун салынды.

— Әнкәй, әнкәй! Бүрегемне элеп куй.

Бүрек эленде.

— Әнкәй, әнкәй! Баядан бирле әнкәй, дим!.. Бияләйләремне дә алып куй.

Бияләйләр алып куелды.

Авыраяк авыраеп тәрәзә аша тышка караса: әлеге эрегән боз яңадан каткан.

Авыраяк авыраеп кына уйлап алды:

— Мин бу кышны тимераякта шуа алырмынмы икән? Әллә киләсе кышны көтимме икән?

**Фәһимә ХИСАМОВА,**
филология фәннәре кандидаты.
**Рәшидә БОРҺАНОВА,**
методист.

## Татарстан эшче, крәстиян һәм кызыл гаскәр вәкилләре советларының Мәркәз (Үзәк) башкармасы һәм Т.С.С.Җ. Халык Комиссарлары Советының ДЕКРЕТЫ

### Татарстан җөмһүриятендә (республикасында) татар телен гамәлгә кую хакында

Озак елгы гражданнар сугышы соңында Татарстан җөмһүриятендә (республикасында) беренче мәртәбә тыныч мәдәни тормыш төзүгә мөмкинлек булуын игътибарга алып, Татарстан Мәркәз (Үзәк) башкармасы һәм Татарстан Халык Комиссарлары Советы үз кул көче белән торган халык өчен карар бирде:

1) Бөтен хөкүмәт совет мөәссәсәләрендә (оешмаларында) татар телен мәҗбүри итеп кертергә.

Т ә н б и һ (искәрмә): Җәмәгать мөәссәсәләрендә (оешмалары) кооператив һәм кәсептәш союзлары оешмалары татар телен үз карамаклары белән кертерләр.

2) Бу положениене тәртипле һәм тиз рәвештә гамәлгә куяр өчен, Татарстан Мәркәз Башкармасы янында аның шөгъбәсе (бүлеге) хокукы белән татар телен гамәлгә кую өчен махсус комиссия төзелә. Бу комиссия татар мәдәни көчләрен кирәк мәркәздә, кирәк урыннарда булсын хисапка алу һәм булу юлы белән тәрәккый иттерә һәм алардан файдалана; шулай ук Татарстан Мәгариф Комиссариаты аркылы татар телен һәм үз кул көче белән торучыларның гореф, гадәтләрен белгән татар мәдәни көчләрен хәзерләү юлында чаралар күрә. Комиссиянең карарлары бөтен совет мөәссәсәләре (оешмалары) өчен мәҗбүри; комиссиянең карарларыннан бары тик Татарстан Мәркәз Башкармасы һәм Халык Комиссарлары Советына гына шикаять итәргә мөмкин.

3) Татар телен гамәлгә куйган вакытта мәҗбүри имла итеп Татарстан Мәгариф комиссариаты тарафыннан эшләнгән яңа имла алына. Халык мәгариф комиссариатына шулай ук мәмләкәт хәбәрләшүе вакытында муафикъ булган истиляхларын һәм телеграф белән хәбәрләшү өчен татар әлифбасы төзергә махсус комиссия төзергә тәкъдим ителә.

4) Халык мәгариф комиссариатына үзләре теләгән халык галякате (элемтә) һәм совет эшчеләре өчен тиз көндә татар теле курслары ачу эше тапшырыла. Бөтен рус 1 нче баскыч мәктәпләрендә теләгән кешеләр өчен татар теле укытуны, шулай ук татар мәктәпләрендә рус теле укытуны кертергә.

5) Татарстан мәгариф комиссариатына вакыты белән ябылган татар мәктәпләренең рухани мәктәпләрдән башкаларын ачу эше һәм татар халык театрларын көчле сурәттә алга җибәрү эше тапшырыла. Бөтен совет мөәссәсәләре (оешмалары) Халык мәгариф комиссариатына ярдәм итәргә тиешләр.

6) Татарстан Мәркәз Башкармасы һәм Татарстан Гадлия (юстиция) эшләре халык комиссариатының һәм урыннардагы мөәссәсәләрнең (оешмаларның) үзара гамәли килешүләре буенча мәхкәмә (суд) эшләре һәм карарлар хөкем ителүченең ана телләрендә булсын өчен, күбрәк халкы татар булган урыннарда татар телендә халык мәхкәмәләре (судлары) ясарга. Кирәк чагында халык мәхкәмәләре мөәссәсә Татарстан Мәркәз Башкармасы һәм Гадлия (юстиция) эшләре комиссариаты яисә аларның урыннардагы мөәссәсәләре (оешмалары) тарафыннан тасдыйк ителгән (расланган) тәрҗемәчеләр белән файдаланырлар.

Т ә н б и һ 1: Тәрҗемәләр протоколга гайнән (үзгәртмичә) кертелеп гаепләнгән кеше һәм шаһидләргә укылып чыгыла. Тәрҗемәләр дөрес булмаган

яисә касдан (белә торып, юри) дөрес эшләнмәгән тәрҗемәләр өчен инкыйлаби (революцион) хәрби трибунал алдында мәсьүл (җаваплы) булалар.

Тәнбиһ 2. Гадлия (юстиция) эшләре Халык Комиссариатына бер ай мөддәт (вакыт) эчендә канцелярия эшләрен (делопроизводство) катнаш йөртү хакында положение төзү эше тапшырыла.

7) Татар шрифты ясалганча һәм татар телен гамәлгә кую комиссиясенең махсус карарына һәм Татарстан Мәркәз Башкармасы Татарстан Халык Комиссарлары Советының декретына кадәр тиешле булган урыннарда Комиссия белән почта телеграф идарәсенең гамәли килешүләре буенча телеграф конторалары тизлек белән рус шрифты белән язылган татар телендәге телеграммаларны кабул итү һәм тапшыру ысулын кертергә. Тизлек белән бөтен телеграф конторларында татарча язылган адреслы заказной хатларны кабул итә башларга. Татар телен гамәлгә кую комиссиясенә простой хатларны да татарча адреслар белән җибәрү өчен ашыгыч чаралар күрергә тәкъдим ителә.

8) Татарстан Мәркәз Башкармасы, Халык Комиссарлары Советы һәм совет мөәссәсәләренең (оешмаларының) игълан ителергә тиеш булган бөтен декрет һәм карарлары татар һәм рус телләрендә нәшер ителер.

9) Казан шәһәрендә һәм кантоннарда рус пролетариаты һәм крәстиәннәренең шактый зур процент тәшкил иткәнлектән бары тик татар телен генә кертүнең аларга уңайсызлыклар тудыруы мөмкин булганлыктан — татар теле белән берәттән үк рус теле дә хөкүмәт теле хокукы белән яши.

10) Хөкүмәт мөәссәсәләре (оешмалары) арасындагы язышу һәм эчке делопроизводство мәмләкәт (дәүләт) телләреннән берсендә йөртелер. Делопроизводство нинди телдә йөртелсә дә, мөәссәсәләрдә (оешмаларда) мәмләкәт (дәүләт) телләренең һәрберсесе буенча справкалар бирә торган тәрҗемәчеләр бюросы төзелер.

Тәнбиһ 1. Тәрҗемәчеләр бюросы татар телен гамәлгә кую комиссиясенең күрсәтүе буенча төзелеп, аерым канцелярие аппараты булмыйча өч мәркәзи (үзәк) комиссариатларда өч тәрҗемәчедән, урыннарда бер, икедән артык булмаска тиеш.

Тәнбиһ 2. Тәрҗемәчеләр бюросы төзелү тиеш табылган бөтен мөәссәсәләрне (оешмаларны) тәрҗемәчеләр белән тәэмин итү татар телен гамәлгә кую комиссиясенә тапшырыла.

Тәнбиһ 3. Тәрҗемәчеләр булмаган вакытта мөәссәсәләр (оешмалар) татар телен үз көчләре белән мөмкин булган дәрәҗәдә гамәлгә куялар.

11) Бу декретны гамәлгә куйган вакыттагы бөтен аңлашылмаулар татар телен гамәлгә кую комиссиясе тарафыннан хәл ителә.

Татарстан Мәркәз (үзәк) Башкармасы рәисе (председателе):

**Б. МАНСУРОВ**

Татарстан Халык Комиссарлары Советы рәисе

**С. СӘИДГАЛИЕВ**

Татарстан Мәркәз Башкармасы сәркәтибе (секретаре):

**ГАЙНУЛЛИН**

1921 нче ел, 25 нче июнь.

*«Татарстан хәбәрләре», 1921, № 130*
*(29 июнь, 1921)*

تاتارستان ئشچی.کره‌ستیه‌ن
هه‌م قزل عه‌سکه‌ر وه‌کیلله‌ری ساۋیتلارینك مه‌ر-
که‌ز باشقارماسی هه‌م ت.س.س.ج. خالق کامیسار-
لاری ساۋیتینك دیکریتی

تاتارستان جومهوریه‌تنده تاتار تلن عه‌مه‌لگه قویوحاقندا.

اوزاق یلغی گراژدانلار سوغشی سوڭندا تاتارستان جو-
مهوریه‌تنده برنچی مه‌رته‌به تنچ مه‌ده‌نی تورمش تو-
زوگه مومکینلك بولوون ئیغتیبارغا آلب، تاتارستان مه‌ر-
که‌ز باشقارماسی هه‌م تاتارستان خالق کامیسارلاری سا-
ۋیتی ئوز قول کوچی بله‌ن تورغان خالق ئوچون قه-
رار بیردی:
۱) بوتون حوکومه‌ت ساۋیت موئه‌سسه‌سه‌له-
رنده تاتار تلی مه‌جبوری ئیتب کرترگه.
ته‌نبیه: جه‌ماعه‌ت موئه‌سسه‌سه‌له‌ری، کاپیراتیف
هه‌م که‌سبده‌ش سایوزلاری ئویوشمالاری تاتار تلن
ئوز قاراماقلاری بله‌ن کرتله‌ر.
۲) بو پالاژینیه‌نی ته‌رتیبلی هه‌م تیز ره‌وشده
عه‌مه‌لگه قویار ئوچون، تاتارستان مه‌رکه‌ز باشقارما-
سی یانندا آنك شه‌عبه‌سی حوقوقی بله‌ن تاتار تلن
عه‌مه‌لگه قویو ئوچون مه‌حسوس کامسیه تو-

زوُله. بو كاميسسيه تاتار مه ده نى كوچله رن كيره ك
مه ركه زده، كيره ك ئورنلاردا بولسن حيسابقا آلو
هه م بولو يولى بله ن ته ره قى ئيتدره هه م آلار-
دان فايدالانا؛ شولايوق تاتارستان مه عاريف كا-
ميسارياتى آرقلى تاتار تلن هه م ئوز قول كوُچى
بله ن ئوُروچيلارنيڭ عوُرف، عاده تله رن بلگه ن تا-
تار مه ده نى كوُچله رن حه زرله و يولندا چاره له ركو-
ره. كاميسيه نيڭ قه رارلارى بوُتون ساۋيت موُئه-
سسه سه له رى ئوُچوُن مه جبورى؛ كاميسيه نڭ
قه رارلارندان بارى تيك تاتارستان مه ركه ز باشقار-
ماسى هه م خالق كاميسارلارى ساۋيتينا غنا شيكا-
يه ت ئيته رگه موُمكين.

٣) تاتار تلن عه مه لگه قويغان واقتدا مه جبورى
ئيملا ئيتب تاتارستان مه عاريف كاميسارياتى تارا-
فدان ئشله نگه ن ياڭا ئيملا آلنا. خالق مه عاريف كا-
ميسارياتينا شولايوق مه مله كه ت حه به رله شووى وا-
قتندا موُوافيق بولغان ئيستيلاحلارنى هه م تيليگراف
بله ن حه به رله شو ئوُچوُن تاتار ئه ليفباسى توُزه رگه مه-
حسوس كاميسيه توُزورگه ته قديم ئيتله.

٤) خالق مه عاريف كاميسارياتينا ئوزله رى تله گه ن
خالق عه لاقه تى هه م ساۋيت ئشچيله رى ئوُچوُن

تيز كونده تاتار تلى كورسلارى آچو ئشى تابشر-
لا. بۇتۇن روس ا نچى باسقچ مەكتەبلەرندە تلە-
گەن كشيلەر ئۇچۇن تاتار تلى ئوقتونى، شولايوق
تاتار مەكتەبلەرندە روس تلى ئوقتونى كرترگە.

٥) تاتارستان مەعاريف كاميسارياتينا واقتى
بلەن يابلعان تاتار مەكتەبلەرينڭ روحانى مەكتەبلەر-
دەن باشقالارين آچو ئشى هەم تاتار خالق تيياتر-
لارن كۇچلى سورەتدە آلعا جيبەرو ئشى تابشرلا.
بۇتۇن ساۋيت مۇئەسسەسەلەرى خالق مەعاريف
كاميسارياتينا يەردەم ئيتەرگە تييشلەر.

٦) تاتارستان مەركەز باشقارماسى هەم تاتارستان
عەدلييە ئشلەرى خالق كاميسارياتينڭ هەم ئورز-
لارداغى مۇئەسسەسەلەرينڭ ئۇزارا عەمەل كيد-
لشولەرى بوينچا مەحكەمە ئشلەرى هەم قەرارلار
حۇكۇم ئيتلوچينڭ آنا تللەرندە بولسن ئۇچۇن،كو-
برەك خالقى تاتار بولغان ئورنلاردا تاتار تلندەخا-
لق مەحكەمەلەرى ياسارغا كيرەك چاغندا خالق
مەحكەمەلەرى مۇئەسسەسەلەرى تاتارستان مەر-
كەز باشقارماسى هەم عەدلييە ئشلەرى كاميسارياتى
يەئيسە آلارنڭ ئورنلارداغى مۇئەسسەلەرى تا-
رافنان تەسديق ئيتلگەن تەرجەمەچيلەر بلەن فايدا-

لانرلار.

تەنبیە ۱: تەرجمەلەر پرتاکولغا عەینەن کرتلب عەیبلەنگەن کشی هەم شاهیدلەرگە ئوقلب چغلا. تەرجمەچیلەر درست بولماغان یە ئیسە قەسدەن دۆرست ئشلەنمەگەن تەرجمەلەر ئۆچۆن ئینقیلابی حەربی تریبونال آلدندا مەسئول بولالار.

تەنبیە ۲: عەدلییە ئشلەری خالق کامیساریاتینا برآی مۆددەت ئچندە کانسەلەریە ئشلەرن (دیلاپرائیزۋودستۋا) قاتناش یۆرتو حاقندا پالاژینییە تۆزو ئشی تابشرلا.

۷) تاتار شریفتی یاسالغانغا هەم تاتار تلن عەمەلگە قویو کامیسییەسینڭ مەحسوس قەرارینا هەم تاتارستان مەرکەز باشقارماسی تاتارستان خالق کامیسارلاری ساۋیتینڭ دیکریتینە قەدەر تییشلی بولغان ئورنلاردا کامیسییە بلەن پوچتا تیلیگراف ئیدارەسینڭ عەمەلی کیلشولەری بوینچا تیلیگراف کانتورلارندا تیزلك بلەن روس شریفتی بلەن یازلغان تاتار تلندەگی تیلیگراملارنی قابول ئیتو هەم تابشرو ئۆسولن کرترگە. تیزلك بلەن بۆتۆن تیلگراف کانتورلارندا تاتارچا یازلغان آدریسلی زاکازنوی حاتلارنی قابول ئیتە باشلارغا. تاتار تلن عەمەلگە قۆ-

بو کامیسییه سینه پراستوی حاتلارنی دا تاتارچا آدریسلار بله‌ن جیبه‌رو ئوچون آشغچ چاره‌له‌ر کوررگه ته‌قدیم ئیتله.

٨) تاتارستان مه‌رکه‌ز باشقارماسی خالق کامیسار-لاری ساوٍیتی هه‌م ساوٍیت مۇئه‌سسه‌سه‌له‌رینك ئیغلان ئیتلرگه تییش بولغان بۇتۇن دیکریت هه‌م قه‌رارلاری تاتار هه‌م روس تلله‌رنده نه‌شر ئیتلر.

٩) قازان شه‌هه‌رنده هه‌م کانتونلاردا روس پرو-لیتاریاتی هه‌م کره‌ستیانلارینك شاقتی زور پراتسینت ته‌شکیل ئیتکه‌نلکته‌ن باری تیك تاتار تلن گنه کر-تونك آلارغا ئوگایسزلقلار تودرووی مۇمکین بو-لغانلقدان- تاتار تلی بله‌ن بر ره‌ته‌ده‌ن ئوك روس تلی‌ده حۇکۇمه‌ت تلی حۇقۇقی بله‌ن یه‌شی.

١٠) حۇکۇمه‌ت مۇئه‌سسه‌سه‌له‌ری آراسنداغی یازشو هه‌م چگی دیلاپرائیزوٍودستوٍا مه‌مله‌که‌ت تل-له‌رندن برسنده یۇرتلر. دیلاپرائیزوٍودستوٍا نیندی تلده یورتلسه ده، مۇئه‌سسه‌سه‌له‌رده، مه‌مله‌که‌ت تل-له‌رینك هه‌ر برسیسی بوینچا ئسپرافکالار بیره تور-غان ته‌رجمه‌چیله‌ر بیوراسی تۇزیلر.

ته‌نبیه ١: ته‌رجمه‌چیله‌ر بیوراسی تاتار تلن عه‌مه‌لگه قویو کامیسیه‌سینك کورسه‌تووی بوینچا تۇزیلب،

ئايرم كانسەلەرىيە ئاپپاراتى بولمىچا ئۈچ تەرجەمەچىد-
ەن، ئۇرنلاردا بر، ايكى دەن ئارتق بولماسقا تيىش.
تەنبىه ٢: تەرجەمەچىلەر بىيوراسى تۇزۇلوتيىش
تابلغان بۇتۇن مۇئەسسەسەلەرنى تەرجەمەچىلەر
بلەن تەئمين ئيتو تاتارتلى عەمەلگە قويو كامىسىيە
سينە تابشرلا.
تەنبىه ٣: تەرجەمەچىلەر بولماغان واقتدا مۇئە-
سسەسەلەر تاتارتلى ئۇز كوچلەرى بلەن مۇمكين
بولغان دەرەجەدە عەمەلگە قويالار.
١١) بو دىكرىيتنى عەمەلگە قويغان واقتداغى بۇتۇن
ئاڭلاشلماولار تاتارتلى عەمەلگە قويو كامىسىيەسى
تارافندان حەل ئيتلە.

تاتارستان مەركەزباشقارماسى رەئيسى:
بۇرهان مانسورف.
تاتارستان خالق كامىسارلارى ساۋيتى
رەئيسى: س. سەيدعەلىيىف.
تاتارستان مەركەزباشقارماسى سەركاتيبى:
عەينوللين.

٢٥ نچى ئيون ١٩٢١ نچى يل.

## Камил Мостафин

# ХАТ БАШЫ — ЯЗ КАРШЫ...

8 ХАТТАН ҺӘМ 1 ТЕЛЕГРАММАДАН ТОРГАН ХИКӘЯ

**I хат: Хикмәтулладан Төхфәтуллага**

28 январь

Төхфәт-дуңгыз!

Җаның кыргыры, нигә язмыйсың?!

Институт бетердем, дип, бик борыныңны күтәрмә! Эшли дә башлагансыңдыр инде. Кай урында? Дәрәҗәң нинди? Акча сугасыңмы?

Минем тормыш чуар. Биш ел тегендә бәрелеп, монда сугылып үтте. Бер хәйванханәгә курьер итеп алганнар иде, мөдире — сволочь: «Иртән соңлап киләсең, дәүләт вакытын урлыйсың», — дип эштән куды. Дәүләт вакыты булса — дәүләт үзебезнеке бит! Тәки шуны аңламады бит, йөзекара! Аннары сәүдә буенча эшләдем... Анда бик озын командировкага җибәреп тордылар. Туйдырды... Инде ерак китәсе килми...

Төхфәтулла! Онытмагансыңдыр бит мине, — ничә ел бер партада утырдык икәү — колакка-колак.

Бәлки, берәр эшкә рикаминдация бирерсең, егәрең бардыр, мөгаен... Уйлап кара әле, Чукмарбаш!

Классташың Хикмәт.

**2 хат: Төхфәтулладан Хикмәтуллага**

4 февраль

Хат башы — яз каршы!

Хикмәт дус!

Хатыңны укыдым. Кайбер урыннарын аңлап җитмәдем. Хәйванханә — дуңгыз фермасымы ул? Кайсы авылда эшләдең? Командировкага әллә чит мәмләкәткә бардыңмы? Анда нинди музейларда булдың?

Минем эшләр ярыйсы: инженер, аена 120 сум түлиләр. Өч айга бер 50 сум тирәсе премия дә биреп куялар кайчагында.

Син минем курсташ егеткә шалтырат, телефоны — 33-22-55. Селтәевне сора — табарлар. Мин дә әйтеп куярмын, ярдәм кулын сузмый калмас.

Төхфәт.

**3 хат: Хикмәтулладан Төхфәтуллага**

15 март

Төхфәт кардәш!

«Маладис» диган сүздән башка нәрсә әйтәсең сиңа! Селтәев шәп егет булып чыкты. Килештек. Мин хәзер кәгазьләр өстәле начальнигенең кече ярдәмчесе.

Мин элек эшләгән хайванханә турында да, озаган командировка турында да искә аласы килми. Хәзер мине башка эшләр кызыксындыра.

Кәгазь дигән нәрсәнең исе тәмле була икән ул.

Бәхетеңә каршы, мач килсә, тормыш кулай нәрсә бит ул, Чукмарбаш!

Ә синниләр бетереп ятасың?

Хикмәт.

**4 хат: Төхфәтулладан Хикмәтуллага**

Бер елдан соң. 21 май

Хикмәт дускай!

Минем тормыш зарланырлык түгел. Беренче Майга грамота бирделәр. Әйбәт эшләгәнгә.

Үзең турында яз.

Төхфәт.

P.S. Мин бер нәмәстә уйлап тапкан идем. Ул безнең төзелештә революция эшләргә тиеш. Сызым-фәләннәрен сезгә җибәргән идем. Селтәев җавап бирмәде. Нигә язмады икән?

**5 хат: Хикмәтулладан Төхфәтуллага**

Тагын бер елдан соң. 11 июль.

Төхфәт!

Селтәев хәзер Главкыда. Аның урынында — мин. Чертежыңны күргәнем юк. «Җавап булмады»,— дип язасың, югалгандыр, хәерлегә булсын.

Бер килеп кит. Хәзинәдә бары белән сыйлармын... Мин үзем эстерләд шулпасын яратам. Кара икра да әйбәт нәрсә, тик бу арада өзелеп тора; гастроном директоры: «Базада беткән»,— дигән була. Беткән икән, кайтарырга кирәк. Уйларга, дәүләт ихтыяҗларыннан чыгып эш итәргә кирәк! Ә ул сүз боткасы белән сыйлый, демагог!

Хикмәт Хәзрәтов.

P.S. Сине бу айда тагын бер грамота белән бүләклибез, котлыйм.

**6 хат: Төхфәтулладан Хикмәтуллага**

5 август

Хикмәт!

Чертежымны табыгыз, зинһар! Аның тормышка ашуы 50 миллион сум табыш китерергә тиеш!

Төхфәт.

P.S. Быел миңа инде өч грамота тапшырдылар.

**7 хат: Хикмәтулладан Төхфәтуллага**

12 сентябрь

Иптәш Т. Сагынганов!

Безнең идарә аша көн саен 15 меңнән артык документ уза. Һәркайсының язмышы белән кызыксына башласак, акыл да, вакыт та җитмәячәк.

Ә без үзгәртеп кору белән шөгыльләнергә тиешбез.

Мөһим эшкә аяк чалма!

Главкы исеменнән —<br>Х. Хәзрәтов

P.S. Кара икра кайтты, кереп чык!

**8 хат: Төхфәтулладан Хикмәтуллага**

15 сентябрь

Иптәш Хәзрәтов!

Кара икраң кадалып китсен! Чертежымны тапмасагыз, грамоталарыгызны урамга чыгып яндырам!

Т. Сагынганов.

**Телеграмма: Хикмәтулладан Төхфәтуллага**

16 сентябрь

Т. Сагынгановка.

Грамоталарны яндырганда Сез янгынга каршы чараларны күреп эш итәргә тиешсез. Янгын чыга калса, аның бәла-казасына Главкы җаваплы түгел...

Х. Хәзрәтов.

---

# *Мәдәният тормышы көндәлеге*

## ЭСТОНИЯДӘ — ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ КӨННӘРЕ

Татар әдәбиятының Балтыйк буе союздаш республикалары белән дуслык бәйләнешләре ныгый бара. Татарстан АССР һәм Эстония ССР Язучылар союзлары идарәләре республикаларыбызда үзара әдәбият көннәрен уздыру турында килешкәннәр иде. Язучыларыбыздан Р. Мөхәммәдиев, А. Гыйләҗев, М. Мәһдиев, Р. Фәйзуллин, С. Маннапов, Ә. Гаффар, З. Мансуров, Л. Лерон катнашы белән 17-21 декабрьдә Эстониядә татар әдәбияты көннәре узды. Татарстан вәкилләре Таллинн шәһәрендә, Тарту университетында, республика авылларында эстон халкы белән очраштылар, ике әдәбият вәкилләре арасындагы иҗади элемтәләрне тагын да ныгыту юллары турында сөйләштеләр.

Быел җәй эстон әдипләре безнең республикага киләчәк.

## БЕЗНЕҢ КАНДИДАТЛАР

Татарстан Язучылар союзы оешмасының киңәйтелгән пленумы булды. Пленум ТАССР Язучылар союзының РСФСР, ТАССР һәм җирле Советларга халык депутатларын сайлауларга үз платформасын эшләү һәм депутатлыкка кандидатлар күрсәтү мәсьәләсен карады. Күпләгән чыгыш ясаучылар сайлау алды платформасына кертү өчен үзләренең тәкъдимнәрен әйттеләр.

РСФСР халык депутатлыгына кандидат итеп Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Р. Мөхәммәдиев, ТАССР халык депутатлыгына кандидат итеп «Казан утлары» журналының баш редакторы Р. Фәйзуллин, халык депутатларының Казан шәһәр советы депутатлыгына кандидат итеп шагыйрь Ә. Мәхмүдов, халык депутатларының Вахитов район Советына депутатлыкка кандидат итеп шагыйрь Р. Зәйдуллин күрсәтелде.

## ЮБИЛЕЙ КИЧӘЛӘРЕ

Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрының оештырылуына 50 ел тулды. 9 декабрьдә театр бинасында шушы бәйрәмгә багышланган тантаналы кичә булды. Аны кереш сүз белән ТАССР Министрлар Советы Председателенең беренче урынбасары, театр юбилеен үткәрү буенча оештыру комитеты председателе М. Х. Хәсәнов ачты.

Совет музыка сәнгатен үстерүдәге уңышлары өчен М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының Мактау грамотасы белән бүләкләнгән иде. ТАССР Верховный Советы Президиумы Председателе Ш. Ә. Мостаев коллективка шушы бүләкне тапшырды.

Котлаулардан соң, кичәнең икенче өлешендә, театр артистлары катнашында зур концерт булды.

21 декабрьдә М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры

бинасында Татарстан Композиторлар союзының оештырылуына 50 ел тулуга багышланган тантаналы кичә булды. Аны кереш сүз белән ТАССР культура министры М. М. Таишев ачты. Татар совет музыкасын үстерүдәге хезмәтләре өчен Композиторлар союзы ТАССР Верховный Советы Президиумының Мактау грамотасы белән бүләкләнде. ТАССР Министрлар Советы Председателе М. Г. Сабиров коллективка әлеге югары бүләкне тапшырды һәм иҗат уңышлары теләде. Республикабыз Композиторлар союзының эшчәнлеге турында РСФСР Композиторлар союзы идарәсе секретаре, ТАССР Композиторлар союзы идарәсе члены М. З. Яруллин сөйләде. Коллективны юбилее белән республикабызның иҗат союзлары, культура учреждениеләре вәкилләре, кунаклар котлады.

Кичәнең икенче өлешендә тамашачыларга «Яралтагы кәккүк авазы» операсы (Р. Кәлимуллин музыкасы, И. Юзеев либреттосы) күрсәтелде.

## «ТАТАР ҖЫРЫ-89» БӨТЕНСОЮЗ КОНКУРСЫ

11-12 декабрьдә, Казандагы универсаль тамаша-спорт залында «Татар җыры-89» Бөтенсоюз конкурсының соңгы туры һәм йомгаклау концерты булды. Әлеге конкурс исә ике ай элек башланган иде. Иң элек аның зона ярышлары булып узды. Иәзләрчә яшь талантлар үзара көч сынаштылар. Аннары алар илебезнең барлык төбәкләреннән Казанга җыелдылар.

Менә алар «Татар җыры-89» Бөтенсоюз конкурсы лауреатлары: I дәрәҗә диплом белән бүләкләнүчеләрдән Гөлназирә Талипова (Мамадыш), Идрис Газиев (Уфа), Венера Ганиева (Казан); II дәрәҗә диплом хуҗалары Салават Фәтхетдинов (Чаллы), «Сабантуй» ансамбле (Ташкент), Нәзиф Арсланов (Свердловск); III дәрәҗә диплом авторлары Георгий Ибушев (Казан), Зөфәр Хәйретдинов (Казан), Әлмир Вәлиев (Нефтекамск).

## ТРАДИЦИЯЛӘР ЯҢАРА

20 декабрьдә Казан дәүләт университетында филология, тарих, этнография, археография проблемалары белән шөгыльләнүче галимнәрнең җыелышы булды. Анда СССР Фәннәр академиясенең Көнчыгыш илләрен өйрәнүчеләрнең Бөтенсоюз ассоциациясенең Татарстан бүлеге оештырылды. Ассоциация председателе урынбасары, «Народы Азии и Африки» журналының баш редакторы А. Алаев ассоциация сафларын тулыландырган Казан галимнәренә членлык билетлары тапшырды.

Татарстан бүлегенең максаты — Казанда Көнчыгышны өйрәнүчеләрнең элекке данын кире кайтару. «Үткән ике елда күп кенә эшләр эшләнде: Казан дәүләт университетында татар филологиясе, тарихы һәм көнчыгыш телләре факультеты булдырылды, СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында кулъязмалар бүлеге ачылды, һәртөрле конференция һәм симпозиумнар оештырылды, Көнчыгышны өйрәнүче чит ил коллегалары белән, бигрәк тә Венгриядә һәм Финляндиядә элемтәләр ныгый»,— диде Бөтенсоюз ассоциациясенең татар группасы җитәкчесе, университет проректоры профессор Миркасыйм Госманов.

Татарстан бүлегенең бюросы сайланды. Аның беренче председателе — М. Г. Госманов.

## МОСТАЙ КӘРИМ ЮБИЛЕЕ

20 октябрьдә Уфаның опера һәм балет театры бинасында Башкортстанның халык шагыйре Мостай Кәримгә 70 яшь тулу уңаеннан хөрмәтләү кичәсе булып узды. Иҗаты башкорт халкының рухи байлыгына әйләнгән шагыйрьне илебезнең барлык төбәкләреннән килгән кунаклар кайнар котлады.

Дагстан халык шагыйре Рәсүл Гамзатов, Калмык халык шагыйре Давид Кугультинов, РСФСР Язучылар союзы идарәсе секретаре Валерий Поволяев, Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Ринат Мөхәммәдиев, Чувашстан Язучылар союзы идарәсе председателе Порфирий Афанасьев һ. б. үзләренең котлау чыгышларында шагыйрьгә карата хөрмәтләрен белдерделәр.

## МИЛЛӘТТӘШЛӘР ОЧРАША

14 декабрьдә Казанның Актерлар йортында Татар иҗтимагый үзәгенең Уфа бүлеге җитәкчеләре белән очрашу булды. Әлеге кичәне филология фәннәре кандидаты Баян Гыйззәт ачты. Анда Татар иҗтимагый үзәгеннән Г. Фәйзрахманов, Уфадан килгән кунаклар — Татар иҗтимагый үзәгенең Уфа бүлеге җаваплы секретаре Кәрим Яушов, Уфадагы татар мәдәнияте йорты рәисе Наил Бәдретдинов, психология фәннәре кандидаты Әхмәт Рәхимов һәм Татарстанның халык язучысы Әмирхан Еники илебезнең төрле өлкәләрендә яшәүче татарларның культурасын күтәрү, туган телләрен кире кайтару, ана телендә укыту кебек актуаль проблемалар турында сөйләделәр, сорауларга җаваплар бирделәр.

## Г. ИСХАКЫЙГА БАГЫШЛАП

Уфадагы Г. Ибраһимов исемендәге татар мәдәнияте сөючеләр клубы советы Г. Исхакый иҗатына багышланган кичә уздырды. Филология фәннәре докторы, Казан дәүләт университеты профессоры Ибраһим Нуруллин клуб советы чакыруын кабул итеп, Уфага барды һәм үзенең лекциясен «Гаяз Исхакыйның татар әдәбиятында тоткан урыны» дигән темага багышлады, әдипнең проза, драматургия, публицистика өлкәсендәге иҗатына күзәтү ясады.

И. Нуруллин Исхакыйның архивы белән тулырак танышу максаты белән күптән түгел үзенең Төркиягә барып кайтуы турында да сөйләде. 27 ноябрьдә шундый ук очрашу Башкорт дәүләт университетында да булды.

## ПЕРМЬДӘ ОЧРАШУЛАР

КПССның Пермь өлкә комитеты чакыруы буенча, 16-19 ноябрьдә шагыйрь Рәдиф

Гатауллин һәм фольклорчы галим Рәшит Ягъфәров Пермьдә булдылар. Алар, анда уздырылган «Татар һәм башкорт көннәре»ндә катнашып, әдәбият һәм мәдәниятыбызның бүгенге мәсьәләләре турында сөйләделәр, уннан артык район һәм шәһәрләрдән өлкә смотрына җыелган сәнгать коллективлары белән очраштылар. Радио һәм телевидение өчен махсус тапшыру әзерләделәр.

Урал татарлары белән даими мәдәни элемтә булдыру турында КПССның Пермь өлкә комитетында җитди сөйләшү үткәрелде.

## ДРАМАТУРГНЫҢ ИҖАТ КИЧӘСЕ

Узган елның 28 ноябрендә К. Тинчурин исемендәге татар дәүләт драма һәм комедия театрында, драматург Ш. Хөсәеновка 60 яшь тулу тантанасы билгеләп үтелде. Татарстан Язучылар союзы, Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры һәм филармония коллективлары тарафыннан юбилярга котлау сүзләре әйтелде.

Юбиляр иҗатына хөрмәт аның сәхнәләрдән төшми уйнала торган «Әниемнең ак күлмәге» спектаклен күрсәтү белән тәмамланды.

## МӘСКӘҮДӘ ТАТАР ТЕЛЕН ӨЙРӘНӘЛӘР

Билгеле булганча, Мәскәү шәһәрендә татарлар күп яши. Хәзер башкалада татар телен төрле курс һәм түгәрәкләрдә өйрәнү мөмкинлеге ачылды. Мәскәүдә Волгоград районы Пионерлар йорты каршында «Чыганаклар» дигән гаилә клубы эшли башлады. Анда татар теле укытыла. Биредә шулай ук әрмән һәм яһүд телләрен өйрәнү өчен дә мөмкинлекләр бар.

«Чыганаклар» клубында дәресләр кызыклы үтә. Анда йорүчеләр татар җырларын өйрәнәләр, татар шагыйрьләре иҗаты белән танышалар. Бу клубны оештыруны Мәскәү матбугаты да актив яклап чыкты.

## ЯҢА ӘДӘБИ ТҮГӘРӘК

Татар мәктәпләре өчен ана теле укытучылары әзерләү нияте белән Башкорт дәүләт педагогия институтында былтыр махсус бүлек ачылган иде. Анда кабул ителгән студентлар арасында әдәби иҗат белән шөгыльләнүчеләр дә байтак. Алар «Карлыгачлар» исемле түгәрәккә берләште. Түгәрәк белән университет укытучысы Марат Шәрипов җитәкчелек итә. Иҗади яшьләр үзләренең стена газетасын чыгара. Зәвык белән бизәлгән бу газетада каләм тибрәтә башлаган студентларның яңа әсәрләре белән танышырга мөмкин.

## ӘДӘБИ ОЧРАШУЛАР

Узган елның 14 декабрендә «Татар кызлары» төркеме Казанның 19 нчы һөнәр училищесы укучылары белән очрашты. «Оргсинтез» берләшмәсенә караган әлеге училищеда бу уку елында татар теле кертелә башлады. Татар теле дәресләрен җанландыру максатыннан уздырылган әлеге очрашуда РСФСРның атказанган артисткасы Вафирә Гыйззәтуллина, язучы Кояш Тимбикова, шагыйрә Шәмсия Җиһангирова һәм баянчы Ирек Галимов катнашты.

Язучы Тәүфикъ Әйди октябрь аенда Казахстанга барып, күренекле казах язучысы Җосыпбәк Аймауытовның йөз еллыгын бәйрәм итүдә катнашты. Татар-казах әдәби бәйләнешләрында Җ. Аймауытов тоткан урын хакында Алма-Ата, Павлодар шәһәрләрендә, Баянавыл районы үзәгендә чыгыш ясады. Т. Әйди Павлодар шәһәрендә татар сәнгать сөючеләренең «Чишмә» берләшмәсе эше белән дә танышты һәм әңгәмә үткәрде.

## ВАРШАВА НӘШРИЯТЫ — ТАТАРЛАР ТУРЫНДА

Польша фәнни нәшрияты биредә яшәүче татарлар тарихына багышланган ике яңа китап бастырып чыгарды. «Польша татарлары, 1918-1939 еллар. Иҗтимагый-культура һәм дини тормыш» дигән китапның авторы А. Миськевич, бай архив материалларына таянып, күпмиллэтле Польша иле тарихында әһәмиятле роль уйнаган татарлар турында сөйли.

Тарих белән кызыксынучыларга шулай ук Я. Тышкевичның «Литва һәм Польша татарлары» дигән китабы да файдалы булыр. Бу китапта Бөек Литва кенәзлегенә күчеп утырган татарлар һәм караимнарнең саны, тормыш-көнкүреше, аларның дине, культурасы турында сөйләнә.

## ХӨРМӘТЛЕ ИПТӘШЛӘР!

Татар дәүләт академия театры журнал укучыларга түбәндәге үтенеч белән мөрәҗәгать итә. 1923 елда күренекле драматург Гаяз Исхакыйның «Салих хаҗи балалары» дигән пьесасы Татар дәүләт театрында куелган. Икенче исеме — «Юлсызлар». Бу әсәрне Әстерхан татар театры да куйган дигән мәгълүмат бар. Репрессия елларында пьесаның тексты юкка чыга. Бүгенге көндә театрыбыз шул пьесага кабат кайтырга омтыла. Бәлкем пьеса кемдә дә булса сакланып калгандыр? Әгәр шулай була калса, Сездән театр белән бәйләнешкә керүегезне сорыйбыз!

**Безнең адрес:** *420021, Казан, Татарстан урамы, 1 нче йорт. Татар дәүләт академия театрының әдәби бүлеге. Телефон: 32-96-38.*

# «ШАЙТАН КАЛАСЫ»

Текә яр өстендә ак ташлардан салынган манара инде ничәмә-ничә гасырлар буе олы туганы чал Иделгә суларын коючы Чулман-Кама агышын күзәтә. Әйтерсең лә ул күз-колак булмаса, гүзәл Кама юлын үзгәртеп, көмеш суларын чит-ят дәрьяларга илтеп коячак. Алабуга шәһәренең көньяк-көнбатышындарак урнашкан һәм гасырлар узу белән «Шайтан каласы» дип исем алган бу манара борынгы болгар архитектурасының монгол яуларына кадәрге дәвердән сакланып калган бердәнбер тарихи-корылма истәлеге булып исәпләнә. Хәер, бу төбәкне кешеләр бик борынгыдан, безнең эрага кадәр беренче мең еллык урталарында ук үз иткәннәр. Тарихчы археологлар фикеренә караганда, биредә иң әүвәл борынгы ананьино кабиләләре яшәгән. Хәзерге вакытта манара торган урында алар дошманнарыннан саклау өчен ныгытма корганнар.

Вакытлар узу белән бу җирләрне тарих фәнендә имәнкискә кабиләләре дип исем алган икенче бер кабилә кешеләре биләгән. Бер яктан Чулманның текә яры, ә икенче яктан тирән чокыр белән уратылган бу урын аларның да күңелләренә хуш килгән, әлбәттә. Тирә-ягындагы урман-кырлар киек белән тулы, яр астында гына агып узган Кама балык-кыслага бай. Һәртөрле яулардан саклану өчен дә уңайлы бу төбәк тереклек итәр өчен кулай җир булган. Идел-Кама буйларында Көнчыгыш Европадагы беренче феодаль дәүләт — Бөек Болгар дәүләте оешкач, бу урынның әһәмияте тагын да арта. Болгар дәверендә элеккеге ныгытманың мәйданы киңәя, ачык кыр ягы өченче рәт ур белән уратып алына, ак таштан дивар һәм манаралар салына. Ныгытма Кама буйларындагы болгар биләмәләренең үзәгенә, йөзек кашына әверелә. Әнә шулай болгар бабаларыбызга берничә гасыр буе игелекле хезмәт күрсәткән бу кальга, 1552 елда Казан ханлыгы руслар тарафыннан яулап алынгач, бушап кала һәм акрынлап җимерелә бара.

Яулар узганнан соң «Шайтан каласы» янында Трехсвятский исемле рус авылы барлыкка килә, чиркәү-монастырьлар төзелә. XVIII гасыр урталарына караган мәгълүматлар буенча «Шайтан каласы»нда өч манаралы таш дивар калдыгы исән булса, хәзерге вакытта исә чал тарихның телсез шаһиты булып бары тик шушы манара гына утырып калган.

Борынгы тарихыбыз ядкаре «Шайтан каласы» Чулман-Кама дулкыннарын ярып һәрвакыт каядыр ашыгучы теплоход, көймә һәм баржаларга юл күрсәтеп, хәерле юл теләп кала шикелле.

Җәүдәт МИҢНУЛЛИН,
тарих фәннәре кандидаты.

Рөстәм МӨХӘММӘТҖАНОВ фотосы.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** Татарстанның Г. Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты, язучы Атилла Расих.

Юрий ФИЛИМОНОВ фотосы.

Бәясе 90 тиен.
Цена 90 коп.

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
(ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ
(на татарском языке)